ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2014



# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ



## *«Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында*

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен профессиональ язучы **Садриев Фоат Миңлеәхмәт улына** «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль. 2014 ел, 7 август. № ПУ-765*

# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ



## *«Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында*

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен шагыйрь, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе» директоры – баш мөхәррире **Мансуров Зиннур Мөҗип улына** «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль. 2014 ел, 21 август. № ПУ-799*

КАЗАН УТЛАРЫ
www.kazanutlary.ru
ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Марат КӘРИМОВ. Хатирәләр – учак көле алар. *Шигырьләр.* ....3
Анатолий ЕГИН. Үзбәк хан. *Роман.* ....9
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Гомер – искән җил генә. *Шигырьләр.* ....82
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Хәтер тибә таш диварга. *Шигырьләр.* ....112
Клара БУЛАТОВА. Яшел яфрак – яшәү төсе. *Бәян.* ....116
Гүзәл ӘДҺӘМ. Зәңгәр кашлы көмеш алка. *Хикәя.* ....130

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Ринат КАМАЛ. Таня-Таңсылу. *Сентименталь бәян.* ....88

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

Фәрит СУФИЯРОВ, Каһим ӘУХӘТОВ, Әхнәф МӘЗҺӘРОВ, Фәвәзит ӘХМӘТШИН, Нәфисә ХӘБИБДИЯРОВА шигырьләре. ....126

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Суфиян ПОВАРИСОВ. Шигъри иман сөйкемлелеге *(Ләйсән Кәшфи поэтикасына бер караш).* ....144

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Нурфия ЮСУПОВА. Күңел кушкан юлда. ....148

**СӘНГАТЬ**

Гүзәл СӘГЫЙТОВА. «Галиябану». ....152

**ХӘТЕР**

Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ. Шуның белән шул... Вокзалдан язам. *Мемуарлар.* ....155
Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....160

**ДИН һӘМ ТОРМЫШ**

Тәлгат хаҗи НӘҖМЕТДИН. Изге сәфәр җиңел гамәл түгел. *Хаҗнамә*....165

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *(Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде).* ....177

**АК ҖИЛКӘН**

Рамил ХАННАНОВ. Җилкәнле яшьлек. ....180
Алсу НУРГАТИНА. Сынаулар. *Бәян.* ....182
Фәнсилә ШӘЙДУЛЛАТОВА, Алинә АКМАЛОВА, Эльвира РАФИКОВА, Алисә МӘГЪДӘНУРОВА *шигырьләре.* ....186

Мәкаль өмәсе. ....189
«Казан утлары» архивыннан. ....142
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

ТАТАРСТАН ... МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

татмедиа

Гамәлгә куючы — «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.1267).*
✆: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

🖳: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.09.2014, график буенча 30.09.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2556. Тираж 3300.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Марат
Кәримов

# ХАТИРӘЛӘР – УЧАК КӨЛЕ АЛАР

## Тере һәйкәлләр

Тереләргә һәйкәлләр юк,
Бәхәсле булганнары.
Үлгәннәргә генә бары
Мәйданга куйганнары.

Әй, яугирләр, сезнең гомер –
Тиңдәше юк батырлык.
Үлгәчтен дә һәрберегез
Һәйкәл булып басарлык.

Сезгә һәйкәл булмас, бәлки, –
Илдә төрлечә хәлләр.
Сез болай да безнең өчен
Үлмәс тере һәйкәлләр.

Туган туфракта каныгыз,
Ил күгендә данырыз.
Тере һәйкәл булып шулай
Арабызда калыгыз!
Безнең белән калыгыз!

Марат КӘРИМОВ (1930) — *Башкортстанның халык шагыйре; өч томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Уфада яши.*

## Урмандагы сөйләшү

— Ни диярсең, кочакласам сине, имән?
— Бүлешермен үземдәге ныклык белән.

— Ни диярсең, кочакласам сине, каен?
— Аклык артыр синдә мине кочкан саен.

— Ни диярсең, кочакласам сине, усак?
— Бар чирләрең мина күчеп бетәр шул чак.

Зар ишеттем имән, каен һәм усактан:
— Без бит сезгә ярдәм өчен әлмисактан.

Тик кешеләр горур, безне санламады,
Табигатьне бернигә дә санамады.

Бушка гына булды барлык ялварулар,
Юккамыни безнең күзен саргаюлар...

## Аэропорт юлында

Аэропорт юлында тирәктә
Бу нәрсә? Комачмы кызара?
Комачтан хәрефләр кычкыра:
«Мин сине яратам, Дилара!»

Юлчылар язуны укый да
Сөйләшеп алалар үзара:
«Кара син, нииндидер егетне
Арбаган нииндидер Дилара».

Аһ, нигә соң әле сулкылдый
Күнелдә онытылган бер яра?
Янадан алдыма баскандай
Авылның чибәре Дилара.

Ничә ел шул сүзне әйтергә
Базмадым мин — гашыйк бичара.
Гомерлек үкенеч калдырып,
Юлымнан югалды Дилара.

Алып оч, самолёт, яшьлеккә,
Нәрсә ул очкычка бу ара!
Мин аңа кычкырып эндәшим:
«Мин сине яратам, Дилара!»

Очмый шул самолёт үткәнгә,
Тик юкка уйларым болара.
Кавышып яшәгез, билгесез
Гашыйк һәм билгесез Дилара!

## Еллар арасында

Мин генәме, аны күпләр әйтә:
Чибәрләр күп Уфа каласында.
Язмышынны күргән кебек булдым
Бер чибәрнең жылы карашында
Утыз белән кырык арасында.

Өмет дигән нәрсә бик тиз генә
Сүнми икән адәм баласында.
Шушы чибәр белән очмак булдым
Хыялымның зәңгәр чанасында
Кырык белән илле арасында.

Чана очамыни! Очалмадым,
Үкенүләр – йөрәк ярасында.
Өметләрем йолдыз булып очты
Селкенгәндә гомер арбасында
Илле белән алтмыш арасында.

Инде хәзер кемнәр чагыладыр
Чибәрләрнең серле карашында?!
Ә мин бары йолдызларга карап
Яшәп ятам Уфа каласында
Йөгереп үткән еллар арасында...

## Иелгән башлар

*Иелгән башны кылыч кисми.*
Халык әйтеме

Кылыч янамый, дигәннәр,
Иелгән башка.
Ә иелмәгән башларның
Язмышы башка.

Аларның баш очларында
Уйнаган кылыч.
Елга-елга каннар аккан,
Туймаган кылыч.

Каберләре өстендәме
Өелгән ташлар?
Исән калган, имин калган
Иелгән башлар.

Нәрсә генә әйтә алсын
Иелгән башлар?
Иелгән шул бахыр башлар
Безгә охшашлар.

Иелмәгәннәр кайда соң
Безнең көннәрдә?
Курку белмәгәннәр каны
Кайның кемнәрдә?

## Очрашасы иде тагы бер

Буласылар булды. Барысы узды,
Хәзер инде мина барыбер.
Күнелләрем тәмам тынычланыр,
Сөю газабыннан арыныр.

Хатирәләр килеп шакыса да,
Алларында ишек ябылыр.
Хатирәләр – учак көле алар,
Жылылыгы булмас барыбер.

Араларда безнең еллар ята,
Син башканың, бәлки, ярыдыр.
Көнләшә бу диеп уйлый күрмә,
Ни кылсаң да, мина барыбер.

Эчке халәтләрне каплый торган
Калкан икән шул сүз «барыбер».
Һич югында бер карашыр идек,
Очрашасы иде тагы бер.

## Булабыз

Әллә чынлап без шулаймы,
Әллә күз буабыз:
«Булабыз» да «булабыз» дип
Яшәгән булабыз.

Без ул! Без ул! Күкрәк сугып,
Жилкенгән булабыз.
Болар эшли, дип әйтсеннәр,
Селкенгән булабыз.

«Жир байлыгы – безнеке!» – дип
Шатланган булабыз.
Ә ул байлык читкә китсә,
Мактанган булабыз.

Капиталның кара ягын
Күрмәгән булабыз,
СССРны тапый-тапый
Жирләгән булабыз.

Кайда булган икән безнең
Холкыбыз, йолабыз?
Шулай яшәп кем булабыз?
Монафикъ булабыз.

## Искә алу

Менә тагын житте Бөек Жиңү көне,
Жиңүчеләр алдында баш ию көне.

Бәйрәм бәйрәм буламыни мәжлес кормый?
Түрәләргә аны кору берни тормый.

Жыелдылар үзләре һәм хатыннары,
Каламы соң куштаннары, якыннары!

Өстәлләрдә закусканың затлылары,
Эчемлекнең татлыдан да татлылары.

Чит илнеке төрле-төрле хәмер-шәраб,
«Мине эч!» – дип утыралар күзгә карап.

Түрә иптәш торып басты: «Агай-эне,
Яугирләрне бүген искә алу көне.

Шуңа аны тиешенчә үткәрик без,
Ветераннар хөрмәтенә күтәрик без!»

Китте тостлар берсеннән дә берсе матур:
— Аларга — дан! Аларга – сан! Алар – батыр!

Әйткән һәр тост күңелләргә охшап кала,
Стаканнар тулган саен бушап кала.

Ә соңыннан түрәләрне зурлау китте,
Егылганчы бию китте, жырлау китте.

Күңел ачу дәвам итте таңга кадәр.
Шунда берсе, айнык, ахыры, салды хәбәр:

— Ветераннар хакына бит чарабыз да,
Ә нигә соң берсе дә юк арабызда?

Әйтте түрә:
— Оныткан юк, алар истә.
Игътибарсыз калдырырга уй юк һич тә.

Үпкәләргә аларның юк һичбер хакы,
Почта аша җибәрелде котлау хаты!

## Эз яздыру

Әй яшьлекнең тиле чагы!
Без бит үлемсез, имеш.
Шуңа яшәлгән әҗәлгә
Өстән караган килеш.

Күптән тиле яшьлек үткән,
Бераз акыл да иңгән.
Үлемсезлек кикриге дә
Нәрсә эшләсен? Шиңгән.

Инде картларның корына
Илтә гомер агышы.
Чү! Артымнан кемдер куа,
Кемнең аяк тавышы?

Әҗәл икән. Туктатырга
Ымлап, тамагын кыра.
«Яшәү лимитең тулган!» — дип
Чалыш авызын ера.

Мин ул кадәр юләр түгел
Тыңларга аның сүзен.
Җан-фәрманга торып чаптым,
Күздән яздырдым үзен.

Өемә кайтып егылдым,
Ишекне эчтән элеп.
Тын алырга да куркыта,
Ятамын ярты үлеп.

Әнә ишек дөбердәтә,
Куптара инде биген!
Минем кайда яшәгәнне
Ничек тиз белгән диген.

Тәрәзәдән чыгып тайдым,
Миндәй житез сирәктер.
Күз яздыру ярдәм итми,
Эз яздыру кирәктер.

Хәзер инде башкачарак
Минем гомер сөрүем.
Ничә еллар өйгә кайтмый
Эз яздырып йөрүем.

Әҗәл эзләп тапмасына
Ышанычым нык әле.
Әҗәл түгел, хатынның да
Табалганы юк әле.

Таба калса, абзыегыз
Күрмәгәнен күрәчәк,
«Алиментщик!» — дип әҗәлгә
Үзе тотып бирәчәк.



Анатолий
Егин

# ҮЗБӘК ХАН

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### Хан

Уныштан Үзбәкнең күнеле күтәрелде. Аның кул астында зур ил, миллионлаган кеше, бай далалар, урман-елгалар, бик әйбәт дингез, караблар туктый торган урыннар, сәүдә юлы чатлары, монда шәһәрләр төзергә, һөнәрчелекне үстерергә кирәк! Эшләр буа буарлык.

Мондый илне сакларга, ныгытырга, очсыз-кырыйсыз киңлекләр белән житәкчелекне яхшыртырга, кешеләрне, бигрәк тә низаглашырга яраткан аксөякләрне бер йодрыкка тупларга кирәк.

Тәхеткә тантаналы рәвештә утырганда, яңа гына идарә эшләрен кулына алган хаким – Үзбәк хан ислам титулын кабул итте. Хан-солтан, күчмәләрнең электән килгән ырымыннан куркып, Туктай сараенда яшәмәскә булды. Ырымда, кемнеңдер йортында коелган кан Күк-Тәңренең ачуына дучар була, диелгән. Үзбәк кышны балачагы узган атасының иске йортында чыгарга булды.

Яз килде. Беренче чиратта хәл ителәсе эшләр башкарылды. Котлыгъ Тимер ханның һәм үзенең гаиләсен Хәрәзмнән Сарайга күчерде. Алар белән бергә Үзбәк тарафыннан Алтын Урданың югары мөфтие дигән биек урынга чакыру алган Алла әд-Дин ән Нуман шәех тә килде. Ханның һәм аның тәхеткә утырган көненең икенчесендә бәкләр бәге итеп билгеләнгән Котлыгъ Тимернең эшләре муеннан иде. Алар өч зур реформа уйладылар: дәүләткә ислам дине кертү, илнең административ бүленешендә үзгәрешләр булдыру һәм Урда белән җитәкчелек системасын яңарту.

Ханның көннән-көн күңеле күтәрелә барды. Эшләр бер көйгә бара, балалар үсә, хатыннары чын ханбикәләр булып җитеште. Ләйлә гүзәллеге белән балкыса, Тай-туглы, матурлыгы өстенә акыллы да иде, Үзбәк бабасының ук хатыны булган Баялунның тынгысызлыгын һәрдаим искәртеп торды. Өлкән ханбикә эшсезлектән үзенә урын тапмаудан, дәүләт эшләренә кысылырга теләде. Элекке кебек киңәшләрен бирде, әмма аларга беркем колак салмады, аннан беркайчан бернәрсә турында сорамадылар һәм эшлекле хатын үзен кирәксез итеп тойды. Ул берничә тапкыр йөрәгенә чыдый алмыйча үги улына – хәзер инде иренә:

— Күпме акча түгеп, сине тәхеткә утырттым, син исә мине оныттың, ташладың, хәтта төнгә үз янына да чакырмыйсың, — дип үпкәсен белдерде.

*Ахыры. Башы 9 нчы санда.*

— Хатын-кыз үз урынын белергә һәм кирәкмәгәнгә ирен ялыктырмаска тиеш. Синең бар нәрсәң бар: байлык, хөрмәт, хезмәтчеләр, тагы ни кирәк, әйт — үтәрмен, — дип йомшак кына җавап кайтарды Үзбәк.

Тик Баялунның ачуы кабарганнан-кабара гына барды. Хәер, аныкы гына булса иде. Нойоннарның бер өлеше, Илбасарны шулай кыю рәвештә үтергәннән соң, баштарак тынып торды, ләкин әкренләп, үзара пышылдаша башлады. Озакламый барысын да ислам динен кабул итәргә мәҗбүр итәчәкләр дигән сүзләр колакларына кергәч, яшерен сөйләшүләр башладылар. Аның башында Урдада абруйлы булган зур түрәләр Төнгуз һәм Таз торды. Әмма Котлыгъ Тимернең үткен күзеннән бернәрсәне яшереп булмый, аның колагы аз гына кыштырдауны да тотып ала иде. Бәкләр бәге үзенең шымчыларына — ир туганнар Хәрәзмдә чакта Сарайда яшәп хезмәт итүчеләргә — бик юмарт түләде. Котлыгъ Тимер сүз куешуның вак-төягенә кадәр белеште, әмма вакыты җитмичә ханны борчымады. Бер көн кала ул Үзбәкне кисәтте. Түнтәрелешне бастыру өчен, хан сарай эчендә сакны көчәйтте, әмма аның күпчелеген яшереп торды. Сарайдан ерак түгел тупланган меннәрчә сугышчы фәрманны көтеп торырга тиеш иде. Хатын-кызларны һәм нәни балаларны төнлә шыпан-шыпан гына сарайдан чыгардылар һәм капкаларны юри бикләмәделәр.

Үзбәк һәм коралллы хезмәтчеләре берни белмәгәндәй, тыныч кына үз эшләре белән мәшгуль булды. Хәтта ун яшьлек Тимербәккә кадәр, кылычын халаты астына яшереп, ишегалдында уйнап йөргәндәй кыланды. Үзбәк уңышка ышанды, ул беркайчан да куркыныч алдында каушап калмады, дәһшәтнең күзенә карап атлады һәм җиңде. Улы да ничек эш итәсен карап торсын, алда аны ни көткәнен беркем белми.

Яшерен сүз куешучылар бернинди киртәләргә очрамый хан сараена үтеп керделәр, уңышлары белән канатланып, хан йортына омтылмак булганнар иде, әмма бик тиз үзләренең капкынга эләккәннәрен белеп алдылар. Алар артыннан ук ханның йөзгә якын сугышчысы капканы япты. Баш күтәрүчеләр бирелә башлады, каршылык күрсәткәннәрне әллә ни арада койма өстенә менеп кунаклаган мәргәннәрнең очлы уклары куып җитте. Үзбәк болдырга чыкты, кылычның булат корыч йөзе белән бер селтәнүдә Тазның башын кисеп төшерде.

— Бу шакалның башын алыгыз, сөңгегә элегез дә бөтен Сарай буйлап күрсәтеп чыгыгыз. Калганнарны бәйләгез, таяклар белән бәргәләп шәһәр буйлап йөртегез. Бар халык күрсен, аннары барысын да үтерегез. Минем үлемне теләгәннәрнең һәрберсе белән шулай булачак!

Икенче көнне Үзбәк язгы дала буйлап төньякка таба күченде. Ул каһәр суккан Сарайда, үзенә ике тапкыр үлем янаган җирдә калырга теләмәде.

Кук-Тәңредән шикләнеп, кан түгелгән йортларда яшисе килмәде. Даланың исертерлек хуш исе, шаян җил һәм елмаеп торган кояш ханга көч өстәде, күнелен күтәрде. Аның белән бергә башкаланың яртысы диярлек күченде. Үзенең максатын тормышка ашыру өчен бар да кул астында иде.

Көннәрен эш белән үткәрсә дә, хан хатыннары турында да онытмады. Кичләрен Тай-туглыны башкаларга караганда ешрак чакырды, һәм сөеклесе аның янында үзен беренче мәртәбә төн үткәргән шикелле тотты, аның назлаулары Үзбәкнең ару-талуларын юып төшергәндәй итә, әйтеп бетергесез дәрт уята. Шундый кичләрнең берсендә, шашып яратышканнан соң, күзләрен серле генә кысып үзләрен күзәткән йолдызларга карап ял итеп ятканда, Тай-туглы Үзбәктән:

— Урдада исламны кертү турында Хәрәзмдә сөйләшкәнебез исеңдәме? — дип сорады.

— Бик яхшы хәтерлим. Болай да әйбәт, нигә ашыгырга?

— Сина тагын да яхшырак булуын телим. Син хак юлда, ханым! Илне көчәйт, хакимлекне үз кулыңда нык тот, шул вакытта сина берәү дә каршы чыгарга батырчылык итмәс. Каты тор, үз сүзеңнән чигенмә, шул ук вакытта рәхимсезлегеңне киң күңеллелек һәм юмартлык белән аралаштыр. Исеңдәме, бабаң Елбаздук үзенә буйсынганны ничек бүләкли иде?

Тай-туглы ирен суырып үпте һәм кабат аны татлы хыяллар иленә алып китте.

Үзбәккә кенәз Елбаздукның аннан, ягъни күчмә тукталышыннан ике көнлек юл ераклыгында булуы турында хәбәр иттеләр. Күрешү тантаналы да, шатлыклы да булсын өчен, зур әзерлек башланды. Далада зиннәтле чатыр кордылар, аның астындагы биек урынга хан, аның уң ягына Баялун, сул ягына Ләйлә белән Тай-туглы урнашты. Ханның өлкән хатыныннан аз гына алдарак Тимербәк, Тәнбәк һәм кечкенә Жанбәк утырдылар. Алар белән рәттән аз гына астарак Котлыгъ Тимер ике хатыны һәм балалары, ә икенче якта — гаиләсе белән Мөхәммәд хажи урын алды. Елбаздук килеп җитте һәм, бу зур гаиләне күреп, аның күзеннән яшь чыкты.

«Менә бу кызлар, ичмасам! Менә акыллылар! Нинди уллар тудырганнар! — дип уйлады карт кенәз. — Болар минем оныкларым, хәзер алар Алтын Урда белән җитәкчелек итәләр, халык аларга буйсына, шундый зур җирләр белән алар идарә итә! Кайчан да булса болай булыр дип, хыяллана ала идемме мин? Күр, хәзер оныкларым мине иң зур, иң кадерле кунак кебек каршы алдылар».

Бар да күрешү шатлыгын көтеп тынып калды, кенәз исә иярендә килеш нәсел дәвамчылары, аларның көче һәм даны белән горурланып утыра иде. Ханнан башка берәү дә Елбаздукны ашыктыра алмый иде. Тик аның да моңа хакы юк: чиркәс йоласы буенча, ул урыннан торып, дәшми генә көтәргә тиеш иде. Үзбәк урыныннан кузгалды да бабасының каршына китте, аның артыннан Котлыгъ Тимер атлады. Алар атны йөгәненнән әләктереп, тыныч кына чатыр янына алып килделәр. Урдада моның кадәрле зур хөрмәткә берәүнең дә ия булганы юк иде әле. Елбаздук аптырап калса да, үзен горур тотты. Оныклары шулай олылап каршы ала икән, димәк, гомере заяга узмаган! Ул һәрвакыт Үзбәк белән горурланды, аннан күпне өмет итте. Көтте — вакыт килде, хәзер инде тыныч күңел белән күзен йомса да була.

Кенәз Урдада айга якын кунак булды. Көннәр буе оныкларын, оныкчыкларын күзәтте. Олылары дәүләт эшләре белән мәшгуль, кечеләренә исә ул үзе булышты. Тимербәккә — уң, Тәнбәккә — җиде яшь, алар үзара ярыштылар, әмма һәрвакыт олысы җиңде. Тәнбәк үпкәләде, бар көченә җиңмәкче булып тырышты, ачуланды, тик ачу эштә булышмый иде шул. Бабасы Тәнбәкне көч белән генә түгел, хәйлә белән дә җиңәргә өйрәтте. Өч яшен тутырып маташкан Жанбәкның борыны күккә чөелгән, ул инде тыныч кына, кечкенә генә бер бия өстендә йөргән булып маташа.

— Кенәз, сез минем улымны башын югары тотарга өйрәтәсезме? — дип шаяртты Тай-туглы.

— Нишлисең, кызым, минем баштан күптән кар коела инде, һәм түбәсе дә өскә түгел, соңгы вакытларда гел аска карый. — Елбаздук килененә күз төшерде һәм аның үз-үзен матур тотышына, акылына сокланды, ул очраклы рәвештә аның Үзбәк белән сөйләшкәнен ишетеп калган иде, шулай да Тай-туглы барыбер шаян күзле, тиктормас булып калган. — Ә син, кызым, минем төшемә еш керден.

— Мин сезнең турында еш уйлыйм, кенәз, сезнең белән гел киңәшәм, менә шуңа күрә сез минем барлыкны тоясыз һәм төшегездә күрәсез.

Елбаздук кайчандыр үзендә тәрбияләнгән кызны кочаклап, битеннән үпте.

— Мина бары бер нәрсә кызганыч, ник син бер кырык ел алдан тумадың икән, — диде дә балалар янына китеп барды.

Тай-туглы анын артыннан карап, озак басып торды. Ул да Елбаздукны ярата иде. Бергә яшәгән еллар эчендә ул кыз өчен бик якын үз кешегә әйләнде. «Үз гаиләсенә алган өчен рәхмәт аңа. Кем булыр идем мин? Әй, бабам Хетэг күрсен иде мине хәзер. Бәлки күрәдер дә, күкләрдән карап сөенәдер».

Елбаздук китәргә җыенды. Оныклар белән озаклап сөйләшерлек сүзе юк, өйрәтермен дә димә — алар үзләре бабаларыннан күбрәкне белә. Кузгалырга бер көн кала Үзбәк бабасы янына килде.

— Аталык, сиңа ике үтенечем бар.

— Беренчесеннән башла, улым.

— Беренчесе, мөгаен, Тимербәк хакында. Аны үзең белән аласыңмы?

Елбаздук дәшмәде. Үзбәк дәвам итте:

— Буйсынучыларын арасыннан акыллысын тап. Малайны тәрбияләгез.

— Хан улларын тәрбия кылу кенәзләр эше. Әлегә көчем җитәрлек. Кирәк булса, узденьнар булышыр. Ләкин кабатлап әйтәм: бары тик ярдәм итәрләр.

— Уйламый әйткәнем өчен кичер, кенәз.

— Икенче үтенечеңне әйт.

Үзбәк сакалын кашыды, күзен кысып елмайды:

— Үзең белән Баялунны алчы.

— Мина нәрсәгә ул бәйләнчек хатын? Нәрсә, әбиең булмагач, мине хатынсыз үлә дисеңмени?

— Син мине дөрес аңламадың, әй тәрбиячем, — дип басым ясады хан. — Баялун күпләргә мәшәкать ясый, картайдым дип тынычлана белми, дәүләт эшләренә тыкшына, хәйлә корырга ярата, һәм миннән дә булдыра алмаганны таләп итә. Сиңа ир кеше булганга әйтәм: әби белән йоклый алмыйм мин, менә дигән яшь матур хатыннарым бар.

— Моңа Византиядә ничек карарлар?

— Берни әйтмәсләр дип уйлыйм. Хәзерге император Андроник IIгә ул туганнан туган туры килә, әмма аның үз мәшәкатьләре җитәрлек, Баялунда эше юк. Аның оныкчыгы үсеп килә, Византия белән тынычлыкны саклау өчен мин әнә шул Баялунны алыр идем.

Елбаздукка башка аңлатып торасы юк, ул хакимиятнең корбаннар соравын белә иде. Әйдә, карчык аның белән китсен. Хәер, алай ук карт түгел әле. Шул уйдан соң кенәз башын югары күтәрде...

Баялунга җыенырга куштылар. Ул Үзбәктән калганнарга котырынды, кычкырды. Ханнар белән яшәү аны бер нәрсәгә өйрәтте: иренә тупаслык кылсаң, башыңны югалтасың. Шашынуының югары ноктасына җиткәндә, ханбикәнең йокы бүлмәсенә Котлыгъ Тимер керде. Хатын аны күрүгә, арты белән борылды.

— Ачуланма, мина борыл да тыңла. Синең белән бәкләр бәге сөйләшә.

Баялун, зәһәр елмаеп, Котлыгъ Тимергә борылды.

— Бөек ханбикәм, мине игътибар белән тыңла. Син күпне кичердең, күп игелекләр кылдың, мәкер-хәйләләрең дә аз булмады. Әмма кайчан да булса бар нәрсәнең ахыры була. Тормыш безне һәрнәрсәне вакытында эшләргә өйрәтә — тыңларга, әйтергә, дәшмәскә, килергә, китәргә. Синең дә китәр вакытың җитте. Еллар уза, заман үзгәрә, табигать алышына. Хәзер безнең эшләр көчеңнән килми, шуңа күрә башка аяк арасында буталып йөрмисең.

Баялун авызын ачты, теленнән дорфа сүзләр атылам дигәндә, бәкләр бәге аны узып:

— Синең ни диясеңне беләм. Әйтми калсаң яхшырак булыр, ханның кире уйлавы бар. Ул сине буш кул белән җибәрми. Үзеңдәге бар милекне калдыра,

өр-яна алтын-көмештән бүләкләр бирә һәм гомерен буена Азовта Венеция сәүдәгәрләре белән сәүдәдән кергән табышның ун процентын синеке булачак. Хезмәтчеләрдән, кемне телисең — үзең белән аласың.

Баялун тынычлана төште, шактый күп байлык бирәселәрен аңлап: «Бәлки гомерем ахырында моннан да яхшырак мөмкинлек булмастыр», дип уйлады.

Киткән чакта Котлыгъ Тимер елмайды:

— Безнең бабабызга игътибар беләнрәк кара әле. Хәзер синең хакимең — ул, ут борчасы карчык.

Тиз-тиз хушлаштылар. Ләйлә улын озатканда, ярсып бетте. Улы анасын, яхшы сугышчы булып кайтырмын, дип юатты. Ахырда Елбаздук Ләйләнең башыннан сыйпады:

— Елама, кызым, күз яше сезне картайта. Кара аны, ирең бизәр үзеңнән!

Килене шунда ук туктады, күз яшьләре дә кипте.

«Бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһ, Баялун язмышын бирә күрмә», — дип уйлады хәзер Алтын Урда ханының өлкән хатыны урынында калган Ләйлә.

Үзбәк барысы белән дә саубуллашты һәм кәефе кырылган Баялун утырган ябулы арба янына килде:

— Барысы өчен дә кичер. Аллаһ сакласын үзеңне!

— Мине болай да үземнең Аллам саклый, ике Алла күбрәк булыр,— диде өч ханның хатыны булган ачы телле Баялун. — Син дә сау бул, улым! Мине яманлык белән искә алма. Ә бабаңны сакламын, озакламый мин аннан яшь тай ясармын.

Бабасын да, Баялунны да соңгы тапкыр күргәнен белгәндәй, Үзбәк китеп баручы кәрван артыннан озак итеп карап торды. Ахырдан да икеле-микеле уйлар башыннан китми җәфалады: «Баялунны үз янымнан куып дөрес эшләдемме? Анам исән булса, нәрсә дияр иде?» Шундый борчулы вакытларында Тай-туглы аның гел янәшәсендә булды. Әй, бу гүзәл Тай-туглы! Әй, бу сөекле Тай-туглы! Ул иренең йөрәгендәге кайгы-сагышны ничек оста тарата белә, аның уйларын башка якка борып тынычландыра ала...

Үзбәк баш-аягы белән яна эшләргә чумды, әле генә булган хәлләр куркыныч төш сыман китеп югалдылар.

Бервакыт иртүк Тай-туглы уйламаганда-көтмәгәндә хан каршына бәйрәм киемендә килеп басты:

— Кичер, ханым, сине иртә таңнан борчыйм, ачуланмый гына хатыныңны тыңла.

— Сине ничек ачулана алыйм, сөеклем!

— Дәүләт эшләренә кысыласым килми, хакимем, әмма нәкъ менә минем яныма урыс Православ чиркәвенең митрополиты Пётрдан атчабар килде, ул үзен Бөек кенәз Михаил Ярославович белән бергә кабул итүемне сорый.

— Алар бездән ничә көнлек юлда?

— Бер, данлыклы хакимем.

— Ике көннән өйлә намазыннан соң рәхим итсеннәр.

Кызу кояш даланы көйдерде. Кунаклар кырыйлары кеш тиресеннән тегелгән, озын җиңле милли кафтаннан, алар ара-тирә яссы савыттан су йоткалап алалар — эсседән тәмам интеккәнлекләре күренә, аркаларыннан, битләреннән шыбырдап тир ага. Аларга хан белән очрашыр алдыннан, җаннарын чистарту өчен берничә ут аша чыгарга туры килде. Башкаларга караганда митрополит Пётрның хәле әйбәтрәк, ул җинелчә монах киеменнән иде. Күтәренке күңелле, акыллы, укымышлы рухани малайлар кебек дулкынланса да, тыштан сиздермәскә тырышты.

Урыс илчелеге тирмәгә кереп башын иде, монда җиләсрәк, күтәртелеп куелган аскы киезләр арасыннан җил уйнап тора.

Алтынланган тәхеттә утырган хан урыс кунакларга карады. Үзбәк элегрәк урыс кенәзләре һәм руханиларын бик сирәк күрде, якыннан бөтенләй аралашканы булмады диярлек, шуна кемнең кем икәнен аерырга теләгәндәй, һәрберсен аерым-аерым күз уңыннан уздырды. Урыслар ишек төбендә кымшанмый да басып тордылар, аларның дулкынлануы йөзләренә чыккан иде. «Монысы яхшы! – дип уйлады Үзбәк. – Каушыйлар, димәк, куркалар. Куркалар икән, димәк, буйсынырлар».

Хан әлегә хәл итмәде: җәза бирергәме аларга, әллә рәхим-шәфкать күрсәтергәме?

«Ә нәрсә өчен җәзаларга? Алар урыслар арасыннан беренчеләрдән булып баш иеп килделәр – бу бит бик әйбәт. Карыйк, ни белән килделәр икән».

Үзбәк якынрак килергә ымлады. Кенәз, аның ике улы һәм митрополит аска ук иелеп, берничә адым атладылар да тезләренә төштеләр. Бары владыка[1] гына башын игән хәлдә басып калды.

— Әй бөек һәм кодрәтле солтан Үзбәк хан, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен, Аллаһ сине, хатыннарыңны, балаларыңны төрле бәла-казалардан сакласын. Аллаһ сиңа яу кырларында бары тик җиңүләр генә юлласын, — дип сәламләде Үзбәкне Михаил Ярославович. — Әй бөек хан, урыс җиреннән бүләкләрне тапшырырга рөхсәт итче.

Кенәзнең ике улы алга чыкты һәм, башларын игән хәлдә, ханның аягы янына алтын һәм көмеш кублар, бизәнгечләр һәм энҗе тезмәләр белән тулы подноснлар китереп куйдылар.

— Ә хәзер, ханым, синең өчен үземнең бүләгемне тапшырырга рөхсәт ит.

Хан нойоннарының берсе, кенәздән тирмәгә кергәндә алып калынган кыйммәтле ташлар белән бизәлгән кылычны кертте.

Үзбәккә сәламләү дә, бүләкләр дә ошады, ул эченнән генә урысларны ярлыкарга дигән нәтиҗәгә килде. Хан кенәз белән митрополитка үзенә якынрак утырырга боерды һәм алардан яшәү-көнкүреш хәлләре турында сораштыра башлады.

Михаилның зарланмавы да ханның күңеленә хуш килде, ул исә урыс җирләрендә тормыш итүнең бик үк гади булмавы турында бернәрсәне яшермичә сөйләде, ясакны киметүне сорап тел тибрәтмәде, кенәзләр арасында булып торган ызгыш-талашлар турында әйтеп тормады. Ә Үзбәк гауга-җәнҗаллар турында сорау биргәч, кенәз йомшак кына җавап бирде:

— Атабыз, моны үзебезгә тәртипкә салырга рөхсәт итче, инде барып чыкмый икән – синең хөкемеңә килербез.

Ханга бигрәк тә аның атабыз дип мөрәҗәгать итүе ошады . «Димәк, хөрмәт итәләр. Башланышы яхшы булды. Миңа андагы мәсьәләләргә ныграк үтеп керергә вакыт».

Күңеленә иң хуш килгәне митрополит Пётр — уйчан, ашыкмас, үзләренең изге китапларыннан тыш Коръәнне белгән монах белән сөйләшү булды. Алар тегe яки бу диннең өстенлекләре турында түгел, ә диннең кирәклеге турында әңгәмә алып бардылар. Бары шундый инану гына безнең гөнаһлы дөньяга яктылык алып керәчәген әйттеләр. Сүзенең ахырында митрополит Үзбәкнең онытылмас остазы Самир хаҗи сүзләре белән, Алла кешеләргә күңелләре теләгәнен сайлап алсыннар дип берничә динне индергән дип тәмамлагач, Пётр ханда тирән хөрмәт уятты.

— Син Урдада беренче тапкырмы?

— Беренче.

«Урдага беренче килүе икән, койрык та болгамый, тәлинкә дә тотмый

[1] Архиерейгә мөрәҗәгать итү сүзе

булып чыга, минем уйларымны, укытучымның мине нәрсәгә өйрәтүен ул кайдан белсен».

Аннары мәҗлес кордылар. Хан әле соңгы сүзен әйтмәгән иде: кунакларны аерым тирмәдә төн кунарга калдырдылар.

Иртән Тай-туглы ханбикә митрополит Пётрны чакырырга хәбәр йөртүче җибәрде. Рухани тирмәгә кергәндә, хан янында киенгән-ясанган хатынныннан башка кеше күренмәде. Хуҗабикә тезләнеп, митрополитка, үбүен сорап, кулын сузды:

— Алла хакы өчен фатихагызны бирегезче?

Пётрга Тай-туглының гыйсави булуы хакында имеш-мимешләр ирешкән иде, әмма мөселман ире каршында үзен болай тотарга батырчылык итәр дип һич уйламады.

Кичен Тай-туглы Үзбәктән урысларга карата фикерләрен сорашты.

— Кенәз Михаилның урыслардан беренче булып ханын баш иеп сәламләргә килүе мактауга лаек, әмма ул акыллы һәм хәйләкәр, аны күз уныннан ычкындырырга ярамый. Митрополит руханиларга хас булганча тотнаклы, ашыкмас, гадәттә андыйлар үзләре зыян салмый һәм яман кыланышлардан тыелып калалар. Аны янымдарак тотармын, рухи яктан урысларны безгә файда кылырга чакырсын.

Икенче көнне урыс илчелеген хан янына аның соңгы олуг сүзен тыңларга чакырдылар. Хан Михаил Ярославовичка Бөек кенәзлеккә ярлыкны раслады һәм митрополит Пётрга ярлык тапшырды, ул анда урыс православие чиркәвенең аерым хокукларын шактый арттырган иде. «Православ чиркәвенең барлык дәрәҗәләре һәм монахлары моннан соң Урда чиновникларына да, кенәз суды да түгел, бары тик православ митрополит хөкеменә буйсына. Кем дини кешене талап ала, шул аңа өчләтә түләргә тиеш була. Кем дә кем православие динен мыскыллап көләргә батырчылык итсә яки чиркәүне, кәшишханәне, кәшәнәне мәсхәрә итсә, урысмы ул, монголмы — үлем җәзасына хөкем ителә. Урыс руханилары үзләрен Алла хезмәтчеләре дип хис итсеннәр».

Шушы ук ярлыкта элегрәк Православие чиркәвенә бирелгән иреклэр дә расланган: «...Чиркәүдән һәм митрополит Пётрдан, аның кешеләреннән беркем бернәрсә алмый...». Үзенең олуг сүзе ахырында Үзбәк урыныннан торды һәм мәһабәт тавыш белән:

— Без аларны ярлыклар белән бүләклибез, Аллаһ та безне бүләкләсен, якласын; Алла биргәнне саклыйбыз, Аллага биргәнне алмыйбыз, митрополит та тыныч һәм сабыр булып, гадел йөрәк һәм гадел фикер белән безнең өчен, хатыннарыбыз, балаларыбыз өчен, нәсел-ыруыбыз өчен Алладан сорасын!

Митрополит Пётрның йөрәге сөенеч белән тулды, ул яшертен генә Тай-туглыга карады, тегесе исә бәхетле елмайды.

Урдадан әйләнеп кайткач, митрополит мәрхәмәтле Үзбәк хан һәм аның хатыны Тай-туглыга исәнлек сорап бер генә гыйбадәт кылмады. «Әй хатыннар! — дип уйлады монах. — Фикер-теләкләрегез хәйләгә буйсынмый, әмма Аллага күндерелгән икән, сез күп нәрсәгә сәләтле».

Шул ук 1313 елда урыс елъязмачысы болай дип язып калдырган: «Святитель Пётр в Орде у царя бысть в чести велицей и отпущен бысть от царя со многою честию вборзе».

Хан җәйне үзенең иле белән күчмә тормышта уздырды. Көзгә җылы урынга урнашырга кирәк иде. Кышлар Итилнең түбән агымында кайчакларда үзәккә үтә торган ачы җилле һәм түзә алмаслык суык була иде. Сарайга кире кайтудан Үзбәк катгый рәвештә баш тартты.

— Бәркә ызанында кышлыйбыз, — диде ул кискен итеп.

— Анда жылы йорт жимерек хәлдә, безгә туры килердәе башка юк. – Котлыгъ Тимер аны фикереннән кайтарырга теләде.

— Безнен ата-бабаларыбыз кайчан жылы өй таләп иткәннәр? Нәрсә, сиңа тирмәдә начар мәллә? Әгәр сез, әй минем рәхимле вәзирем, юртада кыш чыга алмасагыз, шәһәр төзергә тотыныгыз.

— Кайда салырга?

— Ә син сизмәденме?

— Әлбәттә, анладым, боеручым! Әлбәттә, Бәркә ызанында, бары тик шунда! Әгәр безнен мәнге онытылмас Бату ханыбыз үз вакытында сәүдә юлларын өйрәнгән булса, ул Сарайны бары тик шунда тергезгән булыр иде.

— Син хаклы. Анын ир туганы Бәркә Яңа Сарайны шушы урында салдыра башлаган, әмма күп нәрсәгә өлгермәгән, ә минем бабам Мәнгүтимер төзелешне ташлаган. Тынлале, Котлыгъ Тимер, ничек матур янгырый: Яңа Сарай – Сарай әл-Жәдид. Яңа калабызны нәкъ шулай атарбыз! Булды, хәл ителде! Яңа кала төзелеше турында уйларга өч көн вакыт бирәм. Мин дә уйлармын, һәм Яңа Сарай төзү хакында гына да түгел, безгә каланың Хәзәр дингезенә Уралдан агып төшкән елга янында булуы шарт. Анысын Сарайчык дип атарбыз, Итилнең теге ягында Актүбәнең су башы янындагы Бәлҗәмин, Тартанлыны үзгәртеп төзергә кирәк булыр. Эшебез бик күп, бәкләр бәгем.

Кышны Бәркә ызанында чыктылар. Кыш буе яңа кала төзелеше турында фикерләштеләр, шулай да күп вакытларын хакимият төзелешендәге үзгәрешләр алды. Хәзер яна зур булмаган хакимият төзелешендәге берәмлекләр – түмән башлыклары дип аталачак әмир вазифасына лаеклы кешеләрне жентекләп сайладылар. Бу эшкә чынгызыйларны гына түгел, башкаларны да билгеләргә булдылар. Төп билгеләр шул: ханга бирелгәнлек һәм сугыша белүгә караганда эшне оештыра алу кебек эшлекле сыйфатлар булуы шарт.

Сиздерми генә яз да килеп житте. Дала сызаларында кар ята әле. Төннәрен юк-юк дигәндә дә каты суыклар булып ала, йөз тирәсе атчабар исә Алтын Урда буйлап сибелде. Аларнын букчаларында ханнын үз Олыс бәкләренә җибәргән фәрманнары ята, аларда кала төзүчеләрне, кирпеч, балчык яндыру осталарын, төзүчеләрне һәм ярдәмче эшләргә дигән колларны кемгә, кайчан, күпме һәм кайсы вакытка Бәркә ызанына китереп житкерергә тиешлеге күрсәтелгән иде. Өстәвенә китерелгән төзүчеләрне асрау тулысынча Олыс башлыкларынын иннәренә төшәчәк диелгән. Хан ялгызы гына яна башкала төзергә тиеш түгел бит. Сарайга исә Үзбәк бару түгел, кереп чыгарга да теләмәде.

«Әйдә, минем өчен яман булган бу калада Чынгызхан нәселенен хөсетлеләре бурсып ятсыннар. Андыйларга минем сарайда урын юк. Мин Сарай әл-Жәдидне Үргәнечтән дә, Хива белән Бохарадан да шәбрәк итеп төзиячәкмен. Императорлар, солтаннар һәм корольләр мине катып калган кучмәнгә санамасыннар. Мин, мәдәниятле утрак хаким, башкала нинди булырга тиешлеген күрсәтәчәкмен әле!» – дип уйлады Үзбәк хан.

Дала төрле төстәге кызалаклар белән капланды, кошлар, бала чыгарырга дип, ояларына утырды, агачлар яшеллеккә төренде. Итилнең өске ягыннан күбекләнеп язгы гөрләвекләр йөгерде. Төзелешкә дә ташкын кебек агылдылар. Беренчеләрдән булып, күрсәтмәдә язылганча, кытайлар килде. Урынны хан белән бергәләп карап чыктылар.

— Каланы елга буенча буйга егерме, кинлеккә дүрт чакрым итсәгез итегез, әмма ызан өстеннән даланы өскә күтәргән калкулыктан чыкмагыз, – дип кинәш бирде хан.

Хезмәт яратучы кытайлар көн-төн эшләделәр, алар ханнын уен аңладылар – каланын елга буена урнашуы су кытлыгын бетерүдә, бай йортларда пычрак

суларны агызу мәсьәләсен хәл итүдә, фонтаннар өчен басымны көйләүдә җинеллек тудырачак. Төзүчеләр үзләреннән алдарак кемнендер бик тырышканын күрделәр, һәм Бәркә хан вакытында ук авыл буйлап төзелгән каналларны ничек итеп кинәйтергә, үзгәртергә икәнен уйлап таптылар. Сарайны кайда урнаштырырга, бәкләр бәгенен утары кайда булачагына төшенделәр. Үзләренен ниятләре белән таныштырганда өлкән кытай хакимнән:

— Сез үзегезнен сараегызны кайда күрергә телисез, бөек ханыбыз? — дип сорады.

Үзбәк атын куалады, кытайлар анын артыннан иярделәр. Озак чабарга туры килмәде.

— Менә монда, — дип күрсәтте хан, — яр буйлап тут[2] агачлары үсеп утырган елга култыгы белән күл арасында.

Нәкъ менә шул җирдә Бәркә хан белән Толуй атлы улынын кечерәк ташландык сарайлары тора иде.

— Тик бу корылмаларны тәртипкә китерергә, кинәйтергә һәм нигезләрен ныгытырга кирәк. Сезнен биналар өчен, әй бөек ханыбыз, алар житәрлек дәрәжәдә нык түгел, — дип фикерен белдерде кытай архитекторы.

— Ханнар осталарнын эшенә катышмый. Алар осталарны йә бүләкли, йә җәзалап үтерә. Эшләгез!

Үзбәк төзүчеләргә шәхси кирәк-яраклары өчен акча түләргә әмер бирде. Ул кул астындагыларны узындырырга күнекмәгән иде, әмма, ничек түлисен, шулай эшлиләр дигәннән чыгып, кәефләрен дә кырырга теләмәде.

— Йортынны минеке белән янәшә төзергә рөхсәт итәм, — диде хан бәкләр бәгенә. — Оештыр да мине куып җит.

Үзбәк, атына атланды да, күлне әйләнеп, мул сулы дала елгасы — Көлгетнен тамагына чапты. Хан кулларына таянып, күлдән су эчте. Дала күлләренә хас булганча, анын суы тозлы түгел иде. Ул су эчкәндә, яр буена санакларын ялкау гына кыймылдатып зур балык йөзеп килде. Үзбәкнен ширвәншаһ ишегалдындагы сулык исенә төште, анда нинди генә төсле балыклар юк иде: сарылары, кызыллары, яшькелтләре. Ат аягы тавышы ишетелде, хан ир туганына борылып, бармагын авызына куйды һәм:

— Карале, нинди могҗиза. Күрәсенме? Уйла, зирәк бәкләр бәгем, һәм шулай ит: бу сулыкта балык бетмәсен. Гадиләре түгел, төрле төстәгеләре дә булсын.

Кала салуга әзерлек эшләре бөтен көченә барды. Кирпеч сугу өчен балчык чыгару урыннары ачыкланды. Известь сүндерү өчен сыешлыклар корыла башлады. Каналлар торгызылды, алар булачак шәһәргә Актүбәдән су алып килергә тиешләр иде. Хан төзелеш эшләре барышын күзәтергә төпле бер әмирне (гарәпләргә охшатып, түрәләрне шулай атарга күнектеләр) билгеләп, үзе Бәркә ызанынннан дала буйлап төньякка таба утыз чакрымнар тирәсе күченде. Күчмә тукталышта тынычлыкта һәм тынлыкта бәкләр бәге, Мөхәммәд хаҗи һәм тагын үзенә якынрак торган ике кеше белән бергә Үзбәк эчке һәм тышкы сәясәт турында фикер алышуга күчте.

Ин беренче итеп алар Урданы житмеш түмәнгә бүлделәр, дүртәр Олыс билгеләделәр. Шулай итеп өч баскычлы идарә барлыкка килде: хан һәм анын ставкасы, Олыс бәге, түмән әмире. Өч Олыска чынгызыйларны — Үзбәкнен якын туганнарын утырттылар. Урыс Олысы белән житәкчелек итүне, хакимнен нык күзәтүе астында, Бөек кенәзгә тапшырдылар.

Әмирлеккә каралган житмеш кешене хан белән очрашуга чакырдылар. Булачак башлыклар арасында хәрби житәкчеләр дә, тәҗрибәле түрәләр һәм

[2] Яфракларын ефәк корты ашый торган киньяк агачы һәм шул агачның җимеше

бай гаиләләрдән чыккан акыллы кешеләр дә бар иде. Иң мөһиме, аларның туганнары арасында сатлыклар һәм качып-күчеп йөрүчеләр юк иде.

Хан чатыр астындагы тәхеттә утырган җирдән, булачак әмирләргә күз йөгертеп алды. Хакимнең карашы кешеләрне үтәли тишеп чыкты, җанны бораулап, казып чыгаргандай итте. Болай да киеренке хәлдә торган халык Котлыгъ Тимернең тимер чыңына охшаган таләпчән тавышыннан куырылып килде:

— Безнең зирәк Үзбәк хан, Аллаһ аның гомерен озайтсын, кушуы буенча, мин сезгә башкаларның колагы ишетмәскә тиешле бик мөһим хәбәр ирештерергә тиешмен. Аны беркемгә әйтмәгез, кем әйтә — шул күрсәткән хезмәтләренә карамастан җәзага тартылачак.

Безнең ханыбыз, белемле һәм бай Шәрык мөселман дәүләтләреннән кайтыш булмасын өчен, үзенең ханлыгын үзгәртеп кору эшен башлый. Хан Алтын Урда белән җитәкчелек итү юлын алыштырды. Сез, монда җыелганнар, хакимнең уң һәм сул куллары булачаксыз. Бүгеннән сез — әмир, төмән башына куелачаксыз. Урданың сезгә ышанып тапшырылган төмәннәре белән җитәкчелек итәчәксез. Сезнең башлыгыгыз — кулы астында ике йөзләп төмәне булган Олыс бәге. Олыс бәге үзе бары тик ханга гына буйсыначак. Ханга бары тик ул гына Олыстагы хәлләр турында яхшы һәм начар хәбәрләрне җиткерә алачак, бары тик Үзбәк хан гына аны ярлыкый яки җәзага тарта алачак. Сезгә, әмир вазифасы алганнарга, хөкемдар Олыс бәге булачак, әмма сез аның гадел булмаган гамәлләре турында ханга җиткерә аласыз. Олыс бәкләре итеп хан үзенең нәселеннән булган, ышанычлы һәм сыналган кешеләрне билгеләде.

Сезгә әмир дигән бөек вазифаны алганда аерым таләпләр куела. Беренчесе һәм иң мөһиме: син мөселман булырга тиешсең. Вазифа бернichә көн көтеп торачак. Әгәр син башка Аллага табынасың һәм иманлы булырга җыенмыйсың икән, хәзер үк торып, бөек җыелыштан чыгып китәргә тиешсең. Ханның хәтере калмас. Соңыннан хыянәт иткәнче, хәзер дөресен әйтсәгез яхшырак булыр. Хыянәт өчен аяу булмаячак. Хәзер торып чыгып китүчеләр мондагыны сер итеп сакларга тиеш. Кем тарата, ул кешене табып, ана җәза биреләчәк. Өч кеше ашыкмый гына берсе артыннан икенчесе торып басты. Берсе — Гүюк исемле чиста канлы монгол ханга башын иеп:

— Ачуланма, әй бөек ханым. Мин сатлыкҗан түгел, әмма суга батканда урыс кенәзе Дмитрий мине үлемнән алып калды. Мин аңа гыйсави булырга һәм улымны аның исеме белән атарга сүз бирдем. Мине Урыс иленә җибәр, бөек хан, анда сиңа тугрылыклы хезмәт итәрмен.

Үзбәккә хәрби җитәкченең сөйләве ошады, андыйлар сине сатарга сәләтле түгелләр.

— Тверьга Дмитрий янына кит һәм җиренә җиткереп хезмәт ит. Бу ике кешене дә үзең белән ал. Урыс — Урданың бер өлеше, тик шунысы бар: аны күз уңыннан ычкындырырга ярамый.

Өч монгол атларына сикереп менделәр дә китеп бардылар, алар артыннан тузан гына күтәрелеп калды. Үзбәкнең кыю һәм туры сүзлеләргә хөрмәте һәрвакыт зур иде.

Котлыгъ Тимер дәвам итте:

— Икенче шарт: ханга һәрчак һәм һәрнәрсәдә тугрылыклы хезмәт итәргә, чөнки диндәшләр туганнарын сата алмый. Хыянәт өчен — үлем җәзасы!

Өченче шарт: үз төмәнендә үз вакытында һәм тулаем ясак җыярга. Байлыкны яшереп калдырган өчен — җәза. Яхшы хезмәт өчен — бүләк. Хан, «гомереңне сат — намус ал», дигән васыять белән яши.

Дүртенче шарт: үз халкыгызны таламагыз, аны хәерчелеккә төшермәгез.

Аларга байлыкларын арттырырга ярдәм итегез, шул чакта сез алардан күпне өмет итә аласыз. Ярлылардан бернәрсә дә алмагыз, хәерче кеше усал һәм куркыныч та була ала. Усал һәм хәерче кешеләр күп булу – бу афәт. Шуна кешеләр өстеннән хөкемегез гадел булсын, мәчетләр торгызыгыз, намаз адәмнен җанын тынычландыра. Үзегез дә догалар укыгыз, чын иманлы кешеләр булыгыз һәм Аллаһ сезне беркайчан ташламас, хан бүләкләргә күмәр.

Бишенче шарт: башка диндәгеләрне кысмагыз, аларнын динен хөрмәт итегез, шул чакта Аллаһ аларны тәртипкә чакырыр һәм алар ханыбызга тугры хезмәт итәрләр. Әмма белемле, укымышлы муллалар сайларга тырышыгыз, аларга халыкны дингә басым ясамый, гауга-талашсыз юл белән әкренләп китерергә мөмкинлек бирегез.

Бүген дә һәм мәнге шулай булсын. Кодрәтле һәм гадел Аллаһка дан!

Ә хәзер бөек һәм гадел ханыбыз сезне кичке аш табынына һәм үзе белән бергә төнге догаларны укып, кодрәтле һәм мәрхәмәтле Аллаһтан бергәләп гөнаһларыбыздан арындыруны һәм ниятләребезне башкаруда ярдәмен сорарга чакыра. Иртәгә иртән һәммәгез дә элеккеге хезмәтегезне дәвам итәргә кузгалырсыз һәм әмир вазифасына билгеләнү өчен чакыртып алганны күтәрсез.

Үзбәк үзгәртеп корыларны ашыкмый гына башлап җибәрде. Ханнын яналыклар кертүе анын исемле кардәшләренен кайберләренә ошап бетмәде. Түмәннәрнен берсендә әмир булып Гайсатай исемле тырыш монгол хезмәт итте. Әмма Җүчинын турыдан-туры нәсел дәвамчылары аны санга сукмадылар һәм элеккечә табышларыннан казнага акча кертмәделәр, өстәвенә түмән кешеләренен язмышы белән идарә итмәк булдылар. Фарсы сәүдәгәрләреннән берсе сәүдә итү өчен түләнергә тиешле акчаны чынгызыйнын үзенә бирергә дигән таләбен үтәми. Ул акчаны хан фәрманында язылганча казнага кертә. Монын өчен элеккеге тулы хакимлеккә ия хуҗалар сәүдәгәргә үлем җәзасы бирәләр. Гайсатай моны оятсызлык дип атады һәм ханнын ике ерак туганын кыйнарга боерды, аннары бу турыда ханга җиткерде.

Хан бу түмәнгә үзе килде.

— Мин сезгә үлем җәзасы бирмим, сез үлемгә лаек түгел! Сез коллыкка лаек. Әмир Гайсатай кайчан сезне кичерә, шунарчы анын коллары буласыз. Әгәр кемдер сезне коллыктан коткарырга маташса, үлем җәзасы бирәчәкмен һәм бөтен тамырыгызны корытачакмын. Сез ата-бабаларыбызнын исеменә тап төшердегез, чөнки Чынгызханнын һәр варисынын бурычы — үзенен дәүләтенә файда китерү. Ә сез зыян саласыз. Хәзер менә суалчаннар кебек тирестә актарыныгыз, бәлки акылыгызга килерсез.

***

Алтын Урданын ана якын илләр арасында абруе зур иде. Күршеләре, яу чыгуларыннан куркып, анын хакимнәренен ачуын чыгармаска тырышты. Үзбәктән элгәреләр тагын да ераграк һәм көчлерәк дәүләтләр белән дә әйбәт мөнәсәбәттә булганнар. Үзбәк хан да бу гадәтләрне саклады. Кемгәдер яу чабарга теләмәгән һәм яратмаган хан Ән-Надыйр Мөхәммәдкә үз илендә үзгәртеп корулар алып баруы, кешеләрен дингә тартуы турында хат язды, ныклы дуслык, туганлашырга тәкъдим итте. Мисыр солтаны тәкъдимне кабул итеп алды һәм яучылар өчен илчеләр җибәрде. Үзбәк хатынлыкка үзенен җияне[3] Толынбайны күрсәтте, тик бик зур калым сорады, илчеләргә, солтаннарын оятка калдырмас өчен, хәтта урындагы сәүдәгәрләрдән акча алып торырга туры килде.

[3] Хатын ягыннан туганнар (племянник-племянницаларга шулай әйтү бар — тәрҗемәче)

Эн-Надыйр Мөхәммәд Толынбайга өйләнде, әмма күп тә үтми, сәбәбен анлатып тормыйча, аннан баш тартты. Әллә ханның калым белән кыланышы ошамадымы, әллә инде кызның үз-үзен тотышы бәйләнчек солтанның холкына туры килмәдеме, ул аны ниндидер әмиргә бүләк итте.

Үзбәк Эн-Надыйр Мөхәммәдтән кызларының берсен үзенә хатынлыкка сорады. Әмма тегесе, кызларым яшь, кияүгә чыгарга иртә дигән булып, каршы килде.

Алтын Урданың ханы гарьләнсә дә, солтан белән ызгышып тормады, аның дошманына әйләнергә теләмәде.

Аллаһ сакласын, Эн-Надыйр Мөхәммәд Иран илханы белән килешү төзесә, авыр һәм канкойгыч сугыш башланачагын көт тә тор, димәк, барлык үзгәртеп корулар да тәмам дигән сүз. Хан бу ачы жинелүне сүзсез генә уздырып жибәрсә дә, ачуы басылмады, берсүзсүз буйсынырга тиеш дигәнгә күнеккән хаким тынычлыгын югалтты. Кичтән Ләйләнең тырышуы да бушка булды, төнлә хан күзен дә йоммады.

Таң атты. Тәгәрәп якты кояш чыкты. Кошлар, бар көчләренә чыркылдашып, үлән өсләренә төшкән чыкта коендылар. Бар да нурлы иртәгә карап сөенеште, бары Үзбәкнең күнелендә генә буран улады. Ул Котлыгъ Тимерне чакыртты.

— Ауга барырга телим, сугышчыларга кыр кәжәләре көтүен текә калкулыкка куарга боер. Син дә минем белән барырсың.

Хан белән бәкләр бәге иярдә килеш офыкны күзәттеләр. Кинәт анда, жирән болытка төренеп, нәрсәләрдер селкенде. Бераздан коңгырт ташкын бар аралыкны тутырды. Биш менләп кыр кәҗәсе бик зур тизлек белән, дала буйлап чапты.

— Артларыннан куып жит тә әйт, өч чакрым тирәсе әйләнсеннәр дә кайтсыннар.

Көтү кире борылды һәм Үзбәккә орынып диярлек узды, хан кәҗәләрнең борын тишекләрен киң ачып сулыш алганнарына кадәр күрде. Даланың бөтерелеп өскә күтәрелгән кызгылт-көрән тузаны әкренләп кире үз урынына ятарга да өлгермәде, ерак түгел тагын тузан болыты кузгалды. Йөзләгән сугышчы куалаган кыр кәҗәләре кире әйләнеп килделәр, аларның тизлекләре кимегән, хайваннар арган иде. Хан атын каулады һәм кыр кәҗәләре күп булган урынга кереп, кылычы белән унга һәм сулга селтәнде. Хайваннар егылды, алар өстенә башкалары килеп ауды. Үзбәк селтәнде дә селтәнде, жир өстеннән күбекләнеп кан акты... Ниһаять, көтү берничә өлешкә таркалып төрле якларга томырылды. Үзбәк кәефсез генә калкулык кырыена килде:

— Менә шулай барысын да кырам, хайваннар кебек куып ардырам да тураклыйм!

Котлыгъ Тимер сүзнен кем турында барганына төшенде, әмма дәшмәде.

Атлар ашыкмый гына ир туганнарны күчмә тукталышка илттеләр.

— Иртәнге ашка вакыт түгелме? — дип сорады хан.

— Вакыт. Һәм эшкә тотынырга да, — дип тәкъдим ясады бәкләр бәге хакимгә.

Эшләр турында ашаганда сөйләштеләр.

— Ханым, митрополит Пётр, Кастантиниягә Православие чиркәве патриархы янына барырга жыена икән, дигән хәбәр житкерделәр. Рөхсәт сорый икән.

Үзбәк дәшмәде, бик тырышып ит чәйнәвен дәвам итте һәм аны бия сөте салып ясалган чәй белән йотып куйды. Котлыгъ Тимер, хан анын үтенечен колак артыннан уздырып жибәрде ахры, дип уйлады һәм башка сорау биреп тормаска булды. Шунда ук кайнап торган казаннан зур кисәк бәрән ите чыгарды

да аның йомшак җиренә таза, нык тешләрен батырды һәм үткен пычак белән ирене янынннан җинел генә кисеп төшерде.

— Кастантиниягә дисен инде? — Үзбәк кайтарып сорады. — Барсын, тик безнең аша. Митрополит Пётр башка руханилар кебек, акыллы, хәйләкәр. Минем хатымны император Андроник II гә илтеп тапшырыр, алар ничек яши — карасын, күрсен, безнең бүләкләрне биреп сөендерсен һәм кире кайтканда тагын безгә керсен. Без аннан барысы турында белербез. Митрополитка алтын байса[4] бир һәм аның башыннан бер бөртек чәче коелмасын. Андый күзәтчеләр безгә бик кирәк.

***

Ханның яраннары Яңа Сарайга якынлашты. Бераздан калкулык буйлап иренеп кенә агып яткан дала елгасы Сарайчык янына килделәр. Аның суы искиткеч тәмле һәм салкын иде. Үзләре дә эчте, атларын да эчерделәр һәм шунда кинәт сандугач сайравы ишетелде.

— Нинди кош бу, бик матур сайрый? — дип сорады Үзбәк.

Гаҗәпкә калган ханны озатып йөрүчеләр, аптырап, җилкәләрен сикертте.

— Сүз әйтергә рөхсәт итче, бөек хан. — Тавыш иясе ханны саклаучыларның берсе иде.

— Әйт.

— Бу — сандугач. Алар бик күп, тик менә көзен сайрамый ул сандугачлар.

Яңа каланы әйләндереп алган калку җиргә менделәр һәм дала өстеннән күтәрелгән төтенгә таба киттеләр. Кирпеч яндыру миче янында кайнашкан эшчеләр, ханны күрү белән йөзләре белән җиргә капландылар.

— Өлкән оста, тор һәм ханга монда ни белән шөгыльләнүегез турында сөйләп бир, — дип боерды төзелеп яткан Яңа Сарайның әмире Түлә-Буга.

Кытай остасы тезенә төшеп:

— Әй, бөек хан, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен, без монда кирпеч ясыйбыз. Менә монда балчык казыйбыз, аны изәбез, калыплыйбыз, аннары кояшта киптерәбез һәм кирпеч әзер була, әмма гасырлар буена чыдасын, нык булсын өчен без аны уттай кызган мичтә яндырабыз.

Үзбәк берни дәшми-нитми эш барышын күзәтте һәм канәгать калды.

— Ә сездә сандугачлар мичтә сайрыймы? — дип көлемсерәде хан.

— Җәзаларга кушма, бөек хан. Минем укучым сайрый. Балчыктан сыбызгы ясый да барыбызның да күнелен күтәрә.

— Шәкертеңне күрсәт әле.

Егерме яшьләр тирәсендәге аксыл чәчле егет башын күтәрде, аның зәңгәр күзе елмая иде. Ул сүзсез генә кесәсеннән балчык кош алды, эченә су тутырды һәм, тынын өреп, сандугач тавышы чыгарды.

Үзбәкнең кәефе килде:

— Әйдәле, тагын! Моннан башка тагын нәрсә ясыйсың, күрсәт.

Егет кесәсеннән берничә курчак алды һәм ханга сузды:

— Мәгез, ханым, балаларыңны уенчыклар белән куандыр.

Үзбәк курчакларны карады да елмайды:

— Ә кирпеч эшли беләме ул? — дип, кытай остасына борылды.

— Аның бар нәрсәгә кулы ята. Аллаһдан бирелгән.

Хан билбау астыннан күн акча савыты тартып чыгарды:

— Тот, син ханны шатландырдың!

Аннары Яңа Сарайның әмиренә борылып әмер бирде:

---

[4] Алтын Урдада соңрак татар ханлыкларында саклау һәм вәкаләт кәгазенә тиң булган тамга. Хан идарәсе байса белән, дәүләттә каршылыксыз хәрәкәт итәргә хокук биргән.

— Аның өчен яна мич төзергә, әйдә, кирпеч кенә түгел, балалар уенчыклары да ясасын. Кара, төзелештә күпме халык мәш килә, күбесенең, мөгаен, балалары бардыр. Күбрәк тудырырга кирәк, балалардан менә дигән сугышчылар һәм осталар чыга. Бу уенчыклар исә аларны да, өлкәннәрне дә сөендерер.

Хакимнең очлы күзеннән бернәрсә дә читтә калмады.

Төзелештә эшчеләр хисапсыз күп, төзү мәйданы егерме чакрым озынлыкта сузылган иде. Нигездә каналлар төзелде, аларның ярлары бик җентекләп балчык белән дыңгычланды, өстенә салыначак юллар өчен акташ җәелде.

Сарай төзелешен карадылар. Нык итеп салынган нигезгә дивар өя башлаганнар. Үзбәкнең күнеле җырлады. Ул дөньяда тиңе булмаган кала торгызыр!

Төнгә Яна Сарайда калдылар. Үзбәк бик озак әйләнгәләп ятты, йокымсырап киткән иде – кабат уянды. Гөмбәздәге тишеккә карады, ә аннан, күктән, йолдызлар ханга күз кыстылар.

— Йолдызларда ниләр бар икән? Мөгаен, Аллаһның оҗмах бакчаларыдыр. Анда минем атам, анам. Алар уллары турында ни уйлый икән? Хыяллары тормышка ашканын – улларының хан булганын беләләр микән?

Бәлки мина үз дигәнемә ирешергә кирәк булмагандыр? Олыс бәге булып калып, гыйлем белән шөгыльләнергә иде? Авыр бу йөк – хакимият: йоклыйсы килә, ә күз йомылмый, — дип, төнге тынлыкка, даладагы кыштырдаган, эт өргән тавышларга колак салып, үз алдына уйланып ятты Үзбәк. Кырын ятып карады һәм Котлыгъ Тимернең дә боргалануын сизде.

— Йоклап булмыймы, вәзирем?

— Әйе, никтер йокы алмый, Бөек хан.

— Уйларын белән уртаклаш, туганым.

— Иртән әйтергә җыенган идем. Инде йокламыйбыз икән, әйтәм. Юрий Данилович Московский Урдага килергә рөхсәт сорады.

— Ни тели икән ул тынгысыз хәйләкәр? Җирләре азмы? Хәзер Бөек кенәз Михаил белән кабат ачуланышкан дип әйтерсен.

— Аларның низаглашудан туктаганнары да юк. Нәни балалар курчак бүлешә алмаган кебек, болар да Новгородны бүлешә алмый. Михаил Новгородны Юрийның абыйсы Афанасийдан тартып алган, ә тегесе биш мен гривенны шунда ук, аннары дүрт ел эчендә Бөек кенәзгә тагын уникемең көмеш белән түләп, каланы кире кайтармакчы була. Шундый шартлар белән Михаил килешү төзегән, ләкин үзенең башлыкларын Новгородта калдырган.

— Менә кайдан мина Бөек кенәз әйбәт ясак түли икән! Акыллы! Афәрин! Ә син, минем изге күнелле бәкләр бәгем, баскаклар[5], баскаклар дисен. Барысын да куарга кирәк, шайтан алгыры. Уйла бу турыда, акыллы вәзирем.

— Һичшиксез уйлаячакмын, ханым, тик мин сүземне дәвам итәр идем.

— Дәвам ит.

— Новгородлылар Михаилның эшләре белән канәгать калмаганнар, ханым. Бөек кенәз илчелекне кулга төшерде дип, сина шикаять белән килергә уйлаганнар. Бу турыда белгәч, Новгородта яшәүчеләр Михаил Ярославовичның башлыкларын куганнар. Менә шулай итеп, Юрий абыйсын һәм новгородлыларны яклауны сорап безгә килергә җыена.

— Килсен, сөйләшербез, уйлашырбыз. Бәлки, чыннан да, Бөек кенәз югары оча башлагандыр?

1316 – 1317 еллар кышын Юрий Данилович Урдада уздырды. Яна Сарайдан Актүбә буйлап ун чакрым тирәсе өстә, камыш куе булып үскән елга буенда, үзенә тирмә корды. Кышларын уйсу ярга бик күп кабаннар килде, шунлыктан

[5] Алтын Урда ханының биләмә өлкәләрдәге урынбасары; ханга ясак җыючы отряд башлыгы

Мәскәүдән кенәзгә хезмәт күрсәтер өчен алып килгән йөзләгән кешене туйдыру кыенлык тудырмады. Сугышчылар һәм хезмәтчеләр балык тоттылар, Актүбә белән Итил арасындагы урманнарда күпләп үрчегән коралай[6], болан, куян, кыргавыл[7] кебек киек кош-корт, хайваннар ауладылар.

Язга таба кенәз үзе янына тарлауга Урда аксөякләрен чакыра башлады. Өстәлләр муллыктан сыгылып торды, сыра белән ачы бал елга урынына акты, өстәвенә киткәндә һәр кунакка көмештән ясалган һәйбәт бүләкләр бирделәр. Юрийның бай мәҗлесләре турындагы имеш-мимешләр хан колагына да барып ирешә, хан кенәздә кунакта булу теләге барлыгын белдерде. Күптәннән Юрийның яшерен тарафдары булган Котлыгъ Тимер шунда ук хакимнең теләген кенәзгә житкерде. Мәскәү хәйләкәре вакытны сузып тормый Үзбәк янына килде һәм түбәнчелек белән, үзенең тыйнак кына сыенып урынын карап чыгуын үтенде.

Уйсу ярга көн уртасында килеп җиттеләр. Үзбәк кенәзнең өлгерлегенә хәйран калды, ярдан ерак түгел тау астында урнашкан кенәз тирмәсен түтәннәре күккә үрләгән дистәләгән нык агач ызбалар әйләндереп алган иде. Җыйнак кына кәшәнә утыра. Аз гынаерактарак амбарлар, кәнүшни, мал-туар өчен араннар тезелеп киткән. Болар бар да берничә ай эчендә үсеп чыккан иде.

Юрий ханны басу капкасы янында тезенә төшеп каршы алды. Кеш тиресеннән тегелгән башлыклы, өрфия мамык яулыкларга уранган ике гүзәл кыз, йола буенча, Үзбәккә ипи-тоз тапшырдылар. Аннары куас һәм ачы баллары белән мунча көтә иде. Бөек ханны шул ук ике чибәркәй чабындырды. Себеркеләр ашыкмый назлап кына парны тәнгә йөгертте, ә кызларның йомшак куллары ханны акылдан яздырды һәм дәртле ирлек көчен уятты. Хан мул күкрәклесен кочаклап алды һәм алар бергәләп җинел пар белән каядыр югарыга таба очтылар.

Мунча алдындагы кин сәкедә күнелне күтәрә торган ачы бал капкалап ятканда, бөек хан тәненең бушанып, җинеләеп калганын тойды. Соңрак зур сый мәҗлесе булды. Ханга бигрәк тә ит белән суганнан пешерелгән бөккәннәр ошады, ул бик рәхәтләнеп элек яратып бетермәгән балык бөккәннәрен дә ашады.

Ахырдан кенәзнең гөсләгә кушылып бик оста итеп әкиятләр, дастаннар сөйләве искиткеч булды. Төн уртасына кадәр утырдылар. Берәү дә Урдадагы хәлләр, бигрәк тә урыс кенәзлекләре арасындагы ызгыш-талашлар турында тел тибрәтмәде. Үзбәк беравыкка үзенең хан булуы турында онытты, Борчак патша турындагы әкиятне сөйләгәндә малай-шалай кебек рәхәтләнеп кычкырып көлде.

Хан да, кенәз дә очрашудан канәгать калдылар. Бар кешедән бигрәк Юрийдан мул бүләк тамган Котлыгъ Тимер шатланды. Шул көннәрдә бәкләр бәгенең башына бик яхшы фикер килде: «Әгәр Үзбәкне Мәскәү кенәзенә якынрак бәйләп куйсаң, ул аны Бөек кенәз итәргә мөмкин бит. Тик менә ничек бәйләргә? — дип баш ватты зирәк вәзир. — Нишләп әле Үзбәкнең кыз булып озак утырган сеңлесе Кончакны аңа кияүгә бирмәскә?»

Юрий Котлыгъ Тимернең тәкъдимен сөенеп кабул итте һәм, атчабарларын Мәскәүгә зур калым алып килергә җибәреп, үзе ханнан рәсми рәвештә кабул итүен үтенде.

Бәкләр бәге ханына Юрий Даниловичның уй-ниятләрен җиткерде. Үзбәк моны көтмәгән иде — уйга калды.

«Кончакка озакламый егерме алты тула, анасы Зарифа күптән инде Аллаһның оҗмах бакчасында. Сеңлесе соңгы вакытларда аларда яшәде, ана туры килә торган кияү табылмады, начар нәселгә бирәсе килмәде, югыйсә

[6] Кыр кәҗәсе
[7] Тавыксыманнар отрядыннан чуар йон белән капланган эре кош

кәләш матурлык өләшкәндә артта калмаган, холкы да басынкы, әйе, утырып калуы бар. Юрий борынгы кенәз нәселеннән, Кончак өчен лаеклы пар. Кеше буларак та начар түгел. Ризалык бирергә кирәк». Үзбәк йөрәге, күнеле белән бу кушылуның күбрәк сәяси мәгънәгә ия булуын аңлый, әмма бернинди начарлык күрми, үзе дә бит митрополит Пётрдан Византия тәхете варисының кызлары турында белешергә кушкан иде.

Хан бик кыйммәт калым алды. Туй патшаларча бик купшы булды. Хан туй хакына саранланып тормады, киявенә урыс иленең бөек кенәзе ярлыгын тапшырды һәм кенәзгә буйсынган җирләрдә баскаклыкны юкка чыгарырга дигән фәрман бирде. Юрий Даниловичның туйда эше юк, ул күңеленнән явыз дошманы Михаил Ярославовичны җиңүне бәйрәм итте. Яңа гына пешеп чыккан Бөек кенәз ширбәт аен Урдада уздырды, ул һәр йортта көтеп алынган кунак булды.

***

Көз табигатьне алтынга манды, менә-менә суыклар башланыр вакыт җитте, Юрий Данилович өенә кайтырга җыенды. Бөек кенәзлек тәхетенә утырасы, Владимирга күченәсе бар иде.

Михаил Ярославовичның ансат кына Бөек кенәз урынын калдырмасын аңлаган Котлыгъ Тимер Үзбәкне Юрий белән бергә әмир Каугадыя җитәкчелегендә утыз мең урда сугышчысын җибәреп, урыстагы бар халыкка өйләрендә кем хуҗа икәнен күрсәтергә кирәклегенә үгетләде.

Михаил чыннан да килешергә теләмәде. «Теләсә кем булсын, тик башыннан алып аягына каләр үзен сөяр Юрий гына түгел, — дип чәпчеде ул. — Ул кабахәт урыс кенәзлекләрен тәмам сыгачак».

Михаил Ярославович ханның үзен кичермәсен аңласа да, кенәзлекне орышсыз гына бирергә теләмәде. Ул гаскәрен Кострома каласына каршы Итилнең уң як ярына туплады. Әмма елганы кичеп чыгарга җыенмады. Утыз мең сайлап алынган көчле сугышчылар белән бәрелешкә керү, әлбәттә, үлемгә тиң булыр иде, ә менә каршы тору — анысы икенче мәсьәлә. Ике атналап торганнан соң, кенәз дружиналарын Тверь ягына алып килде һәм каршы торырга әзерләнде. Кенәзлекнең башкаласыннан кырык чакрымнар тирәсе Бортенев авылы янында әле катарга өлгермәгән җирдә очлы агач казыклар кактылар һәм беренче кар сибәләп аларны күздән яшерде.

Каршы як декабрь башына килеп җитте һәм шунда ук һөҗүм башлады. Тәҗрибәле җайдакларның күп меңләгән ташкыны дошманына ташланды. Әмма көтелмәгән хәл килеп чыкты: Юрий белән Каугадыя күз алдында атлар егыла башлады. Тверьлылар, гайрәтләнеп, поскыннан атылып чыктылар һәм ат өстендә генә сугышырга өйрәнгән һәм хәзер җәяүлегә калган сугышчыларны бик тиз кырдылар. Хан гаскәренең калдыклары артыннан куа киттеләр. Юрий Даниловичның ир туганы Борисны һәм Юрийның хатыны Кончакны әсирлеккә төшерделәр. Әсирләрне Тверьга китереп, тверь кенәзләренең берсенең йортына урнаштырдылар. Юрий, эзәрлекләүдән котылып, Новгородка качты һәм урыс җирләренең бөек кенәзе булуыннан файдаланып, Михаилга каршы гаскәр туплады. Новгородлылар бик шатланып үзләре куралмаган тверь кенәзе һәм тверьлыларга каршы барырга ризалык бирделәр. Алар Итил буендагы шәһәрне камап алдылар һәм сугышка керергә әзер иделәр. Ләкин кенәз Юрий һөҗүм башларга әмер бирмәде, чөнки ул Михаил белән яуда тартышудан мәгънә юклыгын аңлады. Мәкер-хәйлә белән алырга була.

Мәскәү кенәзе кирәк кешене табып, аны саранланып тормый сатып алды һәм Тверьга үтеп кереп, яраткан хатынына хат белән бүләк тапшырырга кушты. Кечерәк

кенә букчага бик көчле агу сендерелгән тәмле күмәчләр һәм бөккәннәр салынган иде. Кончак, сөйгәненең бүген-иртәгә коткарачагына ышанып, шатлыгыннан елап җибәрде. Хатны укыгач, Юрий кушканча, мичтә яндырды, тәрәзә янына утырып, канәгатьлек белән бөккәннән авыз итте. Икенчесен инде ашарга өлгермәде.

Хатынының үлеме турында Бөек кенәз бер көннән соң белде, урыс җирендә имеш-мимешләр бик тиз тарала иде.

Кайгыга төшкән Мәскәү кенәзе яшь тулы күзе белән новгородлыларга үзен дошманга каршы һөҗүмгә күтәрерлек көче югын әйтте, кичерүләрен сорады.

Яраткан хатынының үлеме аны аяктан екты.

— Без тиздән аларга икенче төрле җәза бирербез. Бернинди гаебе булмаган хатын-кызларны агулап үтерүче ерткычның озак яшисе калмады, — дип Юрий үзенең хөкемен чыгарды һәм Каугадыя белән Урдага юнәлде.

Үзбәк тәмам ярсыды, ул Каугадыяны җәзаларга теләде, әмма Котлыгъ Тимер аны бу фикереннән кире кайтарды.

— Ашыкма, ханым. Әмирне җәзаларга өлгерерсең.

Хан килеште, әмма җаны эремәде, ярты айлап, сеңлесе өчен кайгырып һәм Михаил Ярославовичның мәкерлелегенә нәфрәтләнеп, йөзе кара көеп йөрде.

— Ул шакалны минем янга китерегез! Минем янга! Теләми икән, шунда ук башын кисеп алыгыз һәм барлык урыс кенәзлекләре буйлап сабак өчен күрсәтеп чыгыгыз.

Кенәз Михаил Ярославович Урдага үзе килде, ул әле Үзбәкнең аны аңлавына, Кончакны башка берәү агулаганын исбатлап күрсәтә алырына ышана иде.

Итилнең аскы агымында язын даланың яшәргән мәле, аллы-гөлле чәчкәләрдән бөркелгән хуш исләр бергә кушыла да һавага тарала, күкрәк тутырып сулыйсы килә. Кошларның матур итеп сайравы, дала өстеннән берөзлексез чыркылдашып очып йөрүләре колак һәм күзне иркәли. Бөтен тирә-юнь кешегә: күр, тормыш шундый гүзәл, яшә, шатлан дип әйтә шикелле! Тик Михаил Тверскийның күзенә берни күренмәде. Аның белән беркем аралашмады. Аннан хәтта кайчандыр үзе дус санаган, зур бүләкләр белән сөендергән нойоннары да читләштеләр. Очрашу турындагы үтенечләренә Котлыгъ Тимер җавап бирмәде, ханга әлегү өчен башка төрле юл юк иде.

Үзбәк бу вакытка бераз суынган иде инде һәм Михаилны үзе хөкем итмәскә булды, аның күңелендә нинди дер шикләнү бар иде, торган саен, монда нинди дер мәкер барлыгын йөрәге белән тоеп, Юрийдан күңеле кайтканнан кайта барды. Берникадәр уйланганнан соң, хан иң яхшылардан саналган ун әмирен җыярга боерды, алар каршында үзе нотык сөйләде.

— Сез барыгыз да минем ышанычлы хезмәтчеләрем, үз җирләрегездә үрнәк башлыклар, кешеләрнең ни-нәрсәгә мохтаҗлыгы һәм аларның теләкләре белән таныш. Сез ханыгыз һәм дәүләт өчен ясакны ничек җыярга кирәклеген беләсез. Ике кеше арасындагы бәхәсне хәл итә аласыз, гаепсезне акларга һәм канун бозганын хөкем итәргә акылыгыз җитәр. Шулай итеп, ике урыс кенәзе — Юрий Московский һәм Михаил Тверскийга хөкем карары чыгарыгыз. Сез ничек әйтәсез — шулай булыр. Кемне гаепсез дип тапканын ярлыкармын, гаеплесенә җәза бирермен. Бөек һәм зирәк, барын да белүче һәм мәрхәмәтле Аллаһ сезнең белән булсын.

Әмирләр үзләренә нинди җаваплылык төшкәнен аңладылар һәм ялгышлык җибәрүдән курыктылар. Нишләргә? Билгеле инде, бәкләр бәге янына киңәшкә юнәлделәр.

Котлыгъ Тимернең ханнан башка беркайчан, беркемгә турыдан-туры әйткәне булмады.

— Сезгә нишләргә кирәген мин үзем дә белмим. Хан хөкем итәргә сезгә

кушкан, шулай булгач үтәгез. Тик кенәз Михаилның алманнар белән бергә безгә каршы сөйләшүләр алып барганы турындагы хәбәрләрне ничек таратырга мөмкин? Әйтегез, хөрмәтлеләрем, сезнең берәрегез хәтта яшертен генә булса да хан илчесенә каршы көрәшә аламы? Ә кенәз Тверский ачыктан-ачык Каугадыйга гына түгел, хан илчесенә, хакимнең киявенә дә каршы һөҗүмгә барды. Сез хөкем иткәндә кенәз Юрийны тыңлагыз. Аның дошманы Урдага күпме ясакны китереп житкермәве турында әйтеп бирер. Мин сезгә кинәшче түгел, үзегез хөкем итегез. Хан бит сезгә кушты, сез ничек әйтәсез, ул шулай эшләр.

Хөкем тиз генә булмады, әмирләр бик озаклап барысын да бизмәнгә салып үлчәделәр, тик барыбер Михаил Ярославовичны гаепле дип таптылар. Аңа агач богау салдылар. Берәр ай тирәсе сакчылар аны мыскыл иттеләр, ярым ач тоттылар, кыйнадылар. Әмма бу жирдә бер нәрсә дә: шатлык та, кайгы да мәңгелек була алмый. Бер төнне Юрий белән Каугадыя кешеләре килеп, Тверь кенәзен үтерделәр.

Үзбәк аның мәетен Тверьга алып китәргә рөхсәт бирде. Ул әле дә дөрес эшләвенә шикләнә иде. Юрий Данилович үзеннән канәгать калып, урыс жиренә әйләнеп кайтты. Бөек кенәз урынына утырды, үзенең туганы Афанасийны Новгородка билгеләде һәм, иркенләп, Мәскәү кенәзлегенә кушарга теләгән Коломнага яу чабу нияте турында уйланырга керешге.

***

Яңа Сарай үскәннән-үсә барды. Әкрен генә яуган жәйге яңгырдан соң чыккан гөмбәләр шикелле, өйләр баш төртте. Каналлар буйлап кала аша су акты һәм техник хажәтләр өчен кулланылды, пычрак суларны үзе белән алып китеп Сарайчык тамагындагы зур буаларга бушатты, анда бар шакшы төпкә утырып, дала елгасының әкрен агымы буа өстендәге чистарган суны Актүбәгә алып китте. Калада тимерче алачыклары бик күп иде. Бик зур тимерче учакларына һава өрдереп, корыч эреттеләр. Менә дигән корал һәм сугыш киемнәре чүкеп ясадылар, осталар йорт кирәк-яраклары, металл бизәнү әйберләре эшләргә дә өлгерде. Пыяла өрүчеләр таң калдыргыч нәрсәләр ижат итте. Бай йортларда төрле төстәге тәрәзәләр балкыды, бүлмәләрне вазалар, шәмдәлләр, мозаика, керамик савыт-саба бизәде. Төзүчеләр һәм бизәк төшерүчеләрнең дә эшләре мактауга лаек, алар биналарны Хәрәзм, Византия, Идел Болгары һәм Кавказ артының төрле нәфис үзенчәлекле алымнарын берләштереп, ачык-кызыл һәм карага алмашка яңа төсләр бирделәр. Йортларның аксыл-яшел, аксыл-зәңгәр диварлары күзләрне сөендерде.

Алтын Урда түрәләре үзләренең торакларын бизәр өчен акчаларын кызганмады. Кала яши, зур кәрван-сарайларга дөньяның бар читеннән сәүдәгәрләр агылды. Алар сату-алу әйберләре алып килеп кенә калмады, Яңа Сарай, андагы халык һәм аларның зирәк ханының данын еракларга таратты.

Үзбәк хан 1319-1320 еллар кышын яңа сараенда чыгарга карар кылды. Көзен аның күпсанлы гаиләсе үзләре өчен үтә зур урынга, бик әйбәт жылытылган бүлмә һәм залларга ияләнә башлады. Хан кызлары бала караучылар белән әйлән-бәйлән уйнады, сарай осталары ясаган балчык һәм агач уенчыклар белән мәш килде. Үсмерләр – Тәнбәк белән Жанбәк махсус залда кылыч сугышлары, көрәш оештырды. Зиннәтле яңа сарай жанланды, кыйммәтле фарсы келәмнәре һәм кытай ефәгенә төренде, анда тынычлык һәм татулык иде.

Үзбәк кенә борчулы йөрде. Хәрәзм белән Мисырдан ханны, аның тәхеткә утырыр алдыннан биргән вәгъдәләрен үтәмәүдә битәрләгән хатлар килде. Аның ислам динен кабул итүдә әкрен кыймылдавын гаепләгәннәр. Котлыгъ Тимер

да исламлаштыруның әкренәюе турында ханга һәрвакыт әйтә килде. Тай-туглы исә ашыкмаска киңәш итте.

«Ник ашыкмаска? – дип уйлады Үзбәк. – Яңа Сарай төзелеше зур тизлек белән бара, анда инде өч мәчет ачылды. Минем кардәшләрем – чыңгызыйлар, менә кемнәр аяк чала. Алар – исламның төп дошманнары. Мин аларны үгетләп күндергән арада Мисыр солтаны белән Иран илханы берләшеп, ирексезләп ислам урнаштыра калсалар – аяныч булыр. Юк! Үзем эшләсәм – яхшырак!»

Кичен Тай-туглы, Мисырдан килгән хатта нәрсә язулары белән кызыксынгач, ул аңа кычкырды:

– Син кайчан ирләр эшенә тыкшынудан туктыйсың?

Тай-туглы дәшмәде.

– Кайчан борыныңны һәр тишеккә тыгудан туктыйсың? Кайчан мине өйрәтүдән туктыйсың? Күз алдымнан югал, күрәсем дә килми сине.

Тай-туглы иренең ачуы чыкканда карышып торуда мәгънә юклыгын белә иде. Үз-үзеннән канәгать булмыйча, ул иренең йокы бүлмәсеннән чыгып, хәрәмгә юнәлде. Зирәк хатын ханнан диндәшләре нәрсә таләп иткәннәренә төшенде, күңелендәге бу давылдан соң аның ничек хәл итәсен белә иде.

Иртән хан Урданың иң абруйлы утыз кардәш-чыңгызыйны үз янына чакыртырга әмер бирде. Ике көннән алар күндәм генә килеп беттеләр. Үзбәк озаклап аларга исламның өстенлеге, дин аша дәүләтне ныгытырга кирәклеге турында сөйләде, мөселманнарның Аллаһка тугры булуларын, беркайчан да үзләренең хуҗаларына каршы фетнә күтәрмәячәкләрен әйтте. Хаким озаграк сөйләгән саен, җыелганнарның йөзе кара көя барды. Залда киеренкелек урнашты. Үзбәк кардәшләренә күз салды һәм алар арасында бер генә фикердәше дә булмавын аңлады. Бар да караңгы чырайлы иде. Хан үзенең озын нотыгын тәмамлагач, Бату хан нәселенең Үгәдәй атлы абруйлы кешесе торып, барысы өчен дә җавап бирде:

– Син бездән күндәмлек һәм буйсынучанлык көтә аласың, безнең нинди дин тотуыбызда исә синең ни эшең бар? Без ни өчен Чыңгызхан ясасыннан баш тартырга һәм гарәпләрнең диненә күчәргә тиеш?

Үзбәк андый җавап көтмәгән иде. Ул җыелганнар алдыннан әрле-бирле йөренеп, уйга батты, тыналышның озаккарак китүен чамалагач:

– Мине аңламадыгыз, ахры. Сезгә уйланыр өчен вакыт бирәм. Кайтыгыз һәм хәл итегез, – диде.

Туган-тумачалары сөйләшми генә сарайдан чыктылар. Үзбәк Котлыгъ Тимерне туктатты һәм каты гына боерды:

– Үгәдәй йортына кайтып җитмәскә тиеш.

Бәкләр бәгенә аңлатып торасы юк иде.

Икенче көнне ханга Үгәдәйнең башын китереп күрсәттеләр. Хаким төкерде дә читкә атлады, аннары:

– Каугадыяны минем янга! – дип әмер бирде.

Ханның элеккеге ышанычлы кешесе тәхет залына тезләре белән шуышып керде. Тәхет каршында башын әз генә күтәреп:

– Әй кодрәтле һәм мәрхәмәтле Аллаһ, безнең бөек һәм рәхимле ханыбызның гомерен озайтуыңны сорыйм. Әйбәт еллар гына җибәр, хатыннарының һәм балаларының сәламәтлеген сакла, байлыгын арттыр! Әй Аллаһ, Тәңребез безнең, кичер мине, әгәр ханымның гөрләп алга баруы өчен кирәк икән, җанымны ал.

– Төзәлер өчен сиңа мөмкинлек бирәм. Үгәдәйдән калган бар нәрсәне ал, Иске Сарайга чап, бу шакалның башын минем ырудашларым Борһан белән Хәйдәргә күрсәт. Кире уйламаганнармы – сора. Әгәр кире уйламаган булсалар, агач богау кидереп минем янга алып кил.

Монарчы берәүнен дә Алтын Урда ханын шундый явыз итеп күргәне булмады. Ул хәтта бәкләр бәге белән дә сөйләшмәде, төнгә хатыннарын да чакырмады, сарай буенча шәүлә кебек йөрде һәм, күзеннән очкын чәчеп әмерләр бирде. Котлыгъ Тимер мондый дәһшәтле карашны кайда күрүен исенә төшерде. Хан: «Менә шулай аларны да кырачакмын! Хайваннар кебек чаптырам да тураклыйм!» — дип, кыр кәҗәләрен кырганда күрде ул бу явыз карашны. «Вакыт житте, — дип уйлады бәкләр бәге. — Хан үз өстенә шундый зур гөнаһ алырга тиеш түгел. Мина да кушылырга вакыт, минем тамырларда да Чынгызхан каны ага бит».

Кулай вакытны туры китереп, Үзбәктән сорады:

— Бәлки мина да имансызларга каршы көрәшкә кушылыргадыр?

— Күптән вакыт. Синдә Чынгызхан каны акканга, безнең кардәш-ыруларны үтерергә хокук бирәм. Әгәр безнең ата-баба хәзер яшәсә, алар да безнеңчә эшләрләр иде, дип уйлыйм. Тормыш алга бара, Күк-Тәңрегә ышану тәмам булды. Без дә бабабыз өйрәткәнчә эш итәрбез — каршы төшкәннәрнең — кем арба тәгәрмәченнән биегрәк — барысын да гаиләсе белән юк итәбез. Булды, түземлек бетте, вәзирем!

Язга Чынгызхан нәселенең йөз егерме гаиләсе үтерелде. Аларны бар җирдә: күчмә тукталышларда, ханнын кансызлыгыннан котылырга теләп, качып барган чакта — һәркайда юк иттеләр. Нигездә Котлыгъ Тимер үтерде, әмма берничә кардәшен Үзбәк үзе дә чәнечте. Ир туганнар бөек ыру башлыгының изге канунын сакладылар: кол ни патшаның, ни патша улларының, ни туганнарының гомерен өзәргә тиеш түгел. Бу кешеләрнең канын бары тик чыңгызыйлар гына коя ала. Түрәләрнең каны бөтен дәүләт буйлап инеш булып акты. Талгын жил дала үләнен әз генә селкетеп узган кебек, Урда пышылдады, кыштырдады һәм тавыш-гауга күтәрми тынды.

Мәчетләр Аллаһка якынаерга теләүчеләр белән тула башлады, әмма кичләрен, күчеп йөргәндә, күпләр яшертен генә Буддага табынуларын дәвам итте. Яшеренгән шаманнарны табып, алар белән борынгы йолаларны үтәделәр. Ата-бабадан килгән бәйрәм һәм йолаларны үтәп, халык нигездә ике дин тотты.

Теләр-теләмәс кенә исламга күчкәннәрнең балалары соңрак чын күнелдән мөселманнарга әйләнделәр. Ә ул чакта, ундүртенче гасырнын егерменче елында, гаять зур дәүләтнең ханы аптырашта һәм кайгыда иде. Төннәрен төшендә анын янына үтерелгән кардәшләре канлы киемнәрдән килделәр һәм анын жанын көйдереп, сагышлы күзләрен төбәделәр. Үзбәк бер уянгач, кабат йоклый алмады. Аллагы төндә дә, шул ук төшләр кабатланыр дип, күзен йомарга курыкты. Бары анын тугры һәм сөекле хатыны Тай-туглы гына анын арганлыгын һәм дәһшәтне бетерә ала иде. Кулын иренең башына якын китерүгә, кара көч каядыр очып китә, ул башын хатынынын күкрәгенә салып, яшь бала кебек тирән йокыга чума. Тик иртәгесен ханнын башына яңадан-яңа бәла-каза ябырыла. Византия императоры Андроник IIнең хаты кәефен кырды, ул хатында Үзбәкне бик күп төрле гөнаһларда, бигрәк тә, гыйсавилары да булган илне көчләп исламлаштыруда гаепләгән. Император Баялунны үзеннән этәреп, бабасына кияүгә бирү өчен битәрләгән. Андроник, нечкәләп тормаган, нинди генә матур сүзләр белән зурламаган ханны. Ә хат азагында аны канэчкеч дип атаган һәм Алтын Урда белән барлык мөнәсәбәтләрне өзүен хәбәр иткән. Ханнын ачуы бугазына менде, ул аякларын тибеп акырды:

— Бу ангырайган карт сарык бабамның хатыны, аннары үги анам, анамнын ахирәте булган карчык белән йоклый алмавымны анламый!

Котлыгъ Тимер дәшми, таш кебек катып калган йөз белән, башка кичерешләр уятмаска тырышып, ханны тыңлады.

— Безнең диндә ни катнашы бар анын? — дип дәвам итте Үзбәк. — Ул нәрсә,

чиркәүнең бездә нинди өстенлекләрдән файдалануын белми мәллә? Төрекләр белеп кыйныйлар аны! Бу борынгы императорның бәхетсез кыйпылчыгы хәтта, үзенә госманлылар белән көрәштә булышыр өчен килгән каталон сугышчылары белән дә низагка керде. Ялланган гаскәриләрне үзеннең дошманың ясау бернинди киртәләргә сыймый... Менә нәрсә, зиһенле бәкләр бәгем, гаскәр тупла, башлык итеп ир туганыбыз Сарай-Тимерне куй, Фракиягә барып, карт ишәкнең бераз тынычлыгын какшатсыннар.

— Кызып китмәденме, ханым? Әйбәтләп уйладыңмы, хакимем?

— Бик яхшылап уйладым. Үзең анла: бу карт алаша безгә нинди хат җибәргән, димәк, бу турыда үзе генә түгел, ә аның тирәсендәгеләр дә белә дигән сүз. Аларның бит яртысы төрек юлбашчыларыннан акча ала. Төрекләр белгән икән инде, Мисырның солтаны да, Иранның илханы да һәм бар мөселман дөньясы хәбәрдәр, димәк. Безнең диндәшләр Үзбәк хан ни әйтер дип көтәләр: бәлки ул төкереген йотар да дәшмәс? Юк! Үзбәк әйтәчәк, әле ничек кенә! Минем сугышчылар Фракияне кырырга тиеш, шуннан күршеләре Үзбәкне мыскыл итәргә ярамаганын белерләр. Ата-бабалары кебек ул да дошманның башын чаба ала. Ә күршеләр: лаеклы мөселман, чын иманлы, гыйсавиларга каршы көрәшә диярләр. Сугышчыларга да тузаннарын коеп кайтырга вакыт, алайса тирмәләреннән ерак киткәннәре юк. Ничек яу чабарга икәнен онытырлар. Яхшы ганимәтләр дә комачауламас, калаларны төзү өчен акча су урынына ага. Нәрсә дисең, вәзирем?

— Җавап биреп торасы да юк. Син хаклы! Атлыларга күптән дала буйлап чаптырып, саф һава суларга вакыт, берьюлы кан исен дә исләренә төшерерләр.

— Иртәгә үк Үргәнечкә Сарай-Тимерне чакыртырга атчабар җибәр, Хәрәзмгә туганыбыз урынына кемне әмир итеп куярга икәнлеген дә уйла. Мин дә улым Тимербәккә хәбәр итәргә атчабар юллыйм, ана да эшләргә катнашырга вакыт, унсигезенче яше китте, ә аның һаман бабасы түбәсе астыннан башын чыгарганы юк. Фракиягә яу чабу егет өчен тәҗрибә туплау булыр.

Яңа Сарайда Тимербәкне тантаналы рәвештә каршы алырга әзерләнделәр. Актүбәне кичеп чыгу өчен аның иң тар җирендә балта осталары агач күпер салдылар. Үзбәк гаиләсе һәм яраннары белән варисны сул ярда зур чатырда көттеләр. Ниһаять, яшь ханның аты, тояклары белән тукылдап, күпер өстенә килеп керде. Атасы якынлашып килгән улына карады, күңелен шатлык биләп алды. Ана таба, чиркәс киемендә, буй-сынын төз тотып, атын көчле кулы белән иярләгән җайдак килә иде. Ул якынлашкан саен, ханның йөрәге ешрак типте. Үзбәк үзенең Кавказдан кайтуын исенә төшерде. Улы ике тамчы су кебек үзенә охшаган иде. Ләйләнең ике бите буйлап яшь ага, күзе бәхеттән ялтырый. Бу бит аның улы!

Бу — аның улы! Ул ничек үскән, көче ташып тора.

Тимербәк атыннан сикереп төште, йөгәнне хезмәтчегә тоттырды, җитди генә ашыкмыйча чатыр янына килде һәм тез чүкте:

— Сәлам юллыйм сиңа, бөек ханым, Аллаһ синең көннәреңне озайтсын. Үз яныңа чакырып алганың өчен мин бик бәхетле, әй яхшылардан-яхшы атам, зирәкләрдән-зирәк хакимем. Мин сиңа улың буларак та, хезмәтчең буларак та чын күңелдән бирелгәнлегемне исбатларга әзер. Минем ниятләрем чиста, Аллаһы Тәгалә күрә! Үземнең илем өчен, атам һәм анам өчен, мәрхәмәтле һәм гадел Аллаһ сакласын аны, теләсә нинди сынауларга, теләсә нинди хезмәткә әзермен.

Үзбәк үзен Туктай ничек каршы алганын исенә төшерде. Басты, улы янына килде, күтәреп алды да кочаклады. Җыелышканнар куаныштылар.

Мәҗлес бар кеше өчен әзерләнде. Халык өчен — урамнарда, түрәләр исә хан сараеның ишегалдына җыелды. Икенче көнне Нәдам бәйрәме үткәрделәр. Тимербәк

сынаулар сораган иде, атасы аны канәгатьләндерде. Ханнын тизрәк улының Елбаздук бабасы өйрәткәннәрне яхшы үзләштергәнме икәнен тикшерәсе килде.

Тимербәк атасын унайсыз хәлгә куймады, ул яхшы укчы, чын егет һәм көрәшче, бөек һәм гадел Аллаһка дан.

Бәйрәмнәр үтте, Фракиягә китәр вакыт җитте. Алтын Урда карт императорга җавап сүзен әйтергә тиеш. Ләйлә, улының китәсен ишеткәч, бик каты елады, һәм унай вакытны туры китереп, яшь тулы күзе белән иреннән сорады:

— Тимербәкне яуга җибәрергә иртәрәк түгелме?

— Күзенне сөрт, хатын! Син бәлки аңа күкрәк сөте имезергә җыенасыңдыр? Бәлки итәгең астына качырырсың? Аллаһ синнән матурлыкны җәлләмәгән, ә менә акылны...Үзең дә улыңның нинди сугышчы икәнен күрдең, андыйлар бик аз. Сугышта ул берүзе унга каршы торырлык. Тимербәк — минем варисым, аңа гаскәрне сугышка алып керергә һәм аз югалтулар белән җиңәргә өйрәнү зарур. Ә син аны шуңа өйрәтә аласыңмы? Мин булмам, моның белән кем шөгыльләнер? Билгеле, ул — варис.

Ире соңгы сүзләрне әйткәндә, Ләйләнең яше кипкән иде инде, йөзенә ягымлы елмаю таралды. Аңа карап, Үзбәк: «Юкка Ләйләне акылсыз дип атадым. Әх, хәйләкәр дә соң бу хатын-кыз! Әх, хәйләкәр!» — дип уйлады.

Гаскәр кузгалыр алдыннан хан яу сәфәре белән җитәкчелек итүче Сарай-Тимергә ахыргы киңәшләрен бирде:

— Урданың көньяк төмәннәреннән сезгә тагын биш мең сугышчы кушылыр. Шунда ук сезне азык-төлек белән тәэмин итәрләр. Болгар патшалыгы җирлегендә сугышка кермәгез. Әгәр мәҗбүр булсагыз, бик каты кырмагыз, ә менә Фракияне шәп итеп чистартырга кирәк, аннан шактый табыш көтәм. Аз гына туктап торганнан соң Үзбәк туганыннан:

— Тимербәкне хәзергә йөз башы итеп куярсың, — дип сорады. — Алга таба карарбыз. Җитәкчелек итәргә өйрәт аны һәм улымны сакла.

***

Тимербәк янында булганда, бәйрәм иткәндә ханның күңеле күтәренке булды. Барлык шик-шөбһәләрдән котылган сыман иде. Әмма гаскәр Фракиягә китеп, ике көн узгач, Үзбәк төшендә үзе тарафыннан үтерелгән Таз нойонны күрде. Ул канлы-кызыл күзләре белән аңа төбәлеп:

— Тагын кеше үтерергә яу чыктыңмы? Каһәр суккан үтерүче! — дип кычкырды.

Өстәвенә, Таз имән бармагы белән Үзбәкнең күзенә төртте. Хан уң күзе авыртудан уянып китте һәм авыртуы иртәнгә кадәр узмады. «Эт этлеген эшли, — дип уйлады хаким. — Анда да тыныч кына ятмый!»

Шул вакыттан Үзбәкне куркыныч төшләр һәр төнне диярлек бимазалады. Аның янына әле Таз, әле Төнгүз, әле Үгәдәй килде. Хан инде ятакка ятарга курыкты, ябыкты, агарды, һәр кыштырдау тавышы ишетелгән саен кылыч сабына ябышты. Хан тирәсендәгеләр бар да авыр сулады, аһ-ваһ килде, әмма дәшмәде. Аның тугры һәм тәвәккәл хатыны Тай-туглы түзмәде — эшкә керешге. Үзбәк үзе дә бары тик аңа гына ышанды, аның алдында гына ачылып сөйли ала иде. Тик хатынына тәүбә кылган өчен Алла гөнаһларны кичерми, шуңа Тай-туглы болай дип тәкъдим итте:

— Әйдәле, ханым, чиркәүгә барабыз, тәүбә кылырсың, рухани белән бергә гыйбадәт кылырбыз, аннары күрерсең — Алла синең гөнаһларыңны кичерер.

— Юк, чиркәүгә бармыйм! Аллаһ нәрсә уйлар? Кешеләр ни дияр? Юк, юк һәм юк!

Атна үтте, икенчесе, Үзбәкнең хәле яхшырмады. Якыннары яшертен генә

пыш-пыш килде, әмма, сарай диварларнын да колаклары барлыгы билгеле. Котлыгъ Тимер ин күп такылдаган ике гайбәтченең телләрен кисәргә боерды.

Тай-туглы чигенергә җыенмады, ана ирен, димәк, уларын да коткарып калырга кирәк иде. Алла сакласын, Үзбәк белән бер-бер хәл булса, Тимербәк үзенең көндәшләрен аяп тормас.

— Чиркәүгә барасын килмәсә, әйдә, дала буйлап ераккарак китәбез, шаман табарбыз, ул сине дәвалар. Һәм бу турыда беркем белмәс.

— Кайдан табасын ул шаманны? Минем әмер буенча аларнын барысын да юк иттеләр. Могҗиза булып, берәрсе исән калган булса да бик ышанычлы итеп яшеренгәндер.

— Табам, табам мин сина шаманны. Урдада булмаса, Күк-Тәнрегә кеше җибәрәм, син генә риза бул.

Үзбәк дәшмәде. Хатыны аны аңлады һәм иртәгесен иртүк үзенең ышанычлы кешеләрен шаман эзләргә җибәрде.

Ике ай үтте дә китте, тик бер генә атчабар да әйләнеп кайтмады. Хан дәүләт эшләреннән бөтенләй читләште, барысы белән дә Котлыгъ Тимер шөгыльләнде. Якыннары ханны бары мәчетләрдә генә очраттылар, анда ул бик тырышып Аллаһка дога кылды. Төннәрен анын янында Тай-туглы гына булды, ул, кара көчнең берникадәрен үзенә алып, ханны тынычландырырга тырышты.

Яхшы хәбәрләр гадәттә көтмәгәндә килә. Ниһаять, Тай-туглынын бер кешесе шаман табуы, тик анын хатын-кыз булуы һәм тәҗрибәсе дә җитеп бетмәве турында әйтте. Ул ханны дәвалап карарга ышандырган һәм Богдо изге тавы янына килергә кушкан.

Дәвалауны озакка сузарга ярамый иде. Тай-туглы барысы турында да Котлыгъ Тимергә сөйләп бирде. Ул Үзбәкне, көзге дала изрәгән булуга карамастан, Мөхәммәд хаҗи белән күченергә үгетләде. Беркадәр тынычланган Тай-туглы үзенең атчабарыннан:

— Шаман хатын изге тауга юлга чыктымы инде? — дип кызыксынды.

— Юк, ханбикә, ул төңгер[8] әзерли.

— Төңгерсез нинди шаман ул, ник ышандың аңа? — дип ачуланды ханбикә.

— Җәза бирергә кушмагыз, әй ханыбызның матурлардан матур хатыны. Мин сезгә бу шаман хатынның тарихы турында сөйлим, шунда барысын да аңларсыз. Безнең җирләрдә шаманнарны юк иткәндә, алар арасында анын атасы да булган. Атасы башына болан мөгезле башлык киеп йөргән. Андый башлыкка бары тик иң яхшылар һәм тәҗрибәлеләр генә лаек булганнар. Әмма аны тотканнар да үтергәннәр. Ярты ел чамалы вакыт узгач, төшендә кызы янына рухлар, әрвахлар килә башлаган һәм алар хатынга шаман итеп билгеләнүе турында хәбәр җиткергәннәр. Бу ханнарнын хезмәтчеләре эзәрлекләвеннән курыккан, үзенең дә шаман буласы килмәгән. Көннәрдән бер көнне әрвахлар төшендә тагын килеп, әгәр сүзләрен тыңламаса, абыйсы үләчәк дип кисәткәннәр. Ул тыңламаган һәм анын абыйсы үлгән. Рух тагын килгән һәм колагына пышылдаган: «Аңладыңмы инде? Әгәр шаман булырга теләмәсән, өч көннән сине бүреләр бугазлар».

Шуннан соң гына ул күнәргә мәҗбүр булган. Чынбарлык белән арасы өзелгән, җаны икенче дөньяга күчкән, анда ул атасы белән очрашкан һәм ул да кызы янына килеп йөргән.

— Шуннан, нәрсә, атасыннан аңа төңгер дә калмаганмыни?

— Әй, ханбикә, шаманнарга башка шаманнарнын әйберләрен кулланырга рөхсәт ителми. Һәркем үзенекен булдырырга тиеш. Хатын инде төңгер эшләгән,

[8] Күн тартылган һәм кырыйларына шөлдерләр, вак калайлар беркетелгән кыршаудан торган бәрмә музыка коралы

хәзер ул аны ясар өчен киселгән агачны һәм тиресе ана тарттырылган хайванны терелтә. Аннары ул болар белән сөйләшәчәк һәм алардан кешеләр һәм рухлар дөньясына хезмәт итү өчен ризалык сораячак.

— Син барысын да белешкәнсең. Мине ышандырырлык итеп сөйләдең. Мактыйм сине, тугры хезмәтчем, шаманга дигән акчаны үзеңә алырсың, аны мин аерым бүләкләрмен. Хәзер исә аның янына бар, ул әзер булуга, Богдо тавына алып килерсең. Без сезне шунда көтәрбез.

Гаҗәеп тау бу Богдо! Ул ярым буш далада япа-ялгызы Баскынчак күле янында басып тора; бер як итәгенә күлнең суы чупылдап чәчрәсә, икенче ягыннан коры сыза кисә, ташлары канга буялган кебек кып-кызыл, кыяташ кебек калкып тора. Тау бите дала һәм сахра үсемлекләре белән капланган. Бик көчле жил вакытында да тау янында тыныч була, Алла саклый, ахрысы, күлнең ак тозы монда усал рухларга яшәргә ирек бирми. Тоз үзенең аклыгы белән жирне, тауны, һаваны чистарта һәм туендыра, шуңа монда сулавы жиңел, рәхәт, күкрәккә бетмәс-төкәнмәс көч тула, яралар күз алдында төзәлә, төннәрен исә күктән йолдызлар коела һәм иксез-чиксез далага чәчелә.

Шаман озак көттермәде. Берничә көннән ханбикәнең атчабары аны хан тирмәсенә алып китереп житкерде. Башында тасма да кулында төңгер — менә шулар аны галәти дала хатынынннан аерып тора иде. Ул хан алдына килеп тезләнде һәм башын түбән иде.

— Син түгел, мин сина баш иярга тиешмен, — диде Үзбәк. — Торып бас һәм үз эшенне башла.

— Башлыйм, бөек хан, тик монда түгел.

Шаман ханны әйләндереп алган ирләргә күз йөртеп чыкты, аннары карашын учактан читтәрәк утырган хатын-кызларга күчерде һәм Тай-туглыга әйтте:

— Без хан белән мәгарәгә керәбез, син безнең белән барырсың. Башка кеше кермәсен.

Алар караңгы тау куышы эченә үттеләр. Үзбәк белән Тай-туглыны идәнгә утыртып, шаман йоланы башлады. Төңгер әле бик каты тавыш чыгарды, әле ишетелер-ишетмәскә әйләнде. Аның ритмы да бер кызулады, бер әкренәйде. Аннары, тау куышында көчәеп, тагын дөмбердәде, жирдә тәнен калдырып, жанын икенче дөньяга алып китте. Тай-туглы төштәге сыман иренең һушсыз калуын күрде, Үзбәкнең күзе әйләнде, ул берни ишетмәде, күрмәде, әмма сулышы тигез һәм тыныч иде. Бераздан тау куышы рәхәт зәңгәр яктылык белән тулды. Яктылык шаман хатыннан, аның тәненнән, киеменнән, төңгердән тарала иде, ул йола биюен никадәр дәрт белән тырышып башкарса, яктылык та шулкадәр яктырак була барды. Хатын кемгәдер кычкырды, кемгәдер урынын төртеп күрсәтте, кемнәндер шыпырт кына сорады һәм кабат төңгер гөрселдәве астында әйләнеп кызулаганнан кызулана барды.

Кинәт бар да тынып калды. Тай-туглы күпме вакыт үткәнен, хәзер төнме, әллә көнме икәнен аңлый алмады. Алар шаман белән икәүләп Үзбәкне култыкладылар. Ул күзен йомган килеш, һәр ташны жиңел генә әйләнеп, алга атлады.

Өч көн һәм өч төн хан ашамый-эчми йоклады да йоклады. Шаман аннан күзен дә алмый янында утырды. Алтын Урданың ханы күзен ачкач, хатын торды, төңгерен алды һәм бер сүз әйтми тирмәдән чыкты. Тай-туглы аның артыннан атылды:

— Аның хәле яхшырырмы?

— Әгәр ул бер гаепсез кешеләрне икенче дөньяга озатудан туктаса, бар да әйбәт булыр.

Тай-туглы шаманның кулына күн акча савыты белән көмеш сонды.

— Акчанны кире ал, ханбикә. Мин хан өчен рухларга жанымны куйдым,

алардан акча белән генә котылып булмый. Атамны үтергән кебек, минем дә гомеремне өзмәгез.

Хатын-кызларга хас булмаганча шаман житез генә ияргә сикереп менде дә дала буйлап төн эченә кереп югалды.

Икенче көнне Үзбәк Яна Сарайга таба кузгалырга боерды. Ул Котлыгъ Тимерне очрашуга чакырды. Дәүләт эшләре көттергәнне яратмый иде.

Тай-туглы сихердән озак арынды, аннары иреннән ата-бабаларның һәм исламның элек-электән килгән бәйрәмнәрен янарту өчен исән калган лама һәм шаманнарны куылган жирләренә кире кайтаруны сорарга булды. Хан ризалашты. Аның трансга булган чакта күргәннәре һәм ишеткәннәре турында беркем беркайчан белә алмас. Анысы гына аз, бәкләр бәге белән сөйләшүләрнең берсендә, ул болай диде:

— Безгә дә зирәк шәрык патшаларындагы кебек Диван булдыру гадәтен кертергә кирәк. Бар кеше өчен бер хан гына уйларга, аннары барысы өчен дә жавап тотарга тиеш түгел бит инде.

Хәзердән башлап, барлык еракта һәм якында торган эшләребезне Диван әгъзалары белән сөйләшеп башкарырбыз. Лаеклы һәм тугры кешеләрне сайлап ал.

***

1322 елда Диван утырышында урыс кенәзләре арасында барган дау, дәгъва, аларның бер-берсе белән тартышуның тукталмавы турындагы мәсьәлә каралды. Бу хәлнең бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән Котлыгъ Тимер чыгыш ясады:

— Юрий Данилович ике ел элек Бөек кенәз булып алгач, Коломнага сәфәр чыкты һәм аны яулап алды. Аның фикере болайрак иде: «Владимирда Бөек кенәз урыны мәңгелек түгел, Михаил Тверскийның уллары аталарының үлеме өчен мине кичермәсләр. Ә мин рәхәттә, муллыкта яшәргә өйрәнгән. Тверьлеләр мине алып ыргытса, зур табышны кайдан алырга? Менә Коломнаны алам, Мәскәү кенәзлегем дә артыр, мин дә баерак яшәрмен».

Мәскәү тарафыннан Коломна яулап алынгач, урыс кенәзләре дәшмәде, без дә әллә ни игътибар бирмәдек: ханның элеккеге кияве, язнасе. Моны күреп, Мәскәү кенәзе Тверьне буйсындыру хакында уйлана, ханга шикаять итәчәге белән куркытып, кенәз Дмитрийны кыса башлады. Дмитрий Юрийга карышып тормады, киресенчә, үзе килеп, Бөек кенәзгә баш иде һәм тугры булачагы турында ант итте. Үзенең сүзләрен раслар өчен Тверь кенәзлегенең Урдага тиешле бар ясагын мәскәүлеләргә тапшырды һәм болай дип әйтте:

— Син, Юрий Данилович, Бөек кенәз, Үзбәк хан алдында бөтен урыс кенәзлекләре өчен сиңа жавап тотарга. Бөтенебездән ясакны да син илтеп бир.

Әмма тверьлеләрнең ат тоягы астыннан күтәрелгән тузан урынына да төшеп утырмый, Юрий ясакны Новгородка, абыйсы Афанасийга илтеп тапшырырга, сәүдәгәрләргә биреп әйләнешкә кертергә һәм тапшырылган акчаларның процентын үзенә бирергә кушкан. Урдага исә ясакны ярты елдан соң гына жибәрергә булган. Дмитрий бу турыда белеп, хан фәрманында әйтелгәнчә, халыкның һәм табышның исәбен алып баручыларга хәбәр иткән.

Диван утырышы бик шау-шулы булды. Бөек жыелышның фикере аерылды: берәүләре ханга урыс кенәзлекләрендә яңадан баскаклар урнаштырырга тәкъдим иттеләр, икенчеләре исә урыс кенәзләрен әмирләргә алыштыру ягына басты, өченчеләре, акылга утырту өчен, урыс жирләренә һөҗүм итү кирәклеге турында әйтте. Үзбәк барысын да игътибар белән тыңлады һәм уйланды. Әмма эчендә кайнаган ачу һәм ярсу аңа бер генә юл күрсәтте: «Урысларның тешләрен санарга кирәк!».

Иртәгесен ул гаскәр башы Әхмәлгә урыс жиренә бик күп сугышчы белән

барып, ясак жыярга әмер бирде. Кемнәр каршы килә — әсирлеккә алырга яки үлем җәзасы бирергә боерды.

Әхмәл ханга ярарга тырышты. Яна гына төзелеп беткән урыс кенәзлекләре кабат ыңгырашты. Суздаль, Муром, Ростов, Владимир җирләре зур бәла-каза күрде. Ярославль исә тулысынча янып бетте.

Үзбәк хан бик озак тынычлана алмады. Ул Юрийны Бөек Мәскәү кенәзлегеннән мәхрүм итүе турында белдерде һәм кыланышлары өчен аны эзләп табып җавапка тартырга кушты. Урдага Дмитрий Тверский чакыртылды һәм ул хан кулыннан бөек кенәзлек ярлыгы алды. Урыс җирләренең яңа идарәчесе хан янында озаклап кунак булмады. Ул ханның якын зур түрәләрен, хатыннарын, балаларын бүләкләр белән күмде һәм Владимирга Бөек кенәз урынын алырга юнәлде. Юл уңаенда Юрийның кече энесе Иван кенәзне очратты, аның хан янына Мәскәү кенәзлеге ярлыгын алырга барып ятышы иде. Алар сөенми, бер-берсенә кинә дә тотмый сөйләште: туганнары бер-берләренә күп явызлык эшләде шул.

Владимир шәһәрен күреп, кенәз Дмитрийнең исе китте. Янгыннан соң бар корылмалар диярлек каралып ята. Бары тик гыйбадәтханәләргә һәм Алтын Капкага кул тидермәгәннәр. Урамда беркем юк. Сугышчыларны күрүгә бар да качу ягын карый, бары тик шәһәр буйлап ачлыктан интеккән этләр генә чабып йөри, алар, бер сыный ипи эләкмәсме дип, монсу гына кенәзнең күзенә текәлгән. Дмитрий әйләнә-тирә урманнарны йөреп чыгып, кешеләрне җыярга һәм аларга, кайтсыннар, урнашсыннар, дип әйтергә боерды. Кенәзләрдән Юрий Даниловичның кайда яшеренгәнен сорашырга кушты. Кем очрата, шул аның кай тарафка юнәлгәнен ачыклап, шунда ук үзенә хәбәр итәргә әмер бирде.

Юрий үзенең ни кылганын — барысын да аңлады һәм нишләргә белми, яраланган куян кебек дала буйлап бәргәләнде. Урдага ярамый — хан башын кистерәчәк, Мәскәүгә дә ярамый — Бөек кенәз шунда ук эләктерәчәк. Яна гына Мәскәү кенәзе булган ир туганы Иван күзенә туры карап:

— Юләр син, Юрка, абыемны шулай дип атаган өчен Алла кичерсен, тик син чынлап та тиле. Син ник дип Бөек кенәзлек өчен сугыштың? Син, бабабыз Александр Невский кебек, үз җиреңне сакларга тиеш идең, ә син исәр баш, яндыруга дучар иттең. Урыс ирләре елыйлар, ханны каргыйлар, ә бит алар сине казыкка утыртырга тиеш иде. Бар, Мәскәүдән олак, Алла сакласын, яңа афәтләр чакырып китерерсең.

Юрий яшерен рәвештә Новгород җирләренә качты һәм аның тавыш-тыны бетте. Тик туганы Афанасийны беразга кенәз урыныннан мәхрүм итте һәм үзе идарә итәргә кереште. Ә нәрсә? Хан моннан еракта, бөек кенәз исә аны Новгородта тота алмаячак, чөнки тверьлеләр үз гомерләрендә шикаять белән маташмадылар.

Бер ел да узмады, Юрий Орешек кирмәнен салды. Новгородта акча бар иде, шәһәрнең яуда катнашканы, бөлгенлеккә төшкәне булмады диярлек. Шведлар үзләренең көньяктагы күршеләренә бик шикләнеп, сак карадылар һәм шуңа күрә ялындырып тормый Юрий белән килешү төзеделәр. Тегесе исә шундук Урданың төньяк чикләреннән куркынычсызлыгын тәэмин итүе турында хәбәр итте. Дмитрий, ачуын эченә йотты, атасын үтергәне һәм Әхмәл сугышчыларын бөлгенлеккә төшерткәне өчен, Юрийдан үч алырга җыенмады.

— Новгородка һөҗүм ясаса, тагын урыс урысны үтерә башлар. Илне аяккка бастырыйк, аннары Юрий турында уйлармын.

Тирә-якта тыныч иде. Юрий Даниловичның күнеле күтәрелеп китте. Ул үзенә тел-теш тидермәсләренә ышанды. Озакламый Устюгка сәфәр чыкты, тагын җирләр яулап һәм акча көрәп алды, Урдага ясак түләүне арттырды

һәм шулай итеп ханның кичерүен көтте. Көтте һәм кул кушырып утырмады. Урдадагы үзенең бөек урындагы дусларын туендыруын дәвам итте, әмирләр һәм шәехләр ханны әкренләп, Юрий яхшы идарәче, шуна аның өстеннән ялган сөйлиләр, кенәзнең булганлыгыннан көнләшәләр, дип ышандырырга тотындылар. Ханнан ул бәхетсезне кичерүен сорадылар.

Үзбәкне ышандыруы кыен булмады. Аның кәефе күтәренке иде. Ел уздың, Сарай-Тимер житәкчелегендәге гаскәр Фракиядән аз югалту һәм мул табыш белән әйләнеп кайтты. Хан улы Тимербәк меңбашы булган иде. Яу сәфәренең беренче көннәреннән үк яшь хан үзен зирәк хәрби житәкче итеп күрсәтте, үзе генә берничә сугыш хәрәкәте алып барды һәм һәркайсында таң калдырып жиңүгә ирешә. Һөҗүм башлар алдыннан ул барысын да: урынның үзенчәлеген, жил юнәлешен, тәүлекнең кайсы вакыты икәнен — барысын да җентекләп бәяләде, оста итеп поскын корды. Сугышчылар үзләренең меңбашына ышандылар һәм һөҗүмгә бары тик җиңәр өчен генә бардылар.

Үзбәк улы белән горурланды, рәсми рәвештә үзенең варисы итеп игълан итте, Диван эшчәнлегендә катнаштыра башлады һәм өйләндерде. Егеткә егерме тулып киткән иде. Кәләшне озаклап сайлап тормадылар. Котлыгъ Тимернең атасы буенча туганнан туган сеңлесе бик чибәр һәм акыллы кыз иде. Шулай итеп хан белән бәкләр бәге тагын бер кат туганлашты.

Юрийдан аерым ясак алганнан соң, Котлыгъ Тимер берчак ханга әйтә куйды:

— Бәлки, без Юрий Даниловичка урынсызга ачуланабыздыр? Бәлки, тәкъдиренә шулай язылгандыр, әмма ул бик тырыша. Күр: Дмитрий ясакны ничек киметте дә, Юрий ничек арттырды. Аңлыйм, бөлгенлеккә төшкән кенәзлекләрдән күп алып булмый, тик ышанам, аның урынында Юрий булса, бу җирләр тизрәк аякка баскан булыр иде.

Менә шулай көн саен Үзбәк Юрий Данилович турында бары мактау гына ишетеп торды һәм ханның күңеле йомшарды.

Озакламый Новгород кенәзенә хат тапшырдылар, анда бары бер генә сүз язылган иде — «Кил».

1325 ел. Юрий Урдага килде.

Аның Актүбәдәге уйсу җирне биләгән утарына кабат җан керде. Мунчалардан һәм аракы куучы биналарыннан төтен күтәрелде, куас һәм ачы бал елга булып акты. Урданың зур түрәләре өчәр-дүртәр көн кунакчыл урыс кенәзендә мәҗлес корып яттылар. Бар да канәгать һәм бәхетле булып таралышты, ханның кабул иткән вакытында бар да мәрхәмәтле һәм акыллы Юрий Даниловичны мактады.

Бер айдан соң Владимирга атчабар килде. Дмитрийны хан чакырткан иде.

Бөек кенәз кәефсез генә юлга чыкты. Ул үз нәселенең мәңгелек көндәшенең инде күптәннән Яңа Сарай янәшәсендә мәҗлес оештырып ятуын белә иде.

Юл авыр булды, ханга дигән бүләкләр белән тулы арбалар көзге даланың лычкылдык пычрагында бара алмыйлар иде. Юлны төннәрен, катыргач, дәвам итәргә туры килде. Урданың яңа башкаласына якынайган саен, Дмитрийның кәефе төшә барды. Юрий тарафыннан атасына ясалган җәберләрне тагын бер кат хәтереннән үткәрде. Мәскәү кенәзе Михаил Ярославовичның мәетен үзенә алды да улларына мәрхүмне сатып алырга тәкъдим итте. Комсыз Юрий бик күп көмеш сорады. Уллары ул сораганның барысын да бирделәр, аталарын Тверьдә бик зурлап күмделәр.

«Бу еланның тынар исәбе юк. Минем турыда ханга тагын ни әйтергә мөмкин ул? — дип уйланды Дмитрий, һәм башында үч алу нияте туды, — кабахәтне үтерергә кирәк!».

Үзбәк хан Бөек кенәзне кабул итәргә ашыкмады. Тегесе дә ялынмады. Үзе

яклылар белән очрашты, дошманнарына бүләк өләште. Әмма ханның аңа ни өчен ачулануын ачыклый алмады. «Бәлки хан мина ачулы түгелдер? Бәлки, Юрийга җәза биргәндә минем монда булуымны теләгәндер. Юк, аның сәбәбе миннән үч алу! Юк!» –дип уйлады Дмитрий, вакыйгаларны күнеленнән берәм-берәм үткәзеп.

Ә инде ханның Юрийны үз янына Бөек кенәзлекнең ярлыгын бирергә чакыртуын белгәч, ныклы карар кабул итте: елан ярлыкка ия була алмас!

Егерме беренче декабрь иртән иртүк Дмитрий Юрийны хан сарае янында көтеп алды. Билгеләнгән вакытка шат йөзле Новгород кенәзе аз санлы яраннары белән килеп җитте һәм атыннан төште. Шулвакыт көтмәгәндә аның каршында Бөек кенәз пәйда булды. Юрий авызын ачарга өлгергәнче, кылычның үткен йөзе аның күкрәген умырткасына кадәр кисеп керде. Новгород кенәзенең сакчылары Дмитрий кешеләре чолгап алганнан соң гына аңына килде. Алар кар өстен кызартып кан сиптергәнен һәм кенәзләренең аягы соңгы кат тартышып алганын күрделәр.

Үзбәк кычкырмады, аяк типмәде. Ул үз янына Котлыгъ Тимерне чакырды, башына кулы белән ябышты да:

— Бу урыслардан бәла-каза көт тә тор! Нәрсә телиләр алар? Нәрсә?

— Без теләгәнне. Хакимият телиләр, — дип, явызланып җавап кайтарды бәкләр бәге.

— Алар мине җир йөзеннән юк итәргә телиләр. Тагын минем йортымда үтереш, тагын кан коеш. Тагын Күк-Тәңренең ачуын китерү. Янә минем башыма кайгы-хәсрәт ишелеп төшәчәк.

— Сон, үтер ул шакшы этне!

— Сабыр ит, ашыкма, монда түгел, хәзер ярамый. Күк-Тәңре ни әйтер, көтик. Бәлки, бөек, барын да күреп торучы Аллаһыбыз да берәр серле ишарә ясар. Көтик!

— Үтерүче белән ни кылмакчы буласың? Җибәрәсеңме?

— Җибәрәм, әмма бөтенләй үк түгел. Ана әйт, Юрийның мәетен алсын да Мәскәүгә илтсен. Үзен генә җибәрмә. Минем туганым Туданның улы Шәүкәлгә житкер, үтерүчене, Литвага каенатасы Гедемин янына качмасын өчен, озата барсын. Мәскәүгә килгәч, анда Дмитрийга кенәз Иван үлем җәзасы бирер яисә мәскәүлеләр ботарлап ташларлар. Үтермәсәләр, Шәүкәл аягына агач богау кидереп, минем аяк астына китереп ыргытыр.

Калита кушаматлы Мәскәү кенәзе Иван Данилович аны үтермәде һәм үтерергә җыенмады да. Яшь кенәз акыллы иде,Үзбәкнең кая борганын анлады. Дмитрийга юкка гына шундый сак куймаган. «Мин Бөек кенәзнең жанын кыям, ә хан минекен. Әгәр Үзбәк Тверь кенәзен юк итәргә теләгән икән – рәхим итсен, үз куллары белән башкарсын. Алла изге, Алла хәл итәр!» – дип уйлады Иван һәм Юрийның җаны тынычлык алсын дип, гыйбадәт кылырга юнәлде.

Үзбәк тә, Аллаһтан киңәш бирүен сорап, догалар укыды. Хәзер ниләр булыр? Күк галимнәрен җыйды. Тегеләр ханга, бик тиздән аның башына берничә кайгы-хәсрәт киләсен әйтергәме-әйтмәскәме дип, озак кына киңәштеләр. Ул барысын да үткәреп җибәрәчәк, алга таба да гомер юлы болытсыз булмас, әмма яшәве җиңеләя төшәчәк.

Кайгы озак көттермәде. Урамда 1326 елның чатнама суыгы иде. Ачы җил кар көртләрен таратып, юлларга сибеп чыкты. Хәтта ин түзем саналган монгол атлары да кар кабыгын үтеп, азыкка кадәр барып җитә алмады. Далада тунганөшегән башка терлек турында әйтеп торасы да юк.

Кыр кәҗәләре көньякка — Урданың ком калкулыкларына таба юл алды. Бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһка дан, урманнарда агачлар күп иде. Утынга кытлык булмады.

Шундый суыкта Чиркәсиядән кара хәбәр китерүче атчабар далага үтеп керә алды. Ханның бабасы Елбаздук белән үги анасы Баялун тауларда кар ташкыны — ябырылма астында калып һәлак булганнар. Гәүдәләрен тапканнар, әмма жиргә индермәгәннәр әле. Үзбәк олы улы Тимербәккә юлга чыгарга боерды һәм әтисенең бабасын зурлап күмәргә кушты. Өч ханның хатыны булган Византия принцессасы Баялунны Сарайчык белән янәшә махсус аның өчен төзелгән мавзолейда жиргә тапшырырга әйтелде. Тимербәк мең сугышчы озатуында атасының кушканын үтәргә китте. Ул бары тик җәй башында гына, әмма атта түгел, ә арбада, бөтенләй көчсезләнеп һәм авырып кайтты. Йөткерү аның бөтен тәнен дерелдәтте. Авызыннан кан катыш үлек килде.

Дистәләгән им-томчы, дәвачы, шаманнар варисны терелтергә маташтылар; шәехләр, казый һәм муллалар, Аллаһтан яшь ханның сәламәтлеген кайтаруын сорап, догалар укыды. Аның өчен чиркәүләрдә һәм будда храмнарында гыйбадәт кылдылар, тик юкка — яшь, матур, житез Тимербәк бакыйлыкка күчте.

...Бу йөрешнең азагында агач богау кидерелгән Дмитрий Михайлович арбасы өстерәлә иде. Кайчандыр мәһабәт буй-сынлы кенәзне танырлык түгел. Киемнәре ертылган, иреннәре купкан, ябык һәм хәлсез бу адәмнең карашы бу дөнья кешесе түгел икәнлеген аңлата иде. «Тизрәк үләргә иде. Гомеремдә иң мөһим саналган эшне үтәдем. Юрийның жанын кыйдым, атамның үчен алдым. Тизрәк күзне йомасы иде». — Бәхетсез кенәзнең башында башка уй юк иде.

Сарайчыкка житәрәк Кондырча елгасы янында Үзбәк Дмитрийның богавын салдырырга һәм аны Тимербәк мәете янына алып килергә боерды.

— Кара, улым Тимербәк, — сагыш катыш сызлану белән сүз башлады Үзбәк. — Кара, безнең башка төшкән бөтен кайгы-хәсрәтнең сәбәбе шушы — Дмитрий. Бөек Аллаһ каршына килеп баскач, улым, Аллаһы Тәгаләгә бу лаексыз кешенең дөньядан киткәнлеген әйтерсең.

Шул минутта көчле бер сугышчы бер селтәнүдә аның башын кисеп төшерде. Шунда, кешесез далада аны жирләделәр дә. Дмитрий Михайловичның кабере кайдалыгын беркем белмәс, хәер, аның искә алыр кешесе дә юк иде. Хатыны, Литва кенәзбикәсе Мария Гедеминовна, иреннән иртәрәк китте, балалары исә булмады. Бу турыда Дмитрийның ир туганы Александр Михайлович соңрак, Үзбәктән ярлык алырга баргач белде һәм бик озак кайгыга батып йөрде.

Бер көннән матәм йөреше Сарайчыкка килеп житте. Тимербәкнең көле куелган тартманы мавзолейдагы кабергә төшергәндә, Ләйлә аңын югалтып егылды, күзләре әйләнеп китте, авыз кырыеннан ак күбек акты. Бәхетсез хатынны саф һавага алып чыктылар, дәвачы һәм им-томчылар аның тирәли бөтерелделәр. Ниләр генә кыландырып карасалар да, Ләйлә аңына килмәде. Йөрәгe типте, сулыш алды, тик берни ишетмәде, күрмәде. Әйтерсең, жаны гәүдәсеннән аерылып, өстә улының күкләргә ингән жаны белән аралаша иде. Шаманнар никадәр генә тырышмасын, төңгерләрен дөмбердәтеп биемәсен, ханбикәнең жаны әйләнеп кайтмады. Өч көн узды, Ләйлә соңгы тапкыр күкрәген тутырып сулыш алды да бу дөньяны калдырып китте.

Кыш буе Үзбәк кайгы-сагышта булды, кулы эшкә бармады, бик кирәк булганда гына азрак кымшанып алды. Юк, ханны элеккечә куркыныч төшләр борчымады, ул хатыны белән улын сагынды, йорттагы бар нәрсә аларны хәтерләтте һәм ул кабат хәсрәткә батты һәм бар кешедән, хәтта Тай-туглыдан да качып елады. Бернинди шамакайлар да аның күңелен күтәрә алмады. Бары тик иң яхшы табиб — вакыт һәм кыш суыгы гына хакимне исенә кайтара алды. Әкренләп карашы яктырды, ирексездән ял итәргә мәжбүр ителгән акылы икеләтә көч белән эшли башлады.

Элеккеге эш халәтенә кайту өчен, ул Диван жыйды, утырышта хәзер икенче

улы Тәнбәк катнашты. Берничә көн эчендә бик күп мәсьәләләр карадылар, хан һәрберсенең чишү юлын тапты. Төньяктагы урыс кенәзлекләренә җиттеләр.

— Бөек кенәз Александр ничек идарә итә? — дип кызыксынды хан.

— Аннан он да юк, йон да юк — барысы исеменнән Котлыгъ Тимер җавап бирде.

— Нишләп алай?

— Менә шулай! Аны кенәзләр генә түгел, Владимир белән Тверь халкы да санга сукмый. Карарбыз, безгә нинди ясак җыеп китерер икән?

— Карап тормабыз. Күреп туйган инде. Шәүкәлне чакыртыгыз, килүгә яныма кертсеннәр.

Шәүкәл кичкә килеп җитте, хан үзе генә, Византия императорына юллыйсы хат турында уйлана иде.

— Яныма утыр.

Шәүкәл утырды һәм кыюсыз гына ханга карады. Аның дулкынлануы йөзенә чыккан. Ничек инде дулкынланмыйсың, ханның сине ни өчен чакыртып алуы билгеле түгел.

— Мең сугышчы ал да Тверьгә кит. Ул ялкау Александрны ничек идарә итәргә, ясакны ничек җыярга икәнен өйрәтеп кайт. Кара, аның белән сак бул!

Шәүкәлнең күңеле күтәрелде. Ул яу сәфәренә җыену хәстәренә тотынды, киләчәктә рәхәт яшәячәген һәм ханга шәп бүләкләр җибәрәчәген күз алдына китереп ләззәтләнде.

Үзбәк исә Византия белән килеп туган вәзгыять хакында уйлавын дәвам итте. Узган ел азагында митрополит Пётр вафат булды. Үләр алдыннан варисы итеп, руханилар арасында абруе булган Феогностның исемен атады. Пётр үзе Алтын Урда белән Византия арасында яхшы арадашчы булды. Тәҗрибәле, ашыкмас, хаким теләгән һәр нәрсәгә ирешә торган иде. Феогност нинди булыр? Патриарх аңа фатихасын бирерме? Мөгаен, хатны Феогност белән түгел, ул килер алдыннан әз генә иртәрәк җибәрергә кирәктер.

Үзбәк хан үзенең мәктүбендә император Андроник IIдән Фракиядә сугышчылары китергән бәла-каза өчен ун кат гафу үтенде һәм килешү тәкъдим итте. Шулай ук үги анасы Баялунның үлеме өчен кайгыруы турында хәбәр итте, җеназаның ничек үтүен җентекләп тасвирлады һәм хәтта җәсәде күмелгән мавзолейның кечкенә генә рәсемен дә куйды. Хан императорны берминди дошманлык теләмәвенә ышандырды һәм ике дәүләт арасындагы бәйләнешләрне ныгыту максатында аның теләсә кайсы оныгына өйләнергә әзер икәнен белдерде. Хатының ахырында Үзбәк аннан Патриархтан Феогностны Мәскәү һәм бөтен урыс җиренең митрополит кафедрасына юллавын үтенде һәм кафедраның аның ризалыгы белән Владимирдан Мәскәүгә күчерелүе хакында аңлатты.

***

Шәүкәл Тверьда ныклап урнашты. Монда искиткеч: Итилнең башланып киткән урыны, әллә ни кызу булмаган җәй, терлеккә ашатырга сусыл азыкка кытлык юк, даладагыише тәмле үк булмаса да сөт һәм ит күп. Хан башлыгы сыйланырга бик ярата иде, аңа ачы бал һәм сыра ошады һәм, гомумән, Тверьда ул үзен хан урынына күрде, шуңа кәефе күтәренке булды, теләк-омтылышлары исә үскәннән-үсә барды. Шәүкәл Владимирдан Бөек кенәз Александрны чакыртып, аңа кенәз тирмәсен бушатырга кушты:

— Сиңа нигә ике тирмә? Үзең Владимирда яшисең, монда да тирмә тотасың. Хан акчага мохтаҗ чакта бу артык майлы була түгелме?

Александр җилкәсен җыерды да Владимирга китеп барды. Шәүкәл тирмәдән хезмәтчеләрдән башлап барысын да куып чыгарды һәм үзенең гаилә әгъзалары, берникадәр яраннары белән кереп утырды.

Тверь кенәзлегеннән ясакны Шәүкәлнең сугышчылары җыйды. Байлык һәм халыкны исәпкә алучылар ял итте, күләмне шайтанга яисә җенгә олактырдылар. Сугышчылар үзләрен җинүчеләр итеп хис итте, бар нәрсәне – күзләренә ни күренә, шуны әләктерделәр. Халык ризасызлык белдерде, тирә-юньдә, башлык Тверь кенәзен Владимирга куып җибәреп, үзе аның урынына утырачак, дигән хәбәр таралды. Кенәзнең тирмәсен тикмәгә генә тартып алмагандыр, янәсе. Халыкның, ниһаять, түземлеге бетте, алар Александрдан кайтып, Шәүкәлнең хокукларын кисүен таләп итте. Тик моны эшләве ансат түгел иде. Александр үз тирмәсенә керә алмады, аны ярты көн капка каршында бастырып тоттылар.

— Кара аны, Шәүкәл, бәлагә тарымагаең. Бездә халык түзә, түзә дә, кинәт ташкын кебек ярсып күтәрелә, юлындагы бар нәрсәне алып ташлый, туктата да алмыйсың.

— Туктатам! Мин урысны туктатканда, син әле арба тәгәрмәченнән түбәнрәк идең. Аңладыңмы, селәгәй малай? Хан юкка гына әйтмәгән: синең белән катырак кыланырга кирәк. Бар олак, корчаңгы эт!

— Кара аны. Үкенерлек булмасын!

— Нәрсә, миңа янарга килдеңме? Капкадан чыгарып атыгыз көчекне!

Кенәзне үз тирмәсенең капкасыннан җиргә чыгарып ташладылар. Халык инде сукранып кына калмады, дулады, шырпы ташлауга ут булып кабынып хәлгә килде. Озак көттермәделәр. Көннәрдән бер көнне Шәүкәлнең сугышчылары базарда бәрелешкә керде. Менә шуннан суеш-үтереш китте, аннан бар тверь халкы: яше дә, карты да читтә калмады. Тверьлеләрнең байтагы ятып калды, әмма хан сугышчыларын тирмәгә куып керттеләр.

— Яндырыгыз аларны, егетләр. Ут төртегез! –дип кычкырулары булды, берничә җитез ир-ат тирмә диварына үрмәләде һәм аны тыштан салам белән әйләндереп алды. Иске агач тирмә шәм кебек янып бетте һәм төтен хан сугышчыларын Шәүкәл белән бергә күкләргә алып менеп китте.

Ханның ярсуына түзә торган булмады.

— Кайчан тынычланыр икән бу тверь дуңгызлары, мин аларны ничек кенә бүләкләп карамадым, ә аларның үз туксаны туксан. Хәзер инде миңа каршы ачыктан-ачык эш итәргә күчтеләр! Тиз генә Мәскәү Иванны чакырыгыз минем янга! Менә ул урыс җирләрендә тәртип урнаштыра белер. Бөтен нәрсә белән идарә итәргә һәм бар нәрсәне үз кул астына алырга ярата, менә ул барысын да җинсен.

Иван Калита шул сәгатьне көтеп кенә торган, диярсең. Атна да узмады, ул хан алдына килеп тә басты.

— Иван! Күпме сугышчы телисең, хет илле меңне ал! Ярдәмчеләрең итеп кемне телисең, шуны билгелә, тик Тверьны гына җир белән тигезлә. Бар әсирләрне — миңа, бар байлыкны — миңа. Тверь җирләренә Мәскәү кешеләрен урнаштыр. Тверь дигән сүзне башка ишетергә дә теләмим.

Иван Калита үзе белән иптәшкә Суздаль кенәзе Александр Васильевичны алды һәм алар борынгы каланы тулысынча яндырып бетерделәр. Байлык тулы арбалар, төркем-төркем әсирләр Урдага таба сузылды, ә яндырылган Тверьне хәтта ерткычлар да әйләнеп узды, бары тик козгыннар гына төтенләп яткан көл өстендә әйләнделәр дә Итилнең күз яшьләре булып дулкыннан ятим калган ярларына ябырылдылар.

Александр Михайлович үлемнән һәм әсирлектән качып котыла алды. Ул, үзен эзәрлекләүчеләрдән качып, ун ел гомерен Псковта уздырды.

Иван Калита, ниһаять, Бөек кенәзлеккә күптән көткән ярлыкны алды. Әмма шундый ук ярлыкка, көтмәгәндә-уйламаганда, Александр Васильевич Суздальский да ия булды, дөрес, ул тыныч кына Суздалендә утырды һәм Аллага гыйбадәт кылды.

Иван Данилович үзенең уллары Симеон һәм Иван белән бергә ханга мәңге тугры булырга ант иттеләр.

Үзбәк кенәз Иванны ныклап күзәтте. Берәр елдан урыс җирләрендә тәртип урнашканын аңлады, ясак та әйбәт җыелган иде. Моның өчен хан Иванны тагын Кострома кенәзе титулы белән бүләкләде һәм Александр Михайловичны эзләп табарга боерды.

Иван Калита күптәннән урыс кенәзлекләрен бер йодрыкка туплау уе белән янды һәм моның өчен теләсә нәрсәгә барырга әзер иде, биредә әле үзенең күптәнге дошманнары – тверь кенәзләре белән исәп-хисап ясау мөмкинлеге дә туды. Ул Александрны эзләү эшен башлап җибәрде. Әгәр ул Новгородта түгел икән, димәк, Псковтан эзләргә кирәк. Бөек кенәз гаскәр туплады һәм Псковка килде. Кала сугышырга теләмәде, болай да кан күп түгелде. Иван илчеләрен җәбергә дучар булган кенәз белән сөйләшүгә җибәрде. Моисей архиепископ белән менбашы Авраам азап чиккән ил исеменнән Александрны хан алдына барып, хөкемгә басарга үгетләделәр, алайса аның ачуы яман булачагын һәм урысларның йөзләгән сала һәм калаларын янәдән таларга һәм яндырырга тотыначакларын әйттеләр.

Александр уйланды:

— Мин сездән сыену урыны эзләдем, әмма сез мине куарга телисез. Ничек инде аларга хезмәт итә һәм үзегезнең туганнарыгызны сата аласыз?! Әмма якыннарымның йорт-җирләре тыныч булсын өчен, мин үземне корбан итәргә әзермен.

Псковлылар кенәзне якладылар.

— Безнең белән кал, сатмабыз, афәт килә икән – бергә үләрбез.

Илчеләр буш киттеләр. Иван Үзбәкнең ачуыннан курыкты. Үзе өчен шүрләмәде, бары урыс җиренә яна һөҗүм башларга теләге юк иде. Ул качкынның ир туганнары Константин һәм Василийны, Александр Васильевич Суздальскийны үз янына чакыртты. Алар Опока янына килделәр һәм янәдән калага илчеләр җибәрделәр. Тик киребеткән псковлылар үз сүзләрендә нык торды – алар кенәзне бирмәде. Ул үзе дә атасы һәм абыйсы Дмитрий кебек үлемен Урдада каршыларга теләмәде. Шуннан Калита Феогност митрополитны Псковның бөтен халкына каргыш салырга күндерде, шулай итеп ул аларны изге чиркәүдән аерырга теләде. Халык тынып калды, уйланды. Качкын кенәз дә уйга талды.

— Туганнарым, сезгә каргыш төшмәс! Мин каладан китәм.

Александр атына атланды да Псковтан чыгып китте, тик ул Урдага түгел, Литвага – Гедемин канаты астына юнәлде.

Иван канәгать калды, Псковка да ут төртмәделәр, җинаятьче дә хәзер урыс җирендә түгел. Литва белән хан сугышка кермәячәк. Шунысы да бар, бер-бер хәл килеп чыкса, качкын кенәзне Урда дошманы белән килешүдә гаепләргә мөмкин.

Үзбәк инде суынды, ачуы узды, ул Бөек кенәзнең сүзләрен тыныч кына тыңлады һәм ашыгырга кирәкмәс дип хәл итте. Качкын белән ни кылырга икәнен вакыт үзе күрсәтер. Хан Калитага карады һәм елмайды:

— Йортыңа кайт, Иван, һәм барысына да, кем гаебен танымый, хан шуны кичерми, дип тапшыр. Гадел хөкем каршына басуын гөнаһлы булып качып йөрүгә караганда яхшырак.

***

Ханның кәефе көннән-көн әйбәтләнә барды. Аны барысы да: балалары, хатыннары, кардәшләре һәм тәбәгаләре шатландырды, бигрәк тә күзгә күренеп күтәрелгән кала — Сарай әл-Җәдид куандырды. Үзбәк берничә яраны белән иртәләрен калага чыкты, күкрәген тутырып саф һава сулады, ул бар нәрсәне күзәтергә яратты: әнә алачыкта төн эчендә сүрелгән тимерче учагын өреп кабызып җибәрделәр, урамнарда малайлар, бик тәмле һәм салкын дип, мактый-мактый су саталар, базар янына яна гына чалынган ит тутырылган арбалар килеп туктый, балыкчылар төнлә тоткан балыкларын тәкъдим итә. Отыры тагын да көчәя. Йон эрлиләр, чүлмәк ясыйлар. Ул чүкеч тавышлары... Күчмә тормышка караганда Үзбәккә утрак тормыш күбрәк ошый башлады.

Күчеп йөргәндә ничә кәрван очратырга мөмкин? Берне, икене һәм бетте. Ә калага һәр көнне көньяктан, көнчыгыштан, төньяктан көн дә килеп торалар. Кәрван-сарай төрле кешеләр белән тулган, алларында тәмле ризыклар өелеп тора. Кышларын анда җылы, җәйләрен салкынча була. Дөньяның төрле почмагында булган яңалыклар турында ишетәсең. Хан сәүдәгәрләрне, сәяхәтчеләрне, хаҗиларны кабул итәргә, сыйларга яратты, аларның бүләкләренә һәм алып килгән яхшы хәбәрләренә сөенде. Башка калаларда сокланырлык ниләр бар? Үзбәк шуларны сораштырды һәм үзендә булдырырга тырышты. Ул киңәшләр сорады,үзенең һәм каласының данын бар дөньяга таратуларына өметләнеп, заказлар ясады.

Кала чыннан да искиткеч матур иде, ул зур һәм кечкенә каналлар белән кварталларга бүленгән, каналлар аша агач күперләр салынган: турылары — арбалар өчен, кыеклары — җәяүлеләргә. Канал буйлатып салынган юллар яхшылап түелгән, тигезләнгән. Сарай тирәсендә — зур түрәләр кварталлары, аларның йортлары милли бизәкләре белән бизәлгән, аннары һөнәр корылмалары һәм сәүдә мәйданнары китә. Көньякта күбрәк гарәпләр һәм византиялеләр эшли иде, алар керамика, пыяладан әйберләр, корал, йорт кирәк-яраклары ясыйлар. Актүбәнең югары агымында күбесенчә тире иләүчеләр, агач осталары, мичкә ясаучылар, ат абруйлары һәм арба кирәк-яраклары эшләүчеләр яши. Яңа Сарай чәчәк атты, кырмыска өеме кебек гөжләде һәм шатланып тормыш итте.

Бервакыт иртәнге сәйран вакытында һөнәрче утарыннан бала көлүе яңгырап ишетелде. Бу көлү тавышы Үзбәкнең күңеленә сары май кебек ягылды, түзмәде — бу бәхетле йортта кемнәр яшәгәнен беләсе килеп, капканы шакыды. Көлү авазы шунда ук тынды, капканы кызыл балчыкка буялган алъяпкычлы ике яшь егет ачты. Алар шунда ук тезләренә егылдылар һәм башларын җиргә иделәр. Тынлыкны остаханәдән килгән тавыш өзде:

— Йә, ник тынып калдыгыз лачыннарым? Нәрсә китерделәр? Утын мәллә?

Җавап көтеп тормый чүлмәк ясый торган остаханәдән аксыл-сары чәчле оста килеп чыкты һәм көтелмәгән очрашудан катып калды. Һушына килеп, биленә кадәр иелде һәм ханга:

— Рәхим ит, ханым, Алла сакласын сине! Минем йортыма сине нинди җилләр китерде? — диде.

Хан елмайды:

— Синең балалармы?

Бер-берсенә охшаган аксыл башлы өч малай куркудан коймага сыендылар.

— Минекеләр, бөек хан! Синең арканда, атакай! Ызбада тагын ике кыз үсеп килә.

— Ничек инде минем аркада? Синең һәм Аллаң аркасында. Синең балаларынны мин ясамадым.

— Шулаен шулай. Әгәр дә беренче очрашуыбызда акча тулы янчык бирмәгән булсаң, мин гомерем буе кол булып калыр идем, ә менә хәзер — оста. Туктале, шәфкать күрсәтүчем, моннан ике ел элек үк мин сина бүләк ясап куйган идем. Үзем тапшырырга теләгән идем дә синең янга кертмәделәр.

Оста тантаналы рәвештә керамикадан коелган зур тәлинкә күтәреп чыкты.

— Кабул итче, ханым!

Үзбәк зур түгәрәк аскуймага куелган бүләкне кулына алды. Бер-берсенә ятышып торган ак аксыл-көрән, яшел бизәкләр төшерелгән, шома, ялтырап торган гаҗәп тәлинкә. Тар гына көрән сызыклар әле бер-берсенә якынаеп, әле ераклашып бара да бара. Ханның күптәннән мондый матурлыкны күргәне юк иде. Бүләк аның күнеленә хуш килде. Ул үзенә уенчык сандугач биргән шат күнелле егет — Борисканы исенә төшерде.

— Рәхмәт, Бориска оста! Сине шулай дип атыйлар бит?

— Сина да рәхмәт, ханым, искә төшерүең өчен. Синең аркада мине халык Борис Никитович дип олылый.

— Уенчыкларын турында, мөгаен, оныткансыңдыр?

— Ничек инде онытырга? — Борис малайларга кычкырды: — Ягез әле, бөек ханга ниләр белән уйнаганыгызны күрсәтегез.

Малайлар куркып кына ханга якынлаштылар, кулларында атлар, җайдаклар, сөнгеләр тоткан җәяүле сугышчылар, укчылар иде. Бар сыннар да Урда гаскәре төсенә буялган. Хан уенчыкларны кулына алды — гаҗәеп матурлык!

— Булдыргансың, Борис Никитович! Әйт әле, Коръән сүрәләре язылган тәлинкә яки тактачыклар ясый аласыңмы?

— Ә нишләп ясамаска?! Язып бир, жиренә житкереп эшләрмен.

— Иртәгә кешеләр жибәрермен, оста. Бу тәлинкәнне бүләк итеп кабул итәм, син дә тәлинкә өчен ышанмалык алып куй.

Хан билбавы астыннан көмеш салынган акча савыты чыгарды һәм аны Бориска ыргытты:

— Малайларынны белемгә өйрәт, телисен икән — мәдрәсәгә бир, телисең икән —попларга илт. Мин фәрман бирермен.

Икенче көнне Бориска Үзбәктән ярлык китерделәр, анда хан ясаган әйберләрен саткан өчен остадан салым алмаска һәм аның балаларын кайда тели шунда түләүсез укытырга кушкан иде.

Борис оста белән очрашудан соң, хакимнең рухи халәте яхшырды, житмәсә, яна гына бабасының тәхетенә утырган Византия императоры Андроник IIIнең хаты да унай кичерешләр өстәде. Урынын алып кына алмаган, ә карт монахны кәшишханәгә жибәргән. Яшь император килешү теләгән һәм аның туганлашырга дигән тәкъдимен хуплаган. Яучылар жибәрергә тәкъдим иткән.

Ханнын рәсми рәвештә бер хатыны — Тай-туглы гына калды һәм Үзбәк ятак өчен генә ярый торган берничә чибәр кәнизәк тотты. Ул бик нәзберек, нәфис һәм күтәренке рухлы кеше иде. Яшьтән шигърияткә тартылды, үзе дә укырга яратты, башкаларның да укуына мөкиббән булды, әсәрләренең яхшы һәм кимчелекле яклары турында сәгатьләр буе сөйли алды. Аңа шигърият кенә түгел, музыка да, сынлы сәнгать тә ошады, алар бар да аның күнеленә жыр кебек тәэсир ясыйлар иде. Бу турыда янәшәсендәге хатын-кызлардан бары Тай-туглы белән генә сөйләште. Кәнизәкләр бары матур сөяркәләр булырга гына яраклы иде. Ничектер Үзбәк шуларның берсенә Гомәр Хәйямнең робагыйларыннан берсен укыган иде:

Сөю дә – бер бәла, ул бит ходайдан,
Ни кылса да, бөтен эш бит ходайдан!
Явызлык, яхшылыклар үз кулыңда,
Ә соң мәхшәре безгә ник ходайдан?

Чибәркәй ханының исе киткән карашына игътибар итмәде. Ул бары мөлаем итеп хакименә карап тора иде. Үзбәк аннан бу дүрт юлдан нәрсә аңлавы турында сорашмакчы булды. Әмма аның күзләренә баккач: «Бу хатынның акылы башында түгел, ә гаҗәеп матур ботларында» −дигән нәтиҗәгә килде. Кызны хәрәмгә җибәрер алдыннан ул Гомәр Хәйямнән тагын берне укыды:

Серемне ачма, саклан син яманнан...
Ә кем яман? Танып кара арадан...
Бүтәннәргә ничек булсаң үзең син,
Үзең дә нәкъ шуны көт башкалардан.

Менә шуна күрә Үзбәк зур канәгатьләнү белән Кастантиниягә илчелек җыйды. Үз янында тагын бер акыллы һәм нәфис, ирнен йөрәген тәне белән генә түгел, рухи яктан да сөендерә алырлык хатын булуын теләде. Илчелекнең башына ул Сафониянең Сарская һәм Придонская епархияләре хакимен куйды. Архиепископның Византиядә күп мәртәбәләр булганы бар, юнан телендә иркен сөйләшә, Андроник III белән ул варислар рәтендә йөргән чагыннан ук яхшы таныш иде.

Хан бүләкләр һәм калымны муллан җибәрде. Иван Калита моның өчен бик тырышты. Сайлап алынган мең сугышчы Алтын Урда ханының киләчәк хатынын Яңа Сарайга озатырга тиеш булды. Үзбәк хан еракта, әле үзенә таныш булмаган Византия ханбикәсен күргәнче үк ярата башлады.

Бөек кенәз Иван Данилович урыс җирен, үз ватанын яратуын дәвам итте һәм аны бергә туплау өчен кулыннан килгәннең барын да эшләде. Кенәз кемгә каршы көрәшә алмасын белә иде, шуңа ул уйларны үзеннән куарга тырышты. Иван биргән антыннан кире кайтучылардан түгел, аны бозарга уйламады. Үзбәк алдында ул күндәм булып кыланмады. Ул чын күңеленнән ханны белемле булуы, кешене кешедән аера белүе, гаделлеге, ачуыннан тиз кайтуы өчен хөрмәт итте. Удел кенәзләрен килештерүдә һәм бер йодрыкка туплауда ханнан башка тагын кем ярдәм итә ала?

Хәйләкәр Котлыгъ Тимер барысын да сизеп йөрде, аны хан белән кенәзнең үзара бәйләнешы борчыды. Алга таба аларның якынаюын теләмәде.

— Син Иван үзенең кул астына торган саен күбрәк җирләр туплый дип уйламыйсыңмы? Син аңа көчәергә юл куясың. Кинәт котырган ишәк кебек тибеп куймасмы?

— Ә үзең урыста кенәзләр артык күп ишәйде дип уйламыйсыңмы? Үзләренең кечкенә җирләрендә утыралар, һәркайсы үзен бик акыллы, бик көчле дип саный. Менә шуңа этләр кебек бер-берсенә ташланалар, сугышалар, үзләренең халкын юкка чыгаралар. Безгә моннан файда юк, безгә ясак күбрәк кирәк. Мин әйтмичә дә беләсең: күп кеше − күп табыш, әз кеше − әз табыш. Өстәвенә, бу чылбырдагы этләр безгә күршеләреннән зарланырга килә. Без аларны килештерер өчен сугышчылар юллыйбыз, тагын җирләрне харап итәбез. Киребеткәннәрне башкача тынычландыра алмыйбыз. Аның каравы Иван зирәк һәм тырыш! Кенәз — хәйләкәр, җирләрне сугыш белән алмый, Ярославль һәм Ростовны сугышсыз алды, кызларын җирле кенәзләр Василий белән Константинга кияүгә бирде дә хәзер аларның кенәзлекләре белән үзе идарә итә. Бу җирләрдә халыкның тормышы алга китте һәм безгә дә байлык

агыла. Юк, Иван ишәк түгел! Ә инде, Аллаһ күрсәтмәсен, тәртәгә тибә башласа, үзен тиз генә башкага алыштырырбыз.

Иван Данилович ашыкмады, ул көтә белә иде. Эшләрен әкрен генә җайга салды, бер нәрсәне дә онытмады. Хан ярлыгы буенча новгородлыларның кенәзе саналса да, аны анда кертмәделәр, ул Новгород янында, киресенә катканнарның биләмәләрен таратып, җир сатып алды һәм үз кешеләрен күчереп утыртты. Бөек кенәзнең акчасы җитәрлек иде. Путасына татарлар калта дип йөрткән акча янчыгы кыстырып куелган. Бу зур янчыкта көмеш тормады, тик кенәз аны үзе өчен тотмады, урыс өчен тырышты.

Кияүләренә үзе янында булырга кирәклеге турында кабатлады.

— Калитадан курыктылар һәм хөрмәт иттеләр, кайберәүләр кирәк булганга аның белән дуслашты. Рязаньлылар ирексездән Мәскәүгә якынрак елыштылар, аларның җирләре Урда олыслары чигендә урнашкан иде. Алар һөҗүмнән беренчеләрдән булып иза чиктеләр. Ә 1327 елда Урдада Рязань кенәзе Иван Ярославович җәзалап үтерелгәч, алар тулысынча Калита кул астына керделәр. Иван Ярославовичны ханга Мәскәү кенәзе саткан дигән хәбәрләр йөрде. Тик имеш-мимешләр генә шул, раслардык берни юк.

***

Үзбәк көткән көн килде. Ниһаять, Византия патшабикәсе Мария йөзләгән юнан һәм әрмән асраулары, мең сугышчы озатуында Яңа Сарайга килеп житте. Кәләш бик чибәр, зифа буйлы, мәһабәт, нәзакәтле иде. Гашыйк хан дәртеннән чак акылын җуймады, принцессаның озын юлдан соң ял иткәнен көтеп житкерә алмады... Көткән мизгелләр якынлашты, Мария, мәһабәт атлап, ханның ятакханәсенә керде, һәм бар матурлыгы белән аның каршына басты:

— Ханым, ирем, сине күрүемә шатмын! Шуны бел, гомерем сиңа багышланган, бары тик сиңа гына. Мин сиңа уллар табып бирергә хыялланам, алар синең эшләреңне һәм ата-бабаларымның бөек эшен лаеклы дәвам итүчеләр булырлар. Көттермә, ирем...

Принцесса чишенә башлады, ә Үзбәк дәртенә чыдый алмый, аңа сокланды, башында буталчык уйлар әйләнде: «Әй Аллаһ! Нинди чибәр ул! Минем әбием, тутам һәм үги анам Баялунга ничек охшаган. Карашы, сөйләшүе, йөреше – бар да аныкы кебек. Мария, хыялым, син дә Баялун булырсың. Әйе, әйе! Мин сине нәкъ шулай атармын».

Хан Мария-Баялунның беренче ир-аты булды. Ул мәхәббәт уеннарының нечкәлекләренә өйрәтелмәгән. Үзбәк үзе көткән канәгатьлекне алмады, әмма кәефе китмәде, яна хатынын Тай-туглының күп нәрсәләргә өйрәтәчәген белә иде. Ә хәзер ана ял итәргә һәм гыйффәтен югалту хәсрәтен кичерергә кирәк. Хәрәмдә ана күптән урын әзерләп куелган иде.

Көннәр үтә торды, ханның Мария-Баялунны канунлы хатыны итәсе килде, шуңа тизрәк никах укытырга теләде. Тик моның өчен хатыны мөселман булырга, ислам динен кабул итәргә тиеш. Мария-Баялун ашыкмады:

— Сабыр бул, каударланма. Миңа иң әүвәл исламга төшенергә, Коръәнне игътибар белән укып чыгарга кирәк.

Берчак Яңа Сарайның казые белән сөйләшкәндә, Үзбәк хан аның, Аллаһ ризалыгын бирмәгән килеш хакимгә үзенең кәнизәген хатыны дип атау яхшы түгел, дигән ишарәсен тотып алды. Моннан соң хан Баялунны исламны кабул итүнең гадиләштерелгән йоласын кабул итәргә үгетләде. Ханбикә, ниһаять, мөселман булды. Мулла кияүдән дә, кәләштән дә өйләнешергә ризалыкларын сорады, икенсеннән дә унай җавап алгач, Аллаһ исеменнән аларны ир белән хатын дип игълан итте.

Хан көн саен дәүләт эшләре белән шөгыльләнде, хөкем чыгарды, ауны да онытмады, ә кич житте исә Баялун янына ашкынды, серле чибәр хатын үзенә тартып тора, хәтта алар арасындагы жинелчә салкынлык та ирне читкә этәрә алмады. Яшь хатынының белеменә Үзбәкнең исе китте, аның белән таңга кадәр күк, галәм төзелеше турында сөйләшергә була, алар озаклап планеталарның ничек һәм нәрсә тирәсендә әйләнүләре турында бәхәсләштеләр. Икесе дә жирнең түгәрәк булуы, әйләнүе, әмма аның өстеннән бер нәрсәнең дә егылып төшмәве турында белсәләр дә сәбәбен әйтеп бирә алмадылар. Ә акыл ияләренең фикерләре!..

Иренең үзе турында исенә дә төшермәвенә Тай-туглының ачуы килде. Ширбәт ае да узып китте, аның артыннан икенчесе, әмма Үзбәк өлкән хатыны турында уйлап та карамады. Кайда ул хатыны турында уйлау, хәтта улларының хәлләре белән дә кызыксынмады. Ә балалар эшенә катнашу кирәк. Тикмәгә генә: «Тездә чакта сөйдерә, үсә төшкәч — көйдерә», — димиләр. Тай-туглы көн уртасы дип тормады, тәвәккәлләп, ире янына китте. Хан эшен читкә куеп, өлкән хатынын шатланып каршылады һәм кочагына алды да шаян күзле чибәркәен шактый озак үпмәгәнен аңлады. Тай-туглы шунда ук һөҗүмгә күчте:

— Мин мәхәббәт теләнергә килмәдем, ханым. Үзеңнең улларыңа игътибар итүеңне сорыйм.

— Кайсы өчен борчыласың, гөлчәчәгем?

— Олысы, Тәнбәк.

— Нәрсә эшләгән минем өлкән улым! Ул бит Хәрәзмнең менә дигән хакиме. Безнең жирләрне үзләштермәкче булган оятсыз иранпарны кавказ тауларыннан, тарлавыкларыннан ул куып чыгармадымыни? Кавказ кешеләрен Алтын Урда кешеләрен урлап колыкка сатудан ул биздермәдеме? Улымның гаебе нидә соң?

— Син — начар ата! —дип кысрыклады аны Тай-туглы. — Син улларыңа варислар һәм сугышчылар итеп кенә карыйсың, аларның кешеләргә хас йомшак якларын күрмисең. Тәнбәк эчә башлаган. Көн саен диярлек лыкынганчы шәраб эчә дә исереклелек сөремендә икешәр, кайчакта өчешәр кәнизәкне берьюлы ятагына сала.

— Бу хәбәрләрне кайдан ишеттең?

— Кайдан булса да, хак сүзләр, үзем тикшердем. Киленең, сорауларыма: «Хатын ирен гаепли алмый, әмма утсыз төтен чыкмый», — дип язды.

Үзбәккә башка аңлатып тору кирәкмәде. Ачудан үзен кулда тоталмасын аңлап, хан Хәрәзмгә Котлыгъ Тимерне җибәрергә карар кылды:

— Барып кайт, кардәшем, малаеның хәлен бел. Әгәр чыннан да эчүгә һәм бозыклыкка сабышкан икән, чылбырга утырт, аңына килсен. Хәрәзм белән үзең хакимлек ит һәм берочтан Үргәнечтә мәчетне дә төзетеп бетерерсең.

Котлыгъ Тимер ханның әмерләрен берсүзсез үтәргә өйрәнгән, тик бу юлы күңеленнән аңа бик каты үпкәләде: «Нигә мине ул шулкадәр түбәнсетте? Бәкләр бәгеннән мине әмиргә? Кеше ни әйтер?».

Кеше һәрвакыт беренче чиратта үзе турында гына уйлый, четерекле мәсьәләләрне бары тик иң якын һәм ышанычлы кешегә генә тапшырып булганына төшенми.

Кичен Үзбәк Тай-туглыны кочагына алды, һәм хатыны һәрвакыттагыча яшь кызлар сыман аның ирлек көчен тәмам сыгып бетерде.

— Рәхмәт сиңа, мәхәббәтем. Вакытлыча онытып торуым өчен кичер. Шайтан башны бутады. Кичер. Учагыбызны Мөхәммәд галәйһиссәлам өйрәткәнчә саклавың өчен дә рәхмәт.

Котлыгъ Тимер Хәрәзмдә калды, Тәнбәкне рәсми рәвештә хакимлектән

мәхрүм итмәде, әмма үзе идарәне үз кулына алды. Бер елдан атасы варисны Яңа Сарайга чакыртты.

— Анаң белән минем янымда утырырсың. Ир-ат була белмәсәң, дөньяга хатын-кыз итәге астыннан карарсың, типтерергә уйласаң, белеп тор: хөкем җыеп торасым юк, үзем дә бик тиз урыныңа утырта белермен! — Үзбәкнең күзеннән чәчелгән очкыннар улының битен пешергәндәй булды.

Варис кул кушырып утырмады, атасының усал карашын аркасы белән тойган хәлдә, фәннәр үзләштерде, ауга йөрде, бар мәзһәбтәге руханилар белән әңгәмә корды.

***

Иван Калита урыс кенәзлекләрен берләштерүне дәвам итте, тик үзсүзле новгородлылар, тәгәрмәчкә таяк тыгып торды. Бөек кенәз, Новгородтагы алтын юуучыларның Камада бик күп көмеш тапканнарын ишетеп, алардан элеккегә караганда артыграк ясак таләп итте, әмма тегеләр каршы чыкты. Иван Данилович новгородлыларның акчасына Мәскәүдә яңа таш гыйбадәтханә төзетергә җыенган иде, шуна кире чигәсе килмәде — гаскәр туплады һәм Торжок белән Бежецкий Верхны кулына төшерде. Новгородлылар уйга калды. Калырсың да, төньяктан — шведлар, көньяктан бөек кенәз кысрыклый. Алар Псковка барып, күрше-кондәшләреннән теләктәшлек өмет итте. Калита исә озакка сузып тормый, үзенең олы улы Симеонны Гедеминнның кызы Августага өйләндерде дә Литва белән яшерен килешү төзеп тә куйды. Өстәвенә, монголлар Волынь сәфәре вакытында эләктергән Литва тәхете варисы Наримунтны урда әсирлегеннән йолып алды. Нәсара динен алдырып чукындырды һәм аннан Мәскәү кенәзен тыңларга ант иттерде. Новгородлылар да Литваны үз ягына авыштырдылар һәм Наримунтка Орешек, Карельск, Конорьеның яртысы белән идарә итүне тапшырдылар.

Иван Даниловичка шведларның новгородлыларга каршы һөҗүмен көтми чара калмады. Һәм ул көтте. Шактый озак көтте — шведлар Орешекка биш елдан соң гына басып керделәр. Наримунтның сакланыр көче юк иде, һәм ул каланы калдырып качты. Нишләсеннәр инде бичара новгородлылар? Канунлы кенәзне чакырып алдылар һәм Мәскәү белән килешү төзеделәр һәм бар еллар өчен бик зур күләмдә ясак түләделәр. Кем көтә белә, шул җиңеп чыга.

Иван кенәз көтте, әмма эшләре турында да онытмады, Мәскәүдә барыбер гыйбадәтханә, имәннән кирмән салдырды. 1331 елда Александр Васильевич Суздальскийның вафаты турында кайгылы хәбәр килде. Бөек кенәз җыенды да, үзеннән алда беркем уза алмасын белеп, хан янына юнәлде. Удел кенәзләре хаким чакыруыннан башка Урдага сынар аякларын да атлый алмадылар, Иван Данилович исә теләсә кайсы вакытта барып йөри ала иде.

Актүбәдәге мәрхүм туганы Юрий биләмәсен Иван да ташламады, киресенчә, тагын да яхшыртты. Килеп төште дә утарда мунча керде һәм Тай-туглы белән очрашты. Ул ханбикәгә бик күп төрле бизәнү әйберләре, кыйммәтле ташлар китерде. Бүләкләрне тапшырып бетергәч:

— Матур ханбикәләрдән иң чибәр ханбикәм, бүләк итеп тагын кечерәк бер урыс каласы — Туланы да бар халкы, йортлары һәм һөнәрханәләре белән бергә ал.

— Әй хөрмәтле кенәзем, рәхмәтем зур, тик андый бүләгенне хан рөхсәтеннән башка кабул итә алмыйм. Иремнән сине кабул итүен сорармын, үзең ана җиткерерсен.

Кенәз нәкъ менә шул җавапны көтте дә.

Икенче көнне иртән хан үзенең хатынына әйтте:

— Иванны кабул итәргә кирәк.

Ә нигә кабул итмәскә? Иван хәйләкәр, Урда йолаларын бик яхшы үзләштергән, шундый зур бүләк ясаган икән — ханның җавап бирәсен белә. Суздаль кенәзлегенә ярлыкка килгән хикмәт иясе, алачак ул аны, зирәклеге өчен алачак. Андыйларга ярлык файда гына китерә.

Өч көн дә узмады, Иван Данилович көткән ярлыгын алды. Тагын бер урыс җире аның кул астына керде. Көче дә, байлыгы да артты Бөек кенәзнең.

Калита өенә кайтырга ашыкмады. Танышып чыгарга булды. Үз биләмәсенә Урданың зур түрәләрен чакырды. Ачы балдан авыз иттеләр, әңгәмә кордылар, бөек кунак — ханның кияве, яна бәкләр бәге Иса гүргәнне дә китертә алды. Бергәләп аугa чыктылар, мунча чабындылар, ачы бал эчтеләр. Кунакны озатканнан соң, хужа бүләкләр җыйды һәм аларны Хәрәзмгә — Котлыгъ Тимергә җибәрде, чынында — ул баш, ә бу Иса гүргән буш шалтыравык сыман, әллә кем түгел. Зирәк кенәз ялгышмады. Ике еллап вакыт үткәч, хан Котлыгъ Тимерне үз вазыйфасына кире кайтарды.

***

Ханның көннәре бер көйгә — тыныч кына, тигез генә акты, вак-төякләр белән борчыган дошманнарын әмир-бәкләр бик тиз урыннарына утырта тордылар. Үзбәк берничә ай ил буйлап күченеп йөрде. Дәүләттә бар да тыныч, халык эшләде, байлык артты. Гаиләсендә дә тынычлык иде. Тай-туглы Тәнбәкнең исерткечне ташлавына шатланып туя алмады, улы хәзер баш-аягы белән укуга чумды. Үзбәк тә улының тәртибеннән канәгать иде, бар гаскәрне аның кул астына бирергәме әллә дип уйлаган вакытлары булды, әмма Елбаздук бабасының «җиде кат үлчә, бер кат кис» дигәнен хәтерләп, сабыр итте.

Вакыт узган саен, ханның күңеле яшь хатынына карата суына төште. Ул гыйшкы белән ирен җылыта белмәде, балага да узмады. Баялун ир белән торуны авырыксына башлаган иде инде. Һәм, Аллага шөкер, соңгы вакытта Үзбәк аны бик сирәк чакырды, ире белән ятак бүлешү аның өчен авыр бер җәзага әйләнгән иде. Хатынлык бурычларыннан күңеле кайтты. Византия принцессасы күченеп йөрүне ошатмады, әмма сәяхәт кылырга бик яратты. Иксез-чиксез далалардагы монсу бертөрлелек аны сагышка салды, ул дымлы җирләрне, бөдрә дулкыннарның шавын өзелеп сагынды.

Тай-туглы ахирәтенең күңел төшенкелеген байтактан чамалый иде. Өлкән хатын буларак, кәефен күтәрергә тырышты, Үзбәк исеменнән бүләкләр җибәртте, ачыктан-ачык сөйләшергә теләде. Әмма Баялун эчке дөньясына берәүне дә якын китермәде. Урда тормышы шулкадәр гайрәтен чигерде, ханбикә качу турында уйлана башлады. Урдадан ансат кына качып булмый, куып тоталар да иренә хыянәте өчен җәза бирәләр. Монда бары тик хәйлә белән генә алдырып була. Баялун уйлады да уйлады.

Хан элеккечә галимнәрне хөрмәт итте. Аның сараенда андыйлар шактый иде һәм ул аларга бик яхшы түләде. Күк галимнәре даими рәвештә Үзбәк өчен йолдызнамәләр төзеде, аңа бәхетле киләчәк юрап сөенделәр. Хан белән бергә башка планета һәм дөнья турында әңгәмә кордылар, кайчакта тамаклары карлыкканчы бәхәсләштеләр дә. Шагыйрьләр ханны һәм аның кабатланмас хатыннарын хөрмәтләп, күтәренке рухтагы шигырьләр иҗат итте, шамакайлар яңадан-яңа әкәмәтләр уйлап чыгарды, кәнизәкләр исә гаҗәеп көйгә искитәрлек шәрык биюләрен башкарып, күңелләргә дәрт өстәде. Көнчыгыш иленең хакимен шатландырыр өчен нәрсә кирәк булса, ханда боларның барысы да бар иде. Күп санлы яраннары Үзбәкне күчмә тормышта озатып йөрде.

1334 елда, дала куе яшел белән капланугa, Үзбәк хан көньякка — Кавказ

тауларына таба күченде. Хаким белән тулаем кала: тирмәләр, мәчетләр, тимерче һәм чүлмәкче алачыклары, күнчеләр һәм корал ясаучылар, көтүләре белән чабаннар да күченде. Хан әмер биргә бар да туктады һәм зур тирәлектә урамнар, юллар, мәйданнар ясап тезелде. Үзбәк бу юлны балачактан ук яратты: бар елга һәм инешләрне, уйсулыкларны, кар суларының кая җыелуын, ачы җилдән ышыкланыр калкулыкларны, терлек өчен иң сусыл азыкның кай урында икәнен бик яхшы белә иде.

Күчмә кала ханның яраткан биш түбәле тавы янында тукталган көнне аның янына күренекле гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута килде. Тиз арада Үзбәккә даны үзеннән алда йөргән кунак турында хәбәр иттеләр. Хаким шатланды. Ул Ибн Баттутаның кайбер башкала һәм дәүләтләр турындагы язмалары белән таныш иде. Сәяхәтчене җомга көнне кичке намаздан соң кабул итәргә булды.

Үзбәк хан биек зиннәтле чатыр астында кыйммәтле ташлардан бизәкләр төшерелгән, алтын йөгертелгән көмеш такталардан ясалган тәхеттә утыра иде. Уң һәм сул ягына хатыннары, аз гына арттарак ике улы, алдында кызы, астарак уң һәм сулда якын туганнары урнашты. Чыгу юлына якын җирдә әмирләр һәм гаскәрнең баш җитәкчеләре өчен урындыклар куелды. Дәрәҗәләре белән түбәнрәк түрәләр кереп ханны сәламләделәр, аннары чыгып чатырдан ерак китми утырдылар. Ибн Баттутаны Диван әгъзаларының берсе тәкъдим итте:

— Әй бөек солтан, бу дөньяда җиде бөек патшаның берсе, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Әй дала, тау, елга һәм диңгезләрнең кодрәтле хакиме, сәламемне кабул итеп ал! Хатыннарыңны, улларыңны, гүзәл кызларыңны сәламлим, кодрәтле һәм мәрхәмәтле Аллаһ аларны сакласын!

Үзбәк тәхеттә туп-туры утырды һәм мәһабәт тавыш белән Ибн Баттута сәламенә җавап кайтарды. Хезмәтчеләр шунда ук биек кәнәфи китерде, хан кунакка утырырга тәкъдим итте һәм дөнья буйлап сәяхәт кылганда нинди илләр, гаҗәеп хәлләр күрүе турында сөйләвен сорады.

Ул барлык мөселман илләрендә булган, Багдад һәм Дәмәшъкнең матурлыгын күргән, Мәккә белән Мәдинәгә барган, бөек галимнәр һәм суфыйлар белән гәп корган. Хикәят төнлә генә тәмам булды, әмма сарай шагыйрьләренең хан һәм аның хатыннары хөрмәтенә күтәренке рухтагы шигырьләрен тыңламыйча, берәү дә таралмады. Таралганда да куелган тәртип буенча: беренче булып өлкән хатын, аның артыннан икенчесе, балалар һәм башкалар дәрәҗәләренә карап кузгалдылар.

Икенче көнне хан Ибн Баттутага хөрмәт билгесе итеп берничә куй, шәп ат һәм көн савыт белән кымыз җибәртте. Сәяхәтче, әдәплелек һәм тәрбиялелек күрсәтеп, хан хатыннары белән күрешергә барды һәм, кайда гына булмасын, аны зур хөрмәт белән каршы алдылар, акчалар, көмеш коелмалар һәм кием-салым бүләк иттеләр. Кунакны бигрәк тә Византия императоры Андроник III кызы – ханбикә Баялунның зиннәтлелеге сокландырды. Аны йөз кол кыз әйләндереп алган һәм аларның һәрберсенең үз бурычы бар иде. Хуҗабикә ым кагуга, аның бар теләге үтәлә иде. Баялунның ачык төсле бай киеме, гүзәллеге, үз-үзен тотышы һәркемне үзенә тартып тора иде. Аннан куркалар да, хөрмәт тә итәләр. Дөньяны танып-белүе һәртөрле мактаудан өстен, ул тыйнак һәм сөйләүчене аңлый да белә иде. Ханбикәнең күзенә игътибар белән карауга, Ибн Баттута анда бик эчкәре яшеренгән сагыш күрде. Баялун бу очрашуга бик сөенде һәм кунакны тиз генә җибәрергә теләмәде. Бу турыда тиз арада Үзбәккә дә җиткерделәр.

Бер ай да узмады, күчмә кала күтәрелде һәм Әстерхан ягына китте, аннан хан Яңа Сарайга корабта кайтырга булды. Озак тукталышлар ясап, әкрен генә бардылар. Ә Итилнең түбәнге агымында урнашкан калага җиткәч, Баялун ханга

үзенең балага узуын белдерде һәм йөклелек чорын үз илендә — атасы йортында уздырасы килүен әйтте.

Хан бу яңалыкка бик куанды, әмма хатынына ризалык бирергә ашыкмады. Йөкле хатын газапланды. Теләсә нинди истән дә укшыды, күп вакытын ятып һәм ыңгырашып үткәрде. Санап бетергесез күп хезмәтче бәхетсез хатынның газапларын үзләренә алырга теләгәндәй, аның тирәсендә кайнашты.

Ниһаять, Үзбәк килеште. Жыену башланды. Ибн Баттутаның да Кастантинияне күрәсе, бу зур илдә буласы килде һәм ханнан рәсми рәвештә рөхсәт сорады:

— Әй солтаным, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Әй үз халкыңның кояшы! Әй Аллаһ Тәгаләнең һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең тугры хезмәтчесе, тынычлык булсын аңа! Мин, синең күндәм колың, хатыныңны озатучылар янында Византия империясенә китәргә рөхсәт итүеңне сорыйм.

Хан шунда ук җавап бирмәде, сәяхәтченең Баялун янында озак тоткарлануы аны төрле уйларга этәрде. Бу якты дөньяда күпне күргән бу хәйләкәр-зирәк бер-бер нәрсә уйлап чыгармадымы икән?

— Юк, — диде хан, кырт кисеп.

Ләкин кырт киселгәнне ябыштырып була бит.

Ибн Баттута чигенмәде:

— Әй солтаным, — диде ул, — Аллаһ сакласын сине! Безнең Аллаһы Тәгалә сиңа хан язмышын тәгаенләгән, Аллаһка мактау булсын! Ә минем бар җирдә булуымны, бар нәрсәне күрүемне һәм җиребез чәчәк атсын өчен безнең ниләр эшләгәнебезне нәсел дәвамчыларыбыз белсеннәр дип, бу турыда язуымны теләгән, мин һәрвакыт юлда булырга, сәяхәт итәргә тиешмен һәм шул максатым өчен, хатыныңны озата баручылар арасында качыр урынына авыр арбаны тартырга да әзермен.

Үзбәк укымышлыларга һәрчак хөрмәт белән карады, ул Ибн Баттутага яңа кием, мең ярым көмеш һәм яхшы пар ат бирергә боерды.

Җәй ахырында Баялунны озата йөрүчеләр хәрәкәткә килде. Көньякка таба исәпсез-сансыз кеше һәм кирәк-ярак төялгән арбалар кузгалды. Аларны мең сугышчы озата барды, алар артыннан, ашыкмый гына кыпчак даласы буйлап сарык көтүе китте. Кәрван бернидән шикләнмәгән, кешеләргә һәрвакыт ышанган Үзбәк хан ставкасыннан ераклашканнан ераклаша барды.

Судакта озаклап тукталыш ясадылар, сәяхәтчеләрнең кибеккән тәннәрен назлап диңгездән дымлы җил килеп ягылды, шунда үзен озата баручылары арасында Ибн Баттута да барлыгыннан бихәбәр ханбикәгә сәяхәтче үзе хакында белдерүләрен сорады. Баялун аны бик сөенеп каршы алды. Аның күңеле күтәренке, күзеннән очкыннар сибелә иде. Ханбикә сау-сәламәт күренде, элеккеге газапларының эзе дә калмаган. Баялун яңа дустын күреп сөйләшкәч, аңа Алтын Урда чикләрен узуга үз арбасына күчәргә тәкъдим ясады, аңа унбиш ат, көмеш коелмасы бүләк итте.

Үзбәк ханның соңгы ныгытмасы Баба-Салтык каласыннан соң Ибн Баттута ханбикә Баялунның зур, киң арбасына күчте. Баялунның шатлыгы чиктән ашты, ул шаярды, шаркылдап көлде, югары дәрәҗәсен онытып, үзен кызчыклар сыман тотты. Атасы җирендә беренче төшке ашта аңа шәраб белән чучка ите бирделәр, моны күреп озата йөрүчеләрнең чәчләре үрә торды. Әмма ханбикәнең ярсуыннан куркып, табынны ташлап китәргә кыймадылар. Румга караган Матули каласында, кызын Кастантиниягә озатырга дип, император гаскәре көтеп алды, менә шуннан Ханбикә ислам хакименең хатыны булудан туктады. Ул әмиргә сугышчылары белән биредә калырга боерды. Иң куркынычы шунда: юл мәчете ташлап калдырылды, мөәзиннәрнең тавышы тынды, Ибн

Баттута һәм озата бару өчен калдырылган берничә кол мөселман кызыннан башка намаз укучы булмады.

Башкалага керер алдыннан аларны башта биш меңлек гаскәре белән Баялунның кече ир туганы, аннары унменлек гаскәр белән олы ир туганы каршылады һәм бу бик зур процессия Кастантиниягә килеп җиткәч, кызы каршына император Андроник III хатыны белән чыкты. Бәйрәм киемендәге халык төркеме ханбикәне чәчкәләргә күмде, тирә-юньне шат авазлар урап алды.

Хәзер инде элеккеге ханбикә атларны туктатырга әмер бирде, җиргә аяк басты һәм иелеп башта туфракны үпте, аннары, торып, атасы белән анасына, халыкка баш иде.

Каладагы күп санлы гыйбадәтханәләрнең кыңгыраулары чаң сукты. Император гаиләсен халык төркеме сарайга кадәр озата барды. Баялун атасыннан ибн Баттутаны үзенең зиннәтле бүлмәсеннән ерак булмаган сарай бүлмәсенә урнаштырырга рөхсәт сорады.

Икенче көнне сәяхәтчене император үзенең хатыннары, балалары катнашында кабул итте. Баялун тәхет янында иң хөрмәтле урында утыра иде.

Андроник III сәяхәтченең Иерусалим, Воскресение храмы, Вифлеем, Дәмәшък, Мисыр һәм Гыйрак турындагы хикәятләрен тыңлады һәм сөйләшүдән канәгать калды. Император кунакка монархны саклаучы символ — кулчатыр, бәйрәм киемнәре һәм ат бирергә боерды.

Ибн Баттутаны бик яхшы ашаттылар, башкала буйлап сәяхәт иткәндә озата йөрделәр. Ул Византия башкаласының истәлекле урыннары белән танышты, әмма керер алдыннан тәре үбәргә тиеш булганлыктан, Изге София соборында булмады, чөнки чын иманлы буларак ул моны эшли алмады.

Көннәр язга авышкач, сәяхәтче дөнья буйлап яңа сәфәренә әзерләнә башлады. Аның тизрәк Хәрәзмне барып күрәсе килде. Ул кабат Үзбәк ставкасы аша үтәргә тиеш, чөнки аның җирләрен өйрәнү өчен ханның рөхсәте кирәк иде. Баялун, ире янына тиз кайтмасын сәбәп итеп, Ибн Баттутадан үзе белән хезмәтче мөселман итеп кызларын алуын сорады. Аның инде үзенең Урдадагы исемен ишетәсе дә килмәде, анда йөклелекнең билгеләре дә күренмәде. Ханбикәнең зирәк юлдашы аның Урданы бөтенләйгә ташлавына төшенде, хәер, кайтып торуның мәгънәсе дә юк иде: ул Үзбәктән балага уза алмады, ханны алдау исә кыен булмады.

Ибн Баттута Алтын Урда ханын Яңа Сарайда туры китерде. Үзбәк күптән көтелгән кунакны шунда ук кабул итте һәм җентекләп Кастантиниядәге хәлләрне сорашты. Баялунны туган җирендә бик хөрмәтләп каршы алулары, туганнары белән очрашканда аның ничек шатлануылары турында ишеткәч, уйга калды һәм башка сорау биреп тормады. Сәяхәтченең юлга тоткан чыгымын капларга әмер бирде һәм саубуллашты. Баттута хушлашканда аның күзендәге сагышны күреп, уйланды: «Хаким булу бик авыр, хәтта кайбер уйларны үз-үзеңнән яшерергә туры килә».

Хәрәзмгә кузгалыр алдыннан сәяхәтче чыгышы белән шул яктан булган Урданың баш имамы Ногманэддин әл-Харәзм белән озаклап гәп корды. Баш имам гаять укымышлы, гади халык белән үзен яхшы һәм карусыз, хан белән таләпчән тоткан, хаким алдында Аллаһ хезмәтчесе дигән мәртәбәсен төшермәүче адәм иде.

Ибн Баттута ханның өлкән хатыны Тай-туглыны да игътибарыннан читтә калдырырга теләмәде. Ханбикә аның белән бик озак төрле темаларга әңгәмә корды. Билгеле инде, сүз үзеннән-үзе Кастантиния, император һәм аның кызына күчте.

— Туган жирендә минем сенлем Баялун үзен ничек хис итә? — дип кызыксынды Тай-туглы.

— Туган жире теләсә кемгә көч бирә, — дип гомуми сүзләр белән генә җавап кайтарды кунак.

— Йөклелеге ничек бара?

— Бу сәбәп буенча аның газаплары бетте, дип уйлыйм.

— Бөтенләйме? — дип төпченде Тай-туглы.

— Әй ханбикәм, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Син бу җирдәге теләсә кемнән акыллырак, хатын-кызның көнелен безнен планетада көн күрүче берәүнен дә аңлый алмаганын миннән яхшырак беләсең. Барысы турында да бары Аллаһы Тәгалә генә тәгаен әйтә ала. Алга таба нәрсәләр буласын,әйдә, без аның иркенә калдырыйк. Бөек һәм кодрәтле Үзбәк ханның гаиләсе бәхетле булыр.

— Әйе, шулай булыр! — дип килеште аның белән ханбикә. Әмма күнеленда ике тойгы көрәште: бер яктан шатлык, чөнки ул бу тәкәббер, һавалы хатынны күрмәячәк, икенче яктан — Үзбәк кабат күнел төшенкелегенә бирелер дигән курку, шом.

***

Иван Калита соңгы вакытларда төннәрен начар йоклады, бигрәк тә хатыны Елена вафатыннан соң башланды бу хәл, ул аны бик юксынды, күзен йомуга мәрхүмәсе төшенә керде. Кенәз ятагыннан торып, тирмә буйлап әрле-бирле йөренә, һаман да могҗизага ышана, тик монарчы теге дөньядан әйләнеп кайткан кеше булмады.

Иван төн буена керфек какмый, башында новгородлыларны ничек күндерергә, Псковны ничек буйсындырырга дигән төрле уйлар кайный. Иван Данилович, чиркәү тычканыннан бай булмаса да, урыс кенәзлекләрен бергә туплау өчен акчасын кызганмады, хәер, кесәсенә күп акчалар керде, әмма алар анда озак тоткарланмады, барысын да иле өчен тотты. Бөек кенәз күптән Угличны, Галич, Белоозеро, Мста һәм Киржач елгалары буендагы дистәләгән авылларны, Костромадан, Владимир, Ростовтан бик күп җирләр сатып алды. Ә менә Новгород һәм Псков йөрәккә кадалган ике шырпы кебек, һаман баш бирмиләр. Үзара ызгыштылар, Мәскәү белән талаштылар, ә бит ул, ни дисән дә, аларның кенәзләре. Иван Феогност митрополит белән бик озак әңгәмәләр алып барды. Алар болай да, тегеләй дә итеп карадылар һәм новгородлыларны дини вәгазьләр генә коткара, дигән фикергә килделәр. Югыйсә тәкәбберлекләре белән үзләрен үзләре тончыктырып үтерәчәкләр. Тезгеннәрен бушата төшсеннәр, шведлар исә шуны гына көтә.

Феогност үз янына Новгород архиепискобы Василийны чакыртты, тегесе берничә айлар үгетли торгач, илчелекне Мәскәүгә җибәрттерүгә иреште. Иван Данилович илчеләрне зур хөрмәт белән каршы алды, аннары үзе җыенып Новгородка китте. Анда аны да шатланып каршыладылар, үткәннәрне онытырга, бер-берене дошман күрүдән арынырга ант иттеләр һәм кенәзне канунлы дип таныдылар. Новгородлыларны мәңгелек низаглар һәм киеренке тормыш туйдырды, урысның башка җирләрен дә дуслык берлегенә тартасылар килде, шуңа бергәләп качкын тверь кенәзе Александр Михайловичны куып чыгарырга булдылар.

Новгород белән Мәскәү арасы җайланды, ә менә каланың эче кайнады: сул яр буенда яшәүчеләр каршы ярдагыларны күрә алмадылар. Кемнәрдер Двинадагы көмеш прискаларын кенәзгә бирергә теләмәде, төньяк каласында аздан гына туган туганынын якасына ябышмады. Аллага шөкер, руханилар акылга һәм халыкны тынычландыру сәләтенә ия иде, бу юлы да туганнарын килештерделәр. Бөек кенәз үз чиратында кем хуҗа икәнен күрсәтте, гаскәр белән Двина өлкәсенә килде һәм көмеш чыгаруны күзәтү астына алды.

Зур эшләр өчен акча да күп кирәк. Халыкның ачуын чыгармас өчен, Калита бирәүдән дә акча сорамады. Ә тиешлесен тиененә кадәр каерды, ясак түләтүгә бик таләпчән булды. Зур эшләр башкарылды, Бөек кенәз куйган максатына таба бара, төннәр исә барыбер йокысыз үтә иде.

***

Александр Михайлович Тверской һаман да сөргендә иде. Псковлылар аны үз итте. Әмма хан җәберенә дучар ителгән кенәз көннән-көн элмәкнең кысыла баруын сизенде. Чыннан да, Александр янындагы тирәлек тарайганнан-тарая, менә Новгород та дошман кулына күчте, Литвага да сыенып булмый, Иван Гедемин белән туганлашты. Янды-көйде кенәз, дусларына әйтте:

— Менә качып йөри торгач, озакламам, үләрмен, ләкин балаларыма нинди мирас калыр?

Уйлады-уйлады да кенәз Үзбәккә барып тәүбә итәргә булды. Әүвәл Урдага бүләкләр тоттырып улы Федорны җибәрде, үзе Тверьга юл алды.

Менә ул туган ил! Менә бөек Тверь! Ун ел эчендә үзгәргән, үскән, яңа чиркәүләр гөмбәзләре белән балкып утыра Халык кенәзне шатланып, күз яшьләре белән каршылады. Энесе Константин, зирәклек күрсәтер, Тверьны элекке хәленә кайтарыр дигән өмет белән, кенәзлекне абыйсына тапшырырга әзер иде.

Иван Данилович берсен дә күз уныннан ычкындырмады, ул туган җирен җимертергә теләмәде. Үзбәк дәшмәде, кенәзгә ачуланмады. Алла сакласын, ханның ачуы чыкса, Тверьга булган элеккеге үпкәләрен исенә төшереп яу чабарга да күп сорамас. Анда ун ел инде тынычлык хөкем сөрде, бары тик арыш басуында чалгы тавышлары чыңлады, балаларның шат авазы яңгырады да һәр ишегалдында әйлән-бәйлән уйнаулары ишетелде.

Алла күрә: хан үч сакламый, ярсуы тиз басыла. Ул Федорны өенә җибәрде һәм Александрга килергә рөхсәт бирде. Александр Михайлович җыенды, бүләкләр алды, Урдага шулай тиз чакырырлар дип уйламаган иде — дулкынланып юлга чыкты. Ни булса, шул булыр.

Юлда килгәндә кенәзнең башынннан күп төрле уйлар узды, ул инде тынычланды, куркудан арынды һәм йөрәге тигез типкән хәлдә кыю адымнар белән тәхеткә таба атлады.

— Бөек хан! Беләм, мин синең ачуыңа лаек, шуңа язмышымны сиңа тапшырам. Ярлыка яки җәзаңны бир. Акласаң, Аллаһ Тәгаләне һәм сине зурлармын. Башымны кисәргә уйласаң, менә ул синең каршыңда.

Үзбәкнең карашы ягымлы иде, ул дәшмәде. Күңелендә ачу юк, тик уйлары гына аны тынычлыкта калдырмады: «Ун ел сөргендә йөрде кенәз, акыл туплагандыр. Аның гомере нәрсәгә? Минем газапланган җанымның әрнүен арттырыргамы...».

Хан елмайды, аның күзләре дымланды.

— Бас, Александр, күндәм акылың сине җәзадан йолып ала. Алга таба да акыллы бул, Бөек кенәз Иван һәм башка кенәзләр белән дә татулаш. Тверь кенәзлегенә ярлыкны мин сиңа бирәм.

Александр Михайлович бик куанды. Ә Иван Калита ачуыннан төкеренде һәм: «Яшәп карыйк, күрербез: кем кемне җиңәр!» — дип уйлады.

***

Үзбәк Александрны тәүбәгә килүе өчен генә кичермәде, ул үз йортында тагын бер кан коюдан курыкты. Баялун качып киткәннән бирле ул үз эченә йомылды. Якты кояш та, шаян җилкәй дә — берсе дә ана куаныч китермәде. Хәтта чибәр кәнизәк Сусаннан туган өч яшьлек улы да йөрәген җылыта алмады.

Баласы тугач, ул Сусанны хатыны дип игълан итте. Тай-туглының да ханның күнелен күтәрергә көче житмәде.

Хаким күп вакытын догалар укып, яшәү, кешеләрнең хезмәте һәм омтылышы турында уйланып уздырды. Болар аны вакытлыча кайгысыннан аралады. Үзбәк үз тирәсенә бик күп суфыйлар туплады, ә алар бер нәрсәне тәкрарлады:

— Байлык һәм хакимият кешенең күнелен үтерә, ирегеи чикли, кешедән кол ясый, жанын яманнан чистартырга һәм Аллаһ бакчасындагы мәңгелеккә әзерләнергә комачаулык итә.

«Ничек инде кешеләрне кысмаска? — дип уйлады Үзбәк үзе генә калгач. — Мәсәлән, новгородлылар — ирекле халык, идарәчене үзләре сайлый. Кенәзне күпме гомер яннарына китермәделәр, акыллы булып кыландылар, тәкәбберлекләре аркасында аздан гына бер-берләрен үтерми калдылар. Попны эт шикелле чиркәүгә бикләделәр һәм ачка тилмерттеләр. Иван вакытында өлгерде, акыллысын да, тилесен дә бер йодрыкка жыеп алды — гауга да бетте, тавыш та. Халыкның чиркәүгә йөрергә вакыты табылды, үз жаны турында уйланды, уйлары чистарды. Шулай, изү изүдән аерылып тора».

Хан йортта да рәхәтлек тапмады. Туганнары, берсеннән берсе уздырып, аңа ярарга тырыштылар. Үзбәк кылт итеп, янынна үтеп киткән улының күзе бик сагышлы булуын искәреп калган иде. Сәбәбен дә сорашмады.

«Улым белән сөйләшергә кирәк», — дип уйлады ул һәм иртәгесен иртә белән аны үз янына чакыртты.

— Рәхмәтемне белдерәм, атам, ханым һәм хакимем, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Мине искә төшерүеңә рәхмәт. Эшсез болганып йөрүдән арыдым мин, атам. Бернинди шатлык тоймыйм, бары хатыннарым һәм балаларым — тормышым чыганагы. Мина инде утыз, син ул яшьтә олыс бәге идең.

— Син дә олыс бәге идең, улым, әмма шәрабкә тартылып, мине һәм үзеңне, динебезне дә оятка калдырдың.

— Мин ул кимчелегемне жиңдем, ханым. Хәзер синең ярдәмчең булырга әзермен.

— Яхшы, улым, сине кая куярга икәнен уйлармын.

Тәнбәк жанланды, күзе ялтырады, елмаюдан йөзе балкып китте.

— Рәхмәт, рәхмәт, ханым, мин котәрмен.

Котлыгъ Тимерне күптән бәкләр бәге вазифасына кайтарса да, Үзбәк хәзер аның белән сирәк очрашты. Кияве Иса гүргән булдыксыз түрә булып чыкты. Ул кылыч айкарга гына яратты, шуңа хан аны гаскәр белән житәкчелек итәргә жибәрде. Ә дәүләт эшләре зур игътибар, булдыклылык, акыл белән эш итүне һәм даими тикшереп торуны таләп итте. Иң беренче чиратта, сүз дә юк, Үзбәк һәркемне, шул исәптән бәкләр бәген дә күз уңыннан ычкындырмады. Котлыгъ Тимернең хата эшләгәне юк, хезмәтен жиренә житкереп үти, тик туганнар бер-берсеннән рухи яктан ераклаштылар, сирәк күрештеләр. Хан беренче вазирен эшләре буенча хөкем итте, үзенең шәхси ихтыяжларын онытмавын игътибарсыз калдырмады. Котлыгъ Тимер бервакытта да үзенә дигәнне кулыннан ычкындырмады, тик барыбер хан ихтыяжларын ул алгы планга куйды. Әйе, хезмәт итә белә иде ул.

«Үзбәк миңа карата суынды, — дип уйлады бәкләр бәге. — Ярар, куркыныч юк. Аның холкын беләм, тузынып-тузынып да кабат чакырып алыр. Хан мине иләшеп бетте, беркайчан да ташламас».

Котлыгъ Тимер хан янына соңгы яңалыклар турында хәбәр итәргә килде. Урдада тынычлык, аның каравы тирә-якта хәлләр кискенләште. Бигрәк тә

көнбатыш борчуга сала. Рим папасы кушуы буенча Польша Алтын Урдага тәре походы әзерләп ята.

— Ничек инде үтермәскә? — дип сорады Үзбәк үз-үзеннән, анын уенда һаман да жанын чистарту иде.

— Кемне үтерергә? — бәкләр бәгенең күзе мангаена менде.

— Кемнен тыныч яшисе килми — шуны. Жир житәрлек, байлык санап бетергесез. Безнен динебез ошамый аларга, үз Аллагызга табыныгыз, комачаулык итмибез бит. Гаскәрне жый, туганым, башына Тәнбәкне куябыз, ул беренче һөҗүмне ясасын! Һәм беркемне аямаска, әсирлеккә бары сугышчыларны, осталарны һәм матур хатыннарны гына алырга!

Котлыгъ Тимер гадәттәгечә сорау биреп тормады. Тәнбәкнең хәленә ул да борчылды. Варисның эшсезлектән интеккәнен күреп эче пошты. Кем белә, хан кинәт кенә улын бәкләр бәге итеп куйса нишләрсен?!

«Тәнбәккә гаскәрне сайлап туплыйсы, тәҗрибәле сугышчылар куясы булыр, хан улының булдыклы хәрби житәкче дигән данын чыгарып, ахырдан Урданың бар гаскәрен аңа бирергә дип киңәш итәргә кирәк. Аннары мин дә тынычлап йоклармын». — Котлыгъ Тимернең уйлары күнеленә хуш килде.

Бәкләр бәге варис жинсен өчен көченнән килгәннең барын да эшләде. Польша гаскәрләре, куяннар усал эттән качкан кебек, койрыкларын тиз кыстылар, бик күпләре әсир итеп алынды. Бер унайдан, Гедемин Литовский моннан ары хан ясагына кулын сузмасын өчен, Киевта баскакларны яңадан үз урыннарына утырттылар. Иң мөһиме: полякларны шул дәрәҗәдә куркыттылар ки, католиклар тәре походлары дип башка авызларын ачмадылар һәм православ чиркәүләренә карата теш кайрамадылар.

Үзбәк сөенеченнән улын кочагына алды һәм, Котлыгъ Тимернең киңәшен дә көтеп тормастан, аңа Алтын Урданың бар гаскәре белән житәкчелек итүне тапшырды.

Тай-туглы моңа бик борчылды һәм иренә бу турыда житкерде:

— Бик иртә түгелме?

— Иртә түгел. Эшсезлектән ул тагын эчкечелеккә бирелер! — Үзбәк өзеп җавап кайтарды.

— Ә уныштан, даннан? Елбаздукның бакыр торбалар турында әйткәнен онытмыйсыңмы?

— Бакыр торбаларны буйсынганнардан тартып алырбыз.

— Син бит Тәнбәктән варис исемен тартып алмыйсың һәм колагын да томаламыйсың?

— Хаталанса, алачакмын! Күземне дә йоммыйм, алам. Сорауларың белән мине жәфалама, әгәр башка юл беләсең икән — әйт.

— Белсәм иде... — дип авыр сулады Тай-туглы.

Атасы белән анасы уйлашкан арада, Тәнбәк гаиләсен алып, олыслар буйлап, гаскәрләрне тикшерергә чыгып китте.

Анасының йөрәге әүвәлгечә үзенә урын тапмады. Ул Үзбәктән кияүләре һәм Котлыгъ Тимернең жияне Һарунбәкне Тәнбәккә ярдәмче итеп куюын үтенде. Бәкләр бәге, бик сөенеп, якын туганын тәкъдим итүләрен яклап чыкты. Хан акыллы үтенечне канәгатьләндерде.

Тай-туглы бераз булса да тынычлана төште, кызы Толынбәкнең, яхшы дигән хәбәре анын шик-шөбһәләрен куып таратты. Һәм ул бар игътибарын оныкларына — кече улы Жанбәкнең балаларына юнәлтте.

Тыныч һәм үз-үзенә ышанган Жанбәк һәрвакыт атасы янәшәсендә булды, Диван утырышларында катнашты, бары кирәге чыкканда гына күченеп йөрде. Утрак тормышта яшәргә яратты, гаилә гадәте белән күп укыды. Укымышлы

кешеләр, күк галимнәре, шагыйрьләр белән аралашты, зур канәгатьләнү белән фикер йөртте, бәхәсләште, кайчакларда абруйлы саналганнарның борыннарына да чирткәләде. Тай-туглы кайчак кече улын күбрәк яратуын тойды, житешмәгән якларын күрмәде, аны кызганды, Алла күрсәтмәсен, әгәр хакимлек өчен көрәшергә туры килсә, абыйсы Тәнбәк көчлерәк дип, аның өчен курыкты. Шул уй башына килүгә, аның йөрәге кысылды, күңеле балавыз сыкты һәм ул бу бәйләнчек уйларны тизрәк куарга теләде, әмма алар таралырга ашыкмады.

Жанбәк тә еллар узуга карамастан, һаман да яшь һәм житез анасын яратты, аның белеменә гажәпләнде һәм анасы вафатына кадәр аның белән бар серен бүлеште.

***

Александр Михайлович Тверский үзенең биләмәсенә жиңүче булып кайтты. Халык аны зурлап каршылады, кыңгыраулар кактылар, шатландылар, туган калабызга бәхет килде, кенәзгә хан якты чырай күрсәткән, дип уйладылар. Александр үзе дә шул халәттә иде, ул Тверьга ун ел эчендә табылган бик күп псковлы дусларын алып кайтты. Соңрак калада кенәзнең күптәнге кинәшчесе — алман Доль күренде. Ул бояр аксөякләрне эшләреннән читләштерде һәм үз янына ырудашларын жыеп алды һәм алар иренчәк урысларны акылга өйрәтә башлады. Тверь боярлары рәнжеделәр. Алар хәзер, артта калганнар, катып калганнар дигән гаеп белән, кайсы мангаен, кайсы баш артын кашып, кенәздән читтә — ерак почмакта утырдылар.

Ярты еллап вакыт узды. Тверьда эшләр ни алып мактарлык, ни салып таптарлык булмады. Ул арада, алманнар кенәзне Литва белән берләшеп Үзбәккә каршы яу чабарга өндиләр икән, дигән имеш-мимешләр таралды. Калада кемнәрдер моны ишетеп, күз яшебез төшәр — аларның сырт сөякләрен сындырырбыз, аннары үзләре безгә ясак түли башлар, дип сөенде. Башында әзрәк акылы булганнар каршы килде:

— Үзбәк белән сугышырга иртәрәк, аның көче иксез-чиксез, әнә күптән түгел Люблинга барып, барысын кырып-жимереп кайтты. Ханның ачуын чыгармаска, тик кенә утырырга кирәк. Әле яңа гына сулыш алдык, балалар туды, кылыч, сөңгеләр тотарга иртәрәк әле аларга.

Ә тверь боярлары, сүз куешкандай, кенәзгә авылларын кайтарып, Мәскәүгә — Иван Даниловичка хезмәткә китә башладылар.

— Кабул итеп ал, атакай, ятим тверьлеләрне, безне һәм балаларыбызны алманнардан коткар.

Иван кабул итте һәм мыек астыннан көлеп әйтте:

— Кенәз Тверский Литва белән килешү төзергә жыена дисез инде?

Тиздән Бөек кенәз Литвага үзенең олы улы Симеонны хатыны белән жибәрде: «Бар, улым, каенатаңның хәлен бел, хатыныңның да анасы белән күптән күрешмәгән, хәл-әхвәлләрен белешсеннәр, һәм син дә безнең Литвалагы кешеләрдән Гелеминның Александр Михайлович белән сүз куешулары турында ниләр ишеткәннәре хакында сорашырсың».

Улы китте, ә атасының эше муеннан. Эшләр бара, Калита шат иде.

Үзбәк тә үзенең Сарай әл-Жәдиде өчен сөенеп туя алмады. Калада урамнар киң, матур, кеше күп, мәйданнарда нинди генә телдә сөйләшмиләр. Актүбә причалларында боз китүдән боз катуга кадәр дистәләгән кораблар йөкләрен бушатты. Кәрван-сарайларда фонтаннар ата һәм гөлчәчәкләр күз явын ала. Барысы ышанычлы саклады, берәүнең дә урларга кулы бармады: тоталар икән — урлаган әйбереннең бәясеннән ун тапкырга артык түләтәләр. Түли алмыйсың икән — башыңны кисәләр. Яңа Сарайга, ханның байлыгын тагын

да арттырып, халык ташкыны агылып торды, алар үзләре белән яхшы табыш алып килде.

Бик матур кояшлы бер көндә көньякта — иң зур кәрван-сарайда ыгы-зыгы башланды. «Бөек хан үзе килә!» дигән хәбәр таралды. Имеш-мимеш расланды. Сәүдәгәрләр өсталләргә, киштәләргә иң шәп товарларын чыгарып өйде, хакимне бүләкләргә күмделәр, мактау яудырдылар, Аллаһтан озын гомер сорадылар. Моннан да матуррак каланы тагын кайдан табасың — Бохара белән Сәмәрканд та аның янында юк булып калды!

— Хан бүрек сатып алырга тели! — ханны озатып йөрүчеләр арасыннан әмирнен көчле тавышы ишетелде.

Шунда ук өсталләр өстеннән корыкларда һәм таякларда дистәләгән яхшы сыйфатлы баш киеме күтәрелде. Үзбәк күзен йөртеп чыкты, әмма берсе дә игътибарын җәлеп итмәде.

— Бу әйберләр хакимнен дәрәҗәсенә лаек түгел. Үзбәк хан кыйбатлы, зиннәтле ташлар белән бизәлгән, җирдә башка тиңе булмаган бүрек тегүче эзли. Кем шушы эшкә алына, шуны хан ике көннән сараенда көтә.

Бары өч кенә сәүдәгәр килде, калганнары ханга ярый алмауларыннан шүрләде. Моның өчен бик күп акчаң һәм бик яхшы осталарың булу шарт. Хан сәүдәгәрләрне тәхеттә утырган килеш кабул итте, янына улы Җанбәк баскан иде. Сәламләү, ханны мактаулардан, бүләкләр тапшырулардан соң, Үзбәк үзенең теләкләрен җиткерде:

— Бүрек ханга лаек булырга тиеш: кыйммәтле мех һәм ташлар белән бизәлсен, түбәсендә тәре торсын, чөнки ул — минем гыйсави патшасына бүләгем. Бу эшне тизрәк һәм яхшырак башкаручыга чыгымыннан өч мәртәбә артыграк түлиячәкмен, соңрак башкаралар да табышсыз калмас.

Сәүдәгәрләр сарайдан чыктылар һәм дөньяның иң кодрәтле җиде хакименең берсе булган Бөек ханның, Аллаһ аңа озын гомер бирсен, сәламәтлеге өчен дога кылырга мәчеткә юнәлделәр.

Еллар үзенекен итте, Үзбәк кыска гына вакытка ауга чыгудан соң да аруын тойды. Аудан башка ул тормышын күз алдына китерә дә алмый иде. Дин галимнәре белән озакка сузылган әңгәмәләр дә ялыктыра башлады.

— Һаман да бер балык башы! Иләк белән су ташыйбыз, — дип, үз-үзенә икърар итте Үзбәк. — Җир Кояш тирәли әйләнәме яки киресенчәме, Аллаһ кайда яши, нәрсәгә дип җир таптыйбыз, шатланабыз, бер-беребезне үтерәбез —шуларны белмичә фәлсәфи фикерләвебездә алга китә алмабыз.

Үзбәккә күңелсез иде, аның дуслары булмады. Ханның нинди дуслары булсын инде? Янында бары тәлинкә тотучылар, берәүләре аның үлеменнән курка, чөнки варис аны кабул күрмәскә мөмкин. Икенчеләре, киресенчә, ханның тизрәк җан-тәслим кылуын көтә, андыйлар хан үзләренә тиешле дәрәҗәне бирмәде дип саный. Бар да бер нәрсәне — акча һәм хакимият тели, әмма хакимият — авыр йөк. Хакимият белән янәшә булу, аннан файдалану, байлык сыгу һәм житештә яшәү күпкә яхшырак. Тик монысы да көтмәгәндә өзелергә мөмкин.

— Хан янында — үлем янында, диләр шул, — сагышлы ханның башында уйлар бөтерелде. — Котлыгъ Тимер, ышанычлы дус һәм туган, ул да уяуга әйләнде. Элекке еллардагыча артыгын тыкшынмый, киңәшләрен Җанбәк белән Тай-туглыга саклык белән бирә. Картая бәкләр бәге, зур байлык туплады, саклый аны, югалтудан курка. Хаклы, хаклы суфыйлар! Байлык аңны томалый, җандагы барлык яхшыны үтерә, менә хәзер туган белән дә күңел ачып утырып булмый. Тай-туглы да үзгәрде, күбрәк балалары һәм оныклары өчен өзгәләнә, минем җан биргәнемне көтәмени, тәхет өчен көрәшерләр дип курка. Муллаларга берничек тә ачылып бетеп булмый. Хан көчле булырга тиеш, йомшакларны

халык өнәми, андыйларны үтерәләр. Юк минем дусларым, юк! Бары берәүне – Мәскәү кенәзен генә үз итәргә була.

Ул ялагай түгел, үзен лаеклы тота, башы белән киртә җимерми, теле һәрчак йозакта. Бәлки аны үз яныма чакырыргадыр? Мунча керербез, куастан авыз итәрбез, күңелләрне бушатырбыз. Ә нишләп чакырмаска ди?!»

Иртән атчабарлар Калитаны чакырырга Мәскәүгә киттеләр.

Бөек кенәз уйга чумды. Симеон Литвадан әйләнеп кайтты, тверь илчеләренең Гедемин янында булулары хак, ә менә нәрсә турында сөйләшүләрен белә алмаган. Берәүләр, берләшеп Урдага каршы барырга уйлаганнар дисә, икенчеләре – килешә алмаганнар ди, тик Литвала сугышка әзерлек сизелмәгән.

«Ярар, Александр Михайлович җибәргәч, димәк, тикмәгә түгел, – дип нәтиҗә ясады Иван. – Тверьның качкынлыкта йөргән кешеләренең барысы диярлек, кенәз Урдадан үч алу ниятен күтәреп чыкты дип торалар. Хан янына барып, кисәтим әле, артык булмас».

Иван Данилович җыена башлады, шул арада ханның атчабарлары килеп төште. Хәзер инде урыслар, кенәз үзе әләк белән барды дия алмаячаклар. Кенәз утырды, уйлады һәм шатлыгы сөртеп алгандай юкка чыкты. Үзбәк аны нигә чакырды икән? Калита башын күпме генә эшләтсә дә, сәбәбен белә алмады. Илчеләр дә дәшмәде, аларга чакырырга әмер бирелгән, нәрсә өчен – анысы аларга караңгы. Урдадагы үз кешеләре Иванга, хан сагышка төшкән, кеше белән юньләп сөйләшми, кычкыру белән боерудан башканы белми, дип җиткерделәр. Хәтта хатыны Тай-туглы да иреннән курка башлаган.

«Бәлки, берәрсе әләкләгәндер? – дип өзгәләнде Иван Данилович. – Юктыр, чөнки бар кенәзләр дә, аларның балалары да йортларында, ә алардан башка хан берәү белән дә сөйләшеп тормас».

Бөек кенәзне Яна Сарайга килеп җиткәнче шик-шөбһәләр газаплады. Үз авылына җитеп, атыннан төшкәч, шиге тагын да артты. Анда көтеп торган кешеләр ана шунда ук хан янына барырга куштылар. Иван юл тузанын юып төшерде, бәйрәм киемнәрен киде, барлык шикләрен ташлап, уллары Симеон һәм Иван белән башкалага юл тотты.

Кояш инде батарга әзерләнә, яна аты, аяк астындагы корыган үләннәрне тоягы белән күңелле кыштырдатып, уйнаклап чапты. Бөек кенәзнең дә күңеле күтәрелеп китте.

«Ни булса, шул булыр,» – дигән нәтиҗәгә килде Калита.

Бәркә ызанына төшкәндә кенәз атын туктатты. Аның күз алдында гаҗәеп манзара ачылды. Баеп бара торган кояшның нурлары манара гөмбәзләрендә һәм хан сарае түбәсендә уйный. Урам буйлап сыер көтүе кайтып килә, хуҗабикәләре малларны каршы алып, кичке савымга әзерләнә. Тимерче учаклары сүнде. Су өләшеп йөрүчеләрнең кычкырган тавышлары тынды. Зур башкала, капкаларын ябып, ял итәргә җыенды.

Ашыкмый гына хакимнең сарае янына килеп туктадылар. Иван Данилович атыннан төшмәкче иде, капкалар ачылды һәм ул иярдә килеш ишегалдына үтте.

Сарай алдында кылычын салмакчы булды, хан сагының башлыгы салырга кушмады һәм балкып елмайды:

– Моннан соң сезгә хан янына корал белән керергә рөхсәт ителде.

Иван Данилович гаҗәпкә калды, күңеле тагын шик-шөбһә белән тулды, әмма чыраена чыгармады, җитез генә бусаганы атлады.

Үзбәк хан ялгызы гына тәхеттә утыра иде. Бары тәхет артындагы ерак почмакта ике сакчы басып тора. Бөек кенәз тезен бөкте, ханга сәламләү һәм мактау сүзләре әйтте, уллары бүләкләр китерде һәм тәхет каршына куйды.

Үзбәк хан Симеон белән кече Иванга китәргә ым какты. Аннары басты да Иван Даниловичны кочаклады:

— Мин сине көттем, Иван, бик көттем! Синен белән сөйләшәсем, күнелемне бушатасым килде. Авылына кайт, кызу итеп мунчанны як, иртәгә килеп житәрмен. Ханны себерке белән сыптырырга телисенме?

— Сыптырырга теләмим, ә рәхәтләндереп чабармын, — диде Калита, сөенечен тыя алмый.

Кенәз сарайдан бик канәгать чыкты, күнеле Үзбәкне зурлап җыр сузды. «Зирәк хан! Ай, бик зирәк!» — дип уйлады Иван һәм ияргә сикереп менде. Аллага гыйбадәт кылырга, башкарган эше өчен мактау сүзләре ирештерергә дип, атын чиркәүгә таба борды.

***

Тан атар-атмас зур мунчанын торбасыннан төтен күтәрелде. Актүбәгә таба чылбыр булып Бөек кенәз кешеләре тезелде, алар бер-берсенә салкын сулы чиләкләрне бирешеп, мунча алдында торган бик зур агач мичкәне су белән тутырдылар. Елга, күл өсләреннән сыек томан күтәрелде һәм тирә-якка таралып, гаҗәеп әкияти күренеш тудырды. Салкынча иртә кәефне күтәрде. Ятьмәләрен тикшерергә барган балыкчыларнын ишкәк тавышыннан өркеп, камыш арасыннан бакылдап, чыркылдап кошлар болыты күтәрелде. Кояш чыкты, иртәнге томан әкренләп югала барды һәм тирә-юнь элеккеге халәтенә кайтты. Күзләренә йокы эленгән кешеләр терлекләрен көтүгә кудылар, алар исә яна көн туганга сөенеп, дала ягыннан искән шаян җилгә каршы атладылар.

Бөек кенәз әле йокысыннан уянмаган, уллары исә күптән инде аяк өстендә, алар Бөек хан белән очрашуга әзерлек эшләре алып баралар иде. Барысы белән дә бүген генә егерме икесен тутырган Симеон җитәкчелек итте. Иван, абыйсын җентекләп күзәтте: уха өчен нинди балык сайларга икәнен карап торды. Кайсы бәрәннәрне чалырга икәнен карт чабан белән кинәштеләр, итне нинди казанда, кайчан пешерсәң яхшырак — барысын да мыегына чорнады кече Иван.

Пешекчеләрнең ипи һәм бөккәннәр пешерү өчен куәстәге камырлары кабарды, эчлекләр әзерләнде. Мичтән кәбестә шулпасының тәмле исе таралды. Бар да бөтерелде: җыештырдылар, өстәлләргә чиста ашъяулыклар җәйделәр.

Төшкә таба коньяк-көнчыгыш яктагы үр өстеннән тузан болыты күтәрелде — авылга озатып йөрүчеләре белән хан якынлашты. Кенәз үзенең уллары белән кадерле кунакны каршыларга чыкты. Инде җайдаклар үзләре дә күренде, шулвакыт кече улы Иван гаҗәпләнүдән кычкырып җибәрде:

— Атам, кара, юлда никадәрле елан!

Чыннан да, нык итеп тапталган дала юлының калкыбрак торган берничә җирендә кояшта җылынып, дистә тирәсе кара һәм җирән елан ята иде.

— Нигә булыр бу, атам? Начар фал түгелме? — дип сорады Симеон.

— Бу — кыш иртә килә дигән сүз. Салкын ояларына шуышыр алдыннан җылыналар, кабахәтләр. Начар фал түгел, борынгы юнаннар еланны зирәклек билгесе итеп дип санаганнар.

Ханны ике йөз сугышчы озата килде. Кенәз уллары белән аны тезләнеп каршы алды. Ике мәскәү гүзәле ханга ипи-тоз китерде. Үзбәк икмәкнең кырыен сындырып алды да тозга манып чәйни башлады.

— Тәмле! — диде хан, кулларына каравай тоткан чибәрләргә карап. — Әйдә, кенәз, мунчага алып бар, тәндәге һәм җандагы пычракны юып төшерик.

Мунча ишегең ачуга, тынны куырырлык эссе бәрелде, ана киштәләргә җәелгән яна чабылган печән исе кушылды.

— Барысын да мунчадан озат, кенәз, син бит мине үзең чабарга вәгъдә бирдең.

Үзбәк печәнне каплаган киндер тукыма өстенә ятты, кенәз таш өстенә су кушылган ипи куасы сипте, кайнар пар, тәннәрне пешереп, түшәмгә атылды. Кенәз тагын, тагын сипте, аннары кулына кайнар суда пешерелгән себерке алды, ханның тәненә кагылыр-кагылмас кайнар пар куды һәм чабарга тотынды. Хан тирләп чыкты, салкын тир күзен әчеттерде, астындагы киндер тукыма юешләнде, ә башында томан йөзде.

— Аз гына тын алырга ирек бир, сакаллы шайтан, алайса үтергәнче чабарсың, — диде Үзбәк көч-хәл белән.

— Минем арттан! — дип боерды тиргә баткан Калита.

Икәүләшеп өч йөз чиләк су сыешлы имән мичкәгә чумдылар. Салкынча су аларга шунда ук хәл кертте, башлары яктырды һәм халык язмышын хәл итүчеләр кабат чабыну бүлмәсенә үттеләр. Ханның тәненә инәләр калалды, аяк-куллары хәлсезләнде, себерке аркасы, күкрәге, корсагы буйлап йөрде дә йөрде һәм барлык уйларны читкә куды.

Мунчадан соң сәкегә сузылып яттылар. Үзбәк йокымсырап алды, чигәләреннән тир агуын дәвам итте. Бик нык сусаудан хан күзләрен ачты. Ул нарат җиләге куасы салынган чүлмәкне бер тында бушатты, өстенә коры киемнәрен киеп, зур өстәл янына килеп утырды. Иван хакимнең аякларын чалыштырып утырмакчы булуын күрде, әмма эссе мунча аның хәлен алган иде. Кенәз хезмәтчене дәшеп, биек ятак һәм тау кебек мендәрләр китертте. Үзбәк җайлап ятты, елмайды һәм ачы бал салынган тоткалы чүлмәккә үрелде. Ул аны тәмләп эчте, артыннан ит, балык һәм кәбестә бөккәннәреннән авыз итте, шатырдатып кара әче торма капты.

— Шәп! Монда булса да үз-үзең буласың. Аллаһ сиңа озын гомер бирсен кенәз Иван.

— Әй ханым, син һәр җирдә үзең булып кала аласың.

— Юмакайланма, кенәз. Нәрсә, син шулай булдырасыңмы? — хан күзен кысты.

— Кичер, ханым. Кичер юләрне.

— Шул шул менә! Тик син юләр түгел, Иван, кайчакларда мин синең акылыңнан, сабырлыгыңнан, кирәк җирдә үз сүзеңдә тора алуыңнан көнләшәм. Абыең Юрий кылыч селтәнгән булды, син коралсыз-нисез әнә күпме җир алдың. Ничектер берчак рәсем ясаучы осталарда булып, шаккатып карап торган идем. Алар җирлеккә кызыл, зәңгәр, яшел буяулар сылап күзәнәкләрне тутыралар, карыйсың, менә дигән матур сурәт килеп чыга. Мин шунда ук сине исемә төшердем. Син дә шулай авылларны сатып аласың, алар арасындагы буш урыннарда калалар һәм салалар саласың. Зирәклек! Бүген миннән ни сорасыңны белми дип уйлыйсың? Әсир полякларны һәм литвалыларны сатуымны телисең! Шулай түгелме?

— Шулай хакимем, сораячакмын. Җирләр буш ятарга тиеш түгел, алар — халыкны, ә халык безне туендырырга тиеш.

— Нәкъ менә шуның өчен яратам да мин сине, Иван, һәм күп нәрсәңне кичерәм. Минем бәкләр бәге һәрвакыт әйтә: «Мәскәү кенәзе ныгый, урыста озакламый күп сугышчылар үсеп житәр һәм алар безгә каршы яу чабар», — ди. Ә мин ышанмыйм. Бәлки, ышанмый ялгышамдыр? — Үзбәк хәйләкәр елмайды.

— Алла сакласын, ханым! Яхшылыктан яхшылык эзләмиләр. Син миңа бар нәрсәне бирдең: башка кенәзләр өстеннән хакимлек тә, ясакны үземә җыярга мөмкинлек тә, гаскәр белән ярдәм итәсең. Рәхим-шәфкатең өчен рәхмәт сиңа, Үзбәк хан! Үзең әйткәнчә, мин юләр түгел, әмма Тверь кенәзе дә түгел.

— Ә нәрсә булган Тверь кенәзенә?

— Кичер, хан, әйтергә теләмәгән идем, ул Литвага илчеләр юллаган. Ничек килешкәннәрдер, анысын белмим, Александр Гедеминны Урдага яуга чыгарга өндәгән. Кенәзлегеннән дә имеш-мимешләр килә: кенәз тынычлана алмый, кабаттан элеккегә ябышкан: «Дус дустын һәм туган туганын якларга, татарларга бирмәскә тиеш, бөтенебез бер булып аларга каршы торырга, урыс жирен һәм барлык православ гыйсавиларны сакларга тиешбез», — дип әйтә икән.

— Эт икән! Котырган эт икән бу Александр! Сөйрәлүче хәшәрәт, әмма башсызы, — дип ярсыды Үзбәк. — Православ гыйсавиларны мин якламыйммы? Көнбатыш урыста православ динен яклап, Рим папасын акылын утырткан мин түгелме? Бөтен Урда буйлап урыс чиркәүләре тора, һәм мин иманлы мөселман, шуна түзәм. Түзәм генә дә түгел, яңаларын төзергә рөхсәт бирәм... Бу эт миңа әйтте: «Менә башым, әгәр теләсәң — чап», — диде. Хәзер инде телим, башын гына түгел, төбе-тамыры белән юкка чыгарам мин аны. Урдада тверьлеләрнең эзе булмас.

Ханнын күзен кан басты. Әгәр тегесе шул мизгелдә кулына эләккән булса, шунда ук башсыз калган булыр иде.

— Тынычлан, хөрмәтле ханым, бу борча синең чәч бөртегенә дә тормый. Ачы балдан авыз ит, тынычландыра ул, аннары тагын чабынырга. Бүген андый этләр турында онытып торыйк.

Кайнар мунча килеште. Үзбәк ашыкмый гына ачы бал эчте, яраткан сусыл бәрән итен капкалады һәм күз яшьләрен эченә йотты. Иван Данилович берни сизмәгән кыяфәт чыгарды, үзенен ата-бабаларының тормышыннан кайбер тарихи истәлекләр сөйләде. Хан әкренләп тынычланды, савыттагы куасны төбенә кадәр эчеп бетерде.

— Син минем кайчан үз-үзем булуымны беләсеңме? Чиркәс тауларында бабам Елбаздук тәрбиясендә булганда, сугышчы булырга өйрәнгәндә йолдызларга бактым һәм кодрәтле хан булырга хыялландым. Ул чакта минем чын дусларым күп иде, аларга миннән, миннән аларга берни кирәкмәде, дәрәҗә, намусыбыз бар нәрсәдән өстен иде. Ә хәзер без синең белән, кенәз, ау лачыннары сыман: томшык та, канатлар да бар, кайда телисең — шунда оч, нишлисең килә — шуны эшлә, әмма юк! Миндә — Урда, синдә — кенәзлекләр. Алар, тәҗрибәле аучы кебек, кая кирәк — шунда җибәрәләр, һәм без җирдә канлы эз калдырып очабыз, башкача эшләп булмый — Аллаһ безне шундый тәкъдир белән бүләкләгән. Аллаһы Тәгалә Туктайга мине бәрән кебек суеп ташларга да рөхсәт итә алган бит, юк, ул мине хан иткән. Шуннан кая китим, менә кол корабны агымга каршы өстерәгән шикелле, шул бауны тартам. Син дә урыс халкын өстерисең, Иван. Шулай булгач, әйдә, тату гына бергәләп тартыйк.

— Мин бу турыда күптәннән уйлыйм. Ләкин ничек итеп ханга дуслык тәкъдим итәсең?

— Менә хан үзе сине дусларча яшәргә чакыра. Телисеңме, хәзер үк туганнар булабыз?

Үзбәк өстәлдән үткен пычак алды, сул кулы беләзегеннән өстәрәк сызып җибәрде һәм кан бәреп чыкты. Хан пычакны Бөек кенәзгә сузды, анысы да уйлап-нитеп тормый шуны ук кабатлады. Үзбәк үзенең ярасын кенәзнекенә куйды, аларның каннары кушылды һәм бер тамчы булып өстәлгә тамды, аннары икенчесе, өченчесе...

— Хәзер, кенәз, без мәңгегә ир туганнар булдык, кирәк булганда бер-беребез өчен гомеребезне бирергә тиешбез. Таулылар болай ди: «Гомереңне сат — намус сатып ал!». Ә намуссызларга һәм сатлыкларга — үлем!

Кунаклар кочаклаштылар, намусны һәм тугърылыкны сакларга ант биреештеләр, бар нәрсәне килешеп эшләргә сүз куештылар.

Кунаклар торып бастылар һәм дуслык, гаделлек өчен бирәр савыт бал эчтеләр. Иван, өстәлдәге кан тамчыларына карап, уйга калды:

— Менә урыс каны белән монгол каны кушылды, — диде.

— Ул күптән кушылган инде. Игътибар белән мина кара әле. Мин кем? Ата-бабаларым буенча – монгол, ә миндә монгол каны әллә ни күп түгел. Бабам Мәнгүтимернен, атам Тогрылнын анасы — чиркәс, хатыным Тай-туглыда — осетин белән төрек каны, шуна минем балаларым монголга бөтенләй охшамаган диярлек. Динне шулай ук гарәпнекен алдык, тик аныбыз белән без монголлар һәм бу дөньяны монголлар булып кичәрбез. Ә сездә, урысларда, хакимлеккә варяглар килгәннән соң күпме кан катышты? Сезнен тамырларда бәҗәнәкләр, фин, алман һәм башкаларнын каны ага, тагын кыпчак һәм монголныкы өстәлде. Күпме монголны канатын астына алдын, Иван, күпмесен чукындырдын? Дәшмисен? Әйтер сүзен юк. Жир йөзендә бөтен кан катышып беткәндә, без инде бу дөньяда булмабыз. Кешеләрнен күзе, чәче, буй-сыны – һәммәсенеке охшаш булыр. Менә алар үзләрен кемнәр дип атарлар – монголмы, урысмы яисә литвалымы, аерма юк. Ин мөһиме: алар бер-берсенә карата нинди мөнәсәбәттә булырлар, бәлки начарлыкны жинәрләр, баш кисүнен кирәге дә калмас...

Кенәзнен уллары һәм сак башлыгы бары иртәнге якта гына жинел сулыш алды, балдан һәм сөйләшүләрдән тәмам арып, ниһаять, кунаклар урын җәяргә боерды.

Өч көн дә узмады, Үзбәк Александр Тверскийны чакырырга әмер бирде.

— Мәгәр кенәз тиз кыймылдасын, — дип боерды ул илчегә.

***

Александр Михайлович төш күрде, имеш, ул атка атланып, шәрә һәм коралсыз килеш озын дала юлы буйлап бара. Баш өстендә әйләнгән козгыннар тора-бара ана һөҗүм иттеләр. Кенәз селтәнеп тә карады, качып котылмакчы булып атын да каулады, әмма козгыннын ин зурысы җаен табып анын баш түбәсен чукып алды. Кенәз Тверский шабыр тиргә батып, сикереп торды, аннары инде ятагында күпме генә боргаланса да күзенә йокы эленмәде. Көне буе төшенке кәеф белән йөрде. Башында: «төш нигә юрарга икән», — дигән уй гына бөтерелде. Ә кичкә таба хан илчесе килеп төште:

— Бик тиз генә хан янына элдерт, кенәз. Хан сина ачулы, бик ачулы.

Кенәз озак юлдан килгән илчене ашатты-эчертте, бүләкләр бирде, шул арада сораулар бирергә дә өлгердерде:

— Мәскәү кенәзе Иван Урдада озак булдымы?

— Үзем күрмәдем. Бары шуны гына беләм, хан анын биләмәсенә барып, берничә көн торып кайтты.

— Монысы өчен дә рәхмәт. Син кайта тор, ә мин ханга бүләкләр җыйыйм да артыннан ук кузгалырмын.

Александр бик тиз җыена башлады, әмма башта улы Федорны, үзенен ышанычлы урдалы дусларыннан нәрсәнен ничек икәнен белешергә дип, Яна Сарайга җибәрде. Бер атнадан сон, хан, хатыннары, балалары, ана якын әмирләре өчен бүләкләрен төяде. Күргән төше күнеленнән китмәде, ул борчулы халәттә, юлга кузгалды.

Көннәр җылы, әмма янгырлы, дала баткакка әйләнгән, кенәз Тверский исә ашыкты. Әле ярый Федорнын башы эшләгән, ул атасын Актүбә янында көтеп торган, әйбер-сәйберләрен караларын салларга күчерделәр дә агым уңаена тиз арада килеп җиттеләр. Улы атасына мондагы хәлләр турында ачык кына берни әйтә алмады, ханнын ни өчен ярсулы икәнен белү дә белми икән.

Иртәгесен иртән Александр Котлыгъ Тимер һәм Тай-туглыга үзен кабул итүләрен сорап хатлар җибәрде. Бер көннән соң ул бәкләр бәге янында иде.

Котлыгъ Тимер Сарайчык елгасының югары агымындагы тирмәсендә кайгылы кыяфәттә Литва һәм Смоленск кенәзлекләре ягыннан ишетелгән начар хәбәрләр турында уйланып утыра иде. Гедемин Смоленск кенәзе белән яуга әзерләнә, язын яу чабарга уйлыйлар, тик кемгә каршы – монысы билгесез иде. Александр керде, ханның кодрәтле вазиренә данлау сүзләре әйтте, бүләкләрен тапшырды. Хуҗа бик кырыс иде.

— Нәрсәгә килден? Нинди хәбәрләр белән?

— Хәбәрләр юк. Хан чакырган, нәрсәгә икәнен әйтмәгән.

— Син хәйләләмә, күптән аңлагансыңдыр. Монда синең дошманың Мәскәү кенәзе Иван булды, хан белән бик озак сөйләште. Шуннан безнең хан үзгәрде, күнеле күтәрелде, күп әмирләрне бүләкләде. Иванга православ чиркәве салдыру өчен, үзенең сараеннан ерак түгел җир бүләк итте. Ә сине чакыртырга илче җибәргәндә, бик ярсыган иде.

— Хан белән очрашырга ярдәм итче, хөрмәтле һәм кодрәтле бәкләр бәгем.

— Вәгъдә итә алмыйм, әмма әйтеп карармын. Ә хәзер үпкәләмә, кенәз, дәүләт эшләре күп. Хан белән сөйләшкәннән соң, үзем ым кагармын.

Александр Михайлович кешенең уен укый белмәсә дә, вазирнең кәефенә карап, бу очрашудан мәгънә юклыгына төшенде.

Тагын бер көн артта калды. Кенәзне Тай-туглы чакырып алды. Сарайның хатын-кызлар ягы янәшәсендәге зур залында ханбикә тәхетне хәтерләткән, әмма әллә ни купшы бизәлмәгән биек урындыкта утыра иде.

Александр тезләнде:

— Әй бөек ханбикәм, Урда һәм урыс халкының анасы, барлык бәхетсезләрнең яклаучысы. Аллаһы Тәгалә сина озын гомер брсен!Синнән мәрхәмәтлелек сорыйм, ханбикә. Бөек ханны, безнең атабыз һәм яклаучыбызны ни белән ачуын чыгаруымны аңламадым.

Энҗе җепләр һәм көмеш коелмасы мәңге яшь, гүзәл ханбикәнең аягы янына килеп яттылар.

— Бас, кенәз, һәм Аллабыз белән ант ит, иремә каршы яманлык ниятләмәденме?

Александр Михайлович кабат тезләренә төште, чукынды һәм ант итте, аннары муенындагы тәресен чыгарды, аны үпте һәм янәдән ант итте.

— Торып бас, мин сина ышанам, хаким белән сөйләшермен, әмма ул артык ярсулы, нәрсә эшләдең – исенә төшер. Чиркәүгә бар һәм гыйбадәт кыл, исенә төшер һәм тәүбә кыл. Үзем хәбәр бирермен.

Тай-туглы һәм Котлыгъ Тимер хан янында бер үк көнне булдылар. Бәкләр бәге Үгәдәй һәм Чыгатай олысларындагы хәлләр турында җиткерде, анда кабат хакимият өчен ызгыш-талаш башланган икән. Хан бу хәбәрләрне колак артыннан уздырды. Литва һәм Смоленск кенәзләренең килешүе турында ишеткәч, тәшвишкә калды.

— Менә күрәсеңме, туганым, — диде ягымлы, әмма бераз мыскыллы тавыш белән хан, — бу берлеккә Тверь кенәзе дә кушылса? Мондамы ул? Килеп җиттеме?

Котлыгъ Тимер башын селкеде.

— Яхшы булган! Мин бу этнең башын чабам. Саклагыз аны! – дип, аяк типте хан. – Мәскәү кенәзенә гаскәр бирәм, Смоленскины үзе тәртипкә салыр! Иван — менә дигән кеше һәм ышанычлы кенәз.

Бәкләр бәге тәҗрибәле түрә буларак, хәзер бернинди сораулар һәм үтенечләрнең урынсыз икәнен бик яхшы аңлады.

Тай-туглы ире янына кичке намаз алдыннан килде. Үзбәкнең кәефе күтәрелгән иде инде, ул хатынын елмаеп каршылады:

— Карап туймас чибәрем, сине күрүемә бик шатмын! Сөекле хатыным белән бүген кич күрешермен дигән идем, ул үзе минем янга килде.

— Кичкә мин әзер булырмын, ханым, кич һәм төнне Аллаһ безгә башка эшләр өчен биргән.

— Син дәүләтебез эшләре белән әз кызыксынасың һәм бик дөрес эшлисен, ул хатыннар эше түгел. Инде сорауларың туган икән, тынлыйм, шинмәс чәчәгем.

— Ачуланма, ханым, мин синнән Тверь кенәзе өчен үтенергә килдем. — Тай-туглы иренең йөзе үзгәргәнен күрде, әмма сүзен дәвам итте. — Аңлавымча, аңа яла якканнар. Моны кем эшләгәнен дә беләм. Мәскәү кенәзе Иван! Төлке кебек хәйләкәр, елан кебек зирәк кеше, өстәвенә аңа торган саен күбрәк тә күбрәк кирәк. Нигә дип көч туплый ул? Урыс җирләрен ник берләштерергә тырыша? Көче җитәрлек булгач, Урдага ташланыр һәм шундый итеп орыр!

— Мәскәү кенәзенең ниләр майтаруын мин күрми, белми дисеңме әллә? Беләм, тик Иван миңа беркайчан да кулын күтәрмәячәк! Ишетәсеңме, беркайчан!

— Әй ирем, син моңа ышанасыңмы?

— Ышанам! — Үзбәк хатынына төзәлергә өлгермәгән ярасын күрсәтте.

Тауларда туып-үскән хатынга башка берни дә аңлатып торасы юк иде. Кан белән ант итешкән ирләр дуслыгыннан нык тагын ни бар?!

— Җәза бирү көне билгелеме? — Тай-туглы төшенке тавыш белән сорады.

— Әйе. Тверь кенәзенә һәм аның улына хөкем карары айның соңгы көнендә җиренә җиткереләчәк.

Тай-туглы Александрга җавабын озакка сузды, аның өметен сүндерәсе килмәде. Җәзага бер көн кала гына атчабарын җибәрде.

— Ханбикәгә анысы өчен дә рәхмәт, якыннарым белән хушлашырга, нәсел буенча соңгы күрсәтмәләр бирергә мөмкинлек бирде, — диде үз тирәсендәгеләргә кайгыга баткан кенәз.

Җәзалау көнендә Александр Михайлович иртәдән гыйбадәт кылды, тәүбә итте һәм көтә башлады. Озак көтәргә туры килмәде, аңа җәлладлар килүен хәбәр иттеләр. Алар улы Федор белән кочаклаштылар, бәхилләштеләр һәм үзләрен үтерәчәк кешеләрнең каршына чыктылар.

Тиздән Тверь кенәзенең улы белән бергә җәзалап үтерелүе турындагы хәбәр урыс җирен әйләнеп чыкты һәм елъязмачы болай дип язып куйды: «И схватили их, и розняли по составам».

Александр Тверскийның бу дөнья кешесе булмавына инангannan соң, Симеон энесе Иван белән, тагын бер урыс кенәзенең гомерен өздерткәне өчен халык ачуыннан һәм имеш-мимешләрдән сакланып, күптән Мәскәүгә кайткан аталары янына кузгалдылар. Александрның үлеме турындагы хәбәрне Мәскәүдә шатлык, куаныч белән каршы алдылар. Тверь исә тирән кайгыда иде, аның халкы Урдада үтерелгән кенәзләр — Михаил, Дмитрий, Александр һәм Фёдорны кызганып елады.

Әмма Бөек кенәз Иван Калита моның белән генә тынычланырга җыенмады, ул тверьлеләргә тагын бер куркыныч һөҗүм ясады. Изге Спас соборыннан чаңны алып Мәскәүгә китерергә боерды. Бу инде ачыктан-ачык мыскыл итү иде. Тверьдә Мәскәү кенәзләре һәм аларның нәсел дәвамчылары исеменә каргыш яудырдылар.

***

Үзбәк хан атчабарлары Бөек кенәзгә ашыгыч хат китерде, анда ана бөтен Урда гаскәре башлыгы Тәнбәк белән очрашырга, күпме кирәк шуның кадәр гаскәр алып, урыс дружиналарын өстәргә һәм Смоленскига яу чабып, Литва канаты астына борын тыгарга җыенган кенәз Иван Александровичка әйбәтләп сабак бирергә дип язылган иде.

Кышның язга авышкан чагы, әмма каты суыклар чигенергә уйламады, даладагы инкүлекләрне һәм сызаларны кар белән күмде. Төннәрен салкыннан дала янгырап торды, анда көн күрүчеләрнең барысы да өннәренә кереп яшеренде, ач бүреләр улады, алар куркуларыннан кая барып бәрелергә белмәгән куяннарны эзәрлекләде. Ә көндезләрен кояшның туры нурлары кар өстен изрәтте, аның өстендә төлкеләргә тынгы бирми дала тычканнары әрле-бирле килде.

Көньяк-көнчыгышка юнәлгән җайдакларның күзен камаштырып, кар бөртекләре җемелдәде, Бөек кенәз Үргәнеч тирәлегендәге Тәнбәк ставкасына бара иде. Урыслар күптәннән ерак яу сәфәрләренә тәбәнәк монгол атларында чыгарга гадәтләнделәр, чөнки тегеләр тирән кар астыннан да үзләренә азык таба иделәр, су урынына исә рәхәтләнеп кар ашадылар. Отряд барган саен көньяккарак авышты, кар азайды, шәрә калган калкулыклар урман ягы кешеләренә соры, пычрак тоелды. Әмма озакламый манзара үзгәрә башлады, яна яшел үлән күренде, дала куакларында беренче яфраклар күзгә чалынды, юлчылар максатларына якынайдылар.

Варисның ставкасына килеп җиткәндә, күктә йолдызлар кабынган иде. Иван Данилович шунда ук яшь хан янына үзен кабул итүен сорап атчабар җибәрде. Әмма Калитаның хатына Үзбәкнең кияве Һарунбәк җавап бирде, ул Тәнбәкнең нык аруын һәм хәзерге вакытта ял итүен хәбәр иткән иде. Кабул итү көне кенәзгә хәбәр ителер, дигән. Өч көн узды, әмма чакырган кеше булмады. Калитаның башка көтәр вакыты калмады.

«Нишләргә? — дип фикер йөртте ул. — Мин монда кунакка түгел, хан кушуы буенча килдем. Урдада минем дәрәҗәм олыс бәгеннән түбән түгел, югарырак та булмагае әле, ә варис мине кабул итми маташа».

Иван алай да, болай да үлчәп карады, тик Тәнбәкнең үзен ник түбәнсетүенә төшенмәде. Икенче көнне бүләкләр алып чакырылмаган җиргә үзе китте. Кенәзне шунда ук Һарунбәк янына уздырдылар, тегесе әллә ни ачылмаса да, Иван Даниловичны элеккеге дусты буларак зур хөрмәт белән каршы алды.

— Вакытсыз килдең, кенәз. Көтәргә туры килер.

— Нәрсә көтәргә? Эшләр ашыгыч.— Иван ханның хатын сузды, Һарунбәк аны укып чыкты, озак кына дәшми торды һәм башын иеп әйтте:

— Яхшы, кенәз. Без капчыкта ятмый, диләрме? Тәнбәк ике атна инде айнымый эчә. Тагын күпмегә сузылыр — әйтә алмыйм. Элегрәк өчәр атнага суза иде, ә соңгысында ай буена айнымады. Әйдә бергә барабыз, үз күзең белән күрерсең.

Әмир һәм кенәз Тәнбәк тирмәсенә керер алдыннан коралларын тапшырдылар һәм эчкә уздылар. Варис дәстархан янында шәраб таплары белән буялып беткән халаттан аунап ята иде. Дингездә давылга эләккән кораб сыман, тоныкы күзе чокырында чайкала, менә ул янына керүчеләргә карап алды, зәңгәрләнгән борыны очлаеп, кипкән авызы җәелеп китте:

— Утырыгыз минем янга, шәп шәраб салам.

Кунаклар дәшмәде, алар аңа җирәнеп, борчылып карадылар.

— Минем белән эчәргә боерам.

— Шәраб эчәр чак түгел, ханым. Күңел ачар вакыт түгел, — дип сабыр гына җавап бирде Иван Данилович. — Атаң, Бөек Үзбәк хан, Смоленскины яуларга әмер бирде.

— Атам боерганмы, юкмы — анда эшем юк, мин эчәргә телим, сезнең белән эчәргә телим.

— Акылыңа кил, хан! Минем ни әйткәнне яхшы аңладыңмы? — диде тавышын күтәреп Калита.

Тәнбәкнең күзе кысылды, ул терсәгенә таянды һәм үкереп җибәрде:

— Ах син, мәскәү эте! Корчаңгы эт! Кемне өйрәтәсең? Кемгә әмер бирәсең? Мин хәзер әмер бирәм! Әй, кем бар анда? Бу урыс этенең башын чабыгыз, өрмәсен!

Варис зур савыттагы шәрабны төбенә кадәр эчеп бетерде, сулыш алды, аннары дәстарханга борынын төртеп гырларга кереште.

Иван Данилович һәм Һарунбәк тирмәдән чыктылар һәм дәшми генә шактый озак атладылар. Беренче булып кенәз сүз башлады:

— Ни булуга карамастан, ханның фәрманын үтәргә кирәк. Бир, әмир, әмереңне. Смоленск өчен ун мең сугышчы җитәр дип уйлыйм. Тик меңнәрне кем алып барыр?

— Туглы-байдан да яхшыракны күрмим, шуны кушармын.

— Аңа Яңа Сарайга таба кузгалырга боер. Мин анда иртәгә иртән китәрмен.

— Ханга җиткерергә ашыгасыңмы, кенәз?

— Ә син, әмир, безне капчыкта яшереп тотармын дип уйлыйсыңмы? Хан болай да озакламый беләчәк, бездән башка да җиткерүчеләр табылыр. Син ханның хатын игътибар белән укыдыңмы? Анда гаскәрне Тәнбәкнең үзенә алып барырга әйтелгән. Ханны әзерләргә кирәк.

— Тәнбәк уянгач, миңа котырыр.

— Ә син барысын да миңа аудар. Ханның фәрманын алып килде һәм үзе әмер бирде диярсең. Барыбер исерек варис берни хәтерләмәс.

Иван Яңа Сарайга якынлашты. Иксез-чиксез далада яз хөкем сөрә, һавага яңа типкән үлән, иртә чәчәк атучы гөлләр, ачы әрем һәм татлы төчетамырның хуш исләре таралган. Күктә дә, җирдә дә, тирә-юньгә хәбәр салып, кошлар туй үткәрәләр. Башкала кенәзне үзенең шау-шуы, ыгы-зыгысы белән каршылады. Сәүдәгәрләр беренче язгы кәрваннарын алып килергә дә өлгергәннәр. Сәүдә рәтләре шыгрым тулы, кызып-кызып шәрык сатыш-алышы бара иде. Кенәз ханга һәм Тай-туглыга дип бүләкләр алды. Нәкъ менә аның белән, Тәнбәкнең анасы белән, алда зур, авыр сөйләшү тора иде.

Үзбәк хан якын көннәрдә үзенең яраткан юлы буенча биш түбәле тауларга таба күченергә җыенды, ул Иван Данилович Яңа Сарайга килеп чыгар дигән уйны башына да китермәде, шуңадыр, сарай капкаларын тиз генә ачмадылар.

Сакчылар кенәзгә, үлмы-түгелме дигәндәй, озаклап карап тордылар. Хан да тиз генә кабул итә алмады.

Сәлам биреп, данлау сүзләре әйткәннән соң, кунаклар кочаклаштылар. Үзбәк аның килүенә гаҗәпләнде.

— Син инде Смоленскига җитеп киләсең, дип торам. Берәр нәрсә булдымы? Безгә кемдер һөҗүм итмәгәндер бит?

— Шайтан үзе безгә сугыш ачты, ханым.

— Шайтаннар кешегә бәла-каза тудырыр өчен генә туганнар бит. Ник килдең?

— Аларның нинди афәт китергәнен сөйләмәкче идем.

— Әйдә, сөйлә! Ник сузасың?

— Улың Тәнбәк исереп ята! Якты көнне күрерлек, бер нәрсә уйларлык хәлдә түгел.

Үзбәк башын иеп тын калды. Мие эшләүдән баш тартып, күзләре калайланып чыктымыни. Иван Данилович та дәшмәде, әйтерсең барысына да үзе гаепле. Кинәт Үзбәк акылына килде һәм кычкыра башлады:

— Хатчыны чакырыгыз!

Хатчы атылып керде дә хан алдында тезләренә төште.

— Утыр да яз!

Пөхтә түрә куенынннан күн белән тышланган язу әсбаплары чыгарды, пыяла кара савыты белән каләмне алды, кәгазьне җәеп салды һәм ханга текәлде. Үзбәк тимер кебек чыңлап торган тавыш белән әйтеп яздырды:

— Үлемсез Аллаһы Тәгаләнең көче һәм иреге, бөеклеге һәм мәрхәмәте белән, безнең барлык Бөек һәм урта кенәзләргә, әмирләр, зур түрәләр, воеводалар, безнең бөтен олысларда, Үлемсез Аллаһ көче белән, идарә итүчеләр һәм безнең сүзне тотканнарга әмер бирәм:

Улыбыз Тәнбәкне моннан соң Урда гаскәре башлыгы итеп санамаска. Варис намусына лаеклы булмаган хурлыклы эшләре өчен, аның фәрманнарын үтәмәскә. Бу мәсхәрәле эшләре аркасында, ул алга таба Хәрәзм олыс бәге булмаячак. Үргәнечкә олыс бәге итеп киявебез Һарунбәкне билгелим. Тәнбәккә Һарунбәк янында булырга боерам. Барысына да Тәнбәкне безнең улыбыз буларак санларга. Әгәр кем дә кем, улымның дәрәҗәсен хөрмәт итеп, аңа шәрабмы, сырамы, балмы салып бирә, шул Һарунбәк тарафыннан җәзага тартылачак. Һарунбәккә һәрвакыт Тәнбәк янында булып, аны яман гадәтләрдән сакларга.

Хатчы ноктасын куйды, һәм бөгелә-бөгелә чыгу юлына ашыкты.

— Утыр, Иван. Син Хәрәзмнән гаскәр китердеңме, әйт?

— Ике көннән Яңа Сарайда булачак, аны Тугъла-бай алып килә.

— Тугъла-бай яхшы полководец, башы бар. – Хан сүзен бүлеп, уйга калды. – Сине, Иван, Смоленскига сәфәрдән азат итәм. Урыс кенәзләреннән кемне җибәрергә?

— Иван Коротопол Рязанский белән Иван Друцкийны, алар башкарып чыгачак, дружиналары көчле. Мин үзем дә аларны бу сәфәргә тартырга теләдем, инде әзерләнәләр.

— Иван Смоленскийны минем янга аркан белән тарттырып китерсеннәр, рәхмәтсезнең күзенә багасым килә. Гедемин белән иснәшергә теләгәнме, менә мин аның борынын өзеп атам... Ә син иртәгә Тай-туглы янына бар, тынычландыр аны, ана кеше улы өчен һәрвакыт күзеннән яшь koяр.

— Барам, ханым, иртәгә үк барам.

Тай-туглы Калитаны күл ярындагы чатырда кабул итте. Кенәз, тирә-яктагы тынлыкка, ялтырап яткан чиста агымсуда уйнаган кояш нурларына, үзләрен мәгърур тоткан аккошларга сокланып, агач басмалар аша атлады. Кошларның күлдә чумып-калкып уйнаган балыкларга муеннарын тәкәббер генә боруларын күреп, гаҗәпләнде.

Бу чәчәккә төренгән язгы манзарага һаман да яшь, сылу ханбикә гаҗәеп ятышып тора иде. Тай-туглы бервакытта да киң монгол халаты кимәде, өстендәге күлмәкләре аның шөпшәнеке кебек нәзек билен, матур түгәрәк ботларын ассызыклап торды. Дулкынланып торган кара чәч белән каймаланган ап-ак бите теләсә кайсы ирне үзенә җәлеп итә иде. Ханбикәнең чибәрлегенә сокланып атлаган Иван, инде ничәнчедер мәртәбә сөртенде.

— Аяк астына кара, кенәз, — дип шаяртты аны Тай-туглы.

Иван Данилович чатырга керде, тезенә чүкте:

— Сәлам сина, бөек ханбикә, Аллаһ сина озын гомер бирсен!

— Сәлам сина да, кенәз! Исәнме, хөрмәтлем. Сарайга сине нинди җилләр ташлады? Мин инде улым белән бергә Смоленскины акылга өйрәтәсездер дип уйлаган идем.

— Мин дә шулай булуын теләгән идем, ханбикәм.

— Ни комачаулавы инде?

Иван Тай-туглының сүзне озынга сузуны яратмавын белә, шуңа бер тында әйтеп салды:

— Улың комачаулады.

Гүзәл йөзендәге бер мускулын да селкетмәде. Эчтә ниндидер бер кылы тартылып килде, күзеннән салкынлык бөркелде.

— Тагын хурлыклы эшенә тотынганмы?

Кенәз баш какты. Тай-туглы чатыр кырыена килде, култыксага таянып, күлгә күз салды һәм, өстеннән авыр йөкне алып ташлагандай, кинәт тураеп басты.

— Карале, кенәз, нинди нәфис кошлар бу аккошлар — барлык кошларның патшалары, алар матур гына түгел, көчле дә әле. Беләсеңме, элек монда күпме үрдәк оя корды? Исәпсез-сансыз, аннары бу урынны аккошлар ошатты һәм үрдәкләрне куып җибәрделәр, син урыс җирләрен үз кулына алган кебек, болар да күлне яулап алды. Минем ирем Үзбәк һәм син дә, аккошлар кебек матур, көчле кешеләр, ә Тәнбәк улымның матурлыгы гына бар. Ана тәхеттә урын юк! Юк!

Тай-туглы кискен генә өстәлгә борылды:

— Утыр, кенәз, чәй эчәбез. Син бу кытай эчемлеген яратасыңмы?

— Мин аны сирәк эчәм.

— Алайса, менә эч. Искиткеч эчемлек, кәефне күтәрә, ә кипкән кавын яки өрек белән тагын да тәмлерәк.

Алар озаклап чәй эчтеләр, Яңа Сарай, аның матурлыгы, төзеләсе православ чиркәве турында сөйләштеләр. Кенәз бу әңгәмәнең Тәнбәк белән булган баладән читкә китәргә тырышу икәнен аңлады.

— Әйт әле, Иван Данилович, — диде ханбикә борчылып, — Сездә, исерткеч эчемлекләр күп эчәләрме? Көн саен эчә торганнары да бармы? Андыйларын ничек дәвалыйсыз?

— Ул чирдән дару юк, гыйбадәт кылсаң һәм чиркәүгә корбан бирсәң генә. Бу чирне Алла барлыкка китергән, дәвалау юлын да бер ул гына белә. Гыйбадәт кыл, ханбикә!

— Алла сакласын сине, кенәз Иван! Син, чыннан да, безнең гаиләнең дусты, юмакайланмыйсың һәм мәкерле түгелсең. Рәхмәт, кенәз. Син бар, юлыңда бул, ә миңа уйларга кирәк, бәлки шаман хатынны эзләргә туры килер.

— Уйла, ханбикәм. Нәселеңә ни язган, шул була. Мин моны бик яхшы беләм.

Иван Данилович китәргә кузгалгач, башын югары күтәреп карады, кояш инде биектә, җир кызган, ә бәхетле кошлар чыркылдашалар иде. «Менә эшлексезләр, — дип уйлады ул, — тычкан тоталар да бала чыгаралар. Ә син балаларны уйлап төннәр буе йокламыйсың. Минекеләр белән ни булыр? Симеоны ичмаса чакматаш кебек, Иваны — чүпрәк, теләгән ягына борып була. Менә шулай ул балалар! Тәңре аларга җиңелрәк язмыш насыйп итсен!».

Уйларына чумып атлаган Иван үзенә таба якынлашкан Котлыгъ Тимерне абайламый калды.

— Кенәзнең башына нинди уйлар төште?

— Уйламаслыкмыни, шанлы бәкләр бәге? Балалар турында уйлыйм, аларның язмышы хакында.

— Минем йортка барыйк, утырырбыз, сөйләшербез.

Калита беренче тапкыр кодрәтле вәзирнең өенә аяк басты. Элегрәк гел күченеп йөргәндә очраштылар. Бәкләр бәгенең утары һәм сарае хан корылмаларыннан әллә ни калышмаган, кенәз мона аптырамады. Ник гаҗәпләнергә, ханның дусты һәм туганының акчасы аз түгел, өстәвенә кыйммәтле бүләкләр килеп тора.

— Хан сине эзләргә җибәрде, кенәз, ул синең Тай-туглы янында булуыңны белде. Өенә кайтырга ашыкмаска, авылыңда яшәп торырга кушты, озакламый син ханга кирәк булачаксың. Нәрсәгә — анысын әйтмәде, мин дә белмим. Шулай итеп кайт та ял ит, Иван, — дип елмайды Котлыгъ Тимер.

— Нинди ял монда! Мәскәүдә эшләрем күп калды. Әле ярый, сәфәргә җыенганда, балаларга күрсәтмәләр биреп калдырдым. Хан яудан азат итте дип шатланган идем, хәзер күрәсең, икенчесе белән утыртты.

— Эш бөре түгел, урманга качмый. Ял ит, кенәз, берни турында уйлама. Минем җиянем Һарунбәк турында сөйләсәң иде.

Иван бәкләр бәгенең җияне турында гына ишетәсе килмәвенә төшенде һәм күндәм генә җавап кайтарды:

— Һарунбәк – менә дигән кеше, сина охшаган, матур, зирәк, бик тиз аңлап ала, эшләрен дә әйбәт башкара һәм вариска да күз-колак булып тора.

Кайсы яклап кына суктырып карамады Котлыгъ Тимер, ул Һарунбәккә карата мактау сүзләреннән тыш берни әйтмәде.

«Үзенә кирәкне хан фәрманыннан укыр, сорый икән, димәк, Үзбәк әлегә ана житкермәгән. Хакимнән алда ник кысылырга?» – дип фикер йөртте кенәз һәм тагын бәкләр бәгенең җиянен мактауга күчте.

***

Бөек кенәз ике көн ял итте, Актүбәдәге хуҗалыгын карап чыкты. Дилбегәсен аз гына бушайта төшүгә, Үзбәктән атчабар килде һәм хан яраннары белән Богдо тавына таба кузгалырга дигән әмерен житкерде.

Бу язгы дала буйлап искиткеч сәйран булды, тирә-якта — төрле төстәге лалә чәчәкләре, яшел үлән арасыннан ук кебек сиртмә койрыклар атылып чыга һәм, чыелдап, канатлары белән һаваны кисә. Көтү-көтү булып кыр кәжәләре утлап йөри, кышкы йокыларыннан уянып йомраннар чыккан һәм алгы аякларын күкрәкләренә кушырып, өннәре янында сакчылар кебек үрә катып торалар.

Ашыкмый гына бардылар, юл унаенда ата кыр кәжәләрен ауладылар, итле һәм пычак сабына куярга мөгезле булдылар. Ханның күчмә каласы Богдо изге тавына якынлашты. Җил белән Баскынчак күленең тозлы исе килеп бәрелүгә, хан туктарга боерды. Бар да, мәш килеп, тирмәләр, мәчетләр урнаштырып, мәйданнар, урамнар корып, каланы торгыздылар. Хан Тай-туглы, Иван Данилович һәм Котлыгъ Тимер белән аз сандагы сак озатуында тагын ун чакрымнар узып, тау итәгендә туктады. Биредә ханның артык зур булмаган лагере урнашкан.

Төшке ашны ачык һавада ашадылар, тауга карап сокландылар. Иван Калитага күбрәк Мәскәү янандагы күләгәле урманнар ошый иде, монда да иркен, унайлы, күнелгә тынычлык инә. Кенәздән аермалы буларак, табындашлары, ниндидер мөһим вакыйгага әзерләнгәндәй, игътибарын бер ноктага туплаган.

— Иван Данилович, — дип эндәште хан кенәзгә, — мин хатыным белән тау куышына керәм, безгә бер йола үтәү зарур. Сезгә Котлыгъ Тимер белән тауга күтәрелергә һәм күзәтергә күрсәтмә бирәм. Әгәр гадәти булмаган берәр нәрсә күрсәгез, исегездә калдырыгыз, ахырдан сөйләрсез.

Тауга сактан башка гына киттеләр. Кенәз тауга көнбатыш яктан, ә бәкләр бәге каршы яктан күтәрелделәр. Түбәсенә житәрәк, Иван Данилович күзәтү өчен уңайлы урын билгеләп, таш өстенә утырды һәм күкрәген тутырып иркен

сулыш алды. Югарыдан бар да ачык күренде, менә Үзбәк һәм Тай-туглы шаман белән сәлам алыштылар, йөрешенә караганда ул хатын-кызга охшаган, башында болан мөгезләре куелган зур башлык, кулында төнгер. Өчәүләшеп алар тау куышына керделәр. Кояш инде түбән тәгәрәгән, бары көнбатыштагы кызыллык кына калган. Кенәз төнгернең тонык кына дөмбердәвен һәм еракта вакыт-вакыт кабатланган кычкырып куйган тавышларны ишетте. Ул дикъкать белән куерып килгән карангылыкка карады. Һәм кинәт мәгарәгә керү юлында күз камаштыргыч зәңгәр яктылык кабынды, аннары күккә күтәрелде дә әкренләп көнчыгышка таба китеп югалды.

Хан белән Тай-туглы тау куышыннан ай калкып, тирә-юньне яктыртканнан соң чыктылар. Үзбәк ишарә ясады һәм акрын гына алга атлады, Иван Данилович һәм Котлыгъ Тимер таудан йөгереп төштеләр һәм хан каршында туктадылар, тегесе аларга сораулы карашын төбәде. Тау башында утыручылар бер үк төрле җавап бирделәр, икесе дә тау куышыннан очып чыккан яктылык нурының көнчыгышка таба китеп юкка чыгуын күргән. Канәгать калган Үзбәк хатыны белән ашыкмый гына алдан китте. Тай-туглы ханның колагына ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады:

— Бу яхшы! Бу улыбызга ярдәм итәр!

Калита үз чатырында үлгән кеше кебек йоклады. Кояш инде биеккә күтәрелде, табигать тә күптән уянды, хезмәтчеләр һәм сугышчылар иртәнге ашка утырдылар, ә кенәз йоклавын дәвам итте. Төш житәрәк, аны хезмәтче уятты:

— Торыгыз, кенәз! Хан сезне күрергә тели!

— Нәрсә булды? — дип сорады Иван, киерелеп.

— Белмим, хуҗам, күргәнемне әйтәм: таң алдыннан монда зур кәрван килде. Кояш чыккач, хан ниндидер кешеләрне кабул итте, карап торышка көнчыгыш сәүдәгәрләренә охшаган. Ә хәзер кичә артта калган күчмә кала монда килә. Хан сезгә үз янына килергә боерды.

— Бар, юынырга су әзерлә.

Кенәз тәмам уянып бетте, кәефе шәп иде. Ул инде эсселәнергә өлгергән саф һавага чыкты. Үзен тәртипкә китерде һәм хан янына юнәлде. Үзбәк аны гына көтеп торган шикелле:

— Иван Данилович, кушаматы Калита, Бөек кенәз, сине бүген күңелле вакыйга көтә, шул уңайдан күчмә каладагы бар кешегә сый-хөрмәт әзерләргә куш һәм кичке намаздан соң минем бәйрәм чатырыма килеп жит, — диде.

Үзбәк киң итеп елмайды, кенәз бу ниятнең чын күңелдән булуына һич шикләнмәде.

— Мин нәкъ вакытына әзер булырмын, хакимем.

Каланың урыс ягында бар да хәрәкәткә килде. Жайдаклар төрле якка таралышты. Төштән соң кыр кәҗәләре, тәкә, сиртмә койрыклар, мәрсин балыклары белән кайтып төштеләр. Бу вакытта учаклар яна, аларда көлчәләр пешә, казаннар кайнап утыра иде. Ни хакынадыр зур мәҗлес әзерләнде.

Кичке намаз тәмамланды. Үзбәк хан үзенең алтынланган юл тәхетенә утырды. Аркасының өске ягына һәм култыксаларына беркетелгән кыйммәтле ташлар батып барган кояш нурларында жемелдәде. Янында тындәшсез Тай-туглы балкып утыра. Урданың күчмә түрәләре һәм гаскәр башлыклары, ханны сәламләп, дәрәҗәләренә карап урнаштылар. Бар да жыелып беткәч, тәхет аскуймасы янына Александр Невскийның оныгы, Бөек кенәз Иван Даниловичны чакырып китерделәр. Ул якын килде, аның өстендә куе яшел төстәге, итәге кызыл каймалы кыска бәйрәм күлмәге иде. Жиңнәре беләзектән алтынланган жиңсәгә кысып бәйләп куелган. Күлмәк өстеннән кызыл аслыктагы күк төсендәге киеме уң инбашына алтын эләктергеч белән беркетелгән.

Иңбашларында — көмеш бармы, алтынланган путасына кыйммәтле ташлар белән бизәлгән кылыч, аягында бөгелеп торган очлы кызыл итекләр. Илле ике яшендә Иван Данилович әле шәп күренә. Бүреге чал чәчләрен яшергән. Кенәз тезен бөкте һәм хакимен сәламләде.

Үзбәк басты, Калитаны торгызды һәм кулыннан тотып тәхет аскуймасы кырына алып килде һәм кенәзне тәхет янына бастырды.

— Менә бу Бөек кенәз. Аның белән безгә, Чыңгызхан дәвамчыларына һәм аның Жучи улына Аллаһ Тәгалә бергә яшәргә боерды, һәм без инде тулы бер гасыр әкренләп бер-бербезне узып яшибез. Без бик күп урысларны үтердек, алар — монголларны, әмма безгә тыныч тормышка кайтырга, гомерлеккә дуслык урнаштырырга, Алтын Урданың бер халкы булырга вакыт житте, безнеке саналган бар яхшыны сакларга, аны башкаларга — монголдан урыска, урыстан монголга тапшырырга кирәк.Безнең нәсел артсын, алар дәүләтнең куәтен үстерсен. Без кенәз Иван белән моңа беренче адымны ясадык, гомеребезнең соңгы көненә кадәр агай-эне булдык, безнең балалар да, оныклар да һәм дәүләтебездәге бар халык та бер-берсенә шулай булсын. Дуслыгыбызның һәм Бөек кенәзлек хакимлеге билгесе итеп Иван Даниловичка бүрек бүләк итәм. Аны нәсел буенча тапшыра барырга боерам, канунсыз берәүнең дә бүрекне кияргә хакы юк.

Үзбәк ханның кулында бүрекнең матурлыгын күреп бар да телсез калды. Энже, асылташ, якутлар белән бизәлгән, тәресе дә куелган, алтын очлы башлы бүрек яктырткычлар яктысында балкып тора иде. Мондый матурлыкны әле монарчы берәүнең дә күргәне булмады. Үзбәк хан бүрекне Иван Даниловичның башына кидерде.

— Сине Аллаһ Тәгалә сакласын!

Хаким кенәзне өч мәртәбә үпте. Хуплаган һәм шатлык авазлары киң далага таралды.

Мәжлес шәп булды! Мәжлес күңелле булды!

Бары икенче көнне генә ниләр булганы Иван Даниловичның башына барып житте. Иртә таннан, бүләкләр тотып, кенәзнең юл чатырына Урданың зур түрәләре агылды. Ханның яраткан кешесенә алтын һәм көмеш сибелде, төче чыгышлар, елмаюлар, баш июләрдән ялагайлык сирпелеп тора. Бакыр торбалар Иванны исертер дәрәжәгә житкерде.Тик ул үзен кичкә таба кулга алды. Салкынча төн Бөек кенәзгә кызу тоелды, ул йоклый алмады, башында төрле уйлар бөтерелде. Иртәнгә аның карары әзер иде: «Өйгә! Мәскәүгә! Нихәтле тизрәк, шулхәтле яхшырак. Берәү дә хан янында шундый яраткан кешесе, өстәвенә урыс булуына түзә алмас. Бүген ялагайлык һәм бүләкләр, ә иртәгә агу белән савыт һәм купшы матәм».

Төшкә кенәз иң кыйммәтле бүләкләрне аралап алды һәм Үзбәк янына юнәлде. Хан аны шунда ук кабул итте.

Калита тезенә чүкте:

— Әй Бөек хан, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Сүз әйтергә рөхсәт бирче.

— Бас һәм әйт, Алла сакласын үзеңне.

— Солтаным, минем кебек хезмәтчегезгә күрсәткән зур хөрмәтегез өчен чиксез шатмын. Рәхмәт! Мин сиңа ант итәм: мин дә, дәвамчыларым да беркайчан да үзләре Урдага каршы сугыш башламас, уртак биләмәләребез бай булсын өчен, көндәм хезмәт итеп, балаларың, оныкларың белән тынычлыкта, килешеп яшәргә тырышырбыз. Ханым, шуны үтенәм: жибәр Мәскәүгә, анда уйлаганнарыбызны тормышка ашырырмын һәм абыемны көткән кебек синең кунакка килүеңне көтәрмен.

Үзбәкнең беркайчан да шунда ук җавап кайтара торган гадәте булмады. Ул, Иван нигә өенә ашыга икән дип, сәбәбен эзләде һәм аңлады. Төшенгәч, кунагының сизгер булуына сөенде. Юк, ул бу бәйрәмне зур түрәләре тарафыннан кенәзне кысар өчен оештырмады, киресенчә, чын күңелдән, ихлас йөрәктән шундый зур бүләк ясады. Тик тәхет биеклегеннән үзенең кыланышының икенче, кире ягын күреп җиткермәде. Бөек хан торып, кенәзне кочаклады:

— Кайт. Үпкәләткән булсам, кичер. Ә кунакка көт. Күптәннән урыс илендә буласым килә.

***

1340 елның җәендә, шомыртлар ап-ак чәчәккә күмелгән мәлдә Иван Данилович Мәскәүгә аяк басты. Җәй һәм көзне ул эш белән һәм гыйбадәт кылып уздырды. Янәшәсендә гел булышчылары — уллары булды. Кунаклар да килеп чыкты. Смоленскига сәфәрдән соң Иван Коротопол булды. Смоленск бүләкләрен тапшырды, урдалылар тарафыннан башкарылган батырлыклар турында сөйләде.

Үзбәк хан җибәргән сугышчылар Смоленск җиренә аяк басуга, кенәз Смоленскийның үз дружинасы белән Литвага качуы, шуна сугышып торасы булмавы турында әйтте. Дөрес, аерым ахмаклар баш күтәрергә маташканнар, әмма бик тиз башларыннан колак какканнар. Смоленск кенәзлеген бик каты талаганнар, билгеле. Урыслар да кимен куймаганнар. Ике урыс кенәзе Тугъла-байны Смоленскига ут төртмәскә үгетләгәннәр.

— Яндырып ни файда? Нәрсә кирәк — алабыз һәм өйләргә таябыз, — дигән ике Иван һәм умырып алганнар. Ә Тугъла-бай тагын Урдага куалады, калада баскакларны урнаштырды, кенәз Смоленскины көтеп торырга берничә мең гаскәр калдырды. Ханның фәрманын үтәргә, баш күтәрүчене Яңа Сарайга аркан белән тарттырып алып кайтырга кирәк.

Рязань кенәзе айга якын Мәскәүдә кунак булды. Алар Бөек кенәз белән бергә, урыс илен тагын да ныгытырга дип, ният кордылар, ауга йөрделәр. Ничектер берсендә күп табыш белән кайтканда, Чыпчык тавында Мәскәүгә сокланып карап тордылар: ак таштан салынган гыйбадәтханәләрнең гөмбәзләре кояшта күзләрне чагылдыра,тирмәләр, агач кремльнең манаралары күккә күтәрелгән, елга аша әйбәт күперләр салынган, халык кырмыска кебек сәүдә рәтләрендә кайнаша. Ерактан каланың өскә дә, киңлеккә дә үскәне ачык күренде.

— Мәскәү менә дигән башкала булып килә, кенәз, — дип сүз катты Коротопол.

— Сабыр ит, Алла сәламәтлек һәм көч бирсен, алайса төзеп бетереп булмас. Таш палаталар торгызырга хыялланам, Яңа Сарайдан осталар чакыртам, Үзбәк каршы килмәс, дип уйлыйм.

Иван Даниловичка ниятен тормышка ашыру насыйп булмады. Рязань кенәзе китеп, озак үтмәде, ул авырый башлады, эчендә ниндидер чир интектерергә тотынды. Эш белән мәшгуль кенәз башта моңа игътибар бирмәде.

Аннары хәле көннән-көн начарланды: авызының тәме китте, ашаудан, бигрәк тә иттән бизде, кан коса башлады. Ябыгып, хәлсезләнеп калган кенәз ятакка ятты, авыртуына түзә алмыйча ыңгырашты. Якыннары һәм руханилар гыйбадәт кылды, тик чир Алла колы Иванның көчен көннән-көн ала барды. Бөек кенәз үлеме якынлашканын сизде. Ә мәрхүм Александр Тверский төшенә кереп: «Мин сине көтәм, Иван, бик көтәм, ашыга күр!» — дигәнен ишеткәннән соң, үлемен каршыларга әзерләнә башлады.

Карга төренгән Мәскәү өстенә кояшның якты нурлары төште, йорт һәм кенәз тирмәләренең түбә кыекларында боз сөңгеләре күренде, тып-тып итеп

тамчылар тамды. Кешеләргә яз фасылы, ә Иванга үлем якынлашты. Туктаусыз укшу анын бар көчен бетерде. Калита олы улын чакыртты:

— Минә улым, Алла хөкеме каршына басар вакытым житте.

— Алай димә, терелерсең әле, атакай, күп данлы эшләр башкарырсың.

— Юк, улым, көннәрем бармаклар белән санарлык кына калды, шуңа яхшылап тыңла мине, Симеон. Гомеремдә ниләр башкардым — барысын да ватаныбыз бай булсын өчен эшләдем, аны бергә җыю өчен, кенәзләрнең үзара низагларына чик куйдым. Кенәзлек удельлары булып түгел, ә көчле, акыллы бер дәүләт булып яшәсен дип тырыштым. Бу эштә миңа бабам Бөек Александр Невский маяк булды, шуңа мин яулар күп чапмадым, урыс җирләрен зирәклек һәм акча ярдәмендә берләштерергә теләдем, Урдага ялагайлык күрсәттем, бүләкләр белән күмдем, ә шул арада биләмәләрдә халык арта торды. Акча, улым, бөек көч, шулай ук яхшылык та, яманлык та чыганагы. Минем өчен — яхшылык, чөнки мин аны җыймадым, җәлләмәдем дә, күпме кирәк — шуның кадәр тоттым. Урдага бик күп акча ташыдым, җиңел кергән акчаның кеше күңелен аздырганын аңламыйча, аны анда байлыкка саныйлар. Комсызлык агулы елан шикелле, чага, башны бутый, тагын, тагын сорый. Алтынның ялтыравы сукырайта, һәм башка чүкеч белән органдай, бер генә уй бөтереләә: «Акча, байлык, керем, акча, байлык, керем...» Бу уй даими ызгыш-талашка, хыянәткә, үтерешкә китерә. Син дә, Симеон, Урдага бүләккә акча кызганма, күбрәк илт, килер вакыт, андагы аксөякләр бер-берсенең бугазын чәйнәр, берсе икенчесенең башына җитәр, менә шул чакта кылычны кулга алырга да булыр, хакимиятләрен алып ташлагач, көчле янына алар үзләре шуышып килер. Әмма бу тиз генә булмас әле, шулай да оның яисә онықчыкларның берсе безнең эшкә нокта куяр һәм урыс иле бөек, көчле булыр. Минем эшемне син дәвам итәрсең. Ныклап уйла, Симеон, удель кенәзләрен йогәндә тот, тик юкка кыерсытма. Гадел хөкем яса, халыктан дөреслекне яшермә. Әмма дөреслекне кайчан сөйләргә икәнен дә бел, акча кызганма, аны үзең белән теге дөньяга алып китә алмыйсың, кирәкмәгәнгә дә чәчмә, исеңдә тот: һәр бүләк бары күрсәткән хезмәт өчен генә бирелергә тиеш.

Урда ханы һәм аның зур түрәләре белән дус бул, тәлинкә тот, акчаны күбрәк ташы, Симеон, бүләклә, әмма үзеннең дәрәҗәңне төшермә. Абый-энеләрең белән тату яшә, аларны рәнҗетмә, балаларына мәрхәмәтле бул, үзеннеке — үзенә! Ызгышырга язмасын, сәгатеңдә Урдага житкерерләр, ә анда җәзаны бик тиз тоталар. Кенәзлегеңдә һәм Новгородта беренче сынау булыр: йөгәненне кидерсәң — хакимиятне нык тотачаксың, ә коралсыз сындыра алсаң — хакимлегең тагын да ныграк булыр.

Иван тынып калды, авыртудан йөзен җыерды, озак кына бөгәрләнеп, хәл җыеп ятты. Симеон көтте.

— Кәгазь ал, улым, Үзбәк ханга хат язабыз,— диде Бөек кенәз, ниһаять,телгә килеп һәм кабат күзен йомды.

Улы кайгылы карашын атасына төбәде һәм: «Бик иртә ташлап китәсең безне, атакай. Синнән башка кыен булыр, тик мин барысын да җиңәрмен, синең әйткәннәреңне үтәргә тырышырмын», — дип пышылдады үзалдына. Уйланып утырып, Симеон Иван Даниловичның күзен ачканын сизми дә калды.

— Әзерме? — Бөек кенәз катырак әйтергә тырышты. — Яз! Бөек Үзбәк ханга, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен!

Көчле һәм кодрәтле, Мәскәү һәм бөтен урыс җирләренең Бөек кенәзе Иван Сина баш ия һәм зирәкләрдән зирәк хакиме һәм абыйсыннан кичерүен сорый, синең эшләреңдә Иван, кушаматы Калита, эчтән кимергән чирдән хәлсезләнүе аркасында башка синең ярдәмчең була алмый. Тиздән, хакимем, син үзеңнең

тугры дустың һәм энеңнең вафаты турында ишетерсең, шуна Мәскәү һәм бөтен урыс җирләренә Бөек кенәзлеккә ярлыкны олы улым Симеонга бирүеңне үтенәм, һәм ул да, минем кебек үлем сәгате сукканчы, сиңа, балаларыңа, хатыннарыңа тугры калыр һәм уртак дәүләтебезнең табышын күбәйтер.

Синең алда ирексездән һәм белми кылган гөнаһларым өчен кичер, абыем. Алла шаһит: нindидер начарлык кылган булсам, һич тә яманлыктан түгел, ә үземнең уйлап бетермәвем аркасындадыр. Сине башка күрмәм инде, ханым, теләсәм дә Мәскәүдә кабул итә алмам. Кичер.

Язылды һәм мөһер белән расланды Мәскәүдә кенәз Иван тарафыннан мартның унбишенче көнендә, 1341 елда».

Соңгы юлны язып бетергәч, Симеон башын иде һәм тиздән атасының булмаячагын бөтен ачылыгы белән тойды. Терәге, остазы һәм яраткан кешесе булмаячак. Яшь кенәзнең тамырларында кан тукталгандай булды, күзенә яшь тулды.

— Ятагымны юешләмә, Симеон, мин әле исән, — диде Бөек кенәз каты гына. — Сиңа урыс иле белән идарә итәргә, хөкем чыгарырга, ә син яшь агызасың. Нык бул! Түбән Новгородка бар, ясак җый да Урдадагы биләмәбезгә җибәр, ярлыкка дип хан янына барганда кул астында булыр... Якынрак кил, кочаклашыйк, улым, бу дөньяда башка күрешмәбез дип уйлыйм.

Улын озатканнан соң өч көн узгач, кенәз үзен чәчен кистереп монах итеп кабул иткән Спасс монастырена илтергә боерды. Утыз беренче мартта, Симеон Түбән Новгородтан Урдага олау җибәрткән көнне, атасы бу дөньялыкны калдырды. Кенәзнең җаны чыккан сәгатьтә, Алла хозурына күчкән зирәк, юмарт һәм каты куллы Иван Данилович Калитаның үлеменә кайгырып, Мәскәүдә көчле язгы яңгыр койды.

***

Бөек кенәз Иван Даниловичның үлеме бик тиз арада калаларга һәм бөтен җиргә таралды. Үзбәк хан тирән кайгыда иде. Ул берничә көн бу дөньядан аерылып торды. Юньләп ашамады, йокламады. Тирә-юньдәгеләр, аның җаны тәненнән чыгып, кайдадыр йолдызлар арасында, вафат дустының җаны белән аралаша дип уйладылар. Хан үз хәленә кайту белән, ашыгыч рәвештә биш түбәле тау янына күченергә әмер бирде.

Дала кардан тулысынча арчылган, күчмә кошлар зур-зур көтүләре белән төньякка китеп баралар, җирдә яшь үлән баш тарткан, әмма хан боларны күрмәде, ул һаман кайгысыннан арына алмады. Тукталышларның берсендә Котлыгъ Тимер шулай да ханының тынычлыгын бозарга базды:

— Үзбәк хан, тыңла да миңа кинәш бирче.

— Нәрсә, язгы саф һаваны сулыйсың килми мәллә? Салкын кыштан соң җылыга сөенмисеңме?

— Мин шатланыр идем дә, ханым, урыс кенәзләре мөмкинлек бирми. Ике Константин — Тверский белән Суздальский зур бүләкләр белән монда килгәннәр, башка удел кенәзләре дә юлда.

— Бөек кенәзлекне телиләрме? — дип сорады Үзбәк, күзен хәйләле кысып.

— Телиләр генәме — ашкыналар! — Котлыгъ Тимер көлде.

— Гыйсавилар безне, мөселманнарны, ничек атыйлар, беләсеңме? Нехристлар дип! Ул этләр үзләре нехристлар. Гыйсави йоласы буенча мәрхүмнең җаны бу дөньяны ташлап киткәнче, кырык көн искә алырга кирәк.

Ә алар? Иванның тәхетеннән җылысы суынмаган! Һәм, гомумән, аларны монда кем чакырган? — Үзбәк сүзен өзеп, уйланды. — Кире кума, безнең белән күченеп йөрсеннәр, ач этләр, тик минем янга берсен дә үткәрмә. Иң беренче

Симеонны, Иванның варисын, кабул итәрмен, ә ул атасының җаны тыныч булсын өчен Мәскәүдә гыйбадәт кыла. Килер, карарбыз. Иван Данилович минем белән хушлашмыйча китеп бармагандыр, мин моңа ышанам.

Хан, бер ноктага күзен текәп, тынып калды. Бәкләр бәге аның янында селкенми утырды. Кинәт хан башын туганы ягына кискен генә борды:

— Әйдә, башка эшләр белән шөгыльләник. Литва белән нишлибез, уйла. Иван Смоленскийны аннан ничек алабыз? Тешен санарга вакыт җитмәдеме? Менә шуның өчен безгә урыс кенәзләре кирәк булыр, минем фәрманымны көтсеннәр.

Симеон Иванович Урдага апрель ахырында гына килде. Хан аны шунда ук кабул итте.

— Әй күп халыкларның бөек хакиме, Аллаһ синең көннәреңне озайтсын, һәрвакыт Алланың фатихасы белән яшәргә насыйп булсын! Синең алдыңа атам Иван Даниловичның үлеменнән соң ук килмәгәнем өчен кичер. Аның васыять хатын шунда ук тапшыра алмавым өчен кичер. — Симеон ханга төргәк сузды.

Хан хатны озаклап, дустының һәр сүзен бермәлләп үлчәп, кат-кат укыды, аннары пөхтә итеп төрде дә елъязмачыга бирде һәм яшерен тартмада сакларга боерды. Игътибар белән Симеонга карады. Ул әле дә тезендә, башын иеп тора. Хан хезмәтченең колагына нәрсәдер пышылдады һәм аның кулында алдан ук Бөек кенәзлеккә әзерләнгән ярлык барлыкка килде. Хан урыннан торды һәм аны мәрхүм дустының улына тапшырды.

— Зирәк бул! Әгәр атаң кебек тугры хезмәтче булсаң, хөрмәт итәрмен. Әмма миңа шунысы да билгеле: тормышында нәрсә җиңел бирелә, шул бик тиз онытыла. Хыянәтчеләр белән ничек эш иткәннәрен син беләсең.

— Ханым! Хакимем! — Симеон кабат тезләнде. — Менә монда, синең аягың янында, атамның сүзләрен аяк астына салмам, дип ант итәм, тугры хезмәтчең булырмын, бөтен йөрәгем белән синең варисларыңа хезмәт итәрмен.

— Атаң минем дустым һәм акыллы киңәшчем иде...

Үзбәк тынып торды, яшь кенәз дә дәшмәде.Тик хаким аңа сораулы карашын төбәгәч, Симеон катгый рәвештә:

— Андый зирәк ханга, иң яхшы җиде ханның иң яшысына киңәшләр бирергә мин яшь әле. Тик хаким минем фикеремне сорый икән, үз тәҗрибәм һәм белемемнән чыгып, булдыра алганча тырышырмын. Әгәр белмәсәм, бөек хан, үпкәләмә, мин моны белмим дип әйтермен.

Яшь кенәзнең сүзе Үзбәккә ошады, кыю, ачык итеп, күзгә туры карап сөйләшүен яратты.

— Минем янда бул бераз, кенәз Симеон, Мәскәүгә кайтырга ашыкма. Ауга чыгарбыз, эштә ничек икәнсең, күрермен. Бик тә атаңа охшагансың, сиңа карап, мин дә бераз тынычланырмын.

Урдага җыелган биш урыс удел кенәзен хан иртәгесен кабул итте. Аларга Мәскәү һәм бөтен урыс җирләренең кенәзе Симеон Ивановичка буйсынырга, аңа бар яктан булышырга һәм чакыртмыйча Урдага килмәскә әмер бирелде. Бәхәсләр килеп чыкканда, аның белән хәл итәргә кушылды.

Иртәгесен иртән кенәзләр Симеонны бөек дәрәҗә белән котларга юнәлделәр. Бөек кенәз аларга әллә ни сөенмәде, үзләре белән әдәпле, әмма салкын, һәр сүзен үлчәп кенә сөйләште. Табын янында артык күңел ачу булмады, тиз таралдылар.

— Менә шул-шул! — диде Константин Суздальский Симеон Иванович чатырыннан чыккач. — Борынгы кала һәм башкалаларга төкерделәр, безне Мәскәү астына салдылар. Хәзер шул манка малайның авызына карап торырбыз, ә ул — безгә өстән генә.

— Тәкәббер тек, тәкәббер! — аны тверьле алашы хуплады. — Ярар, яшәрбез — күрербез. Без үзебезгә уйлыйбыз, Алла үзенчә хәл итә. Өйгә кайтабыз, туганнар, безнең Тәкәббер мондагыларның артын яласын.

Удел кенәзләре өйләренә таралышты, Симеон Ивановичка Тәкәббер кушаматы ягылып калды.

Үзбәк хан Симеонны үз янында тагын ике атна тотты. Хан кая гына барса да, Симеон аның янәшәсендә булды. Бергә ашадылар, эчтеләр, тормыш, галәм, дөнья турында гәпләштеләр. Яшь кенәз күбрәк ханны тыңлады, тегесе сораганда белгән кадәрен җавап бирде. Берничә көннән соң Симеон ханның акыл буенча үзеннән ике башка өстен торганына төшенде. Ул беренче тапкыр шәрык шагыйрьләре турында ишетте, яшь кенәзне бигрәк тә Гомәр Хәйямнең робагыйлары әсир итте.

Симеон түбәнчелек белән ханнан үзенең балалары һәм җияннәре өчен укытучы табуын үтенде. Кичен йоклар алдыннан кенәз көн буе булган вакыйгаларны кабат күз уңыннан уздырды һәм ханның үткенлегенә һәм зирәклегенә шаккатты: «Вакыт, безгә наданлык караңгылыгыннан чыгарга вакыт. Шәрыкта кешеләр Галәмне танып-белүдә бик алга киткәннәр, ә без суалчаннар кебек үз казаныбызда казынабыз, Инҗилдән һәм борынгы елъязмалардан башка берни укыганыбыз юк. Надан кешеләрдән кол ясау җиңелрәк. Минем кол буласым килми һәм урыс халкы да кол булырга тиеш түгел!»

Көн аралаш ауга йөрделәр. Үзбәк кугын[9] һәм төз атудан башка яши алмады. Далада да, тауларда да булдылар, кайда да киек күп иде. Бервакыт тау аланында кәҗәләр кудылар. Этләр мөгезлеләрне күп куып чыгардылар, әмма кәҗәләр арасына балалары белән аю да эләккән иде. Куып кертүчеләр аны поскынга кудылар, ул, балаларын саклап, әкрен генә барды, тик кешеләрне күргәч, үкереп җибәрде һәм аларга ташланды. Аның дошманы хан булып чыкты. Ул читкә каерды, ә җанвар тагын бер омтылыш ясады. Ат кабат тынычсызланды һәм җайдакны Симеонга таба алып китте. Ана аю исә аның артыннан. Мәскәү кенәзе, сөңгесен тотып, атын камчылады һәм, күз ачып йомганчы, хайванның юлын каплады. Авыр сөңге ана аюның күкрәген тишеп керде, ул тагын берничә адым барды да гөрселдәп җиргә егылды.

— Шәп табыш! — дип мактады хан.

— Әйе, эре ерткыч! Ханымның аны миңа таба чыгаруы яхшы булды, осталыкны күрсәтергә мөмкинлек бирүегез өчен рәхмәт. Симеон башын күтәрде һәм Үзбәкнең йөгәнен уң кулы белән тотуын, ә сулының ханның боты өстендә ятуын күрде.

— Булыш әле миңа, кенәз, никтер сул кулым оеды.

Симеон ханга атыннан төшәргә ярдәм итте. Хаким җиргә ятты һәм сул ягы белән чирәмгә ышкынды, бармакларын селкетергә тырышса да, алар хуҗасын тыңламады.

— Әйт, Котлыгъ Тимер монда килсен. Башка берәү дә килмәсен. Аңладыңмы?

Бәкләр бәге килгәч, алар су буена төштеләр, ханга чишенергә булыштылар. Ул суга керде һәм сул кулын йомарларга тотынды, бераздан бармаклар селкенде, ә кулы арган иде.

— Ял итәргә кирәк сиңа, ханым, — диде Котлыгъ Тимер, — ә син малай-шалай кебек тәүлекләр буе атыннан төшмисең.

— Бәлки, син хаклыдыр, туганым, әмма миңа картка чыгарырга әле иртәрәк. Елбаздук бабабыз янында без әле малайлар гына. Ә минем хәлсезлегем хакында бары икегез генә белсен.

[9] Качкан кешене тоту максаты белән эзәрлекләп куып бару

Хан соңгы җөмләне шундый катгый рәвештә әйтте ки, тегеләр бу турыда беркем белмәскә тиешлеген аңладылар.

Төнлә Үзбәк йокламады, аны уйлар чолгап алды: «Чынлап та бар да беттеме? Бу Аллаһның хәбәре булмадымы? Һәм, гомумән, нәрсә соң бу? Хан үзенә аюның ташлануын ачык хәтерләде. Ул зур кылычын кыныннан суырып чыгарды, нык итеп уң кулы белән тотты, атын куалады, һәм шул чагында күз алды караңгыланды, йөгән сул кулыннан төшеп китте. Ат аюдан читкә каерды. Үзбәк иярдә көч-хәл белән утырып калды, сул кулы аңа буйсынмады, күз алдында — томан, ә тәнендә хәлсезлек иде. Шулай да башы эшләде. Хан кылычын кынына тыкты, йөгәнне уң кулына тотты һәм атын Симеон ягына борды, аю исә арттан чапты. Хан яшь кенәзнең ерткычка тидерә алырына ышанды. Ничек әйтәләр әле: «Алма агачыннан ерак төшми» диләрме, Симеон да — атасына лаек ул». Үзбәк кулының ни өчен кинәт хәлсезләнеп калуына аптырады. Ипи кисәген дә авырлык белән генә тота. Нигә болай булды соң әле бу?

Хан иртәнге якта гына йокыга талды, әмма күтәренке кәеф белән уянды, һәм сул кулының рәткә керә баруына игътибар итте. Бу шулай да Аллаһ хәбәре дип санады ул. Иртәнге намаз вакытында Үзбәк кат-кат Аллаһка һәм аның җирдәге пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламгә мактавын ирештерде. Эшләрем әле төгәлләнмәгән дип, үзенең көннәрен озайтуны сорады. Һәм намаз ахырында кемдер әйттеме, әллә үзенең башына килдеме: «Үлеменә әзерлән, улым», — дигән сүзләр ишетте. Балачагында аны Туктайдан яшергән вакыттагы кебек, бик нык курыкты. Хан үз эченә бикләнде һәм озак, бик озак уйланды, ниһаять, шундый нәтиҗәгә килде: «Ә нәрсәсе куркыныч моның? Кайчан да булса барыбер үләргә туры киләчәк. Тәнем үләр, ә җаным кайдадыр урнашыр, һәм бәлки Аллаһ мине ханлыкның иң авыр чорыннан азат итәр, җир шары турында уйларга мөмкинлек бирер. Мөгаен, миңа анда яңа серләр ачылыр. Шулай булгач, ник үлемнән куркам соң мин? Ә менә эшләрне тәмамларга кирәк, һичшиксез кирәк! Шуның өчен көн бир миңа, Аллаһ!».

Үзбәк ташып торган көч белән эшкә тотынды. Властьны кулга алганда да ул шулай көчле иде. Башы тиз эшләде, фәрманнарны төгәл бирде.

Әүвәл үз янына Симеон Ивановичны чакыртып алды.

— Өеңә кайт, кенәз, атаңның васыятен миңа биргән антыңны үтә. Ходай безгә ни әзерләгәнен белмибез, әмма шуны белеп тор: минем белән бер-бер хәл була калса, улларымның кайсы гына идарә итсә дә, сине ташламаслар. Мин аларга әйтеп калдырырмын, әмма син тәкәбберләнмә. Өеңә Сарай әл-Җәдид аша кайтырсың, анда архиепископ Сафонияне күреп, менә моны тапшырырсың. — Хан яшь кенәзгә акча белән тартма бирде. — Ач, кара, сине бу шатландырыр.

Симеон акча тулы тартманы ачты, аның мондыйны күргәне юк иде әле.

— Бу яңа акча. Хатыным Тай-туглы улыбыз Тәнбәкнең сәламәтлеге өчен Православ чиркәвендә гыйбадәт кылды һәм шушы акчаны бирергә вәгъдә итте. Архиепископ белән бергә булачак ханның саулыгы өчен гыйбадәт кылыгыз. Бу акчага Сафония һәм Василий атакай яңа гыйбадәтханәне төзетеп бетерсеннәр дә минем гаиләм өчен гыйбадәт кылырга да онытмасыннар. Тагын шундый ук тартманы ал, кенәз. Мәскәүгә алып кайтырсың һәм кешеләргә өләшерсең, атаңны һәм мине яхшы сүз белән искә алсыннар.

Ханның соңгы сүзләренә Симеон гаҗәпләнде, әмма дәшмәде. Икенче көнне Бөек кенәз Яңа Сарайга китте. Үзбәк Котлыгъ Тимерне чакырды.

— Мәрхүм бабабызның йортын күрәсең килмиме, туганым?

— Анда безнең ерак туганнар яши.

— Бигрәк шәп! Туганнарның хәлен белербез, алардан безнең тирмәләрдә

яшәп торуларын сорарбыз, ә үзебез туйганчы бабабызның саклясында яшәрбез.

— Ничек әйтәсең, ханым. Кайчанга җыенырга?

— Хәзер! Сакны күп итеп ал, бездән белән берни булмас. Ә берәр хәл килеп чыкса, балалык дусларым, чиркәс узденьнары онытмагандыр.

Биек тауга күтәрелде Үзбәк хан, җылы буркасына төренеп, күктә җемелдәгән йолдызларга бакты. Анда Аллаһы Тәгалә кул сузымында гына кебек тоелды. «Монда мине Аллаһ әйбәтрәк ишетәдер? Бәлки, алга таба миңа ничек яшәсен, җирдәге эшләремне тәмамласын әйтер?» — дип уйлады Үзбәк. Ул буркасын салды, җиргә җәйде һәм дога кыла башлады. Озак укыды хан. Аннары ятты, һәм очы-кырые күренмәгән күккә карады, шулчак ул үзе белән кемнеңдер сөйләшкәнен тойды. Бәлки ул үзен саклаучы фәрештәдер, бәлки аның үзе сораулар биреп үзе үк шуларга җавап та кайтарыдыр.

— Син малай иден, һәм сине Алла, Коръәндә Ходай тарафыннан сызылганча, халыкны дөрес юлга кертүче хан итәсе килеп саклады. Ә син ни эшләдең? — дигәндәй булды кемдер.

— Мин идарә итәргә яхшылап әзерләндем, фәрештәм. Мин фәннәр, кешеләрнең холкын һәм омтылышын өйрәндем, хәрби сәнгатьне белдем, әйбәт сугышчы булдым, бары шуннан соң гына тәхеткә утырдым.

— Әмма син тәхеткә туганнан туган абыеңны һәм канунлы варис Илбасарны үтереп мендең.

— Бу шулай, тик мин дә варис идем, минем дәүләт белән идарә итәргә әзерлегем яхшырак иде.

— Әйе, син хаклы. Ә суфыйлар белән аралашуың? Син аларга якын тордың һәм чын исламны яклаучының күнеле үтерешләрне кабул итмәвен белдең.

— Илбасар иманлы түгел иде. Имансызны үтерү — бу мөселман өчен дәрәҗә дип уйладым.

— Кеше үтерү дәрәҗә түгел! Сиңа хан булырга язган икәнен белдеңме?

— Әйе, мин нәкъ шулай дип уйладым.

— Ул чакта ни өчен тәхетне аласыңны көтмәдең? Нигә ашыктың?

— Ә күпме көтәргә иде? Миңа утыз бер яшь тулды!

— Мин дә шул турыда әйтәм, син гомерең буе ашыктың. Ә нигә үзеңнән туганнарыңның йөз егерме гаиләсен юк иттең?

— Алар исламны кабул итәргә теләмәде!

— Кылыч белән кертелгән иман, хак иман түгел. Адәм күңеле белән ышанырга тиеш, шунда гына хак Тәгаләгә якынаеп була.

— Нигә суфыйлар, имамнар, муллалар мине ашыктырды, алайса?

— Син бик яхшы беләсең, алар Алла түгел, алар арасында нәфесле кешеләр дә бар. Ә син ашыктың. Син күпне теләдең, Үзбәк. Син әлегә Бөек Алла хөкеме алдына басмадың, җирдәге тормышың әле өзелмәгән. Гомерең турында уйлан, ана тәхеттән түгел, ә мәчет ягыннан кара, догалар күңелне чистарта, хаклыкка юл күрсәтә. Ашыкмый гына барысын да үлчә.

— Болай булгач, мин бер яхшылык та эшләмәгән булып чыгаммы?

— Сиңа моны кем әйтте? Үзеңә үзеңме? Җаныңның бәргәләнүен сизмисеңме әллә? Дога кыл, Үзбәк, һәм уйла. Син орлыкны кибәктән аера беләсең. Өстеңнән кирәксез чүп-чарны кагып төшерсәң, Бөек һәм кодрәтле Аллаһ каршына басарга җиңелрәк булыр.

Үзбәк тагын бер сорау бирергә дип авызын ачты, әммә аны инде ишетүче булмады. Хан урыныннан торды һәм, үз-үзеннән, яшәлгән елларыннан канәгать булмый, түбәнгә төшеп китте. Бабасының саклясына кайтып җиткәнче таң беленә башлады, ул әкрен генә йортка керде һәм ятагына

ятты. Кинәт күнелен тырнап торган уйлар каядыр китеп югалды, хан тирән йокыга талды.

Үзбәк кичкә таба гына уянды, юынды, аннары төнге сөйләшүне исенә төшереп, тагын кайгы-хәсрәткә чумды. Үзен бу сагыш-моннан аралар өчен, ул Котлыгъ Тимерне сәйранга дәшәргә булды. Кардәшләр елга буена киттеләр. Елга һаман да шул ук, аларның яшьлек елларындагы кебек, шаулап-гөрләп ага. Кайбер урыннарда балыклар, кечерәк шарлавыкларны сикереп чыгып, агымга иярмәкче була. Яр буендагы агачлар, тирә-яктагыларны тыныч булырга өндәп, сүзсез калганнар, әмма ханның күнеле тыныч түгел, аның җанын сораулар кимерә иде.

— Мине еллар һәм хакимлек бик нык үзгәрттеме? — дип сорады Үзбәк.

Котлыгъ Тимер дәшми торды, аннары елмайды да җавап бирде:

— Бик нык, әгәр хәзер дөресен сөйли башласам, син мине җәзаларга әмер бирәчәксен.

— Беркайчан да моны эшләргә үземә юл куймаячакмын. Ничек бар, шулай сөйлә!

— Ханым, син чын идарәче булып житештен. Колагын бары тик төче сүзләрне генә ишетә, начарларыннан шунда ук кайгыга батасын. Син тәвәккәлләүдән туктадын, кешедә яхшылык белән начарлыкны аермый башладын, синең тирәңдә ялагайлар арткannан-арта бара. Мине үзеңнән бөтенләй читләштерден, мин инде ун ел синең нәрсә турында уйлавыңны, ничек сулавыңны белмим, ишетмим. Карарларыңны кабаланып кабул итәсең, каршы килүләрен күрә алмыйсын. Житеп торамы, әллә тагын дәвам итәргәме?

— Әле күпме?

— Күп! Тик башта бер сорау бирергә рөхсәт ит. Син нигә дип урыс илен нығытасың?

Үзбәкнең күзләре ялтырап куйды, ярсуын сүндерергә теләп, дәшми торды, аннары басынкы гына әйтте:

— Ни өчен урысларны нығытам? Бу сорауны аңламыйча бирәсеңме, әллә миннән көлүеңме? Мин инде сиңа җавап бирдем, һәм сиңа гына да түгел. Мине яхшылыкны начарлыктан аера белмәвемдә гаепләгәннән соң, бу сорауны биреп, Урда белән идарә итүдә үзеннең сарыктан калышмаганыңны күрсәттең, минем таң калдыргыч вәзирем! Ни өчен урысны нығытаммы? Без синең белән дәүләтне нығытырга тырышабыз. Урыс жирләре — безнең ханлыкның бер өлеше, һәм шактый зур өлеше. Ни өчен калалар салабыз? Һөнәрчелек һәм сәүдәне үстерү өчен. Тирә-ягына кара, кардәшем, күпме осталарыбыз барлыкка килде. Былтыр Мәскәү кенәзе Иван аларның байтагын йортларны агачтан түгел, таштан салу өчен урыс иленә алдырды. Калитага урыс жирләрен үз кулына алырга ярдәм итеп, әллә мин дөрес эшләмәдемме? Кенәзләр бер-берсе белән сугыш-талаштан туктадылар, без егерме ел инде урыс калаларын яндырмадык, аларның халкы ике тапкырга артты. Иван аларны буш яткан жирләргә күчереп утыртты. Алар яшиләр, эшлиләр, тауар житештерәләр, үзләрен, һәм шул исәптән безнең тамакны да туйдыралар. Һәм бу — ирексез,коллык хезмәте түгел. Син үзен миңа, урыс жирләреннән ясак керү шактыйга артты диден, димәк, без тагын баерак булабыз! Синең байлыгың арттымы, кардәшем?.. Дәшмисең? Шул-шул менә! Дәвам ит, минем тагын нинди начарлыкларым бар?

— Ханым, дәвам итеп тору кирәкмәс, ахрысы. Үз-үзенә читтән карап бак, алайса мине яла яга яки сарык кебек ангыра — берни белми дип уйларсын, — диде Котлыгъ Тимер, үпкәләвен яшермичә.

Үзбәк дәшмәде. Ул фәрештә белән төнге сөйләшүен исенә төшерде. Ул баягы сөйләшүгә бик охшаган, бик. Алай булгач, Котлыгъ Тимер, бәлки, минем жирдәге саклаучы-фәрештәмдер?

— Үземне генә калдыр, вәзирем. Мин уйлармын... — хан сүзләрен иреннәре арасыннан кысып чыгарды.

Ике атна буе Үзбәк үз янына беркемне кертмичә-китермичә ялгызы гына булды. Иртән үзе белән ит, сыр, ипи алды да атына атланып китте. Хан якынтирәдә урнашкан тауларның барысын да йөреп чыкты, кайнар чишмәләрдә, тау елгаларында коенды, дога кылды һәм уйланды. Уйлады һәм дога кылды. Үзенең гомерен күз алдыннан үткәрде, явызлыкларын аклау өчен дәлилләр эзләде. Аңа гомере буе, хан булырга тиешсең, дип тукып килделәр. Көн саен аны шуңа әзерләделәр һәм тәхеткә бару юлында кан коеш — табигый хәл дип ышандырдылар. Дөнья җиһангиры булганчы аның бабасы Чыңгызхан күпме гомерләрне кыйган! Бәркә хан күпме кешене теге дөньяга озаткан! Хәйләкәр Нугайның корбаннарын да санап бетерерлек түгел. Шулай булган, ул шулай эшләде һәм шулай булачак. Хакимияткә бүтән төрле юл бар микән? Бәлки, бардыр да. Әмма ул, Үзбәк тә, дөньяның акыл ияләре дә моны белмиләр.

— Бөек Аллаһыбыз, нишләп син кан коймый гына идарә итү юлын күрсәтмисең? — Хан дога кылганда үзенә дә, Аллаһка да шул сорауны бирде.

— Әйе, күп кенә урыс кенәзләренең гомерен алдым, — дип фикер йөртте ул, — тик алар миннән башка да ике гасыр буе, хакимият бүлешеп, бер-берсен үтергән. Нәрсә, барысы өстеннән бер кеше куеп, мин урыс җирләре өчен яхшылык итмәдеммени? Урыс кенәзлекләре артмадымыни? Юк, бу начар түгел. Бу — яхшы!

Әйе, исламны Изге Китап һәм кылыч белән керттем. Тәре йөртүчеләр шулай эшләмәдеме? Төрле Аллаларга ышанып, ата-бабаларым әллә рәхәт яшәгәнме?Яхшы да, начар да. Гасырлар буе һәрвакыт күчмә тормышта яшәп һәм башка халыкларны талап яшәргә ярамый, җирдәге кыйммәтләрне төзү зарур. Утрак тормыш, көчле дәүләтен булмый торып, аларны ничек тудырырга?! Бердәм дине булмаган дәүләт тә көчле була алмый. Бары дин генә кешене тәртиптә тота, җанының киләчәге өчен җаваплылык тою аны күндәм һәм булдыклы итә. Дәүләт үз кешеләрен, алдагы буыннарның хатасын кабатламас өчен, укый-язарга, тарих һәм башка фәннәрне өйрәтергә тиеш, фәннәр үсешкә илтә, җан һәм тән өчен әлегәчә булмаган кыйммәтләрне тудыра. Дәүләт дине кертеп, дөрес эшләдемме? Ә асылда ике дин калдырып, дөрес эшләдемме? Мине укытучы-остазларым ничек өйрәтте, шулай хәл иттем.

Үзбәк дога кылды, беркем аңа җавап кайтармады. Үз сорауларына ул үзе җавап бирде.

Барысын да дөрес эшләдем! Күп еллар узар, берничә буын алмашыныр, илемдә ислам күп кеше өчен үз дине булыр. Димәк, мин үсешнең дошманнарын юк иттем һәм дөрес эшләгән булып чыктым. Җаным тәмуг утларында газап чигеп, шайтаннар көлсә дә, бу гөнаһым өчен Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотарга әзермен. Аның каравы, үзем төзеткән калаларга, мәчетләр, православ храмнары, мәдрәсәләргә һәм чиркәү-мәхәллә мәктәпләренә карап куанырмын.

Әйе, үтерешләрнең канын Аллаһ алдында юу мөмкин түгел, чөнки ул гына кеше язмышы белән идарә итә ала. Алайса, Аллаһ ни өчен миңа шундый язмыш биргән соң? Ник мине Туктайдан яшереп калды да соңыннан аның янына китерде? Аннары канын коярга рөхсәт итте?

Үзбәк күп сорауларының җавабын белмәде, шуңа катгый рәвештә соңгы көннәренә кадәр гөнаһлары өчен тәүбә кылырга, башка беркемнең гомерен өзмәскә, шул ук вакытта идарә дилбегәсен бушатмаска хәл итте.

«Тиздән, бөек һәм зирәк , бар нәрсәне белүче һәм кодрәтле Аллаһым, синең алдыңа килеп басармын. Бу җирдә мин нәрсәгә лаек, шуны бир, барын да зур шатлык белән бүләк итеп кабул итәрмен».

Котлыгъ Тимер ханның һич көтмәгәнчә күңеле күтәренке булуын, йөзендә авыру билгеләренең эзе дә калмавын күреп, бик гажәпсенде.

Сиздерми генә көз якынлашты. Хан яраннары белән ашыкмый гына Яңа Сарайга кузгалды. Юлда озакка тукталганда ул илчеләрне, сәяхәтчеләр, олыс бәкләре, гаскәр башлыкларын кабул итте. Хан барысын да якты чырай белән каршылап, зур бүләкләр белән озатты.

Сарай әл-Җәдид күчмә каланы остаханә, төзелеш, базарларның гадәти шау-шуы һәм төтен исләре белән каршылады. Җәй эчендә кала тагын да үскән, халкы арткан. Ханның күңеле шатлыктан тантана итте һәм бу дөньяны ташлап китәргә әзерләнде. Хан үлемнән курыкмады, ул аның килгәнен көтте һәм хәтта кеше үтеп чыгарга курыккан чик артынданиләр булуын тизрәк күрәсе килде. Үзбәк хатыннарын үз янына чакырмады, чакырса да Тай-туглыны гына, анда да гыйшык уйнарга түгел, ә сөйләшү өчен дәште.

— Шушы көннәрдә тәхеткә варис итеп улыбыз Җанбәкне игълан итәчәкмен. Син шат булырсың дип ышанам.

— Мин шатмын, чөнки бу акыл белән эш итү. Тик олысы белән нишләргә? Тәнбәк шәрабсыз бер генә көн дә тора алмый.

— Синдә аны авызлыклау гарәп юк бит. Минем дә юк. Үз улыбызны үтереп булмый бит инде. Бездәнерактарак булсын, Һарунбәк аның өчен менә дигән караучы. Авыр хезмәте өчен киявемне бүләкләрмен.

Тай-туглы җавап бирмәде, ул әлегә, Үргәнечнең аксөякләре Тәнбәкнең салуын хуплаулары, шуннан файдаланып Хәрәзмне Алтын Урдадан аерып чыгарырга дип яшерен сүз куешулары турында әйтеп, иренең кәефен җибәрмәскә булды. Зирәк хатын иренең хәлен белә һәм инде киләчәккә үзенең ниятләрен кора башлаган иде. Бераздан ул ирен кочаклады һәм назлы итеп колагына пышылдады:

— Бар да син теләгәнчә булсын, ханым.

Иртәгесен Урданың зур түрәләре җыелышында Җанбәк хан тәхетенең варисы һәм исламны саклаучы дип игълан ителде. Барлык әмирләр, гаскәр башлыклары, олыс бәкләре кундәм рәвештә башларын иделәр. Үзбәк аларның шатмы, әллә юкмы икәннәрен аңлый алмады, әмма алар арасында Җанбәкне хан итеп күрергә теләүчеләр дә, ыгы-зыгы тудырып баш күтәрергә маташучылар да барлыгын бик яхшы белә иде. Күпьеллык тәҗрибәгә ия Үзбәк хан варис игълан итеп, тәхет өчен, башта тавышсыз-тынсыз, аннары канлы көрәш башлап җибәрүен аңлады, әмма аның башка чарасы юк иде. Үлем шәүләсе якынлашканнан-якынлашты.

Аллаһ нык бирелгән көрәшчесен үз янына алырга ашыкмады. Көзен салкын вак яңгыр сибәли башлагач, ханның сул кулы һәм аягы хәрәкәтләнми башлады, теле көрмәкләнде. Үзбәк ятакта бик авырлык белән борылды һәм елмаерга тырышты, әмма сул ягы җилсез көндә асылынып торган җилкән кебек хәрәкәтсез булганга, авызы чалшаеп тора, шуңа елмаюы йөзен шыксызландыра иде. Бар да ханның акылы киткән дип уйлады. Әмма алай түгел иде, ул бик тиздән Аллаһы Тәгаләгә һәм җирдәге кешеләргә авыр хезмәте тәмамланачагын аңлаган шатлыктан елмая иде.

Каткан җир өстендә җинел кар бөртекләре уйнаклады, салкынча саф һава кешеләрне урамга куып чыгарды. Алар, көз пычрагыннан котылганнарына сөенеп, йөгерештеләр, ыгы-зыгы килделәр. Яңа Сарайда тормыш кабат гөрләде. Үзбәк хан да, кәефе килеп, ятагыннан башын күтәрде. Хезмәтчеләр аның баш астына мендәрләр өйделәр, керфеге ябышкан күзен чылаттылар һәм үз янына, инде бар да Алтын Урданың хакиме дип санаган Җанбәкне чакыртырга дигән әмерен ишеттеләр.

Улы озакка сузмый атасы бүлмәсенә килеп керде. Үзбәк аңа утырырга ымлады, һәм хезмәтчеләр чыгып киткәч, сүзләрен аңлаешлы әйтергә тырышып:

— Улым, барысын да сина калдырам! — диде. — Бу авыр йөкне ал һәм абына күрмә. Ике күзеңне дә ачып кара, улым, хакимият өчен ашкынганнар бәрән кебек бугазлап ташламасыннар. Фәкыйрь хаҗинен биштәре хан казнасыннан баерак! Хаҗи күнеле — фәрештә күнеле, хаким күнеле — шайтан күнеле! Идарә иткәндә, Җанбәк, шуны онытма: начар тынычлык җиңүле сугыштан яхшырак! Урыслар белән тату бул, алар белән сугышканга караганда дус яшәвен яхшы, дуслыкта алар эчкерсез, нәфрәттә явызлар, урыс кенәзлекләре белән дошман булудан Аллаһ сакласын. Исламны сакла, хакимияткә халыкның күндәмлегенә ирешүдә терәк ул. Башка дин кешеләрен дә кыерсытма, алар синнән канәгать булсыннар. Әмма сина бар нәрсәне кичерергә дә димәгән. Хаким фәрештә түгел, камчы һәм кылыч кайберәүләр өчен Коръәннән әйбәтрәк. Мәрхәмәтле бул, тик камчынны кулыңда тот...

Үзбәкнең сәламәт ун кулын көзән җыерды, йөзе тартышты, соңгы сүзләрен зур авырлык белән әйтте:

— Саф һавага чыгасым килә... Далага... Каланы күрәсем килә...Минем Сарай әл-Җәдидемне... Күрәм, ишетәм сине, үлем фәрештәсе Газраил... Син инде якында... Тизрәк далага... Сабыр ит, Газраил... Җанымны далада алырсың...

Хезмәтчеләр тиз генә хәлсез ханны киендерделәр, арбага утырттылар һәм башкаласыннан биек калкулыкка алып менделәр. Үзбәк карашы белән зур каланы айкады һәм елмайды. Аның кан качкан битеннән берничә тамчы күз яше агып төште һәм йөзендә елмаю катып калды.

Үлем фәрештәсе Газраил тынып калган Үзбәкнең җанына, аның җирдә кылганнарының яхшысын начарына каршы куеп, күрсәтеп чыкты. Әмма элекке ханның җанын үзе эшләгәннәр түгел, ә хәзер, аның Алтын Урда ханлыгында ниләр кылынганы өзгәләде. Ул кече улы Хозырбәкнең туганнары Җанбәккә каршы яшерен килешү оештырганнарын күрде. Шулар арасыннан берсенең зур акчалар бәрабәренә Тай-туглыга иптәшләрен сатканын да, хатыны үзенә тугры сугышчыларын тегеләрне җәзага тартырга җибәргәнен дә күреп торды. Җиде яшьлек Хозырбәкне сугышчылар йоклаган чагында, бәрәнне чалган кебек, суйдылар. Анасы Сусанны мендәр белән томалап үтерделәр, аннары тагын биш гаиләне нәни балалары белән бергә кырып чыктылар.

Кайчандыр кодрәтле булган хан, үзенең салкыннан каткан гәүдәсен күп санлы яраннары озатуында, җиргә иңдерү өчен, Сарайчыкка алып килүләрен, мәтәм агышын айнымас Тәнбәкнең ничек каршы алуын, анасын кочаклавын һәм Һарунбәккә күз кысуын күрде, ә тегесе кансыз рәвештә хәнҗәрен олы улының аркасына батыруын, йөзе таштай каты Тай-туглының беренче улының үле гәүдәсен җиргә иңдерүен һәм Хәрәзмдәге бу яшерен әзерләнгән үтерүдә катнашкан кешеләрнең барысын да юк итәргә әмер бирүен дә күрде... Аның җансыз гәүдәсе янында ук канлы суеш-үтереш бара иде...

Үзбәкнең җаны иңрәде:

— Әй Аллаһ илчесе, үлем фәрештәсе Газраил, бу хәлләргә башка карый алмыйм. Җирдә яктылыгы күзне рәхимсез сукырайта торган хакимияткә дәгъва кылуга караганда, җанынны саклап калу өчен, тәмуг тагы газаплы хезмәт күпкә яхшырак.

*Русчадан* **Рөстәм ГАЛИУЛЛИН** *тәрҗемәсе.*



Рим
Идиятуллин

# ГОМЕР — ИСКӘН ҖИЛ ГЕНӘ

## Таулар хакында ике шигырь

**1**

Без бу тауга менмәдек бит әле,
Сәлам биреп төшик болытка;
Сузарбыз җыр, зимагурлар сыман,
Кайгырмыйча һич тә мал юкка.

Нинди мал ди! Шагыйрь бахыр энже
Сүзләргә бай, үзе — ыштансыз;
Шул килеш тә, һай, кирәкле заттан:
Үлеп китсә,
                жанның араннарын
Чистартырга кемгә кушарсыз?!

Хәер,
Калыр шигырь, калса, ничә бөртек,
Кәфенлеген Әнкәй мәрхүмәләр
Саклап торткан иске сандыкта;
Сүнмәде ич сүзләр, сынмады ич
Плэтән подвалында ятып та...

Шигырь бит ул — йөрәк катламнарын
Ярып чыккан жанлы хәзинә;
Тәсбих итеп тартсан, хаклык исе
Ачыттырып керер күзенә.

Ә тау — Хак бизмәне, менсәң анда,
Үзгәрә дә куя үлчәмнәр:
Карагызчы! — кәрлә икән ләса
Алпамыштай йөргән кемсәләр.

---

Рим ИДИЯТУЛЛИН – *Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре; башкорт һәм татар телләрендә чыккан берничә китап авторы. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Уфада яши.*

Шәйләдек ич кичкән елларның да
Чытырманлык аша узганын;
Хәерсезен,
абайладык соңлап,
Җәннәтләргә илтер юламаннар
Булып чыкты бар да Сусанин…

Алданыпмы шайтан коткысына,
Әләм иттек гөнаһ, бозыкны;
«Ярлыка!» дип тәүбә кылмагачтын,
Ходай безне тәмам онытты.

Үч, көч җирдә падишаһлык итә,
Иблис үти казый вазифасын,
Низаг купса тиккә арада;
Бәндә хуры татлы ләззәт татый,
Карендәшен манса карага.

Рас яраткан икән Ходай безне
Мен-мең төрле чәчкә төсендә,—
Үрчетик гел иман вә изгелек
Үсентесен җирнен өстендә!

…Йә, хушлашыйк ак болытлар белән,
Юкса,
Тауга менсәң үкенечләр туа,
Беләсезме туа нилектән? —
Үз-үзенә җәллад булмыйм дисәң,
Узганына бакма биектән!

**2**

*Тау иле шагыйре Р.Гамзатовны уйлап*

Рәсүлүллаһ[1], алтын сүзгә төреп,
Мирас иткән миргә дуслыкны,—
Куба калса ызгыш, илләр, ирләр
Арасында, кушкан хатын-кызга
Күз яшьләре сеңгән яулыкны
Ыргытырга аяк очларына[2].

…Чал кыялар монсу уйга талган;
Ниләр булды сина, Тау иле?! —
Нәфис кулга тотып бомба ташлый
Сабыйларның аяк асларына
Сылу кызлар,
кара яулыклы.

Никләр өшим җәйге челләдә дә?!
Күтәрелеп җанның төпкеленнән,
Ачы төер тула бугазга:
И Шагыйрем!
Каберендә рәнжеп ятасыңдыр, —
Алтын сүзен ауный тузанда.

---

[1] Рәсүл – Аллаһының илчесе.

[2] Монда шагыйрьнең билгеле шигыренә ишарә.

Намазлыкка баскан дәһриләр! —
Сезгә дәшәм, олы-кечесе:
Шагыйрьләр вә таулар, —
һәр икесе
Ходай биргән милек — кучемсез;
Таулар чуксә, ил ышыксыз калыр,
Шагыйрь бетсә, булыр исемсез...

## Рәхмәтем бар

Сынды нурлары кояшнын,
Монсу кичләр дә житте;
Рәхмәт сина, тәүге ярым!
Шул бәхетсез мәхәббәтем
Мине бәхетле итте,—
Гомерлек илһам сипте.

Сулкылдый йөрәк, исемә
Төшерсәм сабый чагым:
Телендә жылытып суздын
Туң ипи кыерчыгын...
Белсән, Әнкәм! — ваемлыга
Дөньясы һаман салкын.

Кай тарафка ташламасын
Тәкъдир адәм баласын,
Башын куктә — табанында
Тойсаң туфрак жылысын;
Туган жирем! — жирсер кунел
Синдә таба дәвасын.

Рәхмәтем бар язмышыма:
Маймычын да, маймылын да
Яраттым уз төсендә;
Тирбәттем халкым аһ-зарын
Жанымнын бишегендә;

Гомер — искән жил генә.

***

Аурупага тәрәз уйган Пётр патша;
Нинди уйлар булган ул дуамал башта?
Тынчу илнең эчен-тышын жилләтергә,
Бәлкем, тарих куласасын тизләтергә
Теләгәндер? Белсә, моны Мәнди белер!

Мәгърип рухы салкын илгә жилгән тәүдә,
Сонра — төшкән коммунизм дигән шәүлә:
Томалап ул анны, богаулаган жанны, —
Ал байрагы итеп дөм дәһри ялганны.
Чур, кайтарды жил кабат ертлач заманны.

Аһ, бу тәрәзә бүген дә бит шар ачык!
Әрсез фәхешлек нык исә, шау шакшылык.
Өндә басты безне төрле җен, албасты,
Кайларда соң калды кешелек кыйбласы?
Белмәстер хәтта ки дә Мәнди анасы!..

***

Әкиятләр күптән чынга чыкты,
Ис  китәрми хәзер могҗиза:
Күрәсез ич, алмаштыра табиб,
Туза калса тәндә бер әгъза.

Ә иртәгә ниләр кылмас алар,
Киртә юк ла чик вә чамага,—
Ак тәнлегә негр канын биреп,
Әйләндерер йөзе карага.

Бу әкият түгел, ач хакыйкать:
Бәгырьсезләр үрчи дөньяда;
Җаннар хәйран тузган, тунган,
никләр
Алмаштырмыйлар соң янага?!.

## Чибәркүл

Кисәтәме Ходай? —
Күктән ташлар башка ява;
Кем әйткәнчә, китәрләргә иде
Башкайларны салга салып.
Китәр идем дә бит, елга кипте,
Урман үлгәч, салы да юк.

Һушлар китәр бушлык җанда;
Белми беркем, кайда кыйбла.
...Сүзләр сына, каләм калтырана, —
Аяк аста, ахры, җир убыла.

## Кайсысы өлкәнрәк?

*Ж.Румига ияреп*

Очрап муллага, куйган кемсә сорап:
«Син үзенме, сакалынмы олырак?»

Киткән теге ярсып: «Вәт, шыр дивана!
Сакал учлап тудынмы әллә дөньяга?!»

«Өлкән булгач сакалыңнан байтакка,—
Дигән кемсә,— төшендерче ул чакта:

Кара иде синең күнел элек тә,
Картайгач та ник агармый бөртек тә?!»

***

Кичә бер төш керде бик кызык:
Чәчкә тотып гүзәл Ай кызы
Йөгерепләр килә каршыма.

Ә өнемдә хәят кылчыгы:
Асып бәндә акча капчыгы
Җәннәт капкасына ашкына.

Күрәзәлек кылып утырма:
Дөнья куа-куа адәмнең
Бәгыре дә тәмам тутыга.

Кодрәт юк үзгәртергә өнне;
Яктыртасым килеп көнемне,
Төшләремне юрыйм яхшыга.

...Ялт узачак алкын гомердә
Тудырырга ашкын могҗиза!
Ул чагында һәр көн, һәр төндә
Сузар чәчкә сиңа Ай кызы.

## Үкенеч

Фигылебез иске — гел ызгыш та хөсет,
Яшәсәк тә дәверләрнең янасында;
«Татарымыз» сулар сибеп кенә тора,
Ихма! —
Шаһгалинең нәсел агачына...

***

«Тилевәзир» борып, фин татарын
Тыңлап тордым әле бик кызыгып,
Житәр вакыт: әткәм-әнкәм телен
Өйрәнербез чит илләргә чыгып.

## Горурлык

Онытмаган тарих җирдә җиде
Могҗизаны корган колларны;
Искә алыр бәлкем безләрне дә:
Вата белгән өчен корганны.

## Тормыш

Мәрмәр сарай сары майдай җылы,
Кайный котлашулар, баллап мактау;
...Ә урамда — томан, зыкы салкын,—
Монда бозга катып ага сыктау.

***

Чаңы чукрак, сыны коргак гомер
Каланчамнан миргә яр салдым:

Әй, син бәндә!
Ак биләүдә үстен, ак сөт эчтен,
Яши-яши никләр каралдын?!

***

Көләч нурын кояш батырга да,
Бахырга да бердәй балкыта;
Ал да үрнәк,
Кешеләрнен явызлыгын оныт,
Изгелеген мәгәр онытма!

***

Күздәй жиләк күзгә кереп ятмас,
Араласан гына табылыр;
Бу дөньяда кемнен кемлекләре
Вакыт жиле искәч танылыр.

***

И моннын сихри куәте! —
Эчми дә исерәсен;
Мон — Ходайнын адәменә:
«Кара жирдә ак бул син!» дип,
Эндәшүе, күрәсен.

***

Жанын илгә биргән затнын кабер ташын
Алыштырып куйды гавам янасына;
Дау кубарып мирас бүлгән балалары
Караучысыз ята билчән арасында...

***

«Шигырь ветераны» гомер сүтәр
Төсле калай тагып түшенә;
Ил-халыкнын хәсрәтләрен эчкән
Шагыйрь үләр нәкъ үз яшендә...

***

Көл-күмергә калып янсам да мин,
Язмагандыр, ахры, балкырга:
Кичтән язган «алтын» шигырьләрем
Иртән әйләнәләр «бакырга».

***

Әрвахларны «дус иде» дип сөйләү жинел,
Исәннәрне дус күрүләр, һай, авыр ла!
Һәм мине дә дошман мактап, дус юксынып
Сөйләр вакыт житеп килә, сөбханалла!



Ринат
Камал

# ТАНЯ–ТАҢСЫЛУ

СЕНТИМЕНТАЛЬ БӘЯН

I

«Таңсылулар аерылышкан! Петрик Ишемьярда калган, ә Таня Ригага очкан!.. Очканмы, качканмы шунда...»

Бу хәбәр мине бик аптыратты. Бүгенгедәй хәтеремдә: Таңсылу ахирәтем туй көнен ашкынып-очынып көткән иде. Нинди бәхетле иде ул көндә! Бит алмасы айдай балкый, күзләре очкынлана. Гәүдәсе гүя аккош сыны: ак озын күлмәге ак каурыйлардан гына тезелгән диярсең. Үзе дә әллә кая очып китәрдәй булып талпына. Шул кеше Петригыннан аерыла, кача буламыни?

Әлбәттә, Ишемьярдагы хәлләрне яхшылап белеп тә бетермим... Кышкы каникулда, диплом язарга дип, җәйгә кадәр ял алдым. Ул елда институт тәмамладым — Ишемьярга барырга туры килмәде. Ишемьяр да, андагы иптәшләр дә, Таңсылу да калды. Ишемьяр мәктәбе, тәүге эш урыным — үзаллы тормышымның юл башы.

Хәзер, барысын да хәтерләсәм, күзләрем яшьләнә. Ишемьяр да, андагы көннәрем дә, Таңсылу ахирәтем дә онытырлыкмыни?!

* * *

Таңсылу белән Петрик күптән дус. Бер-берсе өчен өзелеп торалар. Читтән караганда да, болар бер-берсе өчен генә яратылган, диярсең.

Петрикны колхозчы дип уйламассың. Юк, аның, шундый нәзакәтле кыланышлы, ипле, тотанаклы кешенең, фермада эшләвенә хәтта ышанасы да килми. Юк, ул крестьян түгел, купшы бер интеллигент затыннан. Ул зәңгәр күзләр, ул аксыл чәч, кин янак, яссы маңгай... Иягенең уртасында су тамчысы сыярдай гына чокыр шәйләнә. Шәмдәй буй-сынлы. Алдында гүя коеп куйган гимнаст! Башны күтәреп каравы гына көч — син инде җинелдән дигән сүз. Чак кына беленеп килгән мыегы сызылып тора. Ә иреннәре, хатын-кызларныкы кебек, ачык алсу, кура җиләгедәй.

Шулай да мин Петрикны ошатып бетермим. Аның бар белгәне — кылану, икейөзләнү кебек тоела. Ул үзен ничек тә яхшы, чибәр, дан егет итеп күрсәтергә тырыша. Аптырыйм: Таңсылу үзе шуны сизми микән?

Һәрхәлдә, Таңсылу үз бәясен үзе белми кебек. Минемчә, ул мәктәптә барлык укытучылардан да сылурак. Анарда нindiдер сәер чибәрлек бар. Карлы боз

өстенә уелган бәке төсле, тулы соргылт күзләре аксыл йөзенә сөйкемлелек өсти. Күзләре кысынкы, кабаклары кабарынкы, шешенке. Мин Таңсылуны арабызда иң чибәре дип саныйм. Марфа әби генә килешми. Таңсылу йөзгә олырак күренә, ди. Ярый, шулай да булсын, ди: кияүдә андый хатыннар суырыла, тагы да яшәрә төшә бит. Ахирәтем бик тә аралашучан, ачык, күңелле холыклы.

Кием буенча да Ишемьярда ана житкән кеше юктыр. Таңсылу — мода патшасы. Ишемьярда моданы ул чыгара. Һәр мизгелгә килешле итеп киенә, һәр атна саен киемендә бер яңа бизәк уйлап таба. Шуңа мәктәптә хатын-кыз аның белән ярышмый да диярлек — барыбер Таңсылуга житкерә алмаячаклар! Берзаман чәчне башка күбәдәй өеп кую гадәте таралган иде. Таңсылу аны Ишемьярда беренче булып күрсәтте.

— Ай-яй модница да инде безнең Таня, — дип баш чайкый Марфа әби. Мин көләм генә.

* * *

Әй, көн дисәң, көннең теләгенә рас килүе! Сорап алгансыңмыни?! Йә, әйт инде: үзе нурлы, үзе моңлы. Көн бите — күк йөзе чалт аяз. Якты чыраен иртәнге җиләс җилләр иркенә куйган. Иркә сабый бала яңа туып, беркатлы рәвештә галәмгә төбәлгән. Бер серен дә яшерми. Якты карашларыннан бар тарафка нурларын гына коя.

Йөзен вакыт-вакыт аксыл чаршау капларга уйлый. Әйтерсең лә, галәм аны яшерә, күз тидерүдән курка. Сакла, якла, арала, батыр! Күз карасыдай итеп күр чибәреңне, әрсезләрне, хафаларны якын җибәрмә ана!

Тар булса да, Инәк мул сулы. Дулкыннары бер калка, бер күздән югала. Ярлары текә, өстеннән бу бөрки. Кайнар елга ул. Иртәнге мәлдә генә гамьсез, ялкау булып кылана, агышыннан да язып куйган сыман.

Тирә-якларда, елга әрәмәлекләрендә ямьле җәй башлана. Җәй килә яшел паласын җәеп...

Бүгенге көннең үзенең генә төсе, аерым бизәге бар кебек. Һавасы да йомшак.

Иртәгә мин институтка җәйге сессиягә барырга тиешмен. Мәктәптә соңгы уку көне дип, кызлар белән Инәк буена чыктык.

— Быел мин дә институтка укырга керәм әле, — ди Таңсылу көтмәгәндә. — Фәнисә кебек читтән торып уку бүлегенә барам.

— Чынлап та, әйдә, Таня! — Ахирәтем белән бергә уку минем бик зур хыялым. — Бергә-бергә химиядән мәсьәләләр чишәрбез.

Кызлар каршы:

— Юк, юк, Таня, син болай да универсал. Теләсәң, геометрияне, черчениене, арифметиканы, җыр, рәсем дәресләрен укыта аласың. Әдәбият — үз фәнең... Нигә сиңа уку? Фәнисә кебек баш катырырга...

— Кызлар, мин педучилище белән налан калам бит...

— Ха-ха-ха... — Барча су буе яңгырап тора.

Кояш аяусыз кыздыра, су җылы, киемнәребезне ыргытып елгага чумабыз. Суда рәхәт, суда сихәт. Аннан тагы уттай ком өстендә тәгърибез. Кем шулай куана, кем Инәк буен яңгыратып, сабыйларча чыр-чу килә? Инәк суында көмеш тәңкәләр чәчри. Инәк буен бик нык яңгыраталар хыялыйлар.

Таңсылуның белмәгән эше юк. Без комда тәгәрәгәндә, фотоаппаратын шалт та шолт китерә.

— Кая, үзеңне дә төшерик...

— Давай! Менә шул төшенә генә бас!

Мин Таңсылу белән кочаклашып төшәм. Әйдә бу рәсемнәр бер истәлек булып калсын. Инәк буендагы сәхрә көннең хатирәсе...

— Кызлар, элек мин ничек басылып яшәгәнмен икән! — Тагы Тансылу. — Таисия Алексеевнаның кулы астында... Тын да ала алмаганмын. Фәнисә килгәч кенә күзем ачылды. — Ул мине билемнән кочаклый. — Рәхмәт сиңа, Фәнисәкәем!

— Нигә?

— Фәнисә килгәч ничек шатландым мин! Ул килгәч, ял итә башладым, Таиска хәзер миңа түгел, аңа бәйләнә. Ә Фәнисә... Фәнисә — молодец, бирешми! Ул тиргәшкән саен, Таисканың кирәген биргән саен, сөенәм.

— Ха-ха-ха... — Инәк буен янгыратып көлешәбез.

— Нинди начар бәндә син, Таня, кешеләрнең тиргәшүеннән ямь табасың...

— Мин әчемнән: «Фәнисә, бирешмә, Фәнисә чигенмә!» — дип телим бит, кызлар.

— Ха-ха-ха... Тәңресеннән юрый..

— Мусульманка!..

Мин исә эчемнән үземнекен уйлыйм. Җаным көя. Шул Таиска теге көн Тансылу белән Петрик турында нәрсә дигән була!.. Башка милләттән булгач, Тансылуны бер дә өнәп бетерми ул.

— Җаһил!.. — Кызларның өзек-өзек хәбәре колагыма ишетелеп кала. — Үзе, ичмасам, бер елмая да белми...

Утыра-утыра моңсу булып китә. Күңел моңдый көнне әллә кая җилкенә, әллә нинди сихри киңлекләргә җитәрдәй була. Барысы да алда, киләчәктә сыман. Алда, ерак алсу офыклар артында безнең өчен әле башланмаган, ачылмаган дөнья ята. Кызлар җәйне ничек үткәрергә җыенуларын сөйли. Урман һавасы күкрәкләргә тула, сулышларны иркенәйтә. Дөнья шундый ямьле, хозурлы кебек. Җәйнең башында гына, иртәләрдә генә кеше тормышның рәхәтлеген, гомерләрнең озынлыгын тоя, үзен азат дип хис итә. Җәй, җәй башлана алда, алда — азатлык, каникуллар чоры!

— Таня, кара әле, син Түбәнне сөйлисең дә сөйлисең, ә Петригың турында ләм-мим! — ди кызларның берсе.

Менә сиңа иске авыздан яңа хәбәр! Бичаралар, кая барып төштеләр. Тагы ни сөйләрләр, нинди сүз кузгалтырлар икән...

Ярый әле Инәк барыбер ишетми. Хас та йөгерек-шаталак малай. Без, апалары, аңа бар ни, юк ни: ялан тәпи уртага төшкән дә, күбәләк куандай, уңга-сулга тайпылгалап, җилдерә генә. Әй ашкынган, әй чәмләнгән! Өстенә тәнкәләр сибә, елтырап тирә-ягына энҗеләр тарата, җәйгор балкышыдай елмая белә, шаян.

Ниһаять, мин дә серемне чишәргә булдым. Эчтә ятамыни ул, без кебек тишеп чыга. Тагы ничек итеп аны моннан үзем белән алып китәм!

Кызлар күтәреп алдылар яңалыкны, алкышларга тотындылар. Хас та чебеш бәбкәләре — сөенешеп, канатларын кагып җимгә таба ябырылдылар.

— Чынмы?

— Кайчан әйтте?

— Юри шаярта...

— Юк, кызлар, мин ышанам! — диде Тансылу җитди кыяфәттә. — Николай Григорьевич Фәнисәнең дәресләрен гел мактый. Фәнисәдән завуч чыга ул!

— Мин аңа: «Яшьмен, Таисия Алексеевна шикелле булдыра алмам», — дидем...

— Һи, юләр! — Кызлар шулай дип шаулашты.

— Туктагыз, кызлар! Карале, Фәнисә, хәзер син директорга бар да: «Мин уйладым, мин риза!» — дип әйт.

— ...

— Алайса без үзебез директорга барабыз. Әйдәгез, кызлар!

— Кирәкми! — Минем котым очты. — Кирәкми, кызлар! Эчендә сүз тормый дияр...

— Һи, юләр! Теге әтәчнең кикриге шиңәр иде.

* * *

Башым кайный, анкы-минке атлап барсам, артымнан Таңсылу куып житте. Аны да көтеп тормый сыпыртканмын.

— Фәнисә, Фәнисә! Нигә көтмисең? Кара әле, акча капчыгын югалткан кешедәй кылана. Башыңны күтәр, күзләреңне ач! Кара, дөнья нинди ямьле.

— Кояш елмая, кошлар сайрый... — Үчекләшәм.

— Күкләр нинди зәңгәр, һава саф... Чын алтын көз туган!

— Көз тумаган әле, беләсең килсә — җәй дәвам итә.

Таңсылу сер бирми:

— Җәйнең соңгы балкышы, соңгы назлары... Җәй киленчәктәй сылуланып, матурланып киткән, үкенечкә калмасын дигәндәй, бизәкле күлмәкләрен кигән.

— Әй хыялый шагыйрә! Сина чәчкә дә бизәкле күлмәк инде. Миндә башка кайгы...

— Һи, тапкансың хәсрәт. Беләм: директор сине завучлыкка үгетли инде. Ризалаш та куй. Беләсеңме, директор хатыны ял көненә үзләренә чакыра, алма җыярга. Барабызмы?

— Син бар, мин...

— Фәнисә...

— Ярый син мәктәп директоры өендә үз кеше.

— Полина Сергеевна гаҗәп итагатьле ул. Ачык. Сине ошата. «Берүк чакыр Фәнисәне», диде.

— Йә, ярар, ул хакта житәр. Каникулны ничек үткәрдең?

— Сөйләсәң сүз, төртсәң — күз, дигәндәй. Килделе-киттеле үтте дә китте.

Таңсылу Петрикны үзләренә алып кайткан икән. Әти-әнисе һич тә ризалашмаган. «Юк, егетең безнең зат-ырудан түгел, килешә-ярәшә алмасагыз, туганнары да тиң күрмәс, — дигәннәр. — Динебез дә, гадәтебез дә башка, юк белән булышмыйк, килешмәгәнне». Әнисенең: «Сөймәгәнгә сөйкәлмә, кызым», — дип үгетләвенә, Таңсылу: «Ул мине ярата, мин дә аннан башка яши алмыйм», — дигән. Бичара ана авызын каплап елый башлаган. Петрик буш кул белән кайтып киткән.

«Берсе дә якламый мине, берәү дә жылы сүз әйтми. Барысы да өйдә артлары белән әйләнеп тора», — дип балавыз сыга Таңсылу. Үзе дә авылыннан әрнеп, канатлары каерылган коштай, җәберсенеп китә.

— Кагылып-сугылып йөрергә язган микәнни безгә? Тегендә — әниемнәр каршы, монда — Петрикның туганнары. Тегендә — кяферлек, монда — басурман, диләр. Кырын карыйлар, бер дә ризалыклары юк кебек. Әнием күрәзәчедәй дөрес әйткән икән... — Таңсылу янә борынын тартып куя.

Мин нәрсә әйтим инде, дәшмим, башымны аска игәнмен. Дускаемны ничек юатыйм, ана ничек ярдәм итим? Нинди сүзләр табыйм? Хупласам, килешерме, җаны басылырмы; үз-үземә каршы барыйммы, ышанычын аклыйммы? Риза булмаган жиремнән ризамын, син хаклы, син дөрес кыланасың, диимме? Үз-үземне алдау, Таңсылуымны әүрәтү, кылану килешерме? Файда бармы аннан?..

* * *

Таңсылу ай-ваема куймады, барыбер алып китте бит. Ул инде Полина Сергеевнага өйрәнеп беткән. Өйләрендә үз кеше. Полина апа да, Таңсылу да кул эшенә осталар. Икесе дә музыка ярата. Әллә нинди концерт, пьеса, прелюдияләрне, фугаларны беләләр... Полина апа пианинода уйный, Таңсылу баянда сызгырта, мандолина чиртә. Таня-Таңсылу, һәрхәлдә, мин түгел инде: башкорт булса да, әллә ничаклы рус романсларын белә, моңлы итеп

жырлый. Ни дисәң дә, пар килгәннәр алар — Полина Сергеевна белән Татьяна Владимировна, башкортча әйткәндә, Таңсылу Шәрифовна.

Полина Сергеевна безне сөенеп каршылады. Николай Григорьевич өйдә юк икән.

— Петяны беләбез инде, өченчедә, дүртенчедә үзем укыттым. Бәләкәйдән ялкау иде. Диктант яздырсаң, башын басып кына утырган була. Дәфтәрен алып тикшерсәң, диктант юк. Баксаң, ул дәфтәр өстеннән кулын гына йөртә икән. Ярты ел шулай этләде. Йә тагы... шигырь ятларга кушсаң, яртысын гына ятлый да, вәссәлам. Эшенең очына чыга белми... Шуннан үзен бик яхшы итеп күрсәтергә яратканын да әйтим. Көндәлегендә «икеле», «өчле»ләрне «дүрт» кә яки «биш»кә төзәтә дә куя. Жыелышта начар укуын әйтсәм, әтисе аптырый...

Без рәхәтләнеп көлешәбез.

— Көлке түгел бу, кызлар, ә кешенең бәйсезлеге, катлы-катлы булуы. Әнә, хәзер йә юньләп эшләми, эчә.

Су капкандай утырабыз: Полина апа да, аптырап, колачларын жәя:

— Ичмасам, шул эчүе булмаса да... — Полина Сергеевна үгет-нәсыйхәтен тукый гына. — Исәр күбәләк төн заманында бер очкын күрсә, шуңа йомыла. Имгәнермен, ефәк кебек юка канатларымны көйдерермен, дип уйламый. Кабаланып-тонып бара. Син дә үзеңне һәлак итә күрмә. Петяны гына түгел, әти-әнисен дә, барлык нәсел-нәсәбен дә беләбез. Алар заты белән саграк булуың хәерле.

— Аларга якын барма, дисең инде, Полина Сергеевна?

— Нәкъ шулай дим, Таня. Сынап, күрә белеп әйтәм. Кыз кеше бигрәк тә сакланырга тиеш.

— Сез дә каршы, Полина Сергеевна!

— Каршымы-түгелме, үзеңнең дә башың житәргә тиеш. Сабый бала, акылсыз кеше түгелсең. Синең яшьтә акны карадан, яшелне ала-коладан аера белергә вакыт.

Николай Григорьевич кайткач, сүз өзелде. Хәйләкәр карт, шампанский юллап йөргән.

— Әйдәгез, кызлар, житешегез! — Полина Сергеевна кыстый гына: голубцыларын, гуляшларын, салатларын алдыбызга тезә. Телеңне йотарлык. Уңган хужабикә белән ихлас хужа өлтерәп тора. Таңсылуның да әзрәк йөзе ачыла төште. Мин елмаерга да, еларга да белмим. Шулай да бу ачык кешеләрдә күңелле. Сине әрсез авыр караш эзәрлекләми, нидер жәфаламый, рәхәтләнеп, иркенләп тын алырга мөмкин. Николай Григорьевич эш турында ләм-мим дәшмәде. Рәхмәт аңа, рәхмәт ихлас кешеләргә!

* * *

Аңламыйм мин Таңсылуны: бер карасаң, житди, акыллы кебек, икенче караганда, жүләрлек эшли дә куя. Кеше, күрә-белә торып, шул эчкечегә карыймы? Марфа әби белән Полина Сергеевналарның: «Бу Танянын күзе юктыр ул», дигәннәре дә дөрестер. Аңламыйм, кичерә алмыйм мин Таңсылуны.

Кара, Николай Григорьевич та кисәткән бит әле, тыйган хәтта, күзенә туры карап: «Акылына кил, кызый, бәхетеңне аяк астына салма!» — дигән. Һәрхәлдә, мин директор сүзен тынлар идем. Николай Григорьевич — Петрикның элекке укытучысы. Петрик, эш сөймәс жан, жиденчене тәмамлаган да укуына кул селтәгән. Өстәвенә, соныннан директорга үпкәләп, өенә эчеп килеп: «Син мине укытмадың, син — буржуй, мәктәпкә хужа булдың»,— дип ачуланып йөргән.

Ярый, Петрик чибәр егет тә, ди. Бер караштан кызларның йөрәге янып көлгә дә әйләнсен, ди. Кеше шулай бер чибәрлеккә генә карап гаилә корамы? Минем

дә анын кебек ут егетләрне күргәнем бар. Армиядән кайткач, алар янына якын барырлык түгел: горурлар, баһадирлар... Безнен физик Гайфулланы да әйтер идем! Шунда Тансылу белән иш килгәннәр бит инде, ишкә куш, мичкә капкач, ишеккә тотка... Гайфулла — бөркет егет. Уралтау карагае, шәмдәй буй-сын, очкын күзләр. Тансылу — су сөлеге, учка салып кына капмалы. Икесе дә өлгергән: Тансылу — гөлҗимештәй пешкән, Гайфулла — армиядән кайткан, икесе дә — башкорт... Юк бит, юк. Тегесе монысына әйләнеп тә карамады, монысы өчен егет бар ни, юк ни, анда егет асылы тора ни, карагай агачы ни. Гайфулла абыен тотты да икенче елга Ишемьярнын бухгалтершасына карады, маржа белән өйләнеште, ә Тансылу-гөлҗимеш эчкече Петрик өчен пешеп житте.

Юк, анламыйм мин Тансылуны, акылым житми, үзенә кемне иш иткән! Нинди кеше ул, кайда, ничек тәрбияләнгән? Ничек ул Тансылудан Татьяна Владимировнага әйләнгән? Әйтү беләнмени! Тансылу беркемгә дә карамады, беркемне дә тынламады.

Октябрь бәйрәме көннәрендә аларнын туе булды. Ишетүемчә, туй кыз ягында гына үткән. Петрикнын туганнары берәү дә Түбәгә бармаган.

## II

Озаграк йоклаганбыз — тышта күптән яктырган. Тирә-якта тынлык, иминлек. Ишек янагына сөялгәнем дә кымшанырга да иренәм. Капканы этәрәләр. Кем йөри? Таңсылу!

Чәй янында Марфа әби Тансылунын хәлен белеште. Тансылу бернәрсә дә яшермәде.

— Туйдым мин, Марфа әби, әле дә башымны күтәрә алмыйм.

— Әй, балакай. Шулай алар, шулай... Затлары белән... Эчәләр, тагылышып йөреп. Әйттем дә инде, кисәттем дә... — Марфа әби янә үзенекен сөйләргә тотынды. — Әтисе улы белән, әнисе кызы белән.

— Төнлә үтә генә чыгалар. Мин — аяк өсте. Әнисе улы яклы, карт башына. Житмәсә, жиде төн уртасында Петрик аракы таптырып урамга куа, янәсе анын туган көне... — Таңсылу буылып елый.

Киленен якларга маташкан картка кычкырып кына куялар: «Кысылып ятма, карт тәре! Килен икән, ирен карасын!» Күзләре тонган, ак-караны күрмәгән Петрик чәчләреннән тотып чоланга этәрә. Тышта салкын. Тансылунын тешләре тешкә тими, бөтен тәне калтырана. Шунда ишек ачылып китә дә чоланга галош оча. Тансылу аны эләктереп, ичмасам берәр шешә алып кайта алмасмынмы, тынычланыр дип, күршеләргә йөгерә. Тапмый. Кайтышлый гына техничка Федоровналарга керә.

— И-и, балакаем...

— Марфа әби, арыдым мин болай, башка чыгарга иде. Син кемнендер өе буш тора, дигән иден... Язга энесе дә кайта. Ул да мине күралмый. Петяга армиядән: «Шул башкирка-басурманкага өйләнсән, абый дип санамыйм», дип язган.

— Булыр, булыр... — Марфа әби кул гына селтәде.

— Язга чаклы ничек тә фатир табарга иде...

— Фатир ни... — Марфа әби тәрәзәгә төртеп күрсәтә. — Анау Митя зимагурнын өе буш инде. Ихатасына адәм аягы басканы юк. Туганнары белән килешергә дә...

— Мәктәп арендага алса, мин анын эчен-тышын сылап, адәм рәтле итәр идем...

— Николай Григорьевичка әйт. Фәнисә белән икәүләп дәшсәгез.

— Әллә, аптырыйм инде, Марфа әби... Башка чыксак, аруланмас, эчүен ташламас микән дим...

Ишек алдында шат елмаеп, мине билемнән кочаклап әйләндергән ахирәтем хәзер ямансулап утыра. Ай күрде, кояш алды шатлыгын.

* * *

Еш кына Таңсылу янына барып утырам. Әлбәттә, Петрик өйдә булмаганда. Андый чакта безгә күңелле. Гүя бөтен дөньябызны оныткан сабыйларбыз. Гүя Таңсылу да тормышта түгел, ә бер җилбәзәк кыз. Петрик өйдә булса, минем белән әйбәт сөйләшә, үзен тәртипле күрсәтергә тырыша. Килештерә. Чит-ят алдында ул тотанаклы кеше, имеш. Интеллигентларча сөйләшә. Үз-үзен тотышына, теленең үткерлегенә, тәртиплелегенә исең китәр. Укымышлы кеше дип торырсың. Таңсылу өчен өлтерәп торган була: әле бу, әле теге әйберен ала, йөгереп суын кертә. Кеше күзе өчен генә түгел микән, дим.

Аларга барсаң, Таңсылуга хәйран калам. Тыштан караганда, Митя зимагурның йортын өй дисәң хәтере калыр. Тавык кетәге, эчкә керсәң — ялт итеп тора. Таңсылу идәннәрен балавыздай ачык сарыга буяткан, стеналарын аклаган, тәрәзәләрен юган. Зур миче дә фәрештәдәй актан гына киенеп утыра. Гүя ул аккош: чак кына кагылсаң да очып китәр. Әй бу Таңсылу тазалык-пөхтәлек ярата да инде: шул лапас түшәменнән дә тәбәнәк өен курчактай җыештырып куйган. Кайчан килмә, караватын, өстәлен, комодын яңача утырта — шулай өй эченә яна төс бирә. Җиһазы инде: почмакта карават, янәшәсендә өстәл; икенче башта — комод, шифоньер... Үтеп йөрер өчен тар гына ара. Таңсылу барыбер канәгать. Сөенечennән башы түбәгә тигән кебек.

— Ике башыбызга ни... — ди көлеп.

Таңсылу куанычының чиге юк. Мәктәпкә дә дәртләнеп килә, шатланып йөри. Кулында бер эш чыдамый. Әле пионерлар белән сборга әзерләнә, әле концерт куя. Мәктәптә үткәрелгән бер чарадан да калмый. Кысылмаган җире юк.

— Вот наша Таня, вот молодец! — дип мактый директор.

* * *

...Мин Таңсылуга текәлебрәк караганмын, ахрысы. Ул да сәерсенеп миңа карый. «Ни булды? Күз тидерәсең бит?» — дип әйтергә җыенган кебек.

— Әйт әле, платье-костюмыңны кайда тектердең? Әллә әзер килеш алдыңмы? Тәнеңә сылашып тора.

— Яз буе шуны тегеп мәш килдем. Петрик тиргәшә. Болай үзенең авызын тиз яптым ябуын. Вельветтан үзенә куртка тегеп бирдем. Шәп килеп чыкты. Менә. — Ахирәтем байлыгын күрсәтә. — Минем Петрушаны беләсең инде, үземә охшап фырт киенергә ярата.

— Ә зоотехник абый нишләп синең җаныңны үрти ул?

Таңсылу авыр көрсенә. Кичә, мәктәптән кайтканда, аны колхоз зоотехнигы туктата. «Татьяна Владимировна, ирегезне әзрәк тыйсагызчы, бигрәк бәйсезләнде, — дип тирги икән ул. — Үткән төнне тагын ике бозавын үтергән... Котельныйда эчеп яткан».

Зыянны каплау өчен, акт төзеп, малларның хакын Петрик өстенә япканнар. Анысы ярый әле. Таңсылу бигрәк тә зоотехникның «ирне ир иткән дә, хур иткән дә хатын, әзрәк тыярга кирәк» дигән сүзләренә гарьләнгән.

— Менә Кырымга барам әле, барам. Бәлки шифасы тияр. Петрушага ул табып бирәм. Баласы туса, басылыр ул. Яшь, бәйсез тайтулак сыман гына бит әле.

Таңсылу Полина Сергеевна белән Кырымга барырга килешкән икән. Анда, Полина Сергеевна әйтүенчә, гинекология авыруларын дәвалаучы шифаханә бар. Барсыннар. Кем белә, бәлки...

Каникулга таралышыр алдыннан, беркөнне туры китереп, укытучылар быел да күмәкләшеп Инәк буена чыктык. Әйдә, бер утырып, иркенләп күңел ачып алыйк әле! Озын уку елыннан соң...

Инәк буенда учак ягабыз, учак өстенә казан асабыз. Бу — безнең гадәт. Ел да шулай җыелышабыз, шаярып-көлеп утырабыз.

Инәк язгы ташкыннан соң тулыланган, куәтләнгән. Шулай да моңсу, ямансу кебек. Үпкәләгән сыман, талгын гына ага да ага. Басылып эшләгән чарасыз килендәй, ерак-ерак ярларга суын ташуын гына белә.

Без Таңсылу белән яр башында аякларыбызны салындырып утырабыз. Усак дөрләп яна, учак өстендәге казанда балык шулпасы пешә. Петриклар балык тотып китерде. Тәмле аштан, хуш исле мәтрүшкәле чәйдән соң уеннар башланачак.

— Өшисең, Петрик! Чык инде!.. — Таңсылу көяләк кеше, ире өчен хәвефләнә. Тегесе тагы бер чума да яр башына күтәрелә. Шәмдәй сонгыл сын кояш нурында бронза кебек ялтырый, күзләрне камаштыра. Коеп куйган баһадир. Тәнендәге һәр сызаты, һәр мускулы үзенә килешле, гүзәл! Бер артык җөй, бер артык сукул юк. Аполлон!

Мин дә сокландым... Таңсылу, бахыркаем, бөркете алдында бөтенләй җебеп төшә.

Нишләптер минем карашларым Таисия Алексеевнаны эзли. Таисия Алексеевна да аклан читенә басып, энесен күзәтә икән. Гаҗәп! Таисия Алексеевна энесен, килененең һәр адымын күзәтә, табыннан соң дилбегәне үз кулына ала.

— Хәзер банк салу уенына, иптәшләр!

Безнеңчә йөзек салышу була инде. Таня-Таңсылу да Полина Сергеевнадан калышмый: арада буталып, уенны куәтләп йөри. Полина апа әзерләгән билетларны тиз генә таратып чыга. Аннан ике ахирәт читкәрәк китеп, бер-берсенә пышылдашып, киңәш коралар.

Барысы да әзер бугай. Полина Сергеевна игълан итә башлый.

— Беренчегә нинди наказ?

Арты белән әйләнеп баскан Таня-Таңсылу наказ әйтә:

— Сандугачтай сайрасын, күңелләрне оетсын!

— ...

— Есенин шигырен сөйләсен!

— Әйдә, уртага чыксын да әтәч булып кычкырсын!

— Тыпырдатып биесен, баскан җирен селкетсен, өерелеп-чөерелеп йөрәкләрне җилкетсен!..

— Сөйгәне алдына бассын — җиде кат башын исен!.. Иелә-бөгелә йөрсен, аю булып дуласын; биеп-очып күрсәтсен. Шуышып-шуышып алсын, елан кебек кылансын; кыргый карчыгадай кыелсын, һаваларга атылсын!..

— Хәтәр табышмак уйласын, үткер елмаю сөйләсен, такмак әйтсен, биеп-җырлап күрсәтсен!..

— Иң татлысы, иң ачысы ни дияр?..

— Җырлый белсә җырласын; бии белсә биесен; бии-җырлый белмәсә, үгез кебек үкерсен; мөгезләрен очлайтып, котү өереп йөрсен!..

Полина Сергеевна моңсу рус романсын башкарды. «Тыпырдатып биесен — җан тартканын түгәрәккә чакырсын!» дигәч, Таисия Алексеевна ялындырып тормады, уртага төште, үзе белән җан тартканы — Николай Григорьевичны — биергә төшерде. Җан тартканы баш басып читкә кача — Таисия дә елгыр — ишен кире уртага тарта.

Таңсылу җинелрәк котылды бугай:

Не жалею, не зову, не плачу,
Все пройдет как с белых яблонь дым;
Увяданья золотом охваченные,
Я не буду больше молодым.

Николай Григорьевич кычкыра, бер дә әтәчкә охшата алмый.

— Булмаса, Полина Сергеевна, үзең ярдәмләш, — ди ул елмаеп.

Алар икәүләшеп, төн тынычлыгын сискәндереп, әтәч булып сузалар:

— Кукаре-ку-у... Кукаре-куук... куку-рекууук...

Урман буе яңгырап, селкенеп торган кебек.

— Жинел котылдыгыз, жинел, Николай Григорьевич! — дип үчекли Таңсылу битенә тир бәреп чыккан карт кешене.

Мине аю ясадылар, чират Петрикка житте. Читтә торган ир-ат дәррәү чәбәкәй итә:

— Һай, афәрин! Монысына молодец!

— Әйдәле, Петя, сынатма!

Бер мәлгә аклан эче тынып калды. Гүя барча аваз, барча хәрәкәт тынды, бары мәһабәт сылу ирнең еш-еш сулыш алуы гына ишетелде. Кешеләр егетне уртага калдырып, арткарак тайпылды. Офыклар киңәйде, һава гөмбәзләре биегәйде. Кешеләр дә, агачлар да кымшанмыйча торды. Жил исүеннән туктады. Барлык әйләнә-тирә, барлык галәм нидер көтә, нидер тели иде кебек.

Төз сынлы ир, дәрәҗәсен саклап, кабаланмыйча басып, хатыны Таңсылу каршысына килде. Барысы да сулышларны тыеп торды. Жил исүеннән туктады, кошлар сайравыннан язды, яфраклар шыбырдарга кыймады. Барысының да күзе Петрикта. Петрик олы мәйдан уртасында япа-ялгызы (сынаулы карашлардан гына да сыгылып төшмәде!) Башка барлык батырлар да шул мәйданны ташлап китеп беткән. Батырларның батыры — Петрик.

Кемдер арттан:

— Петрик молодец! — ди.

Петрик ашыкмыйча башын ия. Таңсылуның туфли йөзлегенәчә! Бер тапкыр, ике, өч, дүрт тапкыр... Биш... Алты...

— Кланяйся, кланяйся перед башкиркой...

Аһ, тыны кысылган Таисия чыдый алмады: энесенең бу хурлыгын күтәрмәде. Аһ, Таиска, Таиска! «Кланяйся, кланяйся!» дигән сүзләрен кайсылай көчәнеп, ысылдап әйтте ул. Ин сәере — моны берәү дә көтмәгән иде. Бөтен кор, бөтен аклан «ах» итеп, тын ала алмый торды. Жавапка ни дип әйтергә сүз тапмады.

Башым сызлап китте. Гүя миемне ярып электр уты үтте. «Таиска — жаһиллыкның аръягына чыккан зат! Таиска— алабарман!...» Чак-чак аңыма килдем: «Туктале, — дим эчемнән. — Монда синең өеңме, монда син кунакка чакырдыңмы? Нишләп гел син кимсетәсең? Сиңа бер чик тә юк. Туктале, нишләп гел син жәзалыйсың?!»

— Таисия Алексеевна, Таня башкорт булып туганына гаеплемени?

— Син тик тор! Кысылма!

— Нишләп?

— Кысылсаң, дурасың. — Тезеп-тезеп китте-китте Таиска, теле телгә йокмый, сүзе арасына сүз кыстырып булмый. — Син дә дура алайса. Син дә! Аны кешегә саныйсың. Аны, сатлык жанны!.. Ул бит жанын гына түгел, тәнен дә саткан бәндә. Кәнтәй! Иблискә жанын да, тәнен дә саткан нәрсәкәй! Аны үз анасы, зат-ыруы каргый...

«Сатлык жан! Кәнтәй! Үз илендә үзенекен тапмаган, чит-ят дин кешесенә капланган. Продажная. Ару булса, үзенекеләр алыр иде...» Колак төбемдә чыңлый гына, зәһәр сүзләре миемне зеңкетә генә. Айнып, зиһенемне туплый, языла, телемнең кормалуларын чишеп ыргыта алмыйм.

— Ә син шуңа кысыласың, шуны яклыйсың! Тик тор ичмасам, син буялма. — Һаман тыелмый, куймый явыз.

— Мин дә башкорт, бу сүзләрен мина да тия! — Ниһаять, мин дә терелдем, соңгы сүзләрем кор эченә ташланган бомбадай ярылды.

Тәүдә карт директор телгә килде:

— Фәнисә, кирәкми!

— Николай Григорьевич, сез гел мине тыясыз, ә Таисия Алексеевнага ләммим. Ул фәрештәмени?

— Таисия Алексеевна, чынлап та, сез хаклы түгел. Фәнисә дөрес әйтә! — Бу Полина Сергеевна иде. Директор хатынының сүзе нишләптер Таисканың өстенә тере су кою белән бериш тәэсир итте. Таисия терелеп, теле чишелеп китте:

— Ярый, ул гына хаклы! Минем шаярту катыш әйткәннән алларак гауга куптарырга әзер. Усалмын дигәч тә...

— Таисия Алексеевна, — Николай Григорьевичның тавышы калтыранды. — Әгәр үзегезне тыя алмасагыз, мин тыярмын...

Күңелле уенның яме китте. Кешеләр төркемнәргә бүленде, кайсылары кайтырга чыкты. Полина Сергеевна, Николай Григорьевич белән без дә олы юлга чыктык. Арттан Таңсылулар куып житте.

Полина Сергеевнаның Таңсылуга сүзе дә бар икән.

— Таня, быел бик нык сызланам бит, аякларым ката да куя. Шул картайта мине. Кырымга барабыз-барабыз дип жыендык та онгыттык. Инде күпме бер балык башын чәйнәргә мөмкин, чыгыйк та китик. Николай Григорьевич, Петя, ни әйтерсез? Шулай түгелме? Таня, сиңа да файдасы тияр, билләһи, дим. Азрак дәваланып кайтырбыз, әйдә! Николай Григорьевич?

— Мин каршы түгел.

— Петя?

— Мин дә.

— Таня, бер-беребезгә иптәш тә булырбыз... Килешербез, әйе бит...

Таңсылу баш кага.

* * *

Жыена торгач, ниһаять, Полина Сергеевналар Кара диңгез буена чыгып киттеләр. Полина Сергеевна өстендә эшмәкәр хатыннар гына кия торган пинжәк. Таңсылуны исә танырлык да түгел. Юлга сарыдан яна сарафан тегеп өлгергән. Өске ягы тар гына, гәүдәсенә сылашып тора, болай да юан икәнен ныграк сиздерә. Ул, киресенчә, нәзегрәк күренергә теләгәндер. Чалбары да юан ботларын белендереп тора. Бу аны бераз яшәртә, әмма мин аның урынында чалбар дип капланмас идем. Әгәр дә Таңсылу жәйге юка күлмәген кисә, ябыграк та, чибәррәк тә, яшьрәк тә күренер иде. Нәзек озыннарга гына килешә ул чалбар.

Болай ахирәтем киеменнән үзе бик канәгать. Ул яңа сарафаннан, әйтерсең, күкнең жиденче катында. Бичара, шартына китерә дә инде. Ишемьярны шаккатырмаса, берәр ягы белән аерылмаса, ул Таңсылу да булмас иде. Үзенә-үзе хыянәт итми Таңсылу, Ишемьярның мода патшасы.

Читтән карап торганда да, бу икәүне һич төпкел авыл хатыннары дип уйламассың. Икесе дә фырт, заманча бизәнгәннәр.

* * *

Әлегедәй күз алдымда: Таңсылу Кырымнан кайтышлый безнең авылга сугылган иде. Яңалыклары күбәйгән, дулкынланган, хисләнгән. Бигрәк тә Полина Сергеевна турында сокланып сөйли.

— Полина Сергеевна тәүдә үк миңа, дөньяда бер Петрик кына түгел, ә башкалар да бар, син әле яшьсең, сиңа ир-ат карый, — дип әйтте. — Әлбәттә,

ул мина яхшылык кына тели инде. Ул мине ничек тә дингез буендагы егетләр белән аралаштырырга тырышты. Мин Ишемьярдан да башка, Петриктан да башка яшь алам! Дөньяда бер Петрик кына түгел! Шул бер әкчече белән дөнья түгәрәкләнми!.. Шундый дәресләр бирде миңа Полина Сергеевна дингездә. Бер уйласаң, ул хаклы да кебек. Дингез буе, сихри хисләр, назлы да, шомлы да дәрья авазлары тилертә, хискә-моңга урый. Иркә дулкыннарга карыйм, онытылам; бронза тәнле ирләр иреннәннән бал тамуын кичерәм — күңелем генә еракта, теге көйсезем калган Ишемьярда.

— Һай, Таңсылуым, син шагыйрә! Чын шагыйрә! — дим мин дә, әрсезләнеп.

— Санаторийда данлыклы врачларга да күрендем. Тикшерделәр ныклап, диагноз куйдылар. Өмет юк миндә, Фәнисә. Бала табу хакында кайгырткачы, саулыгыңны уйла, диләр. — Ахирәтемнең күз төпләре яшьләнә, башы түбән иелә. — Юк, Фәнисәкәем, мин беркайчан да бала таба алмаячакмын. Беркайчан да!..

Таңсылу Кырымга киеп киткән модалы сарафаны белән йөзен каплап елый.

— Чынлап та, Николай Григорьевич белән Полина Сергеевна дөресен әйтәләрдер... Мин — кысыр сыер, нигә Петрикка ябышып ятам? Мин кысырмын, авырумын — нигә әле сау-сәламәт Петрик мин дип интегеп яшәргә тиеш?! Ул да башкалар күк бәхетле булырга, тулы канлы тормыш белән яшәргә хаклы ласа! Бу дөньяга беркем дә ике тапкыр тумый. Әйдә, бүтәнгә өйләнсен дә бала карасын! Дөньясы түгәрәк, бөтен булыр — минем белән шулай ярты җан булып, күңеле кителеп яшәгәнче. Илдә хатын бетмәгән. Җан биргәнгә юнь бирер әле дөньяда...

Мин янә аптырап:

— Таңсылу, Таңсылу, куй, — дим. Ул мине тыңламый да, ишетми дә.

***

«Саумы, Фәнисәкәем, кадерле ахирәткәем!

Син көләрсең, мине йомшаккай, юләр дип атарсың. Беркатлы, хыялый бәндәләрне бик яратып бетермәгәнеңне дә беләм. Шулай да мин аны оныта алмыйм. Еш кына бергә яшәгән елларыбызны күз алдыннан үткәрәм. Барысы да начар булмаган бит, күңелле, сөенечле көннәребез дә бар иде.

Үземне тыеп та, тиргәп тә карыйм, тагы... Барысы да үткән, кире кайтмас ярларда калган бит инде, дим, ә шулай да йөрәк тыңламый — ярсый да ярсый.

Юл унае синең янга кергәч, әллә нишләп күңелем тулышты да китте. Шул мәлдә үземне ничек кенә тиргәсәм дә, горурлык хисе уянуын тойдым. Мин — кешe, берәүнең газиз баласы. Һич тә Петриктан ким түгелмен! Мусульманка булсам да, икенче сортлы зат түгелмен. Өемә әллә нишләп чәмләнеп кайтып кердем Кырымнан. Кайтсам.... Сөекле кешем мин юкта аракы эчендә йөзгән. Барлык дөньямның астын-өскә китергән. Минем арттан ук кеше җыя башлаган... Өйгә керерлек түгел. Пөгәрәптәге сары майны чыгарып ыргыткан. Унбер банка вареньe кайнаткан идем, берсе дә калмаган. Кайсын түккән, кайсын аракыга алыштырган.

Моның түземен ахыр чиккә кадәр сыныйм, диде микән? «Дөньяны көтәм, малларны карыйм» дип калган иде: дөньяны да көткән, сыерны да ташлаттырган. Өстәвенә, үзен фермадан куганнар. Атна буена эчеп яткан.

Аптырап, өйне кабат аклап, кырып-себереп, юып чыгардым. Мин әйтәм, качып китсәң дә чәчеп кит. Дөньям артымнан ташландык хәлдә калмасын... Ни генә димә, нык икеләндерә. Янымда, ичмасам, син дә юксың. Синнән киңәш сорар, эч серләремне түгәр идем. Марфа әбидән кыенсынам. Полина Сергеевна да хуплый. Барысының да сүзе бер: китәргә кирәк сиңа, Таңсылу! Аерылырга кирәк Петригыңнан!

Әй, Фәнисәкәем, ни хәл итим инде? Сез барыгыз да, барыгыз да каршы. Берегез дә аны якламый.

Һаман куркам, сузам. Үземчә: «Ярый, киттен дә, ди... Аннан нишләрсен, ансыз нишләрсең?» дим. Башым кайный. Петригымнан башка көнемнен ни яме бар? Ул, үч иткәндәй, һаман туктамый эчәр. Кем тыяр, кем кисәтер аны? Төпсез упкыннан кем тартып алыр?

## III

Ярый хат бар дөньяда. Кеше хыялынын тинсез жимеше. Кодрәтле, илаһи көч. Араларны якынайта, сагынуларны баса, йөрәкләрне бергә тибәргә мәжбүр итә... Таңсылу белән мин дә шунын аркасында янәшә яшибез, бергә тын алабыз төсле. Монын өчен рәхмәт сина, и мәрхәмәтле Хат!

«Фәнисә, якыным!

Күптән сина язганым юк, әмма мин гаепле түгел.

Бу хакта сина яздым микән? 12 июльдә дәваханәгә салдылар. 1 августта операция ясадылар, ә 8 сентябрьдә өемә кайттым. Фатирыма... Бары 26 сентябрьдә генә эшкә чыктым. 11 октябрьдә Ригадан очтым, 13 дә кич Түбәдә идем... Хәтта ышанасы да килми, мин тере, мин тагы өйдә! Тупсаны керү белән әнием: «Фәнисәдән хат бар», — ди. Әй, сөендем инде! Дөрес язаммы? Хатасы булса, үпкәләмә. Бездә Түбәдә рус мәктәбе генә бар иде. Хаталарын үзең төзәтеп укы! Хәер, Ригадагы кызык хәлне сөйлим әле.

Марталарда телевизор карап утырабыз. Цирк күрсәтәләр. Мартанын әтисе филгә төртеп, бу хайваннын башкортча ничек аталуын сорый. Телемне тешлим. Русча слон инде. Слон, слон дип өйрәнгәнбез бит инде без. Мәктәптә гел слон дип төртеп күрсәттелер, суpәттә генә күргән нәрсәне! Ул безнен авыл тирәсендә очрамый. Абзарыбызда сыер тора. Мин үзебезчә анын сыер дип аталуын беләм. Сарыкны, казны, бозауны беләм, ә слон... Иренемне тешлим. Әйтә алмыйм да куям. Йә искә төшми. Хәер, мин слоннын башкортча әйтелешен дә белмим бит! Ничек була ул, Фәнисә? Марта да, әтисе дә мина текәлеп катканнар, берни дә әйтә алмыйм. Йөзем агарынгандыр инде. Маргаретта көлә. Сыны катып көлә. Бахыр карт та елмайган булды. Гаепле кебек баш иям, белмим, дим. Маргаретта тагы янгырата. Ахырда мин дә кушылган булам... Шулай оятка калдым бит, әй, Фәнисә, слоннын үзебезчә әйтелешен дә белмим. Шунда жир тишеге дә юк — ичмасам, гарьлегемнән төшәр дә югалыр идем.

Ә Латвиядә, беләсенме, туган телгә, үзләренекенә искиткеч игътибарлылар. Өйдә гел латышча сөйләшәләр. Кеше бишектән алып үзенчә генә ишетеп үсә. Балалар бакчасы латышча, русчасы аз. Балалар бакчасыннан мәктәпкә килгәч, укыту тагы тик үзләренчә генә. Рус теле фән буларак кына керә! Теләсән, рәхим ит! Тик болай бөтен жирдә латышча. Хәтта магазинда да, автобуста да. Магазинда латышлар гына сатучы, латышча сөйләшмәсән, сатуга, транспортка, житәкчелеккә, хастаханәгә эшкә алмыйлар да. Магазинда латышча сорамасаң, сина артлары белән әйләнеп басалар. Хәтәр! Ә бездә? Анлыйсынмы? Автобуста латышча дәшмәсән, урын юк. Аягында торасынмы, култык таягына таянасынмы, эшләре юк, латышча дәш! Латышча дәшсән, дөнья синеке, Латвия синеке. Барысы да колачын жәя, йөзен балкыта, үзләренә чакыра. Мин дә хәзер әзрәк латышча сукалыйм... Шулай хәлләр монда, ахирәткәем. Уен эш түгел. Латвиядә латышча гына бара дөньялар. Ә бездә, төпкелнен төпкеле Түбәдә, сабыйлар — бишектән төшкәннән, шуышып йөргәннән алып, атка атланганнан, аннан таякка таянганына кадәр русча сукалый. Башкортча сорама икмәкне: башкортча сорасаң, бер кабым ризыкны, бер йотым суны бирмәсләр, валлаһи, русча сора, русча үтенсән, алдына куярлар. Әле Түбәдәмен. Жир белән күк арасы. Рига, Түбә. Түбәдә тик үзебезчә чиртеләләр,

## ҖИР ШАРЫ — СУГЫШ КЫРЫ

Кызганыч ки, кешелек тарихы – сугышлар тарихы ул. Тарих безгә һәрвакыт үзара сугышлар хакында бәян итә.

Сугыш – стихия. Давыл, җир тетрәү, вулкан шартлау кебек күренешләр рәтендә ул. Сугыш – коточкыч күренеш. Ләкин шуны онытмаска кирәк: матди нәрсә фәкать рухи чынбарлыкның чагылышы, күз күрерлек билгеләре генә ул. Сугыш та — кешелек дөньясындагы эчке рухи халәтнең трансляциясе.

Вәхшилекне сугышта гына күрү дөрес түгел. Тыныч тормыш та вәхшилекләрдән тора. Тормышның төпкелендә кара, акыл ирешә алмый торган яман чыганак бар. Шуннан чыга тирән фаҗигаләр. Сугыш башлаган дәүләткә каршы кайчан да булса яу белән бармый калганнары юк әле. Еллар, гасырлар узгач та кайчандыр яулар чапкан халыкка сугыш афәте килми калмый. Татар халкының тарихи илләр-җирләр язмышы да моңа мисал була аладыр. Без ерак бабаларыбызның илләр-җирләр яулаганнарын горурланып искә алабыз бит. Әйдәгез, дөресен әйтик: татарның бүгенге көне моңдый булу — тикмәгә түгел.

Фәлсәфи күзлектән караганда, сугыш кайберәүләргә максималь ирек бирә кебек. Ләкин синең хөрлегең белән бергә кулга-кул тотынып җаваплылыгың барса гына син чын кеше буласың.

Украинадагы сугыш аерым кешеләрнең мәнфәгатьләреннән чыгып башланса да, меңләгән гаепсез кешеләрнең каны коела. Гомумән, сугышның зур, бөек максаты бармы? Аерым кешеләр теләгеннән генә булса (ә халыкларга сугышларның беркайчан кирәге булмады), сугышның бөтенләй мәгънәсе юк. Кеше үзенә үзе сугыш игълан иткән халәттә яши. Бик күп яман чирләрдән кешене дәвалау чараларын таба алмадылар әле, кеше үтерү кораллары исә — иң югары техник казаныш үрнәкләре булып тора.

Күкне прожекторлар белән яктыртсаң, Күкнең үзен күреп булмый. Анда йөзгән болытларны гына күрә аласың. Болытлар – Күкнең символлары. Тарихны яктыртып карасаң, сугышлар һәм тираннар аермачык күренә. Кешелек тарихының символлары шулмыни инде?!.

Ничек кенә карасаң да, сугыш — чиктән тыш акылсызлык һәм коточкыч ахмаклык ул. Ләкин адәм балалары һәм кешелек тулаем һаман гыйбрәт алмыйлар әле...

Зөлфәт ХӘКИМ
*2014 ел, сентябрь.*

бишектә ятканыннан алып «мама», «папа» дип кенә өздерә. Ха-ха, Фәнисәкәй, мин милләтче булып барам бугай. Ригада яшәп, латышлар арасында бозылам. Кем әйтер хәзер синең Таня-Тансылуың үзгәрмәгән дип. Әйтеп карасыннар! Үзгәрдем, европалаштым, дингез һәм цивилизация һавасын сулап бозылдым.

Әй, юл аша яшәп, җәй буена бер барып урый алмагансың Ишемьярга! Оят! Синең урында булсам, җәяүләп тә барыр идем. Чын!

Хәзер пычрак, җир-су күтәрелгән чак. Беркайда да чыга алмый өйдә утырам. Хәер, аягымда да юк инде, Ригадан туфлиләр генә әләктереп кайтканмын, монда — мәхшәр... Көзге итегем юк. Гадәттә, мин язлы-көзле туфлидә чыгам, үземчә экономиялим... Нишлисең. Минем эш хакы белән бик типтереп булмый.

Көзге итегем дә, көзге плащым да, көзге пальтом да юк. Аласым килә дә ни, бигрәк кыйммәт шул. Быелга ярар инде, киләсе язга кайгыртырмын. Янартырмын өстемне. Син әйтмешли, Ходай бирсә, баербыз.

Чүпрәк-чапрак табылыр ул, менә саулык юк. Кыш буе авырдым, җәй буе дәваханәдә аунадым. Әнием дә кисәтә: «Үзеңне кара», — ди.

Ярый, Фәнисәкәй, пока. Хат яз. Мин өйдә озак ятам әле. Ял итәм рәхәтләнеп туган илемдә. Алда вакыт күп, икенчесендә үзеңә күбрәк хат язармын. Сәлам белән Тансылуың. Түбә. Октябрь, 1980 ел.»

«Фәнисәм, саумы!

Хәбәремне озын-озакка сузып тормыйм. Рәхәтләнеп синең соңгы хатыңны укыдым, әмма кайсы сүзләрен аңлавы кыен. Котлавың өчен дә рәхмәт. Бу юлы мин үзем берсен дә котламадым, кичер.

Вакыт сиздерми үтте дә китте, тагын кире юлга әзерләнергә кирәк. Янә бер атналап торам әле өйдә: әниемнәрне күргәндәй булыйм. Ригага да бер дә аяк тартмый. Декабрьдә эшкә!

Син: «Нигә үзебездә калмыйсың соң?» — диярсең. Мин синең янында Уфада эшләргә җыенган идем бит... Беләсеңме, тормышта барысы да син уйлаганча барып чыкмый шул. Документларым Ригада. Хәзер ноябрь азагы, декабрь башы, тагы да ярты елдан янә май, янә отпуск... Мин шушы елымны сөекле шәһәремдә яшәп, җәй Уфага бөтенләйгә кайтам. Әле уку елы уртасы, Уфада мин кайда урнашам, кем мине эшкә ала? Фатир эзлисе бар.... Сез дә аз җәфаланмадыгыз.

Шулай, мин янадан үземнең ягымлы һәм каһәрле шәһәремә очам. Нишлисең? Дөнья шулай корылган. Һәрчак киресенчә.

Юл унае сезгә сугылырга уйлыйм. Сибайдан Уфага, аннан Ригага очам. Керергә тырышырмын, әлбәттә. Алдан телеграмма сугармын. Киләсе елга, валлаһи, Уфада төпләнәм, синең янына.

Иреңә, улыңа сәлам. Үбәм. Уфада синдә очрашканга кадәр. Тансылуың. Түбә. Ноябрь, 1980 ел.»

* * *

Эштән җибәрүләрен үтендем. Директор каршысына басып, тезләнеп, башны идәнгә генә бәрмәдем инде... Теге явыз, мин РОНО мөдире алдында җавап тотам дип, күзләрен акайтты.

Кул селтәп, янә шөгылемә тотындым: директор РОНОдан кайткан яңа дәреслекләрне мәктәп өчен аерып алырга җибәргән иде. Төшкәчә бетерәм дә фатирыма йөгерәм, янәсе. Иптәшем дә ашыга. Башны да күтәрмибез...

Кайда ул: төшкә кадәр өлгерә алмадык, бер башлагач, түгәрәклик дип тырышабыз. Сәгать көндезге ике, өч тулды. Үземне эчтән юатам: менә-менә тәгәллибез. Кич бар, арада бер буш көн Тансылу белән серләшергә, күгәрченнәр кебек гөрләшергә өлгерербез. Җитәкчедән сүз ишеткәнче...

Дүртенче яртыда кайтып керсәм, фатирда берәү дә юк. Әллә килмәде микән дим, шатланырга да, көенергә дә белмим. Өстәлдә кәгазь кисәге. Тансылуның кичәге телеграммасы бит. «Уфа. 10.15 часов буду у вас. Ждите, Тансылу...» Телеграмманы өстәлдә калдырып киткәнбез.

Телеграмма янында тәлинкәдә — карбыз кабыклары. Телеграмманы әйләндереп карыйм. Икенче як биттә — язу... Тансылуның кулы!

Йөрәгем тибүдән туктарга уйлый. Үзем белән нәрсә булганын аңламыйм. Юк, ышанырга да, ышанмаска да белмим. Ул әле генә монда булган!

Кәгазь кисәге кулымнан төшеп китә. Аның артыннан гәүдәм дә үлән сабагыдай бөгелә, жансыз кешедәй сынсыз булып ятам.

Тансылуым!

Бичаралар, ин тәүдә эш дибез. Тәүдә — жәмәгать тормышы, аннан — үзеннеке... Шулай өйрәнгәнбез. Эш дибез, чәчибез: тормыш сиздерми янәшә үтә. Үзебезне бетмәс мәшәкатьләр, вак ыгы-зыгы били, ә чын эшкә вакыт юк. Гел жәмәгать йөге, гел аның йомышы... Ә жандай дусларыбызга, якыннарыбызга гомер калмый. Янәсе, эшемне бетерәм, янәсе, Таңсылу көтә, куна кала була.

«Фәнисә, саумы!

Синең әрнү-сагышлар белән тулы хатынны алдым. Берни дә эшләп булмый, язмыш бүләк иткәнне кулдан ычкындырдык. Бик тә, бик тә авыр. «Остановись, мгновение! Ты прекрасно!» Гүзәл илаhи мәл тукталмады. Күрәсең, ул безнең кешеләр иркенә буйсынмагандыр.

Язмыш бездән хәтәр көлде. Ул безнең баш очыбызда торган, без искә алмаганбыз. Без жинелдек, тәкъдир тантана итте. Күрәсең, без бахыр жаннарбыздыр, көнебезгә, үз тормышыбызга баш түгелбездер. Үзебезчә яши алмыйбыз.

Очрашуга алдан әзерләнергә булган. Араларда килер киртәләрне, ташыр кичүләрне истән чыгарганбыз. Уфадан Ригага очар вакытны да язмаганмын бит.

Ярый, үткән эштән төш яхшы, диләр. Башны ташка бәреп булмый. Насыйп итмәгәндер.

Минем сөенечле бер яналыгым бар. Кем әйтмешли — дөнья түгәрәк, әйләнеп тора, якты көннәрен, алмашлап караларын китерә. Минем дә шундый бәләкәй шатлыкларым була. Шунсыз ничек яшәргә кирәк... Хәсрәт, бәла, сызлану кешене бетерә, тормышны ямьсезли.

Бер генә көнгә Мәскәүгә, ахирәтемә барып урадым. Ул мине «София» ресторанына чакырды. Иптәшләре белән... Бик күп тәмле-татлы ризыклар татыдым, кызыл уылдыкларга кадәр. Кыйммәткә төште, әлбәттә. Әмма, ин мөhиме, анда үземнең кумирымны — жырчы Евгений Мартыновны очраттым. Янәшә утырдык. Өстәл аша гына... Кызык! Әлбәттә, әллә нәрсәсе дә юк, сылу хатыны бар...

Беләсенме, Фәнисәкәем, шулай аптырап, башны стенага бәрер булып йөргәндә хәтәр уйларга да чумып куям. Валлаhи, дим, шушы фатир хакына хәзер шайтанның үзенә дә кияүгә чыгарга әзермен кебек. ...Тик тагы, тагы үземне тыям, берәүгә дә күтәрелеп карамыйм, берсе дә күнелемә ятмый. Теге көйсеземне уйлап тик йөрим. Әллә мин аның өчен, ул минем өчен яратылганмы? Ялгызлыкка мин күптән күнектем, теләсәм, чибәрләр — аяк астында.

Дөрес, Петрик мине кыланырга да өйрәтте. Мин саф, гадел, ак булырга тырышып карадым... Бәлки, мине көнбатыш бозгандыр, цивилизация дөньясы. Бу хакта курка-курка уйланам. Бәлки, акыллана гына төшкәнмендер? Тиргәшергә барыбер өйрәнә алмадым, hаман да шул ачык авыз кызыкаймын. Үз-үземне яклый алмыйм, юашмын.

Син мине тиргисеңдер әле: башына нәрсә килә, шуны яза, дип. Ялгыштым,

буталдым мин. Башымны югалттым... Син мине үзгәрмәгән дип уйлыйсыңдыр. Үзгәрдем, үзгәрдем мин: мактанчыкка, кыланчыкка әвереләдем. Мичкә шикелле юанайдым, олыгайдым.

Нинди тормыш бу? Бу дөньяда бәхет бармы ул, юкмы? Кешенен көләргә, шатланырга, сөяргә, сөелергә, жырларга, мактанырга хакы бармы? Минем күргәннәрем хәтәр төш, нәжәгай уен гына. Ялт-йолт итә дә сүнә, жылысы да, яктысы да юк. Күңелемдә — жил, йөрәгем — буш, елларым кош сыман оча, ә тормышта һаман үз урынымны тапмыйм. Хәер, тапмам да инде...

Янарак Полина Сергеевналардан хат алдым. Бер ай элек язган хаты чак килеп житкән. Алар Николай Григорьевич белән безне сагыналар. «Башка сезнен кебек дусларыбыз булмады да, булмас та»! — дип яза Полина Сергеевна. Әлбәттә, үткәннәр һәрчак күркәм сымак тоела. Үткәннәр безне үзләренә чакыра, юксындыра... Гел якты көннәр искә төшә. Үткәннәр безне үз кочагыннан жибәрми.

Әлбәттә, бу — кирәк, бу — күңел шатлыгы; әлбәттә, бүгенге көн артыннан үткәннәр кебек хафасыз, унай гына булган сыман күренә.... Узган көннәрдә яхшысы да, яманы да, сөенече дә, көенече дә булды бит. Үткәннәргә сәфәр кылганда, без аны онытабыз, тик унаен гына хәтерлибез. Тормыш авыр, хәтерләү жинел. Хәтерләгәндә көенергә, кайгырырга, нәрсәгәдер омтылырга кирәкми. Тик чәбәкәй итәргә генә, монсуланырга гына мөмкин.

Үлгән сыер сөтле була, диләр. Ә бәлки, исән-сау чагында, ул сөтле дә булмагандыр. Шулай да без үткәннәргә сәфәр кылабыз, аннан ямь-тәм табабыз, бәхет кичерәбез. Ул безгә кирәк. Полина Сергеевна өчен дә безнен бергә булган чаклар ожмах сыман. Ожмах... Әйе, ул чакта без чыннан да бәхетлерәк тә, гамьлерәк тә идек. Чынлап та, Ишемьярда без бергә идек, без яшь һәм бәхетле идек. Кабатланмас Ишемьяр!

Шулай яшәп ята синең Экзотикаң Балтыйк дингезе буенда. Үзе башкорт, үзе ап-ак, үзе нинди дер картинка — Европа мадоннасы. Исәпсез-хисапсыз чирләр белән жәфаланучы бер Экзотика! Йөрәгендә анын бушлык, чүл бураннары котыра, күңелендә, жанында беркемгә дә бер тамчы да мәхәббәт юк.

Шулай, дускай. Ярый, житәр! Таңсылуың. Рига. Февраль 1981 ел».

«Фәнисәм, якыным!

Беләсеңме, жанымны этләр талый, үкереп елыйсым килә. Үземә бу тормышта ямь тапмыйм. Жаным сыкраган чакта шул жырны искә төшердем. Сабый чакта, Түбәдә ишетә торган идем. Хаталары күптер инде, гафу ит. Син минем башкорт теленнән «шәп» икәнемне беләсең бит! Өйрәнергә һич кул житми. Монда латышлар да мине оялтып бетерде. Алар ул якка игътибарлы.

Беләсеңме, бер жыелышны хәтерләдем. Шул мәсьәләгә кагылышлы. Тыңла.

Янарак Рига балалар бакчасы хезмәткәрләре жыелышында катнаштым. Шунда партия кала комитетынын беренче секретаре да чыгыш ясады. Беләсенме (колагыңны тырпайт, игътибарлы бул), шул түрә латышча гына сөйләде. Бер рус сүзе!.. Ярты зал — рус балалар бакчалары мөдирләре, тәрбиячеләре. Мин дә рус балалар бакчасыннан, минем Дарья Павловна Спиридонова да шунда. Алар гөләшә башлады: ахыр чиктә бер таза гәүдәле, калку күкрәкле (гром-баба), рөхсәтсез-нисез урыныннан торып: «Без берни дә аңламыйбыз, русча сөйләгез», — диде. Нәрсә дип жавап бирделәр дип уйлыйсың? Башта залдагылар шаулаштылар, гром-бабаны сүктеләр, соңыннан теге секретарь нәрсә ди? «Монда латыш жирендә яшисез икән, латыш суын эчәсез, икмәген ашыйсыз, туфрагына басып йөрисез икән, телен дә ихтирам итегез, ул илнен учреждениесендә эшлисез икән, анын телен дә белегез. Бу — гадәти, бу — табигый. Әгәр теләмәсәгез, анын учреждениеләрендә

эшләмәгез, суын эчмәгез, икмәген ашамагыз, жирендә яшәмәгез», — ди. Сезне беркем дә тотмый, берсе дә монда чакырып китермәгән, янәсе. Шундый тойгы калды. Кала комитеты секретаре башы белән шулай дип әйтте дә салды. Исебезһушыбыз китте, ачкан авызларыбызны ябалмый торабыз.

Якты киләчәккә өмет итик, ахирәткәем. Ничек кенә әче булмасын язмыш, өмет, ышаныч, хыял дигәнең генә жилкендерә күнелне.

Балтыйктан кайткач кая урнашырымны белмим әле. Уфадамы, башка жирдәме... Киләчәгем — томан эчендә. Томан таралырмы, юкмы?

Картлык — шатлык түгел. Күнелемдә очкын, йөрәктә жылы, гамь юк. Гомумән, соңгы вакытларда тормышның бер кызыгын күрмим. Жирдә яшәүнең ямен югалта башладым төсле. Кайсы чакта ятам-ятам да, «ни өчен шулай сызланып яшим, нәрсәгә ул тормыш мина, барысы да кадалып китмәгәе» дип куям. Ни өчен, нәрсә дип яшим мин? Бер яме, бер тәме. Гел жәфа, чир, бәлаказа, хәсрәт-хәстәр...

Күк йөзендә аз гына яктылык хасил булсачы, бер очкын гына төшсәче тәрәзәмә! Дөньямны аксыл томан, куе болытлар чорнаган, юлларым бикле, хәтта хыялым да, хисләрем дә бикле. Идеал дигәнең бер аллакчы уен гына. Идеал — юк, буш нәрсә: мәхәббәт — кылану, хыял — аксыл томан чаршавы. Хәер, минем хыялым да, идеалым да юк хәзер, бернәрсәм дә калмады. Хәтта минем варисым да калмаячак Жир йөзендә. Миннән Жирдә бер ут та, бөртек тамчы да, хәтта тузан бөртеге дә калмас. Ни өчен, нәрсә хакына яшим мин? Кем өчен газаплар татыдым? Ни өчен килдем мин бу жиргә?

Хәер, бу уйларның барысы да бушка... Беркемгә дә кирәкми. Дөнья, кешеләр өчен, ахрысы, мин артык бер йөк кенә. Мәгънәсез булды тормышым! Тирә-якта — мәгънәсезлек, ямьсезлек. Барысы да бушка гына. Хәзер:

> Уж не жду от жизни ничего я,
> И не жаль мне прошлого ничуть...—

дип кабатлыйм. Тагы шигырь яздым. Ишемьярда «Шул Есениннарың белән саташасың», — дип көлә торган иден. Болар турында язу миңа жинел түгел, Фәнисә. Авыр, әмма кемгәдер әйтергә кирәк бит. Авыр, кыен, ләкин күнелне кемгәдер бушатасы, кем беләндер серләшәсе дә килә. Ни дисәң дә, әле мин яшим, тын алам бит.

Ярый, ачуланма, Фәнисәм. Хуш, сау бул. Синнән сәламнәр көтәрмен. Таңсылуың. Рига. Май, 1981 ел.»

«Саумы, Фәнисә!

Әзрәк үзем турында. Дәваханәдән соң Маргаретта белән театрлар буйлап чабабыз. Драмтеатрның репертуары алмашынды, ару гына әйберләр бар... Спектакльләр, концертлар карыйбыз. Ригага төрле билгеле кешеләр килә. Үзләре жырлый, үзләре уйный, үзләре көлдерә. Alle gop! Бу яктан, Фәнисә, авыл барыбер шәһәргә житми инде. Ха-ха... Мин гомерем буе авылда яшәдем, ә бөтен ягым белән шәһәр кешесемен икән дә... Шуны яңа аңладым.

Кара әле, Петрик хат язган. Көләрсең дә, еларсың да.

8 мартта Ишемьярлар мине котлады. Петядан, Николай Григорьевичтан открытка, Полина Сергеевнадан хат алдым. Фәнисә, бу юлы кыскарак язам. Күп тә калмады бит инде.

1981 ел.

P.S. «Өреп кап!» дигән әйтем нәрсәне аңлата?»

## IV

— Марфа әби, эссе каба бит, нишләп кояшта йөрисең?

— Әйттең сүз. Хәзер эссе кабамыни ул? Июль кояшының кайнарлыгын да ташка үлчим.

— Марфа әби!..

— Бәй, минем кызларым килгән! Таня! Фәнисә! — Карчык язылa. — Онытмаганнар... — Әле генә бөкрәйгән карчык тиз генә гәүдәсен турайта, йөзен сыпыра. — Кара, ничек алай Ишемьярга килергә булдыгыз?

— Әнә, Танян инде, — дим ахирәтемә төртеп. — Ригадан кайткан да мина килгән. Ишемьяр да Ишемьяр дип тенкәмә тия.

— Ха-ха... Марфа әби, көчкә житәкләп китердем үзен, тынламый да куя. «Минем ир, бала», — ди, чак-чак күндердем.

— И, шильма, әбисен, Ишемьярны оныткан шул...

Ишемьяр... һаман да шул Ишемьяр икән. Безнең матур яшел бишегебез. Табигатьнең бер кыргый почмагы. Ул урман белән катышкан диярлек. Әйтерсең лә, мондагы өйләргә, алачыкларга кеше кулы тимәгән дә: авыл табигать кодрәте белән генә яралган да куйган. Өйләре салынмаган, мунчалар буралмаган, ә шул көенчә үлән, куаклар белән бергә үсеп чыккан. Алар — өйләр, алачык, абзар, кетәклекләр — үлән белән, карама, өянкеләр белән бергә үрелеп яши. Ишемьяр яшел бишек кенә. Колмак сабакларыннан, кычыткан яфракларыннан үрелгән бишек.

Мин бары авылга килеп кергәч кенә аны ничек сагынуымны аңладым. Аны күрү күптән күнелем теләге булган. Мин бу очрашуны көткәнмен, ана озак әзерләнгәнмен... Ишемьяр урамнарында кинәттән бөтен хатирәләрем терелде дә куйды. Алар таш астында бастырылып яткан, шулай да һаман үсеп маташкан яшел үлән шытымнары ише, терелде дә китте. Еракта калган гомер искәрмәстән шулай кешене шаккатыра, уйлар дулкынына сала икән.

Без — һаман да Ишемьяр балалары! Һаман да аның укытучы кызлары! Мәктәбе, өйләре таныш яшьтәшләребездәй күзләребезгә төбәлә, үзләренә керергә чакыра бугай.

Юлыбыз — мәктәпкә табан. Марфа әби, гадәттәгечә, кайтуыбызны пешеренеп көтеп торачак! Без кабаттан Ишемьярның укытучы кызлары! Эштән кайтабыз...

Буыннар өзелә, сулышлар кысыла. Барысы да таныш, кадерле монда. Бәхеткә каршы, берәү дә очрамый. Көпә-көндез жил куабыз, бушны-бушка авыштырабыз. Көн үзәге, ә жан иясе күренми.

Мәктәп тышында — Николай Григорьевичның совет власте турындагы сурәте. Художник, чын художник инде ул. Хәзер, ялга киткәч тә, мәктәптә аның рухы яши.

Мин шулай дип уйлап өлгермәдем, алдыбызда бер озын ир пәйда була. Петрик бит. Петрик жай гына басып безгә табан якынлаша. Чукынгыры, горур кеше, башын югары күтәреп, күкрәген киереп жибәргән: жиргә хужа сыман баса. Әйе, ул, нәкъ үзе — ике күзе! Озын, матур төз буй-сынлы.

Мин куркып ахирәтемне күзәтәм. Каушар, коелып төшәр микән... Петрик үзен гадәттәгечә, интеллигентларча тыйнак тота. Йомшак итеп сөйләшә, янәшәдән сак кына басып атлый. Бер ялгыш ишарә ясасамы, бер артык сүз ычкындырсамы...

— Әйе, авылдамын... Кайнам әйтмешли, читтә дә читәнгә элеп куймаганнар...

— Дөрес...

— Кайсыберда генә күнел тулып китә. Авылда күнелсезрәк бит, шәһәрдәге кебек ыгы-зыгы юк.... Хәзер Марфа әбиләргә барасызмы?

— Әйе...

Марфа әби ихатасына кергәч, мин өйгә ашыгам, алар тышта кала. Марфа әби бөтерелеп йөри, тиз генә ашын өлгертергә тырыша.

— Ите пешеп чыгып килә, хәзер...

— Ул чаклы чәчәп барма, Марфа әби, вакыт күп бит әле.

— Син сабыем дип кабаланасың инде...

* * *

Петрикны күпме генә кыстасак та, ашарга кермәде. Таңсылу аны озатып калды. Әллә шуңа боек: авызына су тутырганмыни, ләм-мим.

Марфа әби әллә нинди үгетләрен тукый, әллә нинди хатирәләрен искә төшерә. Төргәкләрен кыштырдата, чәбәләнә, бушамый, өлгерә алмый бер була... Ана да кыен инде. Кадерле кунаклары аяусыз: күзгә күренделәр дә тагы юкка чыктылар.

Ихатага чыгабыз дип кенә торганда, чолан ишеге шыгырдап ачылды. Бәла — Таңсылу юлдашым дерт итеп калды! Әллә нидән курыкты бичара. Йөзе агарынды, күзләре зур ачылып китте. Ул авыр чемоданын дөп иттереп кире идәнгә куйды, үзе агач караватка лып итеп утырды.

Петрик йөри икән. Мин моңа сөенергә дә, көенергә дә белмәдем. «Петрик Таңсылуы, элекке хатыны белән хушлашырга килгән! Җаны бар икән әзрәк», дип уйладым эчемнән.

Шунда ахирәтем тынлыкны бозды:

— Юк, Фәнисә, мин беркая да бармыйм. Мин хәл иттем! — Үзе карашларын туфли йөзенә текәп каткан, миңа да, Марфа әбигә дә, Петрикка да күтәрелеп карарга кыймый.

Мин берни дә аңламыйм.

— Нәрсә хәл иттең? — дим аптырап.

— Мин күп уйландым, ахрысы, язмышым шулдыр. Мин Петрик белән калам! Без сөйләштек инде.

— ...

— Фәнисәкәем! — дип миңа атыла бу. — Марфа әби! Ачуланмагыз, яме! Кичерегез мине! Мин башкача булдыра алмыйм, башкача юлым юк минем.

Алар — Таңсылу белән Петрик — икәүләшеп мине авыл очына озата баралар. Таңсылу да, Петрик та дәшми, бары мин генә, тынлыктан куркып, өзлексез сөйлим, телемә беренче килгән сүзләремне тезәм. Мин аларны акларга ашыгам: алар ике оялчан кеше — яшь ишләр — минем алда сынау тотамыни! Яшьләрне куркытмаска, базатмаска, ямьсез кыланып, кыерсытмаска тырышам. Өлкән җиңгәчәй, пүнәтәй мин аларга!

Шулай көтмәгәндә, тәкъдир кушуына буйсыныпмы, әллә яшьләрнең йөрәк тибешенә иярепме, ахирәтемне кабат Ишемьярда калдырып киттем. Икенче кат дустымны Анның кочагына ташладым. Абайламастан, кадерлемнең олы җиңгәчәсенә әйләндем, аның язмышын хәл итүчегә әверелдем түгелме?

## V

*Үзе теләп очмый яфрак, җил очыра,*
*Җил күтәрә, җил төшерә, җил уйната.*
Йомабикә

«Фәнисәкәем, якыным минем!

Кеше ничек шулай тиз тормыш түбәнчелегенә төшә икән?! Шул яшемә җитсәм дә (озакламый 33, Христос яше тула), үземнең һаман да сәләтсез, тормышка яраксыз, тар карашлы булуыма, яраша-җайлаша белмәвемә,

сукыр рәвештә мәгънәсез дөнья көтүемә аптырыйм. Тормыш күрмәгән кыз кебек, мәхәббәт кодрәтенә генә ышанып, кабат аның кочагына ташландым. Әйтерсең лә, мине якты гөмбәзле хан сарайлары көтә. Әйтерсең лә, мина — унсигез, тормыш тупсасына чак-чак басам... Бертуктаусыз әшәке сүзләр чәпи йөземә. Аның фантазиясенә исем-акылым китә. Чама дигәнне күптән онытты, түземлегем чиктән ашты. Хәзер «әллә ул мине, чынлап та, беркайчан да яратмады, мине үзенә тамчы да иш итмәдеме икән?» дип уйлый башладым. Бәлки, ул мине бөтенләй санга сукмыйдыр, сукмагандыр?

Гел кимсетүле сүзләр сөйли. Яшьрәк чакта бер дә милләт аермаган кебек иде... Бер эчеп кайткан да, «все у меня спрашивают, зачем я на башкирке женился. А я говорю, что специально, чтоб башкирку, бусурманку в христианку превратить», — дигән була.

Азды бөтенләй, әдәп-чама дигәнне онытты. Әйләнгән саен битәрли, төрле кушамат тага, гайбәт сөйли. Уйнашчы да икәнмен мин, дикарка да. Кырымын да калдырмый, Ригасын да... Ригада мин йортсыз, урам фахишәсе булып йөргәнмен.

Бүген әзрәк басылды. Себергә китәм, ди. Автобус тукталышына барып, өч сәгать торып кайтты. Дуңгыз баласын суеп сатыйк та, әйдә икәүләп китик, яңа җирдә яңача яши башларбыз, булганны онытыйк. Акчабыз бер букча булыр, кайгы-хәсрәтсез яшәрбез, янәсе. Йорттагы әйберләрне сатып куюыннан куркам.

Ярар, зарланганым өчен гафу ит, нишлим соң? Хуш, сау бул. Көтәм. Таңсылуың. Степной. Гыйнвар, 1982 ел.»

«Фәнисәкәем!

Теге хатымда зарланган идем бит... Шуннан ярәштек. Нишлисең, бер кыек астында гомер итәбез. Эштә директор, өйдә ул игәде, озакламый түшәккә аудым. Шундук дәваханәгә салдылар. Ун көннән соң эшкә чыккан идем, кашларын җыерып торалар. Хас та Ригадагы мөдирем Дарья Павловна кебек! Ходаем, бар җирдә дә бер үк кешеләр, бер үк тәртип. Директорым: «Эчкече иреңә уч итеп яткансың», — дип ычкындырды.

Дәваханәдән соң эшемә утыртмый, бернинди прогулсыз көе... «Заправкага бар», — ди директор, мин каршы киләм. «КЗОТ статьясы буенча куам», ди. Мин әйтәм: «Хакың юк!..»

Соңыннан дирекциягә гариза илтеп ташладым. Петрик: «Өйдә утыр, әйдә!» — ди. Мин гариза илтәм, ә директор статья белән куркыта.

— Статья белән куарга хакыгыз юк, — димен.

— Ә нәрсә эшлисең?

— Өйдә утырам.

Атна үтүгә Петрикның үзен шул статья белән куалар. Алар хакында, аларның караңгы эшләре һәм өнсез коллары хакында язып ялыктым мин. Арыдым, хәзер бетерәм. Кайчан да булса бер тулырак итеп тасвирлармын әле мин Ырынбур далалары уртасында онытылып калган бу совхоз турында. Тик кайда туктаганымны гына исемә төшерерсең, ямe?

Фәнисә, син миңа дебет суккыч таптыңмы? Исеңдәме? Мин үзем иләргә, үзем үземә дебет шәл бәйләргә хыялланам.

Ярый, хаталарымны гафу ит инде. Хәзер яңадан укып чыгарга хәлем дә, теләгем дә юк.

Таңсылуың. Степной. Февраль, 1982 ел.»

Сигезенче март бәйрәме алдыннан ерактагы ахирәтемнән котлау открыткасы алып сөендем.

Ә 9 май бәйрәменнән соң, мәңге өнсез Полина Сергеевнадан шундый эчтәлекле хат килде.

«Саумы, Фәнисә!

Ин изге теләкләр белән хат язучы Полина Сергеевна дип белерсең. Үзеңә, якыннарыңа күп сәлам житкер!

Беренче хатым бик кыска һәм буталчык булды бугай. Бәлки, син барысын да аңлап бетермәгәнсеңдер.

Таняны Түбәдә жирләделәр. Николай Григорьевич белән без дә бардык. Ишемьярга тагы тетя Марфа да жыенган иде, тик баралмады. Карт бит инде, шулчаклы арага... Мин үзем дә чак-чак йөрдем. Танюша хакына гына инде...

Түбәгә килеп төшкән идек, йөк машинасында Татьянаны китерделәр.

29 апрельдә ул дәваханәдән өенә кайта. Чәчен юа. Магазинга кереп, зур таш савыт белән көзге ала. Барлык ахирәтләрен йөреп чыга. 30 апрельдә миңа хат язган. 5 майда тагын йөрәк өянәге тота. Әти-әнисен чакырталар.

Әнисе килеп житкәндә, ул сөйләшеп яткан була. Туганы белән әнисе совхозга 7 майда килеп төшә, 9 майда иртәнге сәгать унда ул үлә. Янына беркемне дә кертмиләр.

Әнисен күрү белән Таня:

— Әл дә син килгәнсең әле, әни, рәхмәт инде, — ди. Миңа шундый рәхәт хәзер, тәнем дә жиңеләеп калды... Соңыннан: — Һинд чәе китердеңме, әни? — дип сорый.

— Китердем, китердем, кызым, — дип юата ана.

Ике тапкыр шул чәйне кайнатып эчәләр. Иң азактан туганының учын алып учына сала да, «Дай лапу мне!» — ди Есенинча. Соңгы сулышына кадәр шулай үз-үзен юатып, сөйләшергә тырышып ята.

Дәваханәдә үзенә күлмәк бәйләгән — бетерә алмаган. Шуның өчен хат аша миннән бәйләм сорап язды.

Хәзер, әлбәттә, бик авыр, әйтерлек тә түгел инде... Ләкин мине, күпне күргән, күпне кичергән кешене, бернәрсә аптырата, тагы бу турыда сөйлисе дә килми. Чиркандыргыч нәрсә.. Ләкин сөйләмәсәң, Таня турындагы хикәя тулы булмас кебек. Сиңа да күп нәрсә аңлашылып бетмәс.

Петрик белән икенчегә бәйләнгәч, мин аның белән аралашмадым диярлек. Әлбәттә, ул моны авыр кичерде.

Фәнисә, эш принципта түгел, әмма... Әлбәттә, мәхәббәт принципларга, антларга, акылга буйсынмый. Син минем бу кавышуга катгый каршы булуымны беләсең. Ул мине тыңламады....

Соңгы көннәрдә Таня дәваханәдә ятканда, Петрик эчә, хатыны янына барып урамый. Беркайда эшләми, вакытын бушка уздыра. Аны бер жиргә кабул итмиләр. Күз алдына китерәсенме? Шушы көчсез, авыру хатын үзен тулысынча ана арнады. Тере суның тамчысын да чайкалдырмый сөеклесенә бирә. Теге савытының төбенә кадәр эчеп куя... Петрикка гына булсын, ул гына сусамасын!

Хатынының әниләре килгәч тә, күзгә-башка чалынмый: өенә генә кереп чыга. Ишемьярдагы туганнары «кайгысыннан эчкәндер» дигән булалар, ышанмыйм мин. Бәлки, көйгәндер дә... ләкин барып күренергә, янәшәсенә барып утырырга кем комачаулый?

Таняны дәваханәдән өенә алып кайтырга булалар, ә Петрик-туганкай юк. Төштән соң гына кайтып керә. Өшегән-туңган, танавы төшкән.... Тап-таза ир, чибәр бөркет, эшсез, бернинди хәсрәтсез. Күшеккән-ябыккан. Аның үзен күтәрергә, утыртырга, жылытырга кирәк! Бәла!

Ләкин ул кеше юк инде. Юк! Бүтән ул күтәрмәс, утыртмас, ашатмас... Хәзер ул үзе чарасыз, тынычланып ята. Котылган!

Күз алдына китерәсенме? Шуннан Петрик бөтенләй югала, хатынын озатырга да кайтмый. Таняны куярга Түбәгә дә барып тормый.

Кем өчен, ни хакына тырышты, ачыргаланды, түзде ул? Акылым житми. Бу, мөгаен, минем үз гомеремдә кичергән иң жәфалы, иң үкенечле тарихымдыр. Әлбәттә, аны гади алдану, сәер хаталану дип тә атарга мөмкин. Ләкин, минемчә, бу зуррак, гажәбрәк. Бу ниндидер аңлашылмаучанлык, хәтәр тәкъдир...

Фәнисә, янә жәйләр житте. Жәйләр туган саен мин сезне уйлый торган идем. Һәр яшел жәйне каршылаган саен Таняны, аның белән очрашуны да көтә идем. Үзалдыма, сабый бала кебек, бер дә юкка сөенә башлый идем. Ана бит берүзенә Ишемьярга килеп житүе барыбер жиңелрәк. Үткән жәй килгән, әмма мине күрмәгән, кыш көне тагы... Син күзалдына китерә алмыйсың. Аның ягымлы сүзләреннән соң жаныма ничек жиңел, рәхәт булып кала иде. Ул юата, тынычландыра да. Килсә, күңелгә шатлык, сөенеч. Артыннан жаның басылып кала. Кошчык сыман, куркак, йомшак зат. Баш очында талпынып-талпынып торды да еракларга атылды. Мәңгегә югалды күзләрдән.... офыклар артына китеп, һавалар иңенә сеңде. Югалды, юкка чыкты безнең кошчыгыбыз.

Әйе, без үзебезнең иң якын дустыбызны югалттык. Аны, ахрысы, беркем дә алыштыра алмас. Бүтән беркайчан да андый хыялый, жилбәзәк дустыбыз булмас. Бөтен гомеребез буе аны оныта алмабыз. Соңгы сулышкача, йөрәктә яктылыкка, игелеккә урын калганчы аны хәтерләрбез. Мин Танянын туганнарын, илен тәү тапкыр күрдем. Гүзәл халык, ихлас кешеләр, гажәп як. Башка сыйдырырлык түгел: шушы сихри даланың кызы юк һәм башкача булмаячак та. Башкача ул көлмәс, жырламас, бөтерелеп-бөтерелеп биемәс. Мәгънәсезлек! Ахыр чиктә бу Кеше, Табигать алдында гаепле түгел. Ни әйтәсең инде? Күз алдына китерерлекме? Япь-яшь көе... Юк, Фәнисә, мин моны аңлый, моның белән килешә алмыйм. Бу — язмыш, вәхшилек!

Ярый, син гафу ит. Жаным басылмый, үз-үземә урын таба алмыйм. Николай Григорьевич әйтмешли, минем кебек меланхолик, сентименталь хатын да чыгырыннан чыккач. Шул бәла алдында барлык нәрсә вак, буш сыман. Үзем яңа бер нәрсәгә төшендем. Элек жилбәзәк кызыкай булганмын икән. Хәзер генә дөньяны, аның рәхимсез йөзен аңлый-таный башладым. Шушы яшемә кадәр беркатлы көе йөргәнмен. Мин дә мордва, националка.

Сәлам белән мин, Полина Сергеевна. Ишемьяр. Июнь, 1982 ел.

P.S. Тагы онытгым, тетя Марфа тыела алмый, бичара. Ул бахыр әрәм булып ятканчы, үзем генә китсәм, ди хәтта. Күрәсең, балакаен оныта, жанын баса алмыйдыр. Бигрәк өйрәнгәннәр иде шул бер-берсенә... Үз кызы кебек итә иде.»

## Эпилог

*Жил иркенә очып йөргән үзгән яфрак,*
*Көйгән яфрак — аллә ни уй уйлата.*

Йомабикә

Таңсылуның авылын күргәнем юк иде. Ничектер туры килмәде. Ишемьярда эшләгәндә дә, болай да әллә нишләп юл төшмәде. Түбәне ахирәтем сөйләве буенча гына күз алдыма китерәм.

Кырыс, көйсез чырайлы төбәк. Поселокка да, зур авылга да тарткан. Тоташ олы хафага тарыган төсле. Безне дә ятсынып-сәерсенеп каршылый. Эреле-ваклы, калай башлы, калайсыз кыеклы өйләре дә сәламләргә ашыкмый. Алар арасында — Таңсылуның өе. Шул йортларның берсендә минем ахирәтем дөньяга килгән. Моннан төгәл утыз өч ел элек...

Кем уйлаган... Менә аның газиз туфрагы өстендә басып торам. Бик күп дәверләр, борын-борын заманнар буе аның ата-бабалары яшәгән, хәләл тирен,

ал канын түккән жир битендә. Миемне ярып үткән уйдан хиссез-һушсызмын. Барысы да аңа әйләнеп кайта бит! Барлык нәрсә шушы изге туфракка кире әйләнә. Ахирәтем дә инде ата-бабалар, төп төркиләр янындадыр, йә аларга житәр юлладыр...

Мин кымшанырга да, кыймылдарга да кыймадым. Кадерлемне тудырган һәм кире үзенә алган жир....

Кем уйлаган...

Бераздан чак кына айнып киткәндәй булам: күзләрем ачыла, буыннарым языла, сулышым иркенәя. Тирә-ягымны карыйм, шушы офыкларны киңәйтәсем, үземнең, дөньяның, жиһанның хәлен аңлыйсым килә.

Кем уйлаган..

Алдымда өнсез, кобрасы очкан Түбә. Кайда, кайсы тирәдә соң ахирәтемнең өе?

Бик күп илләр гизеп, исәпсез-сансыз жир-суларны күреп-кичереп, ярты дөньяны айкап чыкса да, Балтыйк ярларына — Жир читенә житеп, аякларын сәләндереп утырса да, язмышы аны барыбер сиңа алып кайткан, Түбә. Барыбер синдә башланып, синдә килеп очланып куйган юллары газиз баланның. Монысы — иң мөһиме! Исеңдәме икән: нинди кызың, нинди затың иде ул? Синдә туган, синдә тәрбияләнгән. Нишләп, ничек ул Тансылудан Таняга әйләнгән? Син тәрбияләгәнсең, шушы күкләр астында туган ул... Сине якын күрә, кичерә белә, ярата идеме ул? Аны аңлый, кичерә аласыңмы соң син үзең? Әллә...

Дала өнсез. Барыбер жавап кайтармаячак. Як-ягыма карыйм. Кайсы жирдә икән, дим, сөеклемнең бишеге-биләве, тәү тәпи баскан яшел чирәме?

— Үтегез, үтегез! — Тансылуның әнисе. Нәкъ — ул... Ана болай да шешенеп беткән күзләрен яулык очлары белән каплый. Гөлжимештәй озынча аксыл йөзле, озынча күзле. Шул ук тулы, озын гәүдә. Аксыл соргылт чәчләре дә юкарган. Күз кабаклары шешенгән лимон сымак бөрешеп беткән, битен жыерчыклар ерып ямьсезләгән. Хәрәкәтләре жай, күзләре боек, йөзе сүнгән. Уйламаганнан миемә суга: «Тансылу да, картайса, шулай булыр иде...»

Кем уйлаган... Әнисенә тартса да, әнисенең язмышын кабатлый алмады. Әнисе кебек үз илендә үз оясын корып, кошчыклар очыра алмады.

...Шәригать буенча хатын-кызларга тыелса да, эчкә үтәм. Яңа балчыклы, яңа гына буялган рәшәткәле... Ташындагы сурәттән (Ригага очканда фатирыбызда калдырган фотоның ише!) моңсу-боексу йөзле хатын карый. Минем якыным...

— Менә кайда очланган аның юлы.

— Таң-сы-лу-ым...

Өнем башкаларга ишетеләме-юкмы, эчемнән генә пышылдыйммы, әллә кычкырыммы?

— Таң-сы-лу-ым, мин килдем...

Фотодан гөлжимештәй озынча ак йөзле, озынча соргылт күзле, киң маңгайлы, моңсу чырайлы хатын карый. Әзрәк тантана да, жинелчә ямансулык та сизелә. Әллә уйлар дәрьясына баткан. Беркемдә эше дә, уе да юк. Гүя ул бу дөньялыктан, аның ыгы-зыгыларыннан өстен. Аңа хәзер берни дә кирәкми: торыр йорт та, эш стажы да, дәваханә дә, Петрик та, һәм мин дә, Полина Сергеевна да. Бездән, безнең бу шау-шулы көн итүебездән, омтылышларыбыздан югары. Аны хәзер берни дә алдый, кызыксындыра алмый. Затлы паласлар, капрон тюльләр, түрәләр, бәләкәй патшалар, хәтта жир тормышы — ана берни түгел. Ул дөньялыктан аерылып, ахирәттәге мәңгелек йортына кайткан.

Башым әйләнеп китә, күзләремне чытырдатып йомам. Мәңгелек дөньясы.

Бәй, нәкъ Инәк буендагыча бит монда... Без, Ишемьярның укытучы кызлары, су чәчрәтеп уйныйбыз. Чыр-чу киләбез, куышабыз... Су өстендә — бөрчекләр коена, җәйгор чаршавы, кызларыбызның гамьсез көлешүләре... Яр буйлары яңгырап тора... Менә берзаман ярымялангач Тансылу алга йөгереп чыкты да шарт-шорт фотога төшерә башлады. Килештерә! Без аны «кил безнен янга» дип чакырабыз, ул — карыша...

Шул фото күз алдымда гына. Инәк янында кумәкләшеп төшкәнбез. Кызлар су коена, комда кызына. Иң бәхетлесе, иң шаяны, иң көләче — Тансылу. Тансылу ирәеп елмаеп төшкән. Йөзендә — кояш нурлары...

Күз алдымны яшь пәрдәсе каплый. Буыннарым калтырый, җаным әрни. Ахирәтем янәшәмдә генә бит.

Юлдашыбыз тагын әллә нәрсәләр турында сөйли. «Тимер коймa», «фото», «буяу» дигән сүзләре колагыма кереп кала... Мин исә аны гына тыңлыйм. Ул миңа карый, мин — аңа. Шулай бер-беребезгә төбәлгәнбез дә сихерләнгәнбез. Ахирәтем миңа нәрсәдер аңлатып маташа бугай. Үзенең серен ача.

Мин курка да башладым. Без Тансылу белән чынлап та серләшергә тотындык. Икәүдән-икәү, күзгә-күз...

— Мине монда Экзотика диләр, Фәнисә...

— Китче...

— Чын! Экзотик гөл дип йөртәләр. «Таня» йә «Тансылу» дигән исемнәрне оныттылар. Экзотик гөл — бетте-китте. Башта гына берсе, кап-кара, ямь-яшь чибәре генә Тансылу дип йөдәтте, аннан тагы Таняга әйләндем, азак бөтенләй «Экзотика»га күчтеләр...

Галәмнәргә төбәләм.

Җир, су, Һава, ничек итеп юатыйм мин ахирәтемне? Дускаем, ничек итеп юатыйм, тынычландырыйм сине? Кайлардан, нинди чараларны табыйм? Әй, Җир, Күк, Кояш, әйтегезче! Үләннәр, чәчәкләр, дәшегез! Әйтегезче, каеннар! Газиз туфрак, дәшмисең. Нигә шулай дөнья?

Тора-торгач, аның карашлары янә йомшара, төссезләнә... Ул битараф килеш кайдадыр еракка, минем аша убалар тарафына бага. Хәзер миндә эше дә юк. Бу дөнья гамьнәренә исе дә китми.

Мин элекке ахирәтемне сагынам: монда да экзотикамын дигәнне аңлый, кабул итә алмыйм.

...Без китәбез, син каласың. Сиңа — йокларга, безгә — яшәргә. Син юк, без һаман Җир йөзеннән барабыз... Кайчан очланыр юлыбыз, кайчан очрашырбыз анда?

Хуш, бәхил бул! Кешеләр барысы да Җиргә бәхет өчен килә, хафалар кичерәләр, эзләнеп-ымсынып йөриләр, сөрлегеп китәләр. Бәхетне кеше тапкан да сыман, табып югалткан да кебек... Син дә җиргә бәхет өчен генә туган идең...

...Без китәбез, син каласың, якын кешем. Тагы җиргә язлар килер... Гөлләр чәчәк атар, үләннәр яшәрер туфрагың өстендә. Син лаек аларга. Син үзең дә шул гөлдәй идең, гомерең дә гөл гомере кебек кыска булды: иртән чәчкә атты, ә кичен, кичен инде шиңде.

Кырау сукты ул бичара чәчәкне. Ят тарафның, чит рухның кыравы...



Халисә
Мөдәррисова

# ХӘТЕР ТИБӘ ТАШ ДИВАРГА

## Вакыт һәм хәтер

*Вакыт-хәтер, хәтер-вакыт —*
*Бу мәңгелек көрәш!*
*Бертуктаусыз бу алышта*
*Кальбең белән түләш.*

Бер орлыктан гөл ярала,
Чәчкә ата балкып,
Җимеш пешә, яшәү бирә,
Өмет бирә вакыт.

Бирә-ала. Яшь сылу да
Инде бөкре карчык,
Шәлберәйткән баһадирны
Бу аяусыз вакыт.

Мәмләкәтләр көлгә оча,
Мона чорлар шаһит,
Җилгәрә тегермәнендә
Һәрнәрсәне вакыт.

Дан-дәрәҗә көлке ана,
Туфрак-энҗе-якут.
Тәкәбберне, тимерне дә
Бер сындыра вакыт.

Тәкъдир базары хәрәмсез —
Булмый алдап сатып,
Яшеренеп, качып булмый,
Таба бикләр ватып:

Халисә МӨДӘРРИСОВА — *шагыйрә, прозаик, татар, башкорт телләрендә чыккан «Көмеш дага», «Шамахә төн», «Балан» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Башкортстанда яши.*

Беркем калмас, һәркем китәр
Әҗәл ачысын татып,
Берчак һәркемне тигезли
Гадәләтле вакыт.

Ул туктаусыз хәрәкәттә,
Ул ял итми ятып,
Ходаның көрси җилеме
Бу кодрәтле вакыт!

Ул тезләнмәс, ул тәкәнмәс
Бакыйлыкка шаһит...
...Бер ХӘТЕР алдында баш ия
Галиҗәнап Вакыт.

## Су белән күк

Кочаклаша дәрья һәм күк анда,
Сокландыргыч сихри бу киңлек
Әсир итә, буйсындыра бара
Һәм исертә бәйсез иркенлек,
Су сыртында биегән ак күбек.

Ниһаять, мин — азат! Тын ярларга
Теткәләнгән көймә бәйләнде,
Хәтерләтә бары упкын дәртен
Палубада дулкын сәйләнә.

Күк белән су патшалыгы тәмам,
Табаннарда ныклык, ачыклык,
Бәргәләнү, чайкалудан арып,
Коры җиргә күпме ашыктык.

Ял итәрмен хәзер сөзәк ярның
Соры комын таптап, кинәнеп,
Гадәтилек һәм гадилек килде
Чиксезлекләр белән түләнеп.

Җиденче вал көче онытылыр
Тартмас бүтән упкын гайрәте,
Җилкәннәрне җигү, давыл көтү,
Җиңелү һәм җиңү сәгате.

Сагынмам да, ашкынмам да бүтән,
Башкаларга булсын бу өлеш,
Акылларын җуеп яратсыннар
Һәм киңлекләр диеп җан атсыннар
Булмышлары тулы җыр килеш.

Аяк асты ныклы: ак һәм кара
(Нигә миңа төсләр кызыгы?)
Тынычланыр вакыт!..
Йомгакланыр,
Бәяләнер хагы, языгы...
...Тик ни өчен тарта — су белән күк
Кавыша торган офык сызыгы?

***

Күз-дәрьяңда сөю-көймәм
Һәлакәткә юлыгу,
Кешедән дә һәм синнән дә,
Үземнән дә бу курку.

Жиде жилгә ачык жаным
Бикле менә кысага,
Чикләр чикли алмый дисәм,
Алда кыя, бусага.

Араларда ажгыр жилләр,
Дулкын шомлы, юк тиңе,
Кемдер сине агарттымы?
Йә каралттымы мине?

Хушлаштың, китә аласың,
Арада — күпер — тәүбәң.
Тик нигә соң күз-дәрьяңда
Тирбәлә һаман шәүләм?

***

Уй-каурыйны очлап алып
Маныйм микән карага?
Каерылып караганда,
Вакыт керә арага.

Хәтер тибә таш диварга
Коен тамчысы кебек,
Сәгать теле, көпчәк шавы
Яшен камчысы кебек.

Яшьлектә вакыт вакланмый,
Гомер өләшә генә,
Кояш көлә, яңгыр бии,
Жилләр сөйләшә генә.

Уйлар өзелеп сагындырып
Үткәннен чәчен тарый,
Бикле ишекләрен даулап,
Йозакларын жил талый.

Хәрәкәттә хатирәләр,
Кайтмаска калган йозләр,
Анда — ачыш, анда — табыш,
Жанга кадерле сүзләр:

Каләменне очлап ал да
Сагынып жыр яз, диләр...

Таныштырган, табын корган,
Сөйгән — сөелгән затлар,
Көлмәк теккән, дага бөккән,
Түләсене түләгән һәм
Дөньяны кочкан чаклар.

(Үкендерә үтәлмәгән,
Түнелгән әманәтләр).

Яңгыр елый, жил зарлана,
Кояш көлми — карала.
Вакыт дисбе төймәседәй
Шуа бара, тарала...

...Кем сагынып жыр язарга
Каурый маныр карага?..

***

Ява янгыр, янгыр ява,
Чәчләренә энже түгеп,
Карашларын утлы тамчы —
Йөрәгемә тама кебек.

Ява янгыр, ләйсән янгыр,
Ерак әле кышларыма.
Тамчы булып тамсам иде
Мин дә синең учларына.

## Яңа ел алдыннан

Нигә котелә бу бәйрәм,
Шатлык жанда тоела.
Ә бит учтан гомер-энжем
Берәм-берәм коела.

Берәм-берәм чәчтә — көмеш,
Маңгайларда — жыерчык.
Хәрәкәттә — бәрәкәт аз,
Айдай чырай — кыерчык.

Буыннарда еллар гере,
Хәтердә — югалтулар,
Эреп югалган хыяллар,
Күз яше, юатулар.

Яулый алмаган үрләрем,
Табылмаган хәзинә.
Язылмаган һаман шәп жыр,
Көен тапмыйм хәзер дә.

Тик карасам тирә-якка,
Нурдан күзләр камаша.
Япь-яшь кызым жыр башлады,
Менә гүзәл тамаша.

Хыяллар чынга артыла
Ачсаң ерак якларны.
Хәзер улым үрләр яулый,
Авызлыклап атларны.

Юк, исраф түгел вакытым:
Елларым — орлыкларым.
Минем гомеремне бизи
Энжедәй оныкларым.

Шуңа котелә бу бәйрәм
Ачышта бөтен булмыш:
Учымнан гомер коела —
Курпылый яна тормыш —
Ачышта бөтен булмыш.



Клара
Булатова

# ЯШЕЛ ЯФРАК — ЯШӘҮ ТӨСЕ

БӘЯН

Ничек шулай килеп чыккандыр, Анук авылдаш егетләргә юри дә бер игътибар итми торган иде. Ул үзенең әллә кем чибәр түгел икәнен дә белә, алай да төшеп калганнардан түгеллеген чамалый. Буе-сыны килешле, чәч толымы саллы, зәңгәр күзләренең карашы чиста, якты. Кашлары... Ничектер үзенә бертөрле садәлек-сафлык белән кызнын мәхәббәтле йөзен каплап-саклап торучы канатлары сыман иде анын кашлары... Бөтенесе өстенә, жырга оста иде Анук! Кәләй керәшеннәре гомергә жырчы булды. Әмма Анук, чордашларын гына түгел, озын-озак гомерләрен жырлап үткәргән олы-сарыны да сокландыра иде жыруы белән. Бормалы-бормалы озын халык көйләрен дә, канатлы-уймак заман такмакларын да ул бик тиз ятлап ала, үзеннән әллә нинди төсмерләр өсти, сүзләрен үзе таба, һәр очракта анын үз жыры әзер була.

Минлегали дә анын шул жырына сихерләнеп, суырылып килә иде бугай. Питрау кайтуына килгән иде егет Кәләй авылына. Элек-электән килгән гадәт. Питрау бәйрәмен Якты Күлдә үткәрәләр дә бәйрәмнең соңгы көннәрендә аны Кәләйгә озаталар. «Питрау кайтуы» дип атала бусы. Кая китеп, кайдан кайткан ул Питрау — яшьләрнең анда эше юк. Аларга кичке уен булсын, жыр-бию, кунак кызлары, кунак егетләре булсын! Питрау кайтуына әллә кайлардан киләләр. Татарлар да килә. Дене урыс, теле татар булган керәшеннәр белән алар арасында элеккеге читләшү күптән юк инде. Карт-коры да бер-берсен ят күрми, яшьләрне әйткән дә юк. Шулай да Кәләйнең берәр кызы күрше-тирәдән берәр татар егете белән йөри башласамы?! Ул чагында көне-сәгате белән кабырганны төрткәли башлаячаклар — көт тә тор! Анук белән Минлегали Дөмәй башындагы

---

Клара БУЛАТОВА – *шагыйрә; «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда», «Каурый-канат – җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

чирәмлектән бер генә урап килделәр, яшьләр түгәрәге Анукны эләктереп тә алды, әйләндереп тә салды:

Биек тауның башларында
Мичкә-мичкә керәчин.
Татарлар белән йөрмәсән,
Беткәнмени керәшен?

Беткән ди сина? Бер дә бетмәгән керәшен. Әнә теге Питрау көнне генә килделәр. Керәшеннәр килде. Сәвәләйнен тегерманче Көҗмә килде читават улы белән. Бетмәгән. Әмма кызнын күнелен менә шушы чутыр кара Кәшер татары тарта иде. Жен белсен, ни-нәрсәсе белән тарта. Әллә шул үзенең дә жыр күәсе булуы беләнме? Әнә бит: аптырамады да, куркытмады да, кинаяле, янаулы такмакларга такмаклап кына җавап кайтарды:

Биек тауның башларында
Керәшеннәр базары.
Керәшеннәр белән генә
Сөйләшерлек бар әле.

Анысы сөйләшерлегә бар иде егетнең. МТСта — беренче тракторист! Кәләйнең Краснов Иваны белән шунда бергә эшли. Питрау кайтуына авылларына аны шул Иван алып килгән иде. Елга якын инде алар Әлмәттә бер фатирда торалар. Бик дус күренәләр. Иван үзе дә Кәшергә баргалап йөри. Юкка түгелдер инде, Миңлегалиләрдә житү кызлар да бар дип сөйлиләр...

Миңлегали тегерманче Көҗмә малае кебек «кодагыйлап» маташмаган да булыр иде. Олырак яшьтәгеләр арасында «татар», «керәшен» дип читләбрәк карарга тырышучылар булса да, инде чирек гасырга якын халыклар дуслыгы булган Советлар Союзында яшәү яшьләрнең мәхәббәтен андый киртәләрдән азат иткән. Апай, дәдәй белән Пидуч түти дә аны анламаслык түгел-түгелен, шулай да аларнын Көҗмә Микулаен кире какмаячаклары сизелеп тора. Ике сүзнең берендә: «Дини дә зат нәсел инде. Микулайның эше дә кулай, арты да бай. Ул йортнын пычагы май-бал өстендә», — диган белешмәне Анукка өзлексез житкезеп торалар. Анук та туган-тумача алдында гел үк коелып-жебеп төшми әллә ни. Менә Торыйсын бәйрәмендә дә керәшеннәрнең әллә кай заманнардан калган Торыйсын көенә үзе теләгән сүзләрен салып әйтте дә бирде. Өздереп-телеп әйтте ул аны.

Кочак-кочак яшел яфрак жыйдым.
Капка башларына элегез.
Жан теләмәгәннәрне димләмәгез,
Үзем теләгәнне бирегез...
Яшел яфрак, яшел Торыйсын,
Сөямсең, дип нигә сорайсың?..

Шул ук Торыйсында инде Сарсаз Баграждан кичке уенның да беткәнен көтмичә Миңлегалигә ияреп кайтты да китте. Андагы Пали тутасы да, Кәләйдән бергә килгән дус кызлары да тыңлата алмадылар. Аты-чабуы чыгудан да курыкмады Анук. Кичке уенда төрттерүчеләргә чатнатып жавабын бирә торды.

И, ул түгәрәк уеннардагы жыр аша үртәшү, жаваплашулар! Кайлардан гына табылып торадыр микән ул ут фикерле үткен сүз-такмак?! Кара гына син, әй, һәр куплет, һәр әйтемдә никадәр кинаяя, мәгънә ята бит! Шунысы кызык тагы: керәшен кызларынын телендә гел татар егетләре исемнәре жырга керә. Юкка-

тикмәгә түгел, ә ниндидер тирән ишарә белән керә үзе. Баграждан кайтканның икенче көнендә үк Анукның түгәрәк уртасына эләгүе булды, Жапай Санаучы гөрелдәтеп алып та китте:

> Бакчаларында ишек,
> Кичә булган егетенең
> Фамилиясе ничек?

Шуны гына көткән яшьләр түгәрәкне дәррәү эләктереп тә алдылар:

> Фамилиясен белмәдем,
> Исемнәре Мингали.
> Дөньясында (син дә шунда)
> Төрле хәлләр булгалый.

Төрле хәлләр булгалый шул. Күпшә Настые белән булган хәлне генә ал. Анук белән бер класста укыдылар жиденчене бетергәнче. Класста аннан да тыйнак, аннан да басынкы кыз юк иде. Кичке уеннардан да чаба-чаба кайта, кыланмый, биеми дә, жырламый да торган иде. Егетләр белән чуалганы да ишетелмәде. Анук шикелле атналап-айлап Бөгелмәдә дә укып-өйрәнеп куна-төнә ятмады Начтый. Гел өендә, гел атасы-анасы янында булды. Баксаң-күрсәң, тымызык күлдә корт уйный, дигәннәре хак булып чыккан. Узган Микулайда бугазына житкән корсагы белән Жарык Жәтүнәрнең Метриенә ияргән дә кайткан. Илдә булмаганны! Ничек яшәп китәрләр алар, Алла белә!

Пидуч түти шушы хәлләрне ишетеп кайткач, Анукның колак итен өзми-куймый чәйнәде:

— Кара аны, кызый! Алай-болай башыңны жуеп йөзгә кызыллык жагасы булма. Кара аны, атаң-анаң холкын беләсең! Миргә оят йөзе ясасак, кара аны! Азындың да азындың быелгысы елларда! Танга кадәр жөреш жакшылыкка илтмәс ул. Кара аны, кызыкай!..

Танга кадәр йөреп нәрсә эшләгән соң әле аның кызы? Таңы да бит аның ындыр артында гына. Түгәрәк таралып, Олы Жәйдән ике урарга өлгермиләр, ул тан дигәне пожар лапасы артыннан «пылт» итеп күтәрелеп чыга. Нишләп шулай кыска була икән бу жәйге таңнар? Әлмәттән Краснов Иванга ияреп Миңлегали килгән көннәрдә бигрәк тә.

Кич иде. Пидуч түтәй баскыч төбендә агач ялгашка салып атлык таптый. (Ат кузгалагының орлыгы әле өлгермәгән, шулай да аның йомарланган башын тавыклар бик яратып ашыйлар.) Анук ачык тәрәзә алдындагы сандыкка бәләкәй одеял жәеп кер үтүкли. Күмер үтүге авылда ике генә кешедә бар. Тегүче Кәнифә белән Бөкем Зояларда. Ануклар шуларның әле берсеннән, әле берсеннән алып торалар.

Анук зәңгәр яулыгын бик чәрдәкләмәскә тырышып бастырды да, урындык артына өеп-өеп куйган киемнәрен урнаштыру өчен түр почмактагы чаршауны моржага таба сыдырып куйды. Алача күлмәкләрен хәзер өйдә генә кияр инде, ә бу куе зәңгәргә ал бизәк төшкән сатин күлмәкне Питраугача сандыкка салып куйсаң да ярый. Көненә өчәр күлмәк алыша кызлар бәйрәмдә. Көненә өчәр күлмәкнең барысы да яна булып бетмәс бит!

Ишек төбендә Пидуч түтәйнең кем беләндер сөйләшкәне ишетелде.

— Куй, печкәчәм, авызына да аласы булма! Ни дип әле буе-сыны ныгып өлгермәгән баланы...

— И, алай дип инде. Үзең безнең Апанга чыкканда ничә яшь иде соң сина? Билең дә ныгыган, буең да туенган булган бит. Торыйсында чыксан унарсын,

киявендә гомер торырсын, дигәннәр. Торыйсында киллен. Олы көнгә кыз да табып бирден. Анугыннан да яшьрәк иден әле.

Анук колакларын тырпайтып күпме ишетергә теләсә дә, әнисе белән Пали тутасының бүтән сүзен ишетә алмады, хатыннар утын абзарынамы, лапаскамы кереп киттеләр бугай. Алай да сүзнен ни турыда икәне көн кебек ачык: тутасы Көжмә тегерменәнә су коярга йөри торгандыр инде.

Көжмә тегермәне. Көжмә тегермәненен күпләр өчен серле булып килгән тарихы бар. Революциягә кадәр тирә-юньдә бер саналган Аксаковлар тегермәне ул. Көжмә (Кузьма Васильевич Антонов) үсмер чагыннан ук шуларга бил бөкте. Тумыштан башы йомры иде егетнен, тегермәндә эшләгәндә йомры башына кәкре кулы да кушыла дип сөйләделәр. Егет булып шактый озак яшәде, дүртенче дистәне ваклый башлагач кына әллә кайдагы Ләке авылыннан сазаган бер кызга өйләнеп куйды. Көянтә кебек бөгелеп төшәрдәй шөкатьсез озын торыклы Үлжи Ләкенен умартачы Иван кызы иде. Бай кәләш. Ике байлыкның варислары бергә кушылып төзелгән бу семьяда хәзер «Якты Күл» колхозында счетовод булып эшләүче Микулай — бердәнбер ир бала. Егет атасының йомры башын, анасы ягының каты бизмәнен нык үзләштергән. Ләкедәге умартачы Иваннар саранлыгын анекдот-мәзәк итеп әле дә сөйлиләр. Имеш, көннәрдән бер көнне, әле Үлжи-Ульяна үсмер чагында, Иван картның йортында пожар чыккан. Бөтен авыл җыелып өйдән урамга әйбер-кара ташый, ә Үлжинен Гриш дәдәсе, чоландагы тәпәнгә атланып, агач кашык белән каерып-каерып бал ашап утыра, ди. Авылдашларыннан берсе:

— Нәрсә, әллә күргәнен юкмы? Пожар вакытында тыгынып утырмасан, — дип әрли башлагач, егет чын ихластан:

— Күрсәтер сина әти тик торганнан бал! Элжен көнне дә кашыгын тутырып каптырганы юк, — дип җавап биргән, ди. Бу кадәре булгандырмы, юкмы, әмма дә ләкин саранлыклары хак инде Үлжи ягынын!

Көжмәнен элеккеге хуҗалары 1919 елда ук Себер ягына китеп олактылар. Тегерменгә ут салып та азапланганнар иде дә, Әлмәт яклап килеп өлгергән кызыллар ирек бирмәде. Калды тегермән. Әллә ничек җай туры килеп. Көжмә тегермәннен төп хуҗасына әверелеп китте. Баштарак, 20-22 нче елларда тегермән бөтенләй диярлек тик торды. Якты Күлдән дә, Кәләй, Сәвәләйдән дә тарттырырга йөрүче иген иляре булмады. Тегермәннен яна хуҗасына әйләнгән Көжмә тып-тын гына шунда йорт-каралтысын корып куйды, яшь хатыны артыннан килгән дунгыз балаларын тегермән буасы артындагы тиреслеккә тәгәрәтеп җибәрде. Әрәмәлек куенына умарталар утыртты. 1921 елда булган бер вакыйга Унтун Көжмәсенен авыл каршында гына түгел, район каршында да атын-данын нык күтәреп калдырды. Авыл Советына килгән уполномуч белән персидәтел Василий Красновны да үзе иярте килеп, Көжмә тегермән артындагы олы келәтләрнен берсендәге идән асты амбарыннан Аксаковлардан калган 17 капчык тере бодайны ЧОН отрядларына төятеп җибәрде. (Әлбәттә, андый идән асты амбарлары бер генә булмаганлыгын Үлжие белән Көжмәнен үзеннән башка беркем белми иде шул.)

28 елда каерылып иген унды. Көжмә тегермәненә Әлмәт, Ямаш, Зәй якларыннан ук олаулар агылды. Тегермән алдындагы куе чирәмле ишегалдында шакмак борын мырылдыклар белән шундый ук түгәрәк бер малай да мүкәләп-тәгәрәп йөри. Антоновнын җыйган малларына — хуҗа, олыгайган көннәрендә үзләренә терәк булырга тиешле малайлары дөньяга килгән иде.

Менә шул Микулай сората инде Анукны.

Атасы — тегермәнче, бабасы — умартачы, арты затлы. Күпләрнен астыөскә килгән бу заманда Унтун Көжмәләре кымшанмады. Таза тормыш. Әмма дә ләкин шул тазалыкнын чисталыгына ышанмый Апан. Атап торып төртеп

күрсәтер дәлилләре дә юк анын Көҗмәгә карата, тик күнеле ышанмый. Шуңа күрә берләнбер кызын алар нәселенә озатасы килми. Күрә, сизә, тәгаен белә ата кеше — кыз үзе дә Сәвәләйдән кияүләүне бер генә дә өнәгән кебек түгел. Әнисе генә Пали чанасына утырмакчы, шулар көенә кушылмакчы.

Авылда андый яналык тиз тарала. Кичке уеннан кайтучы яшьләр Олы Җәйне бер иттереп янгыратып үттеләр.

Кәләй белән Сәвәләйне
Тоташтыралар икән.
Алай икән.
Анук белән Микулайны кавыштыралар икән.
Шулай икән.

Анук өстенә ябынып яткан атача җәймәне ачып атты да яланаякларын идәнгә җәелгән суккан патас өстенә салындырды. Бер генә мизгелгә кулларын тез өстенә куеп, сандыгыннан төшми утырып торды ул. Шуннан, катгый бер карарга килгәндәй, җәлт кенә урыныннан кузгалды.

— Шулай булмый торсын әле! — диде ул иреннәрен кысып. — Кавыштырмый торыгыз әле!

Чәрдәкләмәскә тырышып үтүкләгән зәңгәр яулык та, түшен чеметеп кенә бөреп теккән батист күлмәк тә, ак бизәкле сатины да урындык артында Питрау көткән килеш торып калды. Дөмәй буендагы яшелчә бакчасында уталып бетмәгән түтәлләре белән звенодаш кызлары, тегермәнче Көҗмә келәтендә туйга дип куелган әче бал тәпәне, тәрәзәдән шуып кына төшкән кызның кулындагы шакмаклы букчасыннан тотып җибәрми калырга җыенган кебек чәбәләнгән гөлҗимеш куаклары, таң алды качкынының бу дуамаллыгын аңлый алмаудан гаҗиз булып күзләрен шар ачкан бояр гөле чәчәкләре генә калды.

Өченче көн генә үз-үзенә бик нык ышанып, гайрәти дәрт белән:

Урал-елгаларга аулар салдым,
Сөзәгерәк җирен сайладым.
Анук — алтын алмам, алмый калмам,
Гомерлегем итеп сайладым.

Урал-елгаларга аулар салдым.
Табышларын уртак итәрбез.
Атаң бирсә — алтын туй итәрбез.
Бирми торса — урлап китәрбез —

дип җырлаган Кәшер егете — Анукның йөрәгенә кереп мәңгегә калган берләнбер мәхәббәте Минлегали дә калды.

Ленинград читендәге кирпеч заводында эшләп йөри иде Анук сугыш башланганда. Инна белән шунда таныштылар. Анук, гомумән, өлгерлеге, житезлеге белән бүтән кызлардан аерылып тора. Икешәр смена эшли, кичләрен дә чыгып-нитеп йөрми, бүлмәдә җөй тегеп утыра. Авыллардан килгән барча кызлар кебек үк ул да кибетләрдән күпләп-күпләп челтәр, акбүз, чәчәкле ситса, сатин җыя. Олы көнгә бөтен нәсел-нәсәбен баштанаяк киендерергә уйлый. Юк, үзе төяп алып кайту түгел анын хыялында, посылка итеп салачак ул читтә җыйган малын. Үзе кайтмый әле. Укырга керә ул. Инна белән бергә. Инна медпунктта эшли. ФАШ бетергән булган. Хәзер институтка җыена. Анук аның белән аягына кирпеч калыбы төшеп, тубыгы яралангач, бәйләтергә кергән җирдән танышып китте. Курчак кебек матур фельдшер кызның мамыктай йомшак күренгән

кулларының ныклыгына, сыдырылып канаган балтыр итләрен йод эремәсе белән чистартканда, Анук чыраен сыта башлагач: «Түз, түз, калерлем! Ударница башын белән сытылып утыра күрмә тагын, килешми ул сина», — дип ярым шаяртып, ярым юатып сөйләнгән ягымлы тавышына шундук гашыйк булды ул. Яшь аралары әлләни ерак булмаган кызлар дуслашып та киттеләр. Инна Ленинградны яхшы белә. Үзәк урамнарның берсендә яшәүче агаларына да, Эрмитажга да, Бакыр җайдак һәйкәле янына да ияртеп йөрде ул ял көннәрендә Анукны. Үзенең зур врач булырга хыяллануы белән дә уртаклашты, яраткан егетенең фоторәсемен дә күрсәтте. Май бәйрәмендә хәтта Анукка шәмәхә төстәге үтә күренмәле өрфия шарф та бүләк итте. Берничә мәртәбә завод конторасының икенче катындагы библиотеканың уку залына да кереп утырдылар. Мона кадәр китап белән әлләни дус булмаган Кәләй кызы дустына ияреп әкрен-әкрен медицинага бәйле брошюралар, белешмә китапчыклар яздырып ала башлады.

Авылдагы әти-әнисенә дә, Чутыр Минлегалигә дә хат язмады Анук. Үзенең хәбәрсез китеп олагуы белән аларны хафага салуын аңлый, әмма үзе сүтеп киткән күперләрне үзе янадан ничек сузып ялгарга тиеш булуын гына анык белә алмый иде кыз.

Кичләрен кызлар торагы тирәсендә егетләр дә күренә, кыюрак-тererәкләре бүлмәләргә дә үтеп керәләр. Шунда танышып, өйләнешеп кайтып китүчеләр дә булды. Анукка да күз төшерүче, сүз кушучылар әз түгел. Әмма кызның күңел пәрдәсен күтәрерлек, Минлегали урынына үтәрлек, аны онытгырырлык кеше очрамады. Дөресен әйткәндә, андый кеше очравын үзе дә теләмәде кыз.

Дус кызларның уку хыялларын сугыш өзде. Медицина дөньясына да аларны шул сугыш ашыктырып-куып алып кереп китте.

Блокада көннәрендә үк Инна эшли башлаган хәрәкәттәге кыр госпиталенә Анук үз теләге белән килеп эләкте. Кыскартылган рәвештә оештырылган махсус курслардан кызларны ашыктырып-тизләтеп фронтка ук озату очраклары шактый булып тора иде ул чакта. Инде менә сугыш башланганга да ике ел үтеп китте. 1943 елның июне... Медсанбат күбрәк ылыслы агачлар үскән урман төбенә килеп урнашты.

Ә менә Аннаның туган ягында күбрәк каен, юкә. Бу вакытта инде анда дөньяның куе, чиста яшеллеккә чумып, төренеп утырган вакыты. Урманнарның әле итәге дә керләнмәгән. Урман читләре Питрау житәрәк кенә бераз карала башлый, анда да явымсызрак, корыган елларда гына җәй тузаны сарыла аларга. Ә бу вакытта чиста яшел урман — яшьлекнең үзе төсле...

Анна, юл буенарак сындырып ташлаган чыршы ботакларын иңләп кенә кочагына алды да медсанчасть урнашкан аланга илтүче сукмакка кереп китте. Ботакларның ялпаграк, җәенкерәкләрен җыярга тырыша ул, алары землянка идәненә җәйлы түшәлә. Табигать үзе биргән хуш исле яшел паласлар. Госпиталь начальнигы Морозов үзе кушты аны кызларга: «Күзләр — төсен күреп, борыннар исен сизеп куанырлык булсын», — диде. Әтисе кебек якын булып киткән бу чал чәчле олы кешенең әлеге тәкъдименә Анна чын күңеленнән шатланып кушылды. Дусты Инна гына: «Әллә ниләр уйлап чыгара безнең картлач, башыботы ботарланган солдатлар өчен ни шайтаныма кирәге бардыр аның «яшел паласы»ның», — дип маташты. Тик бүген менә ул да бик теләп Анна белән бергә ике катлы итеп эшләнгән җир асты шифаханәсенә колачлап-колачлап ылыс ташый. Үсеп утырган чыршыларга тимиләр алар. Урманның яныл-тапалып бетмәгән өлеше үсәргә, яшәргә тиеш. Фронт артыннан яз белән бергә яшәү дә кайта бу якларга. Инде безнекеләр кырыла-кырыла чигенмиләр хәзер, кырa-кыра дошманны куалар. Сүз дә юк, сугыш, билгеле, кыруын дәвам итә. Яралanучылар да, һәлак булучысы да житәрлек. Анна госпиталь урнашкан каенлы аланга килеп чыкты. Урнашу ыгы-зыгысы туктаган, медсанбат яна урында

яна яралыларны кабул итәргә әзер иде инде. Төсе унган плащ-палатка өстендә санитарларның үзен землянкага алып керүен көтеп ятучы яралылар арасындагы кара-кучкыл егет кинәт терсәкләренә таяна төшеп күтәрелде дә үз күзләренә ышанмаган бер аптыраулы-куанычлы рәвештә кычкырып җибәрде:

— Анук! Син бугай бит, Анук?!

Анук Миңлегалигә нинди куркыныч янавын аңларлык хәлдә түгел иде әле беренче көндә. Аның башында, миендә бер төшенчә! Ул исән! Ул исән һәм алар очраштылар. Очраштылар! Очраштылар! Айлар буе, ике ел буе кулыннан-күзеннән үткәргән яралы солдатларның йөзеннән сөйгәненең чалымнарын эзләүдән үк туктаган иде бит инде ул. Туктаган иде. Фронт зур. Фронт әле дә илне аркылы кискән. Аларның медсанчасте хезмәт күрсәтә торган әлеге линиягә, нәкъ менә шушы билгесез бер кечкенә таучык итәгендәге өч-дүрт кенә каралтыдан торган хутор артындагы урманлыкка аның Миңлегалие килеп чыгар дип уйлау бернинди хыял кысасына да сыя торган нәрсә түгел иде. Ә ул менә килеп чыкты — ничек кенә булмасын, нинди генә булмасын. Нинди генә булмасын?

Юк, тукта — ничек инде? Хәзер генә аның бөтен барлыгын өшетеп куркулы борчу куырып алды. Ничек? Ничек инде? Әйе, исән. Исән. Әмма... Анук Пекла әбисенең гел генә кабатлый торган: «Дүрт саның төгәл булсын, шулай булмаганда исән кеше түгел инде син», — дигән сүзләрен исенә төшерде.

«Дүрт саның төгәл булсын». Ә соң Миңлегалинең аяклары? Аяклары — «осколочный перелом, сазлыкта шактый озак яткан. Гангрена яный», диде хирург. Әнә аны Морозов янына ашыгыч операциягә әзерлиләр. Операциягә. Кисәчәкләр бит аның аякларын. Кисәчәкләр. Чөнки кыр госпитале шартларында соң чиккә җиткән гангренадан бүтән котылу чарасы юк. Юк, юк. Ә бит аңа 22 яшь тә тулмаган. Тулмаган. Егерме икесе Торыйсыннан соң гына тула аның. Әйе, Торыйсыннан соң гына тула. Анук яхшы хәтерли. Яфрак бәйрәменә әзерләнгәндә әйткән иде бит ул аңа! «Менә алдагы атнада унсигез тула инде миңа, шуннан соң Алан дәдәй белән аяк терәп сөйләшербез», — дип. Аяк терәп сөйләшергә өлгерә атмый калдылармы? Аяк терәп сөйләшергә өлгерә алмый калдылар шул. Тукта, тукта... өлгерә алмый калдылармы? Аяк терәп сөйләшергә... Аяк терәп... Әйе, әйе. Нәкъ менә аяк терәп сөйләшергә... тукта. Юк, юк, алай түгел. Алай кирәк түгел. Тукта. Аяк терәп сөйләшергә кирәк аңа. Аяк терәп сөйләшергә тиеш Миңлегали! Аяк терәп, яшь бит әле ул...

— Бабакай! Прокофий Николаевич! Зинһар, туктагыз! Тыңлагыз әле, Прокофий Николаевич!

Морозов бармакларын тырпайтып өскә күтәргән кулларын төшермәгән хәлдә терсәгенең эчке ягы белән күзлеген этәреп куйды да тыны-көне кабынып одеял ишектән атылып-бәрелеп кергән санитарка кызга сораулы караш ташлады.

— Туктагыз әле, доктор! Тыңлагыз әле!..

Ә бит тыңлады бабакай Анукны. Тыңлады, аңлады, кулыннан килгәнен дә, килмәгәнен дә эшләде. Гәрчә кем белә: бәхетле очраклылык та булгандыр, бәлки. Нәкъ шул көнне госпиталь өчен кирәкле медикаментлар белән самолёт килде, һәм Миңлегалине шуның белән эчкәре госпитальләрнең берсенә озату мөмкинлеге туды.

***

Сугыш беткәч, Анук ни өчендер медицина институтына барырга уйламады. Дөрес, Инна белән аларның: «Исән калсак, институт бетереп, югары белемле врачлар булырбыз әле», — дигән сүзләре бар иде барын. Инна шулай эшләде дә. Җиңү көне килү белән, бөтен «фронтташ ярларын» селтәп ташлап, Ленинградка кайтып китте, мединститутка кереп укый башлады. Фронтовиклар өчен булган

ташламалар да, хатын-кыз чибәрлеге дә әлләни кирәк булмагандыр ана монын өчен. Ни генә дисәң дә, башы, белеме бар иде Иннаның. Анук башка. Инде рус телен ярыйсы ук үзләштерсә дә, үзенең тулы булмаган урта белеме белән генә әллә кая бара алмый шул инде ул. Аннан соң, әгәр исән калган булса, Минлегали дә Әлмәт ягына кайтырга тиештер ләбаса.

Бөгелмә вокзалында да һәркайдагы күренеш: килеп туктаган эшелоннардан хәрби киемлеләр коела, перрон читенә үк килеп туктаган чытыр арбалар, такта кузовлы-әрҗәле йөк машиналары. Машиналарның берсендә сынар күзенә кара повязка-бәйләм ябылган солдат гармунда уйнап җырлап утыра.

Бер метрлы сары каеш
Әле дә билендә микән?
Исән микән? Үлгән микән?
Әллә пленда микән?

Анукның йөрәге чемердәп куйды. Әйе, шушы өч сорауның берсенә дә җавап юк бит әле Минлегали турында. Морозов тарафыннан самолётка салып үзәккә озатылганның соңында бернинди хәбәре дә булмады аның.

Апан дәдәйнең өе элеккечә көлеп тормый. Яз бер, көз бер келпеткеч белән эчентышын кырып юалар иде дә бит аны Анук үскәндә. Ачлы-туклы сугыш елларында көчле яшь кулларсыз калган ихатага андый карау житмәгәнлеге күренеп тора шул. Алай да янбакчадагы бояр гөлләре чекерәеп-балкып шау чәчәктә утыра.

Яшьлек дуамаллыгы белән өеннән качкан, жиңү белән сугыштан кайткан солдат кызны ата-ана гына түгел, бөтен Яләк авылы нишләтергә белмәде. Өй борынча аш-су: туган-тумача, кода-кодача хәленчә кунак итәргә тырыша, йортында өйләнердәй егет заты булганы үзенчә «җәтмә салу» җаен да карап карамак булып уй йөртә. Озын-озак кунаклап ятмады Анук. Вакыты-чоры ул түгел. Бернечә көн үтүгә, почта йөртүче Көйгән Күчтәсенә утырып район үзәгенә юл тотты. Военкоматка учётка басарга, эшкә урнашу мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде кызга. Күчтә, гажәеп жор телле һәм житез егет, юл буе соңгы елларда чыккан халык жырларын такмаклап барды.

Атланып корчаңгы атка
Барам военкоматка –
Киңәш итәргә.
Ашаганым алабута,
Ашасам эчем авырта –
Инде нишләргә?

Анук егетнең зәңгәрләнеп калган ябык йөзенә карап: «Бүген иртән нәрсә генә ашадың икән соң әле син, бахыр», — дип уйлап куйды. Нәрсә булсын? Мөгаен, шул алабута күмәчедер инде. Булса-калса. Күчтәнең әтисе сугышның башында ук диярлек үлеп калган. Дүрт балалы Маланжа түтәйдә бүтән нәрсә булсын ди?

Анук военкомнан үзен эшкә юллаган тәкъдим хатын алып, район үзәк больницасының хуҗабикәсе Балахина янына китте. Чем-кара чәчле, кара күзле, зифа буйлы, чибәр, әмма кырыслыгы карашында ук чагыла торган Зифа Мостафовна сүзне озакка сузып тормады.

— Кайчан эш башлыйбыз, Анна Афанасьевна?

Анна Афанасьевна иртәгесе көнне үк хирургия бүлегендә эшли башлады.

Эшен яратып, белеп башкара иде ул. Дүрт елдан артык атаклы хирург Морозов кул астында эшләү кыз өчен әллә нинди югары уку йортларын алыштырырдай мәктәп булган иде шул сугыш вакытында. Алай да район

больницасының үз үзенчәлекләре, үз шартлары, үз таләпләре. Сугыш бетү белән авырулар кимемәде. Аннан соң ике ел рәттән килгән ачлык үзе дә ана кадәр искиткеч яман эзен салган. Канлы үлем елы дип аталган кырык өчтән калган хроник авырулар да, фронтовикларга ияреп кайткан дөньякүләм имәнгеч чирләр дә ил-халык тормышын төптән кимереп шактый интектерде. Кешеләрнең шәхси тормышлары, үз тормышлары да пира-зара килеп бетте. Жыр-дастаннарга гына лаек булган яшьлек мәхәббәтләре челпәрәмә килде, язмышларга сылтанган ялгышлар, ялгышлардан тукылган язмышлар күбәйде. Әсирлектән котылып илгә кайтучылар үз илләренең тоткыннарына әверелделәр. Теге яки бу сәбәп белән сугыштан соң да ихтыярый-мәжбүри читтә калганнар, хәбәрсез югалганнар кайта, табыла башлады.

Минлегали бер хәбәрсез иде. Анук кына түгел, аның кайдалыгын авылларында да белмиләр. Атасы сугышка кадәр үк үлгән, ә анасы каты яраланып госпитальдә ятучы улы янына күрешергә барган жиреннән юлда вафат булган иде. Писмәндә яшәүче сеңлесе Анук белән күрешкәндә:

— Исән ул, — диде. — Маржа хатыны белән кайдадыр Мәскәү тирәсендә яшиләр. Ике балалары бар бугай...

Хирургия бүлегенең өлкән шәфкать туташы Анна Афанасьевна Красильниковага 29 нчы яшь киткән иде инде. Дөньяның ачысын-төчесен татыган, фронт юлларыннан ир-атлар белән бергә сугышның бөтен авырлыкларын үтеп исән-сау кайткан, тәне дә, рухы да сау-сәламәт кызга гаилә корып балалар үстерергә бик-бик вакыт иде инде. 1952 елның көзендә ул үзе кайчандыр баш тарткан, кияү куенына керәсе жәйдә «кавыштырмый торсыннар әле!» дип чыгып киткән егеткә — Сәвәләйнең тегермәнче Көжмә малае, хәзер инде икмәк заводы директоры булып эшләүче Николай Кузьмич Антоновка кияүгә чыкты. Туйны алар үз вакыты өчен бик бай, бик купшы итеп үткәрделәр. Һәр ике нәсел өчен бик отышлы, уңышлы бәйләнеш булып тоелды ул. Бәхетле туганлашу, бәхетле кушылу. Николай Кузьмич өчен аеруча. Ни генә дисәң дә, ул үзенең моннан 13 ел элек кодалаган «качкын» кәләшен барыбер саф, кагылмаган хәлендә, анасы әйтмешли, «мыскылланмаган жефәк килеш» үзенеке итү бәхетенә иреште бит! Дөресен әйткәндә, «сугыш списать итә» дип бик күп хатын-кызлар гонаһка батып кайткан ул елларда үзләрен саклап кала алган фронтовичкалар чынлап та хөрмәтләү-табынуга лаек булгандыр. Алар начар яшәмәделәр. Анна ханым булдыклы хатын, яхшы ана, ярдәмлекле килен, игелекле күрше, мәрхәмәтле кеше булып гомер кичерде. Тик Николайның кайнар мәхәббәтен шундый ук кайнарлык белән кабул итә алмады. Бары тик хатынлык вазифасын гына башкара иде Анук. Төшләрендә ул һаман Минлегалине күрә, һаман аның:

Анук, алтын алмам, алмый калмам —
Гомерлегем итеп сайладым, —

дип жырлаганын ишетеп уяна иде. Гомер буе шулай.

Анна Афанасьевна пенсия яшенә житкәч тә байтак вакыт эшен ташламады. Район больницасы заманча салынган зур таш бинага күчкәч тә әле аны эштән жибәрмәделәр. Инде тулаем лаеклы ялга чыкканнан соң да ул үзе белән озак еллар бергә эшләгән коллективтан аерылмады. Тик менә Анна ханым, ни дәрәҗәдә теләсә дә, дүрт баласының берсен генә дә тыйбб (медицина) дөньясына кертә алмады. Әтиләре сүзен алга алдылар балалар. «Бер тиенсезгә кеше гомерен саклыйм дип яшәргәме? Түләүсез гомер сатыпмы? Син интеккән житкән!» Тегермәнче Көжмә тамырының жепләре көчле иде.

Соңгы елларда Анна Афанасьевнаның Мәскәү асты сазлыкларында салкын тиюдән сихәтлеген югалткан аяклары борчый. Менә бу язда да (ничәнче тапкыр

инде) аны кайчандыр үзе эшләгән больницага носилкада китерделәр. Кабул итү бүлмәсенә өченче каттан төшкән яшь хирургны күрүгә, Анна ханымның йөрәге туктый язды.

«Миңлегали!» — диде ул эчкә йотылган ярым тавыш белән. «Юк, Анна апа. Миңлегали түгел. Дамир Миңлегалиевич — безнең бу яңа врач. Дворкин урынына килде. Мәскәүдән үк ул!» — дип пышылдап өлгерде кабул итү бүлмәсендәге сестра.

Яшь хирург Миңлегалинең аумаган-ашмаган күчермәсе иде. «Урсалелгаларга аулар салдым...» Мәскәү астындагы химия заводларының берсендә эшләп пенсиягә чыккач Миңлегалинең туган ягына кайтып өй салганын да, беренче хатыныннан аерылганын да ишеткән иде инде Анук. Әмма аның олы малаенын врач икәнен дә, бигрәк тә Мәскәүдән монда килеп эшли икәнлеген дә белми иде. Ә бүген ул нәкъ менә Дамир Миңлегалиевич палатасына килеп эләкте. Диагноз житди, житди генә дә түгел, соң чиктә куркыныч. Гангрена.

— Әле дә йөргән инде ул бу аяклары белән. Гомер буе сызланып эшләгән. Казанга жибәрүдән дә, Мәскәүгә озатудан да фәтва булмаячак, — диде баш врач. — Мине дөрес аңлагыз: элегрәк үзем белән бергә янәшә басып эшләгән апаның аякларын кисә алмыйм. Булмый. Сезгә туры килә, Дамир Миңлегалиевич.

Яшь белгеч баш тартып тормады. Профессиясе шул.

Аннаның баш очында инде аны өч айга якын саклаган, караган төпчек кызы Инна утыра. Ул әле узган ел гына сәүдә техникумын бетереп, «Девон» кафесында эшли башлаган иде. Әнисенең ныклап авырып китүе сәбәпле, менә эшеннән аерылып торырга туры килде. Әлбәттә, аны алыштырырга жиңгиләре дә килгәләп йөрде. Шулай да даими караучысы Инна булды анасының. Авыруның хәле аруланып килә. Хәзер инде аны өйгә алып чыгарга мөмкин, диделәр. Мәскәүгә протезларга заказ жибәрелгән, алар кайтканчы карчыкананы коляскада йөртергә туры киләчәк. Анна Афанасьевна уйчан карашын Иннадан ала алмый байтак эндәшми ятты. Хәзерге яшьләргә хас булмаганча тыйнак аның Иннасы. Балалары арасында бер ул аның үзенә охшаган. Әнә калын сары толымы, һиндыба чәчәге кебек зур зәңгәр күзләре. Өстенә кигән киң итәкле зәңгәр күлмәгенә кадәр...

Палатага Дамир Миңлегалиевич килеп керде.

— Йә, Иннушка-күкчәчәк. Анна апа белән әлегә саубуллашып торырбыз инде. Озакка түгел. Протезлар кайтып житүгә, янадан монда алып киләсе булыр. Беренче көнегүләрне безнең күзәтүләрдән башка үткәрергә ярамас.

Авыруны носилкада машинага алып чыгучы санитарлар белән янәшә атлап барган Дамир-хирург Иннаның беләгеннән тотып әкрен генә:

— Минем үземә дә сезнең йортка килеп йөрергә мөмкин булыр бит? — дип сорады.

Кызның йөзенә йөгергән алсулык, оялчан тибрәлгән керфекләр ананың күзеннән читтә кала алмады бу мизгелдә.

И кадыйр! И Тәңрем! И яшьлек! Ә урамда агачлар ямь-яшел. Жәй башы. Торыйсын атнасы түгелме соң бу?

Яшел яфрак — яшел Торыйсын,
«Ни хәлләр?» — дип никләр сорыйсың?
Яшел яфрак яшәү төседер,
Торыйсыннар яшьлек өчендер.

*Башкортстанның Яңавыл районы Татарстаннан бик еракта булса да, татар әдәбиятына Илдар Юзеев, Нил Юзиев, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Нурихан Фәттах кебек талантларны биргән як. Әдәбиятка, шигърияткә тартылу бу төбәктә бүгенге көндә дә көчен югалтмаган. Яңавыл каласында инде 40 елга якын төрле районнарда яшәп иҗат итүче, төрле өлкәләрдә эшләүче иҗат көчләрен туплаган «Замандаш» әдәби берләшмәсе эшләп килә. Аларның иҗатларын тагын да үстерү, җанландыру максатыннан 1992 елда биредә Яңавыл Язучылар оешмасы төзелә (җитәкчесе — шагыйрь Фәрит Суфияров). Әлеге оешмада торучыларның кайберләре инде Башкортстан Язучылар берлеге әгъзалары, берничә китап авторлары. Укучыларыбызны аларның иҗатлары белән таныштыру максатыннан берничә шагыйрьнең шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

# Фәрит Суфияров

## Үз халкымны зурлыйм

Куанычларымны уртак итәм,
Канатлана йөрәк, талпына.
Тау кадәре хезмәт күрсәтергә
Исәп тотып яшим халкыма.
Максатыма төбәп юнәлдисәм,
Мин яулыймын хөрмәт-дәрәҗә.
Хыялларым чакыра мине юлга,
Кыйбла ягым ача тәрәзә.
Үз җиремне, үз халкымны зурлыйм,
Мактау булып җырым яңгырасын,
Дөнья афәтенә юлыкмасын.
Юып алсын күңел ярасын.
Горурлану хисе кичерәмен,
Елмаюлы таннар эндәшә.
Тормыш кырын бизәп, данлап үтә,
Хөрмәтлесең, халкым, мең яшә.
Тарихта да үз урынын алган,
Язмышыңның түгелсен колы.
Унган, батыр ата-бабамнарның,
Миндә йөгерә аларның каны.

## Өлгерергә кирәк

Мин кунакка килдем, дөнья, сина,
Мәңгелеккә түгел, бик азга.

Көнем якты, шуна рәхмәтлемен,
Күкрәсен җан, сусаган назга.

Хыялларым чынга ашса икән,
Өметләрем бары аклансын.
Кара болыт булып кайгы-хәсрәт,
Күнел күкләремне япмасын.

Игелеген күрим Җир-суымның,
Өстәлемдә торсын икмәгем.
Үкендермәс, уфтандырмас бер дә
Киләчәгем, минем үткәнем.

Еллар имин генә булсын димен,
Илһам бирсен иҗат җимешем.
Бәхет-шатлыгымны юллап алам,
Югалтмадым тияр өлешен.

Мин тормышны матурларга тудым,
Җавап тотам барсы өчен дә.
Вакыт чикле, өлгерергә кирәк,
Кыска гына гомер эчендә.

## Тарих җиле исә

Китапларны, тарихларны укыйм,
Геройлары кырыс холыклы.
Сугышканнар, талашканнар да соң,
Анламассын инде халыкны.

Маузер тотып дуэльләргә чыккан,
Кынысында тоткан кылычын.
Мәрхәмәт юк, әдәп качкан тәмам,
Кан койганнар, белмим, кем өчен.

Мәйданнарда кеше яндырганнар,
Зинданнарда тоткын богаулы.
Авыр хәлне җиңеләйтә алмый,
Укыса да пастер доганы.

Алга сөреп тирән явызлыкны,
Кол итәргә барын чамалый.
Азатлыкка каршы күсәк тоткан
Гаделлекнең күзен томалый.

Әүвәлгедән килә хакыйкатькә,
Үткәннәрнең калган чүбе бар.
Акны — кара, караны — ак итә,
Хөкем кыла — вакыт чиге бар.

Ташпулатлар, сарайларны бизәп,
Кемнәр койган, кемнәр сырлаган.
Җанга кагылып тарих җиле исә,
Богау чыңлый ерак чорлардан.

## Кaһим Әүхәтов

### Вакыт әйтер

Сөенмичә булмас, әмма
Кичәгегә караганда
Бүгенге эш шәп булды дип,
Ашыкмыйк без тамгаларга.
Кайчак күптән онытылган
Эшләр чыга өскә калкып.
Көрәш бара, мәйдан иркен,
Ә мәйданда хаким — вакыт.
Эшләгәнең азмы, күпме,
Үлчәргә хак бизмәне бар.
Дөреслеген аерырга
Кылдан нечкә иләге бар.
Намус, вөждан кушканынча
Эшләреңне арттыра тор!
Тик ашыкма бәһаләргә —
Дөрес сүзне әйтер вакыт.

## Әхнәф Мәзһәров

### Утлар яна

Һәйкәлләрдә мәңгелек ут яна
Иле өчен шәһит улларга.
Исемнәре кайтып мәрмәрләргә,
Алтын сүзләр тезгән юлларга.

Һәр хәрефтә чагыла яу юллары,
Батырларның соңгы язмышы,
Аналарның кайнар күз яшьләре,
Сагыну катыш әрнү сагышы.

Таң атканда офык кызыллыгы
Һәйкәл ташларына коела,
Нурлар булып кайтып яудан гүя,
Яугирләрнең җаны җыела.

Һәйкәлләргә башың ими узма,
Илнең даны — батыр улларда.
Синең өчен, тыныч таңнар өчен
Алар башын салган яуларда!

## Фәвәзит Әхмәтшин

### Мәңге йөрәктә

Нигә тагын килеп керден әле,
Тәмам онытылгач, күнелгә?!
Хәзер инде башка йолдыз балкый,
Син түгел бит зәңгәр күгемдә.

Аралардан салкын җилләр исте,
Безнең язлар ерак калдылар.
Синең белән узган эзләр дә юк,
Анда ятлар сукмак салдылар.

Нигә инде, нигә төшләремә
Ераклардан кайтып керәсен?
Их, яшьлегем, син еракта түгел,
Мәңге йөрәктәсең, күрәмсен.

## Нәфисә Хәбибдиярова

### Аерылу газабы

Кичә генә мин бәхетле идем...
Бер көн үтте, бер төн нибары.
Әле генә кулга-кул тотышып
Үрли идек икәү югары.

Бер сүз җитте безне аерырга,
Бер генә сүз. Ничек түзәргә?
Бәхетебез чатнап аерылды,
Шул сүз җитте өмет өзәргә.

Кичә генә мин бәхетле идем...
Бүген сагыш телә яраны.
Ярый әле, күренмәгән бер кыл
Ялгап тора безнең араны.



Гүзәл
Әдһәм

# ЗӘҢГӘР КАШЛЫ КӨМЕШ АЛКА

ХИКӘЯ

Аңа барысы да сәерсенеп карады. Эскалаторга керү юлында көлешеп торган сакчы егетләр дә Айдар Гаязовичны күргәч, кинәт житдиләнеп, үрә каттылар. Казан метросы өчен ул «бик важный» һәм котелмәгән, шул ук вакытта куркыныч та кунак кебек иде. Өстендәге көлсу пиджагы, чалбар балагыннан күренеп торган затлы түфли башлары, яңалыгын әле һаман искәртеп торучы әчкелтем күн исен жуярга да өлгермәгән юка портфеле дә метроның гадәти пассажирларыннан бик тә, бик тә үзгә иде аның.

Дөрес, хәзер затлы кием белән берәүне дә шаккатыра торган заман түгел, әмма Айдар Гаязовичта тирә-юньдәге һәркемне сискәндереп, үзенә төбәлдерүче нәрсәдер бар. Ул «нәрсә» аның оста чәчтараш тарафыннан бөртегенә кадәр тәрбияләнгән кылдай каты кара чәчләренә дә, иртә-кич кырынудан бераз гына караңгыланып, ялтырап торган шоп-шома яңак һәм ияк тирәсенә дә, гомумән, аның бөтен тәненә сеңеп, хужа булып өлгергән иде инде.

Айдар Гаязович алга таба берничә адым ясап, пиджак кесәсендәге таныклыгын барлап куйды, кисәк кире уйлап, метро жетоннары сатыла торган тәрәзәгә борылды. Аның Казан метросында ничәдер ел элек шушы станцияне ачу тантанасында бары бер генә тапкыр булганы бар иде, башка түрәләр белән бергәләп электричкада ике-өч тукталыш үткән иде дә сымак.

Әле биш минут элек кенә, тән сакчыларын көтмәгәндә-уйламаганда шаккатырып, «Лэнд Ровер»ыннан асфальтка сикерде дә алар тарафына бер генә жөмлә ыргытты ул:

— Ярты сәгатьтән, «Кольцо» метросында!

Айдар Гаязовичның метрога килүенең безнең хикәябезгә бер катнашы да булмаганлыктан, бу турыда сөйләп торуымны кирәк дип тә санамыйм.

Менә шул. Ул эскалаторда түбәнгә шуышты. Аның билгесез бушлыкка төбәлгән тәкәббер карашында, сизелер-сизелмәс маңгай сырларында, шушы

Гүзәл ӘДҺӘМ (Шакирова Гүзәл Әдһәм кызы) – *язучы. «Наласа авылы көе», «Асылмалы күпер» һ.б. китаплар авторы. Казан шәһәрендә яши. 2013 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

мәһабәт ир-егетнең башындагы уй-кичерешләрне гаҗәп оста яшерә белгән, таштай катып калган янак мускулларында да җанны өшетә торган ниндидер бер салкынлык тоемлана иде. Без баштарак искәрткән теге серле «нәрсә»дәй кебек, бу салкынлык та аның бөтен гәүдәсенә инде күптән сеңеп беткән кебек иде...

Тик... Корычтай төз муены кинәт хәрәкәтләнеп, Айдар Гаязовичның мәгърур матур башын бераз гына сулгарак бора төште. Югарыга шуышкан эскалатордан яңгыраган тавыш аны шулай кинәт әсәрләндереп җибәрде.

— ...Икенче парга мин өлгерәм әле. Башта — философия... Аннары... тагын нәрсәдер... Короче, сәгать берләрдән соң, яме...

Кесә телефоныннан көлә-көлә сөйләшеп барган кыз кинәт Айдар Гаязовичның ачуын кабартты. Ул инде күптән хезмәткәрләренең, аны борчымас өчен, ярым пышылдап сөйләшүенә күнегеп беткән иде, ә ниндидер бер яшь җилкенчәкнең үзен шулай иркен тотуы, тирә-юньдәге берәүгә дә исе китмичә, бөтен метро халкы ишетерлек итеп нәрсәдер такылдавы аны чыгырыннан чыгара язды...

Тик... бу тавыш аңа бик таныш сымак тоелып, әллә кайда еракта, теге үткән тормышта ук калган ниндидер үзәк өзгеч бер хатирәнең дәвамы булып, күкрәк тирәсендә нәрсәнедер чеметтереп алды. Ул әсәренде. Кызга таба ныграк борылды, зәңгәр кашлы колак алкасын да мизгелнең меңнән бер өлешендә генә искәреп калды.

Искәрде дә... әллә нишләп китте. Ул таныды аны! Ничек танымасын ди?! Шул алканы онытып буламы соң? Чәчкәнең таҗ яфраклары арасында җемелдәп торган зәңгәр кашлы көмеш алка бит ул! Аның алкасы! Шул бит! Шул кыз...

Кыз — югарыга, ә ул түбәнгә таба шуышты...

Тагын бер секунд! Һәм... Һәм теге ымсындыргыч хатирә дә, кызга ияреп, каядыр бик-бик еракка китәр дә инде бөтенләйгә, мәңге-мәңге кире кайтмаслык билгесезлектә эреп юкка чыгу мөмкинлеген сизенү Айдар Гаязовичны өшетеп җибәрде.

Ул үзендә көмеш алкалы кызны да, тимер басмалары югарыга шуышучы эскалаторны да, хәтта шушы мизгелне дә туктатырдай көч-куәт барлыгына инанып, әллә нинди аңлашылмаган бер билгесезлеккә омтылып куйды. Шул чакта аңа дөньядагы бар хәрәкәт, эскалатордагы кызның ерагаеп баруы да аның — Айдар Гаязовичның, теләү-теләмәвенә генә бәйледер кебек тоелып китте. Бу мәһабәт ирдән бер сүз... Нинди сүз ди! Бары тик бер ым — сизелер-сизелмәс бер ым да җитәр күк!.. Барысы да аныңча — Айдар Гаязовичча булыр күк! Менә хәзер иреннәре кызның исемен пышылдавы булыр... Юк, пышылдау гына түгел... Кинәт аның сагынылган тансык исемне бар җиһан ишетерлек итеп, курыкмыйча кычкырасы килеп китте... Ул авызын ачты:

— ... ... ...!!!

Тик теге исем метроны яңгыратмады...

Ул исем онытылган иде!!! Онытылган?!

Айдар Гаязович тагын-тагын хәтерләргә омтылды. Үз хәтерсезлегенә сәерсенеп, йөзен җыерды, күзен чытырдатып йомды, хәтта башын да чайкап куйды әле.

«Туктале! Нәрсә соң бу? Ничек инде онытылсын ди?! Ул бит... Ул... Мең... Миллион тапкырлар кабатланган исем! Яратып та, таләп итеп, боерып та, куркып һәм шикләнеп тә, ә соңрак сагынып, юксынып та кабатланды бит ул исем! Шул исем белән бәйле җырны да белә бит ул! Җырлы исем! Нинди җыр соң? Нинди исем?!»

Айдар Гаязович соңгы тапкыр кайчан җырлаганын да оныткан иде инде. Менә тамак төбеннән ниндидер авазлар кысылып-сытылып иреккә юл алды...

«Искә төшә башлады түгелме соң? Менә болайрак сыман...

...Үпкәләмәде микән,
Ачуланмады микән?
Уйнап әйткән сүзләремне...
Зәйтүнәкәй, акчарлагым,
Чынга алмады микән?
Зәйтүнә бит!!! Зәй-тү-нә-ә-ә-ә...»

Күзләрен йомган килеш, ишетелер-ишетелмәс җыр көйләп, платформа уртасында басып торган мәһабәт матур иргә үткән-сүткән сәерсенеп борылып-борылып карады...

...Кыз инде әллә кайчан күздән югалган, Айдар Гаязович та метрога ни өчен төшүен оныткан иде.

***

Ул чакта Айдар Казан университетында аспирантурада укып йөри иде. Сентябрь урталарында, җәйге ваемсыз рәхәтлектән арына алмаган бер мәлдә, аны кафедрага чакыртып алдылар.

— Молодец, тиз килеп җиттең, Айдар, — дип кулын кысты фәнни җитәкчесе. — Эш менә болайрак тора: колхозга җибәргән бер группабыз җитәкчесез калган анда — кураторларын аппендицит белән больницага салганнар. Сентябрь беткәнче шунда булырсың...

Иртүк торып юлга чыкса да, электричкадан автобуска күчеп, аннан тагын машина әрҗәсендә җилфердәп, тиешле авылга килеп җиткәндә, төш якынлашкан иде инде. Юлы унды Айдарның: идарәдә аны гына көтеп торганнар диярсең, колхоз рәисен бүлмәсендә туры китерде. Анысы исә Айдарны кочаклап диярлек алды:

— Аспирант дисеңме? Әйбәт-әйбәт! Без яшьләрне яратабыз. Шәп студентлар килгән быел! Сезнекеләрне әйтәм. «Ых!» та итмиләр, көне буе бәрәңге чүплиләр, әле җитмәсә, культура-масса эшен дә җанландырып җибәрделәр. Кичә күрше бригадада шундый концерт куйдылар — настоящий артистларың бер читтә торсын!

Студентлар турындагы мәгълүматы деканаттан алган исемлектән артмаса да, Айдар да сүзгә кушылды:

— Әйе-әйе, безнекеләр шундый алар! — дип, аның сүзен җөпләде.

Колхоз рәисе Айдарның пычракка баткан туфлиләренә күз салып, кеткелдәп куйды:

— Бу сиңа Бауман урамы түгел, энем. Итексез булмый әлегә. Басуда бигрәк тә. Килгән-киткәннәрне выручәт итә торган бер итек бар-барын. Пока шуны киеп торсаң гына инде. Сания-я-я-я! Сания дим!

Ишектә бер хатынның башы күренде.

— Теге дежур итекне китер әле!

«Дежур итек» дигәннәренә Айдарның кырык алтынчы үлчәмле аягы да бик иркен кереп чумды.

Председатель, дустанә елмаеп, егетнең җилкәсен кагып куйды:

— Син хәзер, энем, дуй — «ысталавайга». Үземнең малай да аспирант минем. Беләм мин сезнең халыкны. Студентларың кайрас әбәт ашыйдыр,

үзен дә тамак ялгап алырсың. Түлке ашыгыбрак атла — китеп бармасыннар тагын.

... Дежур итекне лаштыр-лыштыр сөйрәп, ашханәгә тиз килеп житте. Ашханә дигәне гап-гади бер авыл йорты, баскычы ин түбәнге басмасына кадәр ап-ак итеп кырып юылган, чиста оекбашың белән дә чирканмыйча басып үтәрдәй булып балкып тора. Баскыч буенда тезелеп киткән кызыллы-каралы, зәңгәрле-яшелле итекләр студентларның мондалыгын раслый иде.

Айдар да, «дежур итек»не шулар янәшәсендә калдырып, эчкә үтте һәм «ах!» итте. Бер читтә ятсынып диярлек утырган ике үсмерне санамаганда, группа дигәнебез гел кызлардан гына тора булып чыкты.

Аспирант егетебез бераз гына каушап китте, шулай да үзен тиз генә кулга алып, көр тавыш белән кызларга дәште:

— Сәлам кызларга! Һәм тагы... ике егеткә!

Тәлинкә-кашык шакылдавы бер генә секундка туктап торды.

Студентлар бик яшь күренә: яна гына беренче курсны тәмамлап, икенчесен башларга торалар, күренеп тора, кыз-кыркынның әле авыллыгы да чыгып бетмәгән. Айдарга, аспирант кына булса да, профессорларга карагандай, хөрмәт белән төбәлделәр. Егетнең дә эченә жылы йөгерде, иртәдән бирле борчып торган «Мине санларлар микән? Килешеп булса иде!» кебек эчпошыргыч уйлар шул секундта ук әллә кая очып юкка да чыкты.

Күбесе, ашап бетереп, кузгалыша да башлады. Айдар да, аннан-моннан капкалап, алардан калышмаска тырышты. Сөйләшә-сөйләшә, жәяүләп кенә бәрәнге басуына юнәлделәр.

Болай да зур итек кинәт әллә ничек жайсыз итеп, егетнең үкчәсен чеметеп-кадап алды. Ни жайлы атларга тырышуына карамастан, нindидер бер очлы нәрсә табанын чәнчеп жәфалый гына бит. Бераздан теге «чәнечке» аяк бармакларын да тынычлыкта калдырмыйча, әле берсен, әле икенчесен тешләп-чеметтереп ала. Бәла дими ни дисең инде моны?! Житмәсә, кызлар янәшәсендә! Аспирант башың белән, авыл апайларыдай, итек кагып тормассың бит инде. Айдар, аксавын кызларга сиздермәскә тырышып, сак кына атлый бирде. Башында тик бер уй: жаен туры китереп, ничек тә котылырга иде шул жәфадан.

Ниһаять, жае чыкты. Итеген какса, шаккатты: «чәнечке» дигәне сынар алка икән. Көмештән үрелгән нәфис таж яфраклары арасында жемелдәп торган зәңгәр кашлы иде ул колак алкасы. Оста зәркән кулыннан тамган гөл диярсең! Каян килеп бу «дежур итек»кә кереп оялагандыр?! Мөгаен, итекне биргән теге апа югалткандыр. Исеме Сания иде шикелле.

Айдар алканы түш кесәсенә шудырды: «Бер очрамый калмас әле. Шунда бирермен дә!»

Көне бик матур иде — эшлисе генә килеп тора. Аспирант егет үзе дә башкалар белән беррәттән бәрәнге чүпләп йөрде.

Кызларга минем ярдәм тисен әле дип, уйный-көлә, әле берсенен, әле икенчесенең чиләгенә бәрәнге тутырышты.

Бүтәннәрдән арткарак калып, ни турындадыр пышылдашып торган ике кызны да игътибарсыз калдырмады, шаярып, аларга дәште:

— Әйдәгез әле, кызлар, ярышабыз. Безне куып житә алырсыз микән?

Тегеләре исә, аспирант абыйларына да исләре китми, ни турындадыр пошынышып, чыш та пыш килә.

Айдар сагайды: «Әллә елыйлар инде?»

Кызларның калкурагы икенчесен юатып маташа бугай.

— Зәйтүнә дим! Йә, житте, елама! Бәлки табылыр әле...

— Әбием истәлеге иде бит... Бигрәк кызганыч ла...

— Бәлки өйдә төшеп калгандыр. Кайткач, тагын бер тапкыр ныгытып эзләп карарбыз...

Зәйтүнәсе анын саен үкси:

— Юк инде, юк... Кулымны юганда көзгегә карадым ла... Ашханәдә чакта — бар иде бит...

Сүзгә Айдар да килеп кушылды:

— Нәрсә югалттыгыз, кызлар? Әйтегез миңа, бергәләп эзләрбез.

Зәйтүнә дигәненең дус кызы авыр сулап куйды:

— Басуда югалган булгач, табып булмас шу-у-у-л...

Айдарның сабыры бетә башлады:

— И-и-и, без тапмаслык әйбер буламы? Йә, әйт, нәрсә ул?

— Алкам югалган...

Зәйтүнә «менә, карагыз» дигәндәй, башлыгын күтәрә төште дә, чәчләрен аралап, колак яфрагына үрелде.

Кызның алсуланып торган колагында зәңгәр кашлы көмеш алка җемелди иде.

— Менә бит... Сынары бар, ә берсе — юк...

Айдар көлеп җибәрүен үзе дә сизми калды:

— Эх-ма, кызлар! Җир йөзендә без, егетләр булдырмаган берни юк! Шулаймы? — дип, башкаларга күз кысып та куйды әле.

Ул, оста жонглёрлар кебек җитез кыланып, кулларын тиз-тиз болгап алды да:

— Алле-е-е — хо-о-оп!!! — дип, Зәйтүнәгә таба учын сузды.

Аспирант абыйларының кыланмышына аптырабрак калган кызның күзләре кинәт гаҗәпләнүдән зур булып ачылды.

Ул кычкырып җибәрүен сизми дә калды:

— Минем алкам! Минеке! Менә бит табылган!

Зәйтүнә, зәңгәр күзләрен балкытып, томырылып, Айдарга карады һәм бөтен басуны тутырып көлеп җибәрде...

...Зәйтүнә! Онытылмаган икән бит! Барысы да истә икән! Күзләре зәп-зәңгәр иде шул анын... Нәкъ теге алкадагы кебек — көмештән үрелгән таҗ яфраклары уртасында җемелдәгән асылташтай зәңгәр иде...

***

Бу вакытта инде Айдар егерме алтысын тутырган шактый тәҗрибәле гаярь егет булып, беренче мәхәббәт дип янып-көюләр күптән узган, сөю сүзләре пышылдаган шактый кызларның исемнәре дә онытылган чак иде. Әмма өйләнергә әле иртәрәк кебек. Диссертацияне яклагач кына тормышка ашарга тиешле бу «мөһим вакыйга»ның вакыты, аек акыл иләге аша күп тапкырлар иләнеп, әлегә билгеле булмаган чиккә кадәр кичектерелеп куелган иде. Кызлар белән җитәкләшеп кенә йөрергә... И — баста! Әмма Зәйтүнә... Яна гына унсигезен тутырган Зәйтүнәнең зәңгәр күзләре әлегә атлап үтәргә ярамаган шул чик-киртәләрне пыран-заран китереп җимерде дә ташлады...

Айдар гашыйк булды бугай. Әллә чынлап та гашыйк булды, әллә тоелды гынамы? Кыскасы, ул башын югалтты. Көз ахырларында, җиргә беренче карлар төшкән мәлдә, теге баш әйләндергеч дуамал хисләр дә шактый тынычланып, акылның тыңлаучан энекәшенә әверелеп бара иде инде. Әмма Зәйтүнә... Университет коридорында йөзгә-йөз очрашканда анын: «Айдар абы-ы-ый...» — дип ишетелер-ишетелмәс бер пышылдавы җитә, Айдар әллә нишли...

«Йөрәккә әмер биреп булмый!» дигән гыйбарәне мен тапкыр ишетеп тә, аның асылына төшенмәгән егерме алты яшьлек аспирант егет мәхәббәт дингезенә баш-аягы белән кереп чумган иде.

Кызганычка каршы, Зәйтүнәкәй Айдарның киләчәк планнарына бөтенләй туры килми иде шул. Ярату ярату белән... Әмма өйләнү! Анысы инде бөтенләй башка нәрсә. Фәннәр кандидаты булган гаярь егетнең хатыны да үзгәрәк булырга тиеш ләбаса. Мәсәлән, аның житәкчесе Илдар Нурович хатыны кебегрәк... Татар театрында Зөбәржәт ханымны күреп, Айдар аһ иткән иде. Юк, әллә ни чибәр дә түгел үзе, әмма — затлы. Өстендәге күлмәгенә төстәш ялтыр-йолтыр килеп торган муенсалары, кыйммәтле йөзек-беләзекләре — барысы да үзенә бик килешеп, ханымны чын асылташка әверелдергән иде. Ханбикә дисәң ханбикә инде менә. Айдар Зөбәржәт ханымның ялтыравык күлмәген күңелдән генә Зәйтүнәсенә дә кидертеп карады, алтын муенсасын да күңелдәге Зәйтүнәнең нәфис муенына такты. Тик Зәйтүнә... Юк инде. Юк! Профессор, академик янәшәсенә басарлык түгел шул. Затлы алкалар да ана төс түгел, үзенең шул көмеш алкасы килешәрәк тә төшә бугай әле. Артык гади ул Зәйтүнә: киеме дә, кыяфәте дә, сөйләгән сүзенә кадәр бик-бик гади шул аның. Гомумән, Айдарның алдагы тормышында Зәйтүнәгә урын юк иде.

Һәм Айдар аннан арынырга булды. Мескен Зәйтүнә... Зәңгәр күзләре Айдар абыйсына чиксез ярату, ышаныч һәм өмет белән төбәлгәндә, аның зур матур башын күкрәгенә кысып, кылдай каты кара чәчләрен сыйпаганда, үзен дә соңгы чиккәчә иркәләргә ирек куйганда, шул мәһабәт башта туган исәп-хисап, мәсләк-кичерешләрнең үзенә каршы юнәлгәнлеген уйлап карады микән ул? Юк шул, юк! Айдар абый бит ул! Ана ышанмый мөмкинме соң? Кызый аңа бөтен жаны-тәне, бөтен вөжүде белән бирелгән иде шул. Һәр хатын-кыз затына хас табигый инстинкт Зәйтүнәдә дә бихисап иде. Ана, бала һәм гаилә кебек шартлы ноталардан туган илаһи моң, аның күңелендә мәхәббәт симфониясенә әверелеп, Зәйтүнәне үз кочагына бөтереп алган да, ул әнә шул хыялый бишектә рәхәтләнеп тибрәлә дә тибрәлә.

Зәйтүнәдән арыну, имеш. Әйтүе генә ансат! Ул чакта әллә Айдарга жиңел булдымы? Зәйтүнәнең барлыгына, аның назларына шулкадәр ияләнелгән, кайчакта Айдар үз-үзе белән каршылыкка кереп, теге киләчәк планнарыннан ваз кичүен сизми дә кала иде. Айдар ни теләмәсә дә, Зәйтүнә аның бөтен жанының, вөжүденең аерылмас бер өлешенә әверелеп килә иде шул.

Әмма карар кабул ителгән: алда — Зәйтүнәсез тормыш тәгаенләнгән иде. Айдар эшенең бик тыгыз булуын сәбәп итеп, диссертация мәшәкатьләре аркасында бераз очрашмый торырга тәкъдим ясады. Зәйтүнәсез тормышка ияләшә башлауга беренче адымны ясау иде исәбе. Айдар абыйсының фәнни эшенә берничек тә ярдәм итә алмавына үртәлеп, аның өчен жанын бирергә дә әзер торган Зәйтүнә ничек каршы булсын ди инде! Житмәсә, сессия дә — борын төбендә.

Атна-ун көн буе очрашмады алар. Әмма беркөнне аспирантлар тулай торагына Зәйтүнә үзе килеп керде. Айдар бүлмәсендә ялгызы гына һәм, чынлап та, фәнни эше белән мәшгуль иде. Зәйтүнәнең коридор буйлап аяк атлавын, бүлмә ишегенә бармаклары белән сак кына кагылуын ул шундук танып алды. Беренче генә тапкыр килүе түгел лә.

— Айдар абый!... Айдар абый!

— Айдар абыең өйдә юк, матурым. Яна гына каядыр чыгып китте.

Бу — күрше бүлмәдәге аспирант егет алдаша. Шулай килешеп куйганнар иде: сүзендә торуын күр син!

Айдар кузгалмады.

Теге якта нәрсәдер кыштырдады. Бераздан ишек ярыгыннан идәнгә бер кәгазь очып төште. Зәйтүнә хаты!

Кызның аяк тавышы ерагаеп, бөтенләй тынгач кына, Айдар аны үрелеп алды.

Хат бик кыска иде. «Айдар абый, күрешик әле. Сәгать биштә, теге урында. Бу — бик мөһим. З.»

«Теге урында!» Күкрәген үкенечле сагыш чеметтереп алды. Йөгереп чыгасы, Зәйтүнәне куып житеп, кире кайтарасы килеп китте. Шунда ук сүрелде дә.» Ярамый! Араны өзәргә икән — өзәргә! Нигә сузарга?»

«Теге урын» — икесе өчен дә бик таныш иде. Черек күлнең дуга-капкасын алар шулай атады.... Дуганың бу башына берен, ә теге якка икенчең басасың да — пышылдаш рәхәтләнеп! Аралар ерак — ун-унбиш метрлап бардыр. Баш очындагы дугаланып торган түбә пышылдап әйтелгән һәр сүзенне, түкми-чәчми, каршы якка илтеп житкерә. Янәшә торып сөйләшәләр диярсең!

Әле дә хәтердә... Зәйтүнәгә беренче тапкыр «яратам!» дип ул шунда әйткән иде.

... — Зәйтүнә! Мин си-не я-ра-там!

Кыз каушады, шактый вакыт дәшми торды.

— Я-ра-там! Ишетәсеңме?

Кыз һаман дәшми.

Әллә чынлап та ишетмәдеме, әллә кабатлавын теләдеме?

— Мин си-не я-ра-та-а-ам!!!

Шактый тынлыктан соң көтелгән җавап та килеп иреште:

— Мин дә...

Беренче сөю сүзен шунда ишеткәнгәме, Зәйтүнә бу урынны бик ярата иде...

***

...Бераздан Айдар Гаязович метродагы вакыйгага бәя бирерлек халәткә кайтты.

Бу кыз Зәйтүнә түгел һәм ул Зәйтүнә була да алмый иде. Дөрес, аның тавышы да, кыяфәте дә Зәйтүнәнекенә бик тартым, тик ул Зәйтүнә түгел. Теге үткән тормышта ук калган Зәйтүнәгә хәзер, мөгаен, кырык яшьләрдер. Ә бу кыз — яшь. Күп булса — егермеләрдә. Шулай да охшашлык бар... Зәйтүнә... Эх! Зәйтүнә! Кайда икән ул? Теге чакта кинәт юкка чыгып, Айдарны тынычлыкта калдырган, шул ук вакытта борчу-шөбһәгә дә салган Зәйтүнә! Айдар Гаязовичның кинәт кенә кырык яшьлек Зәйтүнәне күрәсе килеп китте. «Күзләренең зәңгәрлеге һаман да сакланды микән? Зәңгәр кашлы көмеш алкасына охшаш иде бит алар...»

«Зәңгәр кашлы көмеш алка?!» Шулчак Айдар Гаязовичның күкрәгендә нındидер бик зур бер ялкын пәйда булды да тамырлары буйлап, үрли-үрли, бөтен күзәнәкләренә таралды. Ана кинәт эссе, бик эссе булып китте.

«Кызның колагындагы көмеш алка Зәйтүнәнеке бит! Шул алка! Аны башка алка белән бутау да, ялгышу да мөмкин түгел. Ничек сөйләгән иде әле Зәйтүнә? Бабамны «Көмешче Зариф» дип йөрткәннәр... Бу алка әбиемә туй бүләге итеп ясалган... Кызганыч, туй көнендә үк сугыш башланган... Әнием дөньяга аваз салганда, бабамнын үлгән хәбәре килгән булган инде... Ә әбием үлгәч, алканы мина бирделәр... Зәңгәр күзле оныгыма — зәңгәр кашлы колагалкам, — дип әйтеп калдырган әбием...»

Алка, тәгаен, Зәйтүнәнеке иде... Димәк, аның бу кызга нindидер катнашы булырга тиеш...

***

Ә теге чакта дуга-капка янында Зәйтүнә белән очрашкач, кызның ниндидер мөһим хәбәр әйтәчәген сизенеп, Айдар тетрәнеп китте. Зәйтүнә һич аңлап булмаслык бер халәттә иде. Йә бик бәхетле кешедәй тыела алмыйча көлеп җибәрә, йә, кинәт моңсуланып, сүзсез генә тынып кала. Серле, бик серле иде Зәйтүнә...

Әмма Айдар алдан планлаштырган тактикасыннан читкә тайпылмаска булды: өзәргә икән — өзәргә. Тик менә Зәйтүнә җиткергән хә -б-ә-ә-әр...

— Айдар абый, мин бәби көтәм...

Кыз, зәңгәр күзләре белән балкып, томырылып аңа карады.

Аспирант егет тетрәнгән иреннәреннән бары тик бер сүзне генә сытып чыгарды:

— Кемнән?

Кыз, кисәк дертләп, аңа төбәлде:

— Аңламадым...

— Авырың... кемнән дим?

Зәйтүнәгә кинәт әллә нәрсә булды. Ул кисәк агарынып киткән, таштай катып калган йөзе белән егеткә төбәлде, калтыранган иреннәре белән нидер әйтте дә сымак, тик сүзләре ни аңа, ни Айдарга барып ирешмәде. Аннан кисәк борылды да, йөгерә-атлый, тукталышка таба чапты.

Бу бик куркыныч һәм көтелмәгән хәбәр иде. Айдарның йокысы качты. Дөрес, хәзер партия заманы түгел. «Син — коммунист яки комсомол», дип мәҗбүри өйләндерә торган чорлар артта калды, әмма — ре-пу-та-ция! Ә ул репутация дигән нәрсә — ай-һай важный нәрсә бит, заразы. Бүген-иртәгә диссертация яклыйм, фәннәр кандидаты булам дип йөргән егетнең анкетасын пычратырга күп кирәкме?! Шул ук Зәйтүнә иртәгә, елап, Илдар Нурович янына кермәс дип кем әйтә? Анда гына кереп калса бер хәл! Ышанма хатын-кызга, ректоратка кадәр барып җитүе бар! Ул чакта инде — үтү-ү-ү-т! — репутацияләрең.

Айдар тактиканы үзгәртергә булды: әлегә араны өзәргә һич кенә дә ярамый! Ярамый! И — баста! Тиз арада Зәйтүнәне күрергә, тынычландырырга кирәк. Хәзер иң мөһиме — вакытны оту. Диссертацияне яклап, башта теге «катыргы»ны кулга төшерергә. Алдагысын күз күрер! Зәйтүнә Айдарны ярата! Монысы — бәхәссез! Димәк, кызның мәхәббәтеннән тагын бер тапкыр файдаланырга була. Матур сүзләрне кызганмаска. Әлегә бик мәшәкатьле чак, диссертацияне яклагач та туй итәбез, дияргә! Кызны шуңа ышандырырга кирәк! Ә ул ышаначак!

Дуга-күпер янында Зәйтүнәгә үзенең нәрсә әйткәнен дә ачык кына хәтерләми иде ул. Ә менә кызның зәңгәр күзләрендәге сөю катыш өметнең кисәк кенә аптырау һәм рәнҗүгә әверелеше күңелдә уелып калган. Ай-һай, каты рәнҗеткән ахры Зәйтүнәне. Ике көн үтте, кыз һаман да күренми. Тизрәк эзләп табарга кирәк үзен... Табарга да вәгъдәләргә күмеп ташларга... Ышансын... Тынычлансын... Тик «бузить итеп» кенә йөри күрмәсен!

Әмма Айдарга алдашырга да, ялган вәгъдәләр бирергә дә туры килмәде. Барысы да бик тиз хәл ителде. Бүлмәсендә аны Илдар Нуровичның телеграммасы көтә иде. Ниндидер эшләр белән Мәскәүгә киткән җитәкчесе, бөтен язу-сызуларын җыйнап, тиз арада башкалага килеп җитәргә боерган. Кушмаган да, үтенмәгән дә, нәкъ менә «приказываю!» дигән.

Зәйтүнә дә, аның теге рәнҗүле карашы да, әйтелергә тиешле ялган вәгъдәләр дә — барысы да онытылды. Айдар Мәскәүгә очты...

Ә Мәскәү аны гына көтеп торган диярсең! Илдар Нурович бөтен эшләрне шундый итеп көйләп куйган: диссертация яклау көтмәгәндә-уйламаганда

шулкадәр тиз һәм җинел хәл ителде, Айдар аңына килергә дә өлгерә алмый калды. Соңрак шундый «уңышлы яклау»ның серенә төшенде төшенүен: Мәскәүдә тәкъдим ителгән кәнәфине биләү өчен, Илдар Нуровичка Айдар кебек аспиранты булуын шарт итеп куйганнар икән!

Казанга ул ике айдан соң гына «фәннәр кандидаты» дигән кызыл тышлы катыргыны тотып кайтып төште. Ул чакта инде бу катыргы үзенең төп вазифасын башкарып та өлгергән, Илдар Нурович үз постыннан бик канәгать булып, Айдарны да онытмаган. Җыйнак һәм кечкенә генә булуына карамастан, эчендәге сүзләре шактый кыйммәт йөргән икенче бер катыргы — Илдар Нуровичның ярдәмчесе дигәне — Айдар Гаязовичның түш кесәсенә кереп оялаган иде инде.

Самолёт җиргә төшү белән, ул Зәйтүнәне искә алды. Казан Зәйтүнә белән бәйле иде. Бу бәйләлекне берничек тә инкарь итеп булмый. Башкаладагы җылы кәнәфигә бик оста гына кереп урнашкан Илдар Нуровичның уң кулы булсаң да, бу дөньяда әле Зәйтүнә дә бар бит! Зәп-зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, «Бәби көтәм!» дип пышылдаучы Зәйтүнә! Айдар ни әйтсә дә, баланың анык булуы хак, тик Айдар Гаязович янәшәсендә бу икәүгә дигән урын гына тәгаенләнмәгән шул. Бик үк мәшәкатьләнмичә, тавыш-гауга чыгармыйча гына кыздан арынырга кирәк иде.

Үзе Зәйтүнәгә бер генә хат-хәбәр юлламаса да, бүлмәсендә Айдарны Зәйтүнәнең исәпсез-хисапсыз хатлары көтәдер кебек тоелган иде. Юк! Берни дә юк! Бу фаразының акланмавы аны бераз аптырашта да калдырды. Үзе бәби көтәм ди, ә үзе... Әллә баладан котылу җаен да табып куйганмы?.. Аның кызга ачуы килеп китте, күңеле һаман Зәйтүнәнең ялваруларын, «бергә булыйк» дип үтенүләрен көтә, шуңа өметләнә дә иде. Шул ук вакытта Зәйтүнәне юллап, тулай торагына бару, бүтәннәр күзенә күренеп йөрү дә кирәкмәгән эш булып тоелды ана.

Ашханәгә әбәт ашарга кергәч, Зәйтүнәнең иптәш кызыннан ишеткәннәре Айдар Гаязовичны бөтенләй шаккатырды:

«Зәйтүнә бүтән вузга күчкән! Зәйтүнә Казаннан киткән! Айдарга бер сүз дә әйтеп торуны кирәк санамаган! Менә, ышан син кызларга!»

Әле кайчан гына репутациясен бозудан куркып, йокысыз төннәр үткәргән, Зәйтүнәдән котылу өчен төрле планнар корган Айдарга кызның шулай көтмәгәндә-уйламаганда юкка чыгуы бик сәер һәм шомлы булып тоелды.

«Ышанма кызларга! Берәр үч алуга әзерлеге булмасын тагын. Алай дисәң, Айдар хәзер беркемнән дә һәм бернидән дә курыкмый. Казан белән алыш-биреше бетте аның. Алда — Мәскәү!»

Ул тагын кесәсендәге теге кечкенә таныклыгын барлап куйды. Әмма үзенең дулкынлануын, эчендә кайнаган вулканнарны Зәйтүнәнең дустына сиздермәскә тырышты: белмәве, сизмәве, аңламавы кулай дип тапты.

— Хат язармын, дип вәгъдә итте дә онытты Зәйтүнә... Сез язышасыздыр бит... Адресын бирмәссез микән?

Айдар үзен бик тиз кулга алды:

— Бирәм, билгеле. Тик йорт номеры хәтердән чыккан. Соңрак, яме...

Айдар кыздан шулай дип качты. Тиешле эшләрен тиз-тиз тәмамлады да Мәскәүгә очты.

...Башкала тормышы аны башка төрле мәшәкатьләргә алып керде, алдарга да, елмаерга да, ялган вәгъдәләр бирергә дә өйрәтте. Башкала — Зәйтүнә түгел, аңа бар да сыя. Кайда — хаклык, кайда ялган икәнен, бар, исбатлап кара син!

Егерме ел эчендә Айдар Гаязовичка төрле кәнәфиләрдә утырырга туры килде, күкрәк кесәсендәге таныклыклар да алмашынып торды. Хәзер ул менә Казанда.

Казан — үз казанын инде! Дөрес, тагын да югарырак дәрәҗәгә ирешү өчен әле соң түгел: кырык биш яшь — самый егет чак, дип, юкка гына әйтмиләр лә.

Зөбәрҗәт ханымдай затлы Фәйрүзә-гөлкәй белән култыклашып, дәрәҗәле тантаналарга барганда, түбәнрәк даирәдәге түрә хатыннарының:

— Аһ, Айдар Гаязовичның хатынын күрәсезме? Нинди гүзәл! — дип пышылдашуларына да күптән инде күнегеп бетелгән.

— Шушы балның гүзәл королевасын биергә чакырырга мөмкинме? — дип, Фәйрүзә-гөлкәйнең нәфис биленә кул салган ялагайлардан да көнләшми ул хәзер.

Бии бирсеннәр, Фәйрүзә ханымның күнелен күрсеннәр, әйдә.

Фәйрүзә-гөлкәй һаман да яшь, затлы һәм... ымсындыргыч. Айдар Гаязович аның һаман бертөрле затлылыгына да күптән ияләште. Үзгәрәк булсын иде ул. Вакыт-вакыт аның күз алдына битенә тут төшкән, иреннәре шешенгән, корсагы иләмсез бүлтәйгән Фәйрүзә-гөлкәй килеп баса. Булсын иде! Берәр вакыт шундый булсын иде ул! Әмма Фәйрүзә-гөлкәй һаман нәфис, зифа һәм... кысыр.

Барысына да күнегелгән, күбесе гадәткә әйләнгән инде. Тик менә Илдар Нурович кына һаман да Илдар Нурович булып кала бирә: сессиядә дә, конференциядә дә... мунчада да... «Бажай» дигән кадерле сүзне, бер булмаса бер, үзенең фәнни җитәкчесенә әйтәсе килә Айдар Гаязовичның. Тик Илдар Нурович кына, ни сәбәпледер, һаман да кичектереп килә, Айдар билгән кәнәфинең аныкыннан шактый кайтыш булуын искәртеп алудан да бер дә тайчынмый ул...

***

«Икенче парга өлгерәм әле... Башта — философия...»

...Көмеш алкалы кызның сүзләре бик тиз исенә төште. Кызның студент булуы бәхәссез иде. Уку йорты, тәгаен, «Кәҗә бистәсе» тукталышында булырга тиеш...

Айдар Гаязович дәрәҗәсендәге түрә өчен көмеш алкалы кыз турында мәгълүмат туплау уен эш кенә. Өч көн дигәндә, көтелгән дискны аның кулына китереп тә тоттырдылар:

— Рәхим итегез, Айдар Гаязович!

Айдар эчке тетрәнү һәм дулкынлану белән дискны алды, үзен борчымаска кушып, кабинетына кереп бикләнде.

...Хезмәткәре кыз турында мәгълүмат туплауны исемләп тә өлгергән. «Зәңгәр кашлы көмеш алка» операциясе икән...

Беренче биттә көмеш алканың егерме тапкыр зурайтылган фотосурәте урнаштырылган... Икенчесе — кыз үзе! Зәңгәр күзләрен тутырып ана — Айдар Гаязовичка төбәлгән!

Айдар Гаязовичның бөтен тәне чымырдап, эсселе-суыклы булып китте, калтыравык бармаклары яңадан-яңа клавишаларга кагылды...

...Зарипова... Нәзирә... Айдаровна!!!

...Зарипова!!! Зәйтүнә фамилиясе бит!!!

...Айдаровна!!!

...Айдар Гаязовичның бөтен тәнен вак калтыравык биләп алды.

...Әнисе — Зарипова Зәйтүнә!!!

...Әтисе? Бу графага сызык куелган иде! Сызык куелган, димәк, юк! Кызның әтисе юк!

...Туган елы... Вакыты... Барысы да туры килә...

...Айдар Гаязович, хәлсезләнеп, кәнәфиенә авып төште.

Кыз — аныкы иде! Аның кызы! Нәзирә исемле! Аның Нәзирәсе!!!

Әллә нәрсә, ачыттырып, күздән сытылып чыкты. Айдар Гаязович соңгы тапкыр кайчан елаганын да оныткан иде. Сулкылдый-сулкылдый рәхәтләнеп елады ул, сафланып, әллә ничек бушанып, җиңеләеп калды.

...Аның кызы — Нәзирәсе бар икән бит!

Бераз тынычлангач, бармаклары тагын клавишлар буйлап йөри башлады...

...Энергетика университетында икенче курста укый икән Нәзирә...

...Менә зачёт кенәгәсенең күчермәсе... Гел бишлеләр!..

Айдар Гаязович канәгать елмаеп куйды. «Молодец, Нәзирә! Үземә охшаган!»

...Менә Нәзирәнең коммерция бүлегеннән бюджетка күчерүне сорап язган гаризасы... Кәгазь читендә «Отказать!» дигән язу да чекрәеп тора...

Алдагы файл кызның әнисе турындагы мәгълүматлар белән шыплап тулган иде...

...Институтны Ижевскида тәмамлаган Зәйтүнә. Кияүгә чыкмаган. Педагогик көллияттә укыта. «Мактаулы мәгариф хезмәткәре» дигән күкрәк билгесе белән бүләкләнгән... һәм башкалар... һәм башкалар...

...Менә Зәйтүнә конференциядә чыгыш ясый. Үз-үзенә ышанган көр тавышы нинди ягымлы аның. Колакны иркәли торган җылы тавыш... Кулындагы кәгазенә дә күз салмый... Сөйли дә сөйли...

Айдар Гаязович видеога төбәлде дә Зәйтүнәгә мөкиббән китеп тынып калды. Бу — шул Зәйтүнә иде. Моннан егерме ел элекке зәңгәр күзле Зәйтүнә. Ничек үзгәргән ул! Һәм бөтенләй үзгәрмәгән дә кебек... Айдар Гаязович үз гомерендә чибәр-чибәр кызларның затлы матур ханымнарга әверелүен күп күрде. Әмма Зәйтүнәдәге үзгәреш аны шаккатырды: ханым күз явын алырлык сылу һәм... затлы иде.

* * *

Соңгы көннәрдә Айдар Гаязович әллә ничек тынып, басынкыланып калды. Андагы үзгәрешне Фәйрүзәкәй-гөлкәй дә сизенде:

— Нәрсә булды? – дип, кызыксынуын да белдерде.

— Юк... Берни юк...

Ныклабрак караса, Айдар Гаязовичта яшеренгән эчке бәхетне, күзләренә сеңгән яшерен рәхәтлекне тоемлар иде ул. Әмма Фәйрүзәкәй-гөлкәйнең андый ваклыкларга исе китми, аңа үз рәхәте мөһим. Әйтте дә онытты: Айдар Гаязовичны иректә калдырды.

Ә Айдар Гаязович үз уйларына чумды. Аның уйларында Фәйрүзә-гөлкәйгә дә, фәнни житәкчесе Илдар Нуровичка да урын юк иде. Нәзирә һәм Зәйтүнә! Зәйтүнә белән Нәзирә! Бу ике зат моңарчы әһәмиятле саналган бик күп, бик күп башка исемнәрне аның күңеленнән кысрыклап куып чыгарды да бөтен вөҗүден биләп алып патшалык итә башлады.

Җаны сафланып, гәүдәсе каядыр югарыга очып китәрдәй җиңеләйгән бер мизгелдә Айдар Гаязович катгый карарга килде: «Очрашырга! Нәзирә белән дә, Зәйтүнә белән дә күрешергә кирәк! Аның кызы, аның Нәзирәсе бит ул! Зәйтүнә дә каршы килмәс. Ник карышсын ди? Аның, Айдар Гаязовичның мөмкинлекләре нинди зур. Иң беренче, ул Нәзирәсен бюджет бүлегенә күчертер! Моның өчен аның бер сүзе житә. Аннары кызына яхшы фатир, машина алып бирер. Акчасы андый гына вак-төякләргә житәрлек аның. Сасы тулай торакларда яшәп, ул метроларда күпме йөрергә була?! Аның кызы бит ул! Аның Нәзирәсе!»

Нәзирәнең дәресләр тәртибе белән дә хәбәрдар иде Айдар Гаязович. Кара тәрәзәле «Лэнд Ровер»ы университет янына килеп туктаганда, Нәзирәнең дәресе бетәргә төгәл ун минут калган иде. Айдар Гаязовичның кызны беренче тапкыр гына каршылавы түгел. Тик менә күрешүне генә һаман кичектереп килә. Ул инде аның дусларын да таный башлады. Нәзирәнең көлүе, елмаюы, ишарәләре, сөйләшү манерасы, тавышы да – болар барысы да Айдар Гаязовичка бик якын иде...

Ниһаять, Нәзирә чыкты. Иптәш кызлары белән елмаеп саубуллашты да, дивар буенда тукталып, кемнедер көтә башлады.

Айдар Гаязовичның күптән болай дулкынланганы юк иде. Күкрәген шыплап тутырган утлы давылны басарга омтылып, ул тирән итеп сулыш алды, аякларының егәре кире кайтуын көтеп, машинасында тагын бераз утырып торды. Менә ул чыгар, Нәзирә каршында пәйда булыр. «Мин синең әтиең, кызым», — дияр, Нәзирәнең йомшак кулын җылы учына кысар... Нәзирә аны кабул итәр, билгеле. Мәхәббәт матур иргә сокланып һәм хөрмәт белән карар. Дөрес, бүген үк кочагына ташланмас. Алай булырга тиеш тә түгел. Барысы да алда – киләчәктә... Ул, һичшиксез, Нәзирә янәшәсендә булыр...

Айдар Гаязовичның кесә телефоны шалтырап, уй-фикерләрен чуалтып ташлады.

Ул башта шалтыратучының тавышын да танымый торды.

— Айдар Гаязович, мин әле бу...

«Ә-ә-ә... Илдар Нурович икән...»

— Тиз генә минем кабинетка килеп житә күр. Это не телефонный разговор... Николай Максимовичны пенсиягә озаталар... Өстәгеләр аның урынына синең кандидатураны күрсәткән, дигән хәбәр бар. Тизрәк бул, бажай, форсатны кулдан ычкындырмыйк, чарасын күрә башларга кирәк...


Бу минутта Нәзирә, «Лэнд Ровер»ның кара тәрәзәсенә төбәлеп, чәчләрен рәтләп тора иде. Кызның йөзе Айдар Гаязовичка шундый якын, янәшәдә генә, әгәр ике арада шул кара тәрәзә булмаса, Нәзирәнең зәңгәр күзләрендә ул – Айдар Гаязович — хәтта үз шәүләсен дә күргән булыр иде. Әмма Айдар Гаязовичта кубарылган теге дулкынландыргыч халәт кинәт сүнеп, шул мизгелдә мәңге кире кайтмаслык ниндидер билгесезлеккә чумып югалган иде инде.

Кисәк кузгалган «Лэнд Ровер» чыелдавыннан сискәнгән Нәзирә аздан гына читкә тайпылып өлгерде: тәгәрмәч астыннан сибелгән асфальт тузаны катыш пычрак янгыр суы кызны баштан-аяк коендырып ташлады.

Икенче көнне Айдар Гаязович «Зәңгәр кашлы көмеш алка» операциясен башкарып чыккан хезмәткәрен эштән алу турындагы приказга кул куйды...



*Моннан 80 еллар элек әдәби-мәдәни хәрәкәтне әйдәп барган бер төркем шәхесләр сурәтләнгән уникаль фото. Иҗат дәрте ташып торган яшь һәм ир уртасы егетләрне киләчәктә ниләр көтә? Ни аяныч, күбесенең язмышлары фаҗигале тәмамланды.*
*Рәсемдә сулдан уңга (беренче рәт): Шамил Усманов, Мирсәй Әмир, Гадел Кутуй, Һади Такташ, ...(?); икенче рәт – З.Гали, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кави Нәҗми; өченче рәт — Шалинский (?), Исмәгыйль Рәмиев, Риза Ишморат, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Лев Рубинштейн, Галиәсгар Камал, Салих Сәйдәшев, Касыйм Шамильский (?). 1930 ел.*




*«Казан утлары»ның элгәргесе булган «Аң» журналы. 1913 елның май ае саны.*



*Шагыйрь Мөхәммәт Шәйхи. 1980 ел.*



*Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның 50 яшьлек юбилее көнендә төшерелгән рәсем. Уңнан сулга – Рахмай Хисмәтуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Илсөяр Хакова, Тәбриз Гыймалетдинов. 1992 ел.*

# ШИГЪРИ ИМАН СӨЙКЕМЛЕЛЕГЕ

ЛӘЙСӘН КӘШФИ ПОЭТИКАСЫНА БЕР КАРАШ

Соңгы вакытта шигъри гүзәллекне аң-акылы, хис-тойгысы, шәфкатьле җаны, шәфәгатьле каны, йөрәк йөгереклелеге, күңел күтәренкелеге белән ихлас аңлаучы каләм осталарыбыз ишәя. Алар сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы заңы шифасына зур игътибар итә. Шундыйларның берсе — филология фәннәре кандидаты, хәзерге вакытта «Кызыл таң» газитенең әдәбият һәм сәнгать бүлегендә хезмәт итүче талантлы хәбәрнамәче, тел диңгезенә чумып, аның төбендәге сүз энҗеләрен таба белүче, аларны җөмлә тукымасына оста чигүче, сәләтле шагыйрә, акыллы тәнкыйтьче Ләйсән Кәшфи.

Ләйсән яңгыр — яз сөйкемлелеге. Әтисе, әнисе (укытучылар) шуны уйлап кушканнар бу исемне. Ләйсәннең гомер язы — бәхет-сәгадәт таңы. Әти-әни бик илтифатлы, кешелекле, таләпчән, каты куллы, шул ук вакытта ягымлы, хезмәтчән, эчкерсез, ярдәмчел була. Барлык авырлыкларны җинә-җинә, кырыкның өске ягына чыккан Ләйсәннең гомере әле чәчәкле, баллы, сандугачлы җәй уртасында. Менә аның «Авыл кызы» исемле шигырьләр җыентыгында урын алган «Әнинең яратуы» дигән шигыре:

*Рәхмәт, әни, синең белүеңдә*
*Олы бәхетемнең серләре.*
*Кырауларда шаулап чәчәк атам,*
*Таш яуса да шиңмәс гөлләрем.*

Биредә сүз-сурәт (әни, кырау, чәчәк, таш, гөл) сүз-фикер, сүз-тойгы — шагыйрәнең рухи байлыгындагы мәрҗән-муенса. Күз алдына ихтыяри көчле гүзәл кыз образы килеп баса. Сөбханаллаһ!

Контаминацияләнгән фразеологик әйтелмәләр (КФӘ) тарихи яктан соңрак барлыкка килә. Алар күбрәк чәчмә әсәр (проза) өчен хас. Ә менә Ләйсән шундыйларны шигъри юллар шаукымына кәрәзли белә (олы бәхет серләре, кырауларда шаулап чәчәк ату, таш яуса да шиңмәс гөлләр). Соңгы икесе ышандырмый да кебек. Ә бит галимнәр боз таулары арасындагы мамык карларның чәчәк атуы турында яза. Кар катламнарын ярып чыккан умырзая чәчәген инглизләр — «кар боравы», французлар «кар тамчысы» дип атый.

Ата-ана турында язганда, Ләйсән югары аң илаһилыгына таяна. Бу, күрәсең, соңгы вакытта дини тәрбиянең иманлы канат кагу миһербанлыдыр:

*Олгайсаң да, олы кулларыңнан*
*Кәрәк-сәнәк төшми, иншаллаһ!*
*Әллә безнең өчен тир түгәсең,*
*Әллә инде Аллаһ кушканга?*

Мондый гыйззәтле сүзләрне игенченең бер бөртек бодай өчен бер пот тир түккәнлеген аңлаган иманлы авыл кызы гына әйтә ала. Авыл кызының таш яуса

да шинмәстәй гөлләргә (бәхеткә) төренгән гүзәллеге (ата-ана шәфкатьлелеге) кырауларда да гөрләп чәчәк атардай илаһилык биргән. Әлеге бозлы тауларда нәфис кар бөртекләренең чәчкәләнгәне сымак, авыл кызының ата-ана рухын Аллаһ гыйззәтлелеге белән нәкышләве дә нәзакәт. Дини тәрбия шифасы бу. Дини тәрбия! Дин авазы — сандугач сайравы. Шагыйрәнең ата-анага булган кайнар мәхәббәте — мең авырлыкны җинә белгән рухи бәхете!

Сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы күркәмлеге белән безнең эрага кадәр үк яшәгән юнан галиме Аристотель дә житди шөгыльләнә. Сөйләмдәге сүзләрне ул өчкә бүлә: югары баскычта, түбән күтәрмәдә, шуларның уртасында торучылар. Югарыдагысына поэтизмнар яки матур яңгырашлы, тирән эчтәлекле сүзләр керә: ак бәхет, ак күңел, ак йөрәк, ак йөз, ак юл, ак ахак, ак тукранбаш, юлына ак җәймә, саф зөбәрҗәт, саф тавыш, саф алтын, саф нәсел, саф һава, саф күңел, саф акча, саф мәхәббәт һ.б.

Шагыйрәнең «Әнинең чигүләре» исемле шигырендә сөйкемле сүзләр контаминацияләнгән (кушылган, катлауландырылган) фразеологик берәмлекләр ясый (матур яшьлек, төсләренең ак җирлеккә чигелүе, яшьлектәге сафлыкның чәчәкләрдә хисләнүе). Алар ярдәмендә шигъри строфа ипләнә. Аның шулай икәнлегенә Тәңре рухы шаһәдәт:

*Ак җирлеккә чиккән чигүләрең –*
*Матур яшьлегеңнең төсләре.*
*Шушы чәчәкләрдә — хыялларың,*
*Сафлыгың һәм нечкә хисләрең.*

Ак җирлек — иманлы кинлек. Сафлык — кандагы хаклык. Шушы дүрт строфалы шигырьдә генә дә төрле-төрле КФӘләр төзү осталыгын гөлләндерә шагыйрә: мең сынаулы язмышның тере сурәтләнүе, кара болытлар кичкәндә дә каралмау, боз яуганда да чыдам чәчкә төсле сулмый калу, ак җирлеккә яшь-яшь кул белән язмыш чигү, гомер күзләренә шау чәчәктә килеп житү.

Мәгълүм ки, К.Насыйри бабакаебыз әйткәнчә, фигыльләр буенча гына фикер йөрткәндә дә, татар теле дөньядагы иң алдынгы телләр сафында данлана ала. Хәтта өстенрәк тору хакында әйткән искәрмә дә бар. К.Насыйри өчен грамматика — тел атасы, этимология — тел анасы. Шигъри поэтика боларны белергә куша. Белә Ләйсән!

Җирнең ерак тарихы куенында тамырланган, аннан киләчәген нигезләгән, шытып чыгып, алтын кәүсә балкыткан, ботакларындагы яфракларын инсаниятчелек рухы итеп җилфердәткән татар теле фразеологик әйтелмәләргә гаҗәп мул. Аның шулай икәнлеген Н.Исәнбәтнең ике томлы җыентыгы раслап тора. Татар милләтенең бай хәзинәсе бу. Әдәби әсәрнең идея-эчтәлеге, чор, тема, сюжет, төрле язмышлы затлар үзенчәлеген искә алып, Ләйсән Кәшфи аларны шул килеш, халыктагыча да куллана, өслүб таләп итсә, үзгәртә дә, үзе дә яңаларын иҗат итә. Соңгысы — күбрәк. Кайберләрен күрсәтеп кенә китик: Ходайның намусын таптатмаганнарны сөюе; сафлыкның бәхет үзәге булуы; халкың бала иткән җирдә абынмый яшәү; зәмһәрир күңелле кешенең бер тамчы җылыдан эрүе; киндек каны тамган туфракка мең бурычлы булу; тәмуг казанына кургаш тавы кадәр гөнаһ җыеп төшү; бар галәмдә ак мәхәббәт булып балкып калу; юксынуның үткәннәрне иртәгәге көнгә ак җеп белән бәйләве һ.б.

Әлеге мисаллар гына да шагыйрәнең нәфис сүз сәнгате остасы икәнлеген тәсдыйклый. Каләм шөһрәтенең эстетик идеалында югары аң, зәңгәр күк, галәм киңлеге, милләт зары, халык зары, кешелеклелек мәрхәмәтлелеге, гомер мәхәббәтлелеге күркәмләнә. Барлык баллы хәбәрләрне аңа, гүя, сәмруг кош ташып тора. Бу — Аллаһ могҗизасы! Гөнаһсыз, намуслы, сөйкемле затларга Аллаһы Тәгаләнең шаһәдәте киң. Кешелеклелек сыйфаты турында имтихан тапшырганда, Аллаһ гөнаһлы бәндәгә «2»ле куя. Ләйсән Кәшфи дә шулай итә. Аңынча, гөнаһсызга — ак җирлек, гөнаһкяргә — кара каберлек. «Минем бәхет» дигән шигырендә болай ди ул:

*Мин — бәхетле!*
*Зил-зиләләр генә*
*Челпәрәмә итмәс бу хисне.*
*Минем бәхет җирдән күккә кадәр,*
*Мәгърур, горур, биек тау төсле.*
*Күңелдәге иман кебек якты,*
*Намус кебек чиста, кер күнмас,*
*Таш кыялар кебек тугрылыклы,*
*Нәфесләргә эреп сатылмас.*
*Минем бәхет бик тирәннән килә,*
*Дога сеңгән нигез ташыннан,*
*Борынгыдан килә, шәҗәрәдән,*
*Нәселемнең чишмә башыннан.*

Чыннан да, шигъри иман сөйкемлелеге бу! Яшәү оҗмахы!!!

Гөнаһкярдән халык төрлечә көлә: җилкә чокыры тирәнәйгән, көймәсе комга төртелгән, балта сабы сынган, намусын шайтан ашаган, бәхете бетләгән һ.б. Мондый гыйбарәләр юктан гына чыгарылмый. Ялкау, хөсет, мәхлук җаннарны халык яратмый. «Минем бәхет» исемле шигырендә Ләйсән андыйларга карата булган нәфрәтен үзе иҗат иткән бер гыйбарә кысасында бирү осталыгына ирешә.

Аш өстәге өресе белән генә түгел, төптәгесе белән дә тәмле. Сүзләр дә шулай. Төрлесе кирәк. Бу үзенчәлек Йосыф Баласагуни (XI гасыр), Кол Гали (XIII гасыр), Мөхәммәдьяр (XVI гасыр, Казан ханлыгы чоры), Утыз Имәни, Г.Кандалый, Г.Тукай чорыннан ук килә. Мәгълүм ки, Тукай Ләйсән әйткән «ак җирлек»не иман белән баетса, каралыкны сүз кылычы белән саектыра. Андый кылыч ак җирлектә таштай чыныккан Ләйсән кулында да булырга тиеш. Бар ул. Гарык булу, кара нәфрәт, әҗәл, бәргәләнү, сөрлегү, түнтәрү, шыплау кебек сүзләр, гөл-бакчага шайтан таягы килешмәгәндәй, Ләйсәннең шигърият сәнгатенә кара яга төсле. Бу, бәлки, өстән караганда гына шулай тоеладыр. Ләйсән — белемле шагыйрә. «Алама» дигән кешенең дә күңел дөньясында ниндидер серле гәүһәрләр ятканлыкны аңлый ул. Аллаһ имансыз кавемнәрне юкка чыгара. Кешелеклелеге корыган затлар да шундый бичара. Табылсын иде аларга «дәва» дигән чара. Шулай уйлый Ләйсән. «Гасыр бусагасында» дигән шигырендә болай ди:

*Мәңгелеккә керәм ялан тәпи,*
*Намазлыкка баскан шикелле.*
*Сәҗдәләргә китәм, күңелемне*
*Бар җиһанга ачкан шикелле.*

*Язмышларга ачы юллар язма –*
*Мәңгелеккә иң зур теләгем.*
*Рухка — экчерсезлек, кешелеккә –*
*Иман булсын иде бүләгең.*

Җир шарының мәхәббәт йомгагы булуы хакында әйткәнем бар. «Чагыштыру — танып-белү анасы» дигәнне халык чал тарихта ук иҗат иткән. Мәрхәмәтле шарыбызның чагыштыруларга корылуы хакында да иманым камил. Әйбер белән әйбер, күренеш белән күренеш, хәрәкәт белән хәрәкәт чагыштырыла. Шулар арасына Өлкәр йолдыздай тиз, кулына иманлы каләм тотып, идея-эстетик максат белән кереп китә Ләйсән. Шигъри зәвыгын канәгатьләндермәсә, үзгәртә, алай да килешмәсә, үзе яңаны иҗат итә. «Мин бәхетле»дән бер строфа:

*Мин бәхетле саф гыйффәтем белән,*
*Тугрылыгым белән көчлемен.*
*Гасыр давылларын сизми торган*
*Төгәл пирамида төслемен.*

Ләйсән — чибәр, нәфис, сөйкемле зат. Чибәр кызга гыйффәтлелекне саклау — үзе батырлык. Тарихта иманлы пирамидалар күп. Алар гасыр давылларына бирешми. Учында яшен ташын биетердәй Ләйсәннен үзен пирамида белән чагыштыруы һич тә жинел уйлау нәтижәсе түгел. Мөселман хатын-кызларынын матурлыгы, батырлыгы — тарих көзгесе. Болгар чорында ире сугышта һәлак булса, хатыны, атка атланып, көрәш давылына чыккан. Мөселман хатын-кызларынын 1812 елгы Ватан сугышында булулары да мәгълүм. Бөек Ватан сугышына үзләре теләп ут эченә киткән хатын-кызларыбыз зур батырлыклар күрсәтте. Төнге очучы Мәгубә Сыртлановага (Бәләбәй кызы), Ләйлә Санфировага (Уфа кызы) Советлар Союзы Герое (Каһарманы) исеме бирелде. Шагыйрәнең «Күнел бакчам, гүя, яу кыры» («Кайту») дигән чагыштыруы да патриотик тойгы белән бәйле. Башкортстаннын бай, матур, гүзәл, нәфис табигатьле икәнлеге сокландыра. Ләйсән аны «Жиләк чагым» шигырендә сүз-сурәт белән тасвирлый:

*Каен җиләк таеп егылырлык,*
*Җир җиләге кибән салырлык.*
*Кура җиләк кызыл чаршау кебек,*
*Шаккатырлык, хәйран калырлык.*

Ватанынны сөю сөйкемлелеге әнә шулай була ул! «Сынама» исемле шигырендә: «Мин — тимер», — ди Ләйсән. Әле пирамидага, әле тимергә, әле давылларга бирешмәс гөлгә тинли ул үзен. Сөялле күнелләр («Сынама»), тыйнак хисләр («Өмет»), илаһи нур дигәндәге логик һәм метафорик эпитетлар авторнын үзен генә түгел, гомумән, мөселман хатын-кызларынын жисмәни һәм рухи дөньясын зиннәтли. Күккә күтәрелгән мөселман кызы Зөһрә төнлә жиргә ак нур коя. Танны уяткан Чулпан иртәнге намазны башлап жибәрә. Ләйсән (бар ул шундый йолдыз) көндез жирне ак тамчылар белән ләззәтли. Галимнәр яна табылган бер йолдызга янә мөселман кызы исеме кушмакчы. Бирсен Ходай! Мөселман кызлары, дәүләт таны гөлен чәчәкләндерүдә дә гүзәллек күрсәтә. Башкортстан кызлары Алсу, Динә Русия һәм Көнбатыш Аурупа илләре халыклары күнелен янача яшәү моны эстетикасы белән әсәрли. Ләйсән Кәшфинен дә шигърияте зур казанышлар яуларга хаклы. Бирсен Ходай!

Академик В.Виноградов күп еллар элек әдәби әсәрләр телен өйрәнүнен киләчәктә мәктәптә һәм югары уку йортларында аерым фән буларак укытылачагы турында әйткән иде. Иманлы хыялы тормышка ашты зур галимнен. Мәктәпләрдә «образлылык», «идеялелек, «эмоциональлек» дигән төшенчәләр белән эш итәләр. Бу мәгънәләрне мин «сүз-сурәт», «сүз-фикер», «сүз-тойгы» дигән парлы сүзләр белән бирү яклы. Башка төрки телләрдә дә (төрек, үзбәк, азәрбайжан һ.б.) бу хакта төрлечә фикер йөртелә.

Кешенен төрле яктан камил, тәрбияле булуына нык игътибар итә Ләйсән Кәшфи. Алар сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы ярдәмендә гамәлләшә. Сурәтләү чаралары аз сүз белән күп мәгънә анлатуга, әдәби әсәрнен идея эчтәлеген ачыклауга ярдәм итә. Матур әдәбият стиле, фәнни стиль, хәбәрнамә (публицистика) стиле чама белеп кулланыла. Ан, акыл, хис, тойгы, белем кардәшлеге йөрәк, күнел, жан, кан туганлыгы белән нәкышләнә. Эстетик идеалын дөньяви хәл-вакыйгалар белән бәйләп бирүе сокландыра. Шигырьләрендәге сөйкемлелек йөрәк белән кабул ителә. Педагогик эстетикасы отышлы. Киләчәктә заман шигъриятенен концептуаль мөмкинлекләренә, темалар кинлегенә һәм тирәнлегенә, жанрлар һәм шигъри калыплар төрлелегенә дә игътибар итәргә кирәктер. Грамматик төзеклек, шигъри техника дигәндә дә камиллекнен чиге юк. Шигъри сөйкемлелеккә Байрон осталыгы таләп ителә. Ләйсән Кәшфи дигән шагыйрә әлеге үрләргә омтылып ижат итә.

**Суфиян ПОВАРИСОВ,**
*Башкортстанның халык язучысы,*
*БДУ профессоры*

# КҮҢЕЛ КУШКАН ЮЛДА



Татар фәнендә олпат, үз эшенә чиксез бирелгән, аңа намус аша караган, һәрвакыт яңалыкка, камиллеккә омтылган галим-остазлар исемлеген Дания Заһидуллина исеме дә тулыландыра.

Филология фәннәре докторы, профессор, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең Баш гыйльми сәркатибе, Казан федераль университеты каршында эшләп килүче докторлык диссертацияләрен яклау советының рәис урынбасары, тәнкыйтьче-галим, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы Дания Фатих кызы Заһидуллина 1964 елның 1 октябрендә Татарстанның Мөслим районы Әмәкәй авылында туа. 1981 елда — Әмәкәй урта мәктәбен тәмамлап, кайсы юлдан китәргә дип сайланган-уйланган көннәрдә — табигатьтән бирелгән иҗади талант, әдәбият, шигърият белән кызыксыну төгәл фәннәргә омтылышы булган кызны сихри һәм серле әдәбият дөньясына тарта. 1981-1986 еллар — Казан дәүләт университетындагы филология факультетының татар бүлегендә укыган чоры — аны танылган, олпат галимнәр белән очраштыра, алардан лекция-дәресләр тыңлау бәхетенә ирештерә. Ул елларда күңелендә әдәбиятка, шигърияткә мәхәббәт йөрткән кыз-егетләрне татар, рус, Аурупа әдәбиятларын, әсәр язуның нечкәлекләрен яхшы белгән, үзе дә язучы булган М.Мәһдиев күреп алып, «Әллүки» түгәрәгенә җыя, бик күп шагыйрь-язучылар белән кичәләр, Татарстан, Башкортстан төбәкләренә әдәби очрашулар оештыра... Андый бәхет яшь студент Дания Салиховага да насыйп була. Мөхәммәт абый белән бергә үтелгән йөзләгән чакрымнар әдәбият серләренә төшендереп кенә калмыйча, дөньяны, кешеләрне танырга, акны карадан аерырга, камиллекне анларга өйрәтүе, ирониялe-әче репликалар аша ныклы ихтыяр көче тәрбияләве белән Хәтер түрендә саклана.

Университетны тәмамлаганнан соң, Дания Заһидуллина хезмәт юлын Татарстанның Балтач районы Түнтәр урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлап җибәрә. Ләкин эзләнүчән, һәрвакыт күңеле белән фән дөньясына, яңалыкка омтылган укытучыны мәктәп даирәсе генә канәгатьләндерми, 1989 елда ул, аспирантурага керү теләге белән, Казанга юл ала. Язмыш аны яхшы мәгънәсендә тынгысыз, холкы-фигыле белән ипле, яшьләргә хәерхаһ мөнәсәбәттә булган, «демократик» рухлы һәм фикерле галим Тәлгат Галиуллин белән очраштыра. Остазы булачак галимәгә олы фән юлында беренче сукмакларны салырга булыша, алга таба да саллы кинәшләре белән һәрчак ярдәм итеп килә.

1991 елдан Дания Заһидуллина үзе белем алган университетта яңа гына оешып килгән татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетының татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасына укытучы итеп эшкә алына. Университетта ассистент буларак башланган хезмәт юлы аны, өлкән укытучы, доцент (1996) баскычлары аша, профессор (2002), кафедра мөдире (2008) дәрәҗәсенә күтәрә. Фәнгә хезмәттә үткән еллар дәвамында Дания Заһидуллина әдәбият белеме фәне үсешен өйрәнүне яшәү гаменә әверелдергән абруйлы тикшеренүчеләрнең берсе, XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен процесс буларак өйрәнгән, үз концепциясен булдырган галим һәм узган гасыр башында иҗат ителгән бик күп әдәби ядкарьләрне татар укучысына кайтарган текстолог булып өлгерә. Университетта эшләү дәверендә ул үзен һәрвакыт һәркемгә ярдәм итәргә әзер торучы, олпат фәнни кинәшләрен

бирүче, фәнгә омтылыш хисен уятучы шәхес, тирән белемле һәм эрудицияле галим, студентларга таләпчән, әдәбиятның төрле өлкәләреннән хәбәрдар, татар, рус әдәбиятларыннан тыш, Көнчыгыш һәм Аурупа сүз сәнгатеннән дә яхшы мәгълүматлы укытучы, яшь укытучылар, аспирантлар арасында тынгысызлыгы, эзләнүчәнлеге белән соклану уяткан, шул халәт-сыйфатлары ярдәмендә туктаусыз алга, яңа үрләргә әйдәгән, яңа сукмаклар ачып, белемлерәк булу тойгысын уяткан, кафедрада гына түгел, факультетта, университет даирәсендә дә үз йөзе булган остаз, иптәш һәм дус буларак таныта. Шуның белән янәшәдә 2007 елдан Дания Заһидуллина хезмәт юлын Татарстан Фәннәр академиясенең Баш гыйльми сәркатибе буларак дәвам итә.

Дания Фатих кызы Заһидуллина фәнни эзләнүләрен берничә юнәлештә алып бара: урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы; әдәби-нәзари мирас, әдәбият теориясенең тарихы; әдәбият теориясе, әдәбият белемендә тикшеренүләр тарихы, дөнья әдәбият белемендәге фәнни-теоретик, нәзари мәктәпләрнең милли нәзари фикердә үзләштерелү һәм трансформацияләнү үзенчәлеге; XX йөз башы татар әдәбиятында барган модернистик эзләнүләр, гасыр башы һәм ахыры татар модернистик прозасы, төгәлрәге ике гасыр чигендәге «яңа» әдәбиятның үзара «диалогы»; XX гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәреше.

Методик мәсьәләләр Дания Заһидуллинаның фәнгә аяк басканнан алып бүгенгә кадәр даими өйрәнеп, үстереп килгән өлкәсе булып тора. 1993 елда яшь галимә Т.Галиуллин житәкчелегендә мәктәптә лирик әсәрләрне өйрәнүгә кагылышлы кандидатлык диссертациясен язып яклый, аннан соң да бу юнәлештәге тикшеренүләрен туктатмый. Студентларга лекцияләр уку барышында методик белемнәрен тагын да камилләштерә, педагогикада барлыкка килгән яңа технологияләрне барлап, өйрәнеп, аларның уңышлы, отышлы саналганнарын милли әдәбиятны укыту барышында максатчан куллану юлларын эзли. «Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту» (2004) дәреслеге шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Әлеге хезмәтендә галимә татар әдәбиятын укыту методикасының тарихын барлый, бу тармакка үз өлешен керткән, методик мәсьәләләр белән шөгыльләнеп, эз калдырган методист-галимнәрнең эшчәнлеген күздән кичерә, яңалыгын билгели. Һәр әдәби төр, жанрны мәктәптә өйрәтү методикасын тәкъдим итә, теоретик материалны мисаллар белән бәйләп, гамәли яктан ныгыта. Бу хезмәт укытучылар тарафыннан зур ярдәмлек буларак кабул ителә.

Моннан соң да Дания Заһидуллина мәктәпләр, урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек, методик кулланмалар әзерләвен дәвам итә. Аның житәкчелегендә эшләнгән «Татар әдәбияты. Теория. Тарих» (2004, 2006, Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйләҗев, Н.Йосыпова), «Әдәби әсәргә анализ ясау» (2005, Д.Заһидуллина, В.Әминева, М.Ибраһимов), «Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз» (2007, Д.Заһидуллина, В.Әминева, М.Ибраһимов), «Татар әдәбияты: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» (2007, Д.Заһидуллина, В.Әминева, М.Ибраһимов, Н.Йосыпова, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйләҗев, Г.Гайнуллина), «Татар әдәбиятыннан таблицалар» (2009, Д.Заһидуллина, Н.Юсупова, Ә.Закирҗанов, И.Кадыйрова) кебек хезмәтләре шул хакта сөйли. Мәктәп программасы һәм дәреслекләрен өстәмә баеткан, әдәби әсәрне, әдип иҗатын өйрәнү юлларын һәм мөмкинлекләрен тәкъдим иткән әлеге кулланмалар республика укытучыларының өстәл китабына әверелә. Галимә татар әдәбиятын укытуны тагын да камилләштерү, фәндә барлыкка килгән яңалыкларны даими рәвештә мәктәпкә кертү йөзеннән вакытлы матбугат битләрендә дә мәкаләләр бастырып килә, укытучылар алдында чыгышлар ясый, татар әдәбиятыннан яңа программа, дәреслекләр эшләүдә дә башлап йөри.

Методика белән берләштән, иҗади холыклы, теоретик нигезле галимәне әдәбият белеме, әдәбият теориясе үзенә тарта, серлелеге, кызыклыгы белән игътибарын җәлеп итә һәм алга таба фәнни эзләнүләренең төп магистраль юлын тәшкил итә. Әдәби күренеш, агымнарның асылына бары аның нигезен барлау, тарихын өйрәнү аша гына төшенеп булачагын аңлап, ул татар нәзариясенең үткәнен тикшерүгә алына. XX йөз башы — татар әдәбиятының алтын чоры — Д.Заһидуллинаның фәнни эзләнүләре үзәгендә тора. Әдәбият белеменең моңа кадәр киң катлам укучыга гына түгел, күп кенә филологларга да аз таныш сәхифәләренә игътибарын юнәлтеп, ул «ак таплар»ны — идеологик кысулар тәэсирендә тарих тузанына күмелгән әдәби-мәдәни бәйләнешләрне, татар әдәби-фәлсәфи фикеренең гарби һәм шәркый бәйләнешләрен ачу теләге белән яна. Махсус төстә күз

уныннан читтәрәк калдырылган XX йөз башы тәнкыйтьче-галимнәренең эшчәнлеген өйрәнүне, хезмәтләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүне намус эше дип саный. Үзенең халәтенә, рухына якын теманы яратып, үз итеп эшләү һәм туктаусыз эзләнүләр, тырышлык нәтиҗәсендә докторлык диссертациясе өлгерә. Татар әдәбият белемендә яңалык буларак кабул ителгән хезмәтен 2001 елда уңышлы яклап, Дания Заһидуллина филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була.

«Әдәбият кануннары һәм заман» (2000) китабында галимә әнә шул тикшеренү нәтиҗәләрен киң катлам укучыга ирештерә, гасыр башында нәзариянең зур югарылыкка ирешүен дәлилли. Әлеге монографиядә әдәбият теориясе барлыкка килү һәм үсү юлы беренче тапкыр эзлекле өйрәнелә. Фәнни тикшерүләр урта гасырдан башлап, үзенең «алтын» чоры — XX йөз башы аша, катлаулы, четерекле саналган, бер үк вакытта әдәбият белеменә шактый гына үзгәрешләр дә китергән 20-30 нчы елларга кадәр җиткерелә. Әдәбият теориясенең урта гасырдан алып, XIX гасырның ахырларына кадәрге вакыты милли нәзария тууга әзерлек чоры буларак аерып чыгарыла. Әдәбият белеме фәненең фән буларак формалашып, мәйданга чыгу вакыты итеп XX гасыр башы билгеләнә, андагы әдәби-нәзари агымнар, аларның оешу тарихы, төп кануннары, милли асылы, йөз тоткан, таянган юнәлешләре ныклап өйрәнелә, «җәмгыятьчеләр», «рухиятчеләр» мәктәпләренең һәм милли сүз сәнгатендәге яңа әдәби концепцияләрнең туу алшартлары барлана, аларның үзгәреш-янарышы ачыклана. Әлеге эзләнүләре белән галимә шул чорда милли аң үсешенең дә югары биеклеккә ирешүен исбатлый. Әйтерсең лә бу тема, юнәлеш нәкъ менә Дания Заһидуллина кебек фәнгә мөкиббән, XX йөз башы татар әдәбиятын, әдипләрен ихлас яраткан, сокланган, яхшы мәгънәсендә табынган галим-эзләнүчесен көткән...

Әлеге монографиясен бастырганнан соң да Дания Заһидуллина нәзарият, әдәбият тарихы белән кызыксынуын киметми. Нәзари фикер тарихын өйрәнү юлындагы эзләнүләре аңа тагын бер өлкәгә — әдәбият белемендәге фәнни-тикшеренү мәктәпләрен өйрәнүгә юл күрсәтә. Галимәнең соңгы еллардагы фәнни-концептуаль эзләнүләре нәкъ шул өлкәгә карый һәм татар әдәбият фәнендә алып барылган тикшеренүләрне баетып, яңа югарылыкка күтәреп җибәрә. Рус телендә дөнья күргән «История науки о литературе у татар» (2011) хезмәтендә татар әдәбият белемендә формалашкан нәзари мәктәпләр аерып өйрәнелә, дөнья әдәбияты белемендәге әлеге мәктәпләрнең милли үзләштерелү үзенчәлекләре билгеләнә.

Татар нәзари фикере тарихын тирәнтен өйрәнү, XX йөз башы татар әдәбияты белән кызыксыну галимәгә киләчәк фәнни эзләнүләр өчен тагын бер өлкәне ачып җибәрә. Ул — моңа кадәр игътибардан читтә калган, идеологик максатлардан чыгып, махсус өйрәнелмәгән яки тискәре яктан гына бәяләнеп килгән, әмма искиткеч кызыклы һәм мавыктыргыч модернистик эзләнүләр. Нәтиҗәдә Дания Заһидуллина, әлегәчә үзенең тикшерүчесен көтеп яткан әдәби катламнарны актарып, «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003) хезмәтен татар укучысына тәкъдим итә. Онытылган авторларны кайтару, аларның иҗатына лаеклы бәя бирү омтылышы ясалган монография шартлы рәвештә ике өлешне — модернизм, аның агымнары, алымнары, милли матбугатта яңалыкка караш-мөнәсәбәт турындагы теоретик материалны һәм шуны гамәли нигезләгән модернистик, аерым алганда, символистик, экзистенциаль, импрессионистик, экспрессионистик проза үрнәкләренә анализны үз эченә ала. Хезмәт татар укучысы өчен билгесез саналган М.Хәнәфи, Ә.Тангатаров кебек авторларны, өйрәнүдән читтә калган әдәби әсәрләрне халыкка кайтаруы, модернизмның рус һәм Аурупа әдәбиятыннан үзгә, милли төсмерләрен аерып чыгаруы, модернистик әсәрләрне өйрәнүнең милли концепциясен булдыруы белән әһәмиятле, актуаль. Сонрак дөнья күргән «Модернизм в татарской литературе первой трети XX века» (2013) хезмәтендә галимә XX йөз башы әдәбият мәйданында алып барылган эзләнүләрнең 1920 елларга кадәр үстерелеп, баетылып килүен исбатлый. Алай гына да түгел, бу хезмәт 1920 еллар татар әдәбиятында алып барылган имажинистик, футуристик эзләнүләрнең гомумәдәби процесста тоткан урынын билгеләве ягыннан да әһәмиятле булып тора.

Модернистик әдәбият белән кызыксыну Дания Заһидуллинаны фәлсәфи әсәрләр дөньясына алып керә. «Дөнья сурәте үзгәрү» (2006) хезмәте шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Әлеге монографиясендә галимә әдәби әсәргә структураль-семиотик

анализ ясау юлларын тәкъдим итә, XX йөз башы татар әдәбиятының үзәгендә торган дөнья сурәтенең мәгърифәтчел, трансценденталь, гыйсъяный һ.б. төрләрен аерып чыгара, Көнчыгыш һәм Аурупа фәлсәфи концепцияләренең татар әдипләре тарафыннан кулланылу үзенчәлеген билгели. Шуның нәтиҗәсендә XX йөз башы фәлсәфи әсәрләренә хас һәм теләсә кайсы фәлсәфи әсәрне бәяләүдә нигез хезмәтен үти алырлык берничә нәзари сыйфатны, тенденцияне аерып чыгара: автор позициясе әсәр структурасында урын алган дөнья сурәте аша тәгалләшә; дөнья сурәте әдәби әсәр төзелешенең нигезендә яткан бинар оппозицияләр нигезендә ачыла; шул юлда символлар үзәкне тәшкил итә; фәлсәфи әсәр күпкатламлы булу сәләтенә ия; татар фәлсәфи әдәбияты, көнчыгыш һәм көнбатыш фәлсәфи концепцияләрен бербөтенгә туплап, милли җирлеккә яраклаштырып трансформацияли — аның, һичшиксез, үз милли йөзе бар.

Модернистик прозаны үсештә өйрәнү теләге галимәнең игътибарын сүз сәнгатенең тагын бер чоры — XX-XXI гасыр чиге «яңартылган» татар прозасына юнәлтә, шуңа бәйләнештә әдәби тәнкыйтькә алып керең китә. «Яңа дулкында» (2006) хезмәте шул юнәлештәге эзләнүләрнең бер өлеше буларак дөньяга чыга. Җыентыкта урын алган язмалар шартлы төстә ике өлешне — «яңа дулкын» татар прозасы үсешендәге актуаль мәсьәләләрне көн тәртибенә куйган, аны өйрәнү юлларын тәкъдим иткән теоретик-методологик тикшеренүләрне һәм шул нәзари күзәтүләрне гамәли дәлилләгән әдәби әсәрләргә анализларны берләштерә. Галимә Т.Миңнуллин, Ф.Бәйрәмова, Н.Гыйматдинова, Ф.Садриев, З.Хәким, Р.Зәйдулла һ.б. модернистик әсәрләренә анализ ясый, аларның чор әдәбияты үсешендә тоткан урынын ачыклый, шул юлда сүз сәнгатенең киләчәк перспективаларын да билгеләп бара.

Шул рәвешле XX гасыр татар әдәбиятының төрле дәверләрен аерым аспектларда тикшерү-анализлау аша Д.Заһидуллина XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен процесс буларак өйрәнүгә килә һәм сүз сәнгатенең әлеге катлаулы, каршылыклы чорын бәяләүдә үз концепциясен тәкъдим итә. Узган гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш тарихын өйрәнү объекты итеп алган «XX гасыр татар әдәбияты тарихы» (2011, Д.Заһидуллина, Н.Йосыпова) дәреслеге XX гасыр сүз сәнгатенең моңа кадәр аерым өйрәнелеп килгән XX йөз башы, 1920-1930 еллар, сугыш һәм сугыштан соңгы еллар, 1960-1980 еллар, 1980-2000 еллар кебек чорларын бербөтенгә туплап, дәвамчанлык принцибына салып тикшерә, өйрәнелә торган чор сүз сәнгатенә яңача караш булдыра. Нәтиҗәдә XX гасыр татар әдәбиятының, югалтулар һәм табышлар аша булса да, XX йөз башында ирешелгәннәрне үстереп, баетып, «совет чоры» дип исемләнгән һәм бәяләнгән дәвердә дә милли нигезләрне саклап яшәргә омтылуы, башка әдәбиятларны кабатламыйча, үз йөзен булдырып үсүе исбатлана.

Әдәбият фәненең төрле аспектларында тирәнтен эзләнүләр алып барган, еш кына яңа сүз булып кабул ителгән, үзеннән соңгы эзләнүчеләргә сукмаклар салып калдырган әлеге монографияләре, кулланмалары белән янәшәдә галимә «Казан утлары», «Мәйдан», «Безнең мирас», «Фәнни Татарстан» кебек журналларда бүгенге әдәби барышны бәяләгән, модернистик әсәрләргә җентекле анализ ясаган, аларның әдәби процесстагы әһәмиятен, тарихи урынын билгеләгән, кимчелекләрен дә күрсәткән, шулар нигезендә кызыклы гомумиләштерүләр ясаган язмалары белән дә чыгыш ясый. Ул мәкаләләр дә, Дания Заһидуллина каләменнән төшкән монография-хезмәтләр кебек үк, теоретик нигезле, фәнни җәһәттән тирән, объектив, бер үк вакытта иҗади рухлы булулары белән аерылып тора һәм авторының чын мәгънәсендә олпат, үз концепциясен булдырган, әдәбият белеме фәнен яңа югарылыкка күтәргән Галим икәнлеген тагын бер кат дәлилли.

Шушы көннәрдә Дания Фатих кызы Заһидуллина үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Без аны ихлас күңелдән күркәм юбилее белән котлап, исәнлек-саулык, гаилә бәхете, фәнни уңышлар, мәңге сүнмәс иҗат дәрте һәм киләчәктә дә концептуаль фәнни эзләнүләрен дәвам итүен телибез.

**Нурфия ЮСУПОВА,**
*КФУ доценты*

# «ГАЛИЯБАНУ»


*Мансур Мозаффаров*

Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан, Салих Сәйдәш, Муса Җәлилләрне күреп кенә калмаган, алар белән якыннан аралашкан, соңгылары белән иҗади элемтәдә булган композитор Мансур Мозаффаров иҗаты күпьяклы, күп катламлы. «Казах кызы», «Саумы, кояш», «Хәерле иртә», «Менәргә иде Урал тауларына», «Җиләк җыйганда», «Башка берни дә кирәкми» — әлеге җырларның исемен әйтү белән, хәтер бик тә таныш көйләрне яңарта башлый. Моннан тыш аның симфоник, камера-инструменталь, сәхнә әсәрләре дә шактый, ул эшкәрткән халык җырлары гына да мирасыбызның күп өлешен алып тора. Бүген исә без композитор тормышының зур бер сәхифәсе — «Галиябану» операсының язылу тарихына тукталырга булдык.

«Галиябану» — татар опера театрында куелган өченче спектакль. Аны иҗат итү вакыты Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән *(«Казан утлары», 2014, №7)* бер чорга — 30нчы елларга туры килә. Исегезгә төшерәбез: 1934 елда бер төркем иҗатчыларны, опера театрына кадрлар әзерләү максатыннан, Мәскәүнең опера студиясенә җибәрәләр. Бу чорда композиторларның һәрберсе яңа опера-балет язу теләге белән яна, языла башлап та ташланган әсәрләр байтак. Мансур Мозаффаров үзе дә «Галиябану»га кадәр «Лачыннар» операсы өстендә эшли. Ләкин либреттода (авторы — Фәтхи Бурнаш) табылган кимчелекләр эшне туктатырга мәҗбүр итә. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» сюжетына опера язу идеясе 1935 елның 25 августында студиянең репертуар советы утырышында — булачак операларның темалары билгеләнгән чакта туа (Муса Җәлилнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган опера студиясе эшчәнлеге турындагы докладында язылган. 10 ф., 2 тасвирлама, 20 сак.берәм.). 1937 елның августында Әхмәт Ерикәй әсәрнең либреттосын тәкъдим итә, ул вакытта әлеге операны язу композитор Александр Ключарёвка йөкләнгән була. Мәгълүм ки, Александр Ключарёв әле студиягә кадәр «Галиябану» увертюрасын иҗат итә, ә 1932 елда аңа ике бүлек өсти һәм әсәр сюита буларак яши башлый. Ләкин операны композитор билгеләнгән вакытта тапшыра алмый, шуңа да студия җитәкчелеге аның белән килешүне таркатырга мәҗбүр була. 1937 елда бу эшкә Мансур Мозаффаров алына.

«Галиябану» пьесасын Мирхәйдәр Фәйзи 1916 елда иҗат итә. Әсәрнең беренче исеме — «Сәгадәтбану». Тугыз күренештән торган әлеге драма шактый үзгәртелеп, беренче тапкыр 1917 елның 19 мартында Оренбургтагы «Ширкәт» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә. Режиссёр Вәли Мортазин-Иманский, пьесаны шактый үзгәртеп, «Галиябану» исеме белән куя. Галиябану ролен труппаның җырчы артисты Сара Байкина башкара. Спектакль татар-башкорт җәмәгатьчелеге тарафыннан зур кызыксыну, яңалык булып кабул ителә, чөнки сәхнәдә беренче мәртәбә җыр-моң, бию, фикер һәм каршылыклар» бергә үрелеп бирелә. *(Татар театры тарихы. — К.: Татар.кит.нәшр., «Җыен» фонды, 1993. — 73 б.).* «Галиябану»ның Оренбург сәхнәсендәге уңышын ишетеп, «Сәйяр» труппасы аны телеграмма белән соратып

ала һәм Казанда куя, шуннан соң бөтен труппалар «Галиябану»ны куя башладылар» *(Шунда ук)*. Ягъни «Галиябану»ның опера варианты туганчы, драматик вариант бик күп сәхнәләрдә куелган, ул чорда Татар академия театрында гына да пьеса дүрт тапкыр Габдулла Кариев, Гомәр Девишев, Гомәр Исмәгыйлевләр тарафыннан сәхнәләштерелгән була. Шуңа да Әхмәт Ерикәй һәм Мансур Мозаффаров каршына җаваплы эш четрекле мәсьәлә булып килеп баса. Таныш әсәргә таләпләр дә зурдан! Операның либреттосы кат-кат тикшерелеп, берничә тапкыр Әхмәт Ерикәй тарафыннан кире эшләнелә. Бу турыда Муса Җәлил латин графикасында җыелган «Галиябану» либреттосына рецензиясендә *(Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать интститутының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 10 ф., 1 тасв., 174 эш, 1-6 б.)* тәфсилләп яза: «Галиябану» либреттосының бу соңгы варианты Әхмәт Ерикәй иптәш тарафыннан редакцион комитетның утырышында тикшерелгән һәм расланган план буенча эшләнелгән. Бу планны тикшерү буенча без шактый киң һәм тулы фикер алышу алып барган идек. (...) Менә шулай тикшереп, нык эшләнгән план белән язу нәтиҗәсендә либретто үзенең композициясе белән бик уңышлы эшләнгән. Либретто пьесадан читкә дә китмәгән һәм шул ук вакытта, опера жанрына яраштырылып, бик оста кыскартылган, кирәксез вак моментлар төшерелеп калдырылган (мәсәлән, Садрый күренешләре, көтүче һәм хатын, Галияне кыйнап күндерү һ.б.). Исмәгыйльнең акча тапшыруы, Бәдрине сатып алу моментлары да яхшы уйланылган. Элеккеге рецензия нигезендә автор хор, ария, дуэтларны, квартет, триоларны бик урынлы һәм ачык формада эшләгән. Икенче картинада кызлар хоры бик урынлы кертелгән».



*Галия Кайбицкая*

Мансур Мозаффаровка да эш җиңел бирелми, чөнки ул төп чыганак кысаларында иҗат итәргә мәҗбүр була. Ләкин, шуңа да карамастан, ул бу операны дәртләнеп, дулкынланып эшли. Төп партия — Галиябану партиясен махсус Галия Кайбицкая өчен иҗат итә. Бу хакта җырчы менә ничек искә ала: «Беркөн шулай Мозаффаров: «Галиябану» партиясен Сезнең тавышка карата яздым. Тавышыгызга уңайсыз җирләре булса борчылмагыз, бергәләп үзгәртербез», — дип, Галиябану партиясен миңа китереп бирде. Мин ул вакытта «Качкын» операсында Рәйханә образы өстендә эшли башлаган идем. Рәйханә җырларын өйрәнү белән аяк-кул бик нык бәйләнгән чак иде. Әмма мин ул батырчылыкны үз өстемә алдым. Композитор үзе тудырган әсәрен, үз кулы белән «Сезне күздә тотып яздым», дип, зур өметләр белән миңа ышанып китергән икән, мин аңа һич тә каршы килә алмадым. Һичшиксез, берьюлы ике образ өстендә иҗат итү миңа җиңел булмады. Шул авырлыкны Мансур белеп, үзе, миңа җиңеллек китерү өчен, бик булыша иде. Остазым белән үткәрелгән дәресләремә үзе кереп, җырлавымны бик озак вакытлар тыңлап, берәм-берәм җентекләп утыра иде. Әгәр мин ул килгәнче класста берүзем булып, «Качкын» операсыннан берәр җыр җырлап утырам икән, «Качкын» җырларын куеп тор әле, Галия, аларны өйрәнеп туйгансыңдыр бит инде, дип ноталарымны читкә алып куяр иде дә «Галия» ноталарын каршыма тезәр иде» *(М.Мозаффаров турында истәлек / Башка берни дә кирәкми. — Казан, 2002. — Б.141-142)*.

«Галиябану» операсының премьерасы 1940 елның 23, 24, 27 июнь көннәрендә, Нәҗип Җиһановның «Качкын» һәм «Ирек» операларыннан соң уза. Дирижёры — Савелий Бергольц, куючы режиссёр — Шириязданн Сарымсаков. Әлеге мәгълүматлар татар опера театры музее архивында сакланган афишадан алынды. «Казан утлары» журналы өчен төшереп алынган программада катнашучылар составы да язылган. Усман Әлмиев тә «Татар опера театры сәхнәсендә» язмасында *(«Еллар һәм җырлар». — Казан: Татар.кит.нәшир., 2007 — 21 б.)* катнашучылар турында әйтеп уза: «1940 елда Мансур Мозаффаровның «Галиябану» операсы сәхнәгә куелды. Мин Бәдри, шулай ук Халил ролен дә уйнадым. Мин Бәдрине уйнаганда, Абу Сәйфетдинов Бәдри




*«Галиябану» операсы афишасының фрагменты*

була иде. Галиябану ролен исә Галия Кайбицкая, Сара Садыйкова, Шәфыйка Котдусовалар, ә ячы карчыкны Мәрьям Рахманкулова, Халидә Зәбирова, Асия Измайловалар уйныйлар».

«Галиябану» опера сәхнәсендә озак бармый. Клара Тажиева фәнни хезмәтләрендә моның төп сәбәбен – либреттоның кимчелеге белән аңлата *(Башка берни дә кирәкми. – Казан, 2002. Оперное творчество М.Музафарова / Музыка и современность. Актуальные вопросы татарской музыки. – Казань, 1980).* Ләкин ул вакытта язылган рецензияләргә карагаңда, музыкага да дәгъвалар шактый була. Мәсәлән, Гази Кашшаф 1940 елның 22 августында «Кызыл Татарстан» газетасында: «Композитор шулай да классик драманы – классик опера дәрәҗәсенә күтәрерлек эшләмәгән. Иң элек әсәрне халык тойгыларына, халык моннарына бай итеп бирү мәсьәләсен алыйк. Халыкчанлыкны саклауны халык музыкасын, халык моңнарын турыдан-туры операга күчерү төсендә аңламаска кирәк. Композиторның бурычы әзер көйләрне теркәп, попурри эшләүдә түгел, бәлки халык йөрәгендәге тирән моңнарны иҗади төстә файдалануда булырга тиеш. (...) Халык хәзер опера тыңларга өйрәнде инде. Ул андагы уңышлы, уңышсыз якларны тотып ала башлады. Образларның музыкаль тулылыгын күзәтергә өйрәнде. Шуңа күрә ул яшь операга скидка биреп, композиторларны бозарга теләмичә, ачык һәм туры әйткәнне ярата», – дип яза. «Музыкальная культура Советской Татарии» китабында Яков Гиршман аерым музыкаль номерлар уңышлы булып та, тулаем алганда, операның музыкаль-сәхнә әсәре дәрәҗәсенә житмәвен ассызыклый *(Музыкальная культура Советской Татарии. – Москва, 1959. – С.104.)* Муса Җәлил исә либреттоның телендәге җитешсезлекләргә басым ясый. Геройларның «бүгенге заман теле белән сөйләшүенә», халыкчанлыктан ерак булуына дәгъвалар белдерә. Шулай ук аерым образларның гәүдәләнеше ягыннан да тәнкыйть сүзләре җиткерә.

Мансур Мозаффаров үзе либреттоның кыскалыгыннан канәгать булмый. Яңа авторны озак эзләгәннән соң, аның игътибары Хәй Вахит вариантына туктала. Анда ике картина – Галиябануның әти-әнисе һәм Бәдринең базарга әзерләнү күренеше өстәлә. «Галиябану» операсының икенче варианты 1952 елның 20 ноябрендә Татарстан композиторларының иҗат җыелышында тикшерелә. Шунысы кызык: ТР Милли архивында «Галиябану» операсының соңгы, өченче вариантының клавиры һәм партитурасы саклана. Димәк, Мансур Мозаффаров «Галиябану» операсын гомеренең ахырына кадәр камилләштергән, бу исә композитор яңартылган әсәрен опера сәхнәсендә күрүдән өметен өзмәгән дигән сүз. Ни кызганыч, Мансур Мозаффаровның опералары, җырларыннан аермалы буларак, бәхетле язмышлы булмый. 40нчы елларда, Бөек Ватан сугышы чорында, ул Әхмәт Фәйзи либреттосына «Зөлхәбирә» операсын иҗат итә. Ләкин либреттоның йомшаклыгы сәбәпле (революциягә кадәр татар хатын-кызларының аяныч хәле турында бәян иткән әсәр), опера театрга кабул ителми. Гәрчә музыка ягыннан Мозаффаров «Зөлхәбирә» аша яңа биеклекләргә күтәрелде дип бәяләнсә дә.

Опера – композитордан күп көч, энергия, вакыт, сәламәтлек таләп иткән катлаулы жанрларның берсе. Һәм аның сәхнәдә дөнья күрмәве яисә тиешенчә бәяләнмәве иҗатчы өчен зур фаҗигагә тиң. Алда – Мансур Мозаффаровның 115, 120, 130... еллыгы. Кайчан да булса, композиторның исеме зурланып, «Галиябану» яисә «Зөлхәбирә» опералары рампа утын күрер әле дигән ышанычта калабыз!

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ШУНЫҢ БЕЛӘН ШУЛ... ВОКЗАЛДАН ЯЗАМ

МЕМУАРЛАР

Фәкыйрегез исә уртакул-уртача уйнады, дөресен генә әйткәндә, мина отыштан бигрәк уен барышы, биредәге азарт атмосферасы кызыклы һәм кадерле иде. Вак акча куелса да, хисләр барыбер ташыды — күрәсен, андый ташкын өчен сумманың зурлыгы-кечелеге мөһим түгелдер, киноларда киресен дәлилләсәләр дә, мин, күрәсен күргән, яшисен яшәгән кеше буларак, барыбер үз фикеремдә калам. Аерым бер ләззәт кичереп, Ярослав Кирилловичның осталарча хуҗалык иткәненә сокланып тордым, мина студентның тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка диеп, фишкаларны теләсә кайда сибәләвен күзәтү дә рәхәт иде, калганнар, ничектер, игътибарымнан читтә калды — хәер, вакыт-вакыт колагыма азартлы, ләкин тыйнак Виктор Гофманның тавышы да чалынгалады — мөгаен, аның хисләре тышка түгел, эчке якка — йөрәгенә — ташыгандыр. Волгинны гомумән күрми башладым — гәрчә минә янәшәмдә генә тора иде кебек үзе, аның нечкә, нәзек, сыгылмалы — пианиночыныкымыни! — куллары бер генә тапкыр күземә ташланды. Игорьны абайлап алуымның житди сәбәбе бар иде — ул... «жөп һәм жөп түгел»гә («чёт и нечёт») өчәр тәнкә куйды. Әүвәл ялгыш куйгандыр, аңлап бетермәгәндер дип уйладым, гамәленең мәгънәсезлеге турында авыз ачып сүз дә әйтергә теләдем, әмма крупье мине бүлдереп, тизрәк үз ставкамны ясарга ашыктырды. Игорь тагын беразга күз алдымнан югалды. Ике тапкыр, йокы аралаш диярсен, исерекле-уяулы килеш крупьеның ана мөрәжәгать иткәнен ишетеп өлгердем: «Волгин әфәнде, зинһар, ашыгыгыз, сезне генә көтәбез». Ләкин монарга каршы Игорь жип-житди рәвештә җавап кайтарды: «Гафу итегез, мин бу конны уздырам әле, уйланып аласым бар». Волгинның мондый акылсызлыгын һичкем бәяләп тормады, бәлки, ишетмәгәннәрдер, ләкин хәтта әче телле студент та дәшмәде. Үзем ихтирам иткән шагыйрьнен кыланмышларын аңларга, ниятенең төбенә төшәргә теләмәдем — яна гына чираттан өч тапкыр җингәнгә күрә, кызыклырак эшләрем дә бар иде... Мин дә, киночылар белән көйчеләр кебек үк, берешәр сум куюга күчтем, әйтергә кирәк, җинә башлавыма, крупье янындагы казна шактыйга кимеде.

Ялгыш кына фишкамны төшереп җибәргәндә, мин кабат Игорьга караш ташладым: ул Головановның яшел «тукыма» буйлап «төймәләрне» шактый зур суммаларга этәрүенә исе дә китмичә, Рузадан килгән кунакларның уйнавын күзәтә иде — әйтерсең, бу гамәленнән башка дөнья жимерелер. Жир күчәреннән кубар! — тегеләре дә игътибар төшмәслек түгел шул — жаннарын биреп уйныйлар, күзләре дөрли генә, өстәлнең бер башыннан икенчесенә таба туктамый чабып йөриләр, шул арада өр-яна, минем башыма мәнге киләсе түгел комбинацияләр уйлап табалар, дөрес, барыбер үзләренә бәхет елмаймый. Аның каравы, чираттагы турда энәсеннән жебенә кадәр шул ук «бөек» алымнарны кабатлаган яшь Проскурин ота да ота башлады. Мин бер мәлгә уен турында онытып тордым, Волгин мине күбрәк борчый иде — нигә берьюлы «жөп һәм жөп түгел»? Нигә чит кешеләрнен кызып-пешеп уйнавын шулай жентекләп күзәтә? Табигате белән гомумән башка төзелешле шагыйрьнен әдәбият кырында (хет шигырьдә, хет прозада булсын!) аркылыга-торкылыга өйрәнелеп беткән зарарлы галәтләргә карата шундый зур игътибар бирүендә нинди сер бар?

Студент артык мәшәкатьләнмичә генә киночылар белән көйчеләрнен чыгышларын кабатлап барды, һәм, нәтиҗәдә, һәрвакыт диярлек отты, минем өч отышым да акрынлап ана күчте. Әйткән сүзенә күпмедер көнчелек хисе дә кушып:

---

*Дәвамы. 2014 елның 7нче саныннан басылып килә.*

«Бәхет менә үзе килә», — диде кайсыдыр кунак. Әлбәттә, алар Проскуринның үз табаннарына басып баруын белә һәм, мөмкин икән, бу алымны хәзер тыярлар иде, әмма уенда алай ярамый дигән кагыйдә юк, кыскасы, бирәр нинди канәгатьсезлек-ризасызлык туса, Голованов, һичшиксез, яшь егетне яклар иде.

Кайсыдыр арада мин өстәлдә янадан Волгинның сөттәй ак манжетларын күреп алдым, ул да берешәр сум салуга күчкән иде һәм бу юлы... «кызыл белән кара»га куйды. Ләкин биредә һәркем үзе турында уйлап, башка кешеләрнең чыгышы һичкемне кызыксындырмый башлаган иде инде. Игорь тактикасының серенә төшенергә теләп, минем башым тубалга әверелде, саташуым, ахры, дип уйлап куярга да өлгердем: бер үк вакытта кызыл белән кара... мондый хәл бернинди очракта да, фантазиян никадәр бай булмасын, беркайчан да туры килә алмый ләбаса! Волгин болай акыллы кешегә охшаган үзе...

Уен җен тизлеге белән барып, сәгать угы бераздан төн уртасына — шундый кызыклы кичәгә йомгак ясалыр вакытка якынлашты, алдан сөйләшенгәнгә күрә, Головановның тагын бер генә өстәмә ставка да ясатмаячагы көн кебек ачык иде.

Рулетка уены тиз арада бөтен Малеевканы бугазлады. Икенче көнне ике кавказлы килеп, иң әүвәл ризасызлык белдерде — аларны, имеш, кичә уенга чакырмаганнар, ләкин сүз дигәндә кесәгә керергә яратмаган Голованов үзләрен тиз урыннарына утыртты: сезне бүген дә чакыручы юк иде, диде ул.

Бүгенге телдә сөйләшсәк, хәзер милләтара низаг туар кебек иде, ләкин яшь кавказлылар сүздән ары башка коралга күчмәде: без сездән начаррак түгел, Тбилиси Париждан бер ягы белән дә калышмый, Тбилисига рулетка патша заманында ук кереп калган, ул хәтта милли уен саналырга хокуклы — кунаклар тарафыннан шунын ише уклар гына атылды. Барыбыз өчен дә Голованов җавап бирә торды, ләкин, әлбәттә, бәхәс сүздән йодрыкка күчсә, без, һичшиксез, Кириллычны үпкәләтергә бирмәс идек. Җәнҗалны грузин теленнән шигырьләр тәрҗемә итүче Гофман туктатты. Уйнарга керештек. Ни гаҗәп — кагыйдәләрне алар, чыннан да, белә иде, ставкалар турында беркем кисәтмәгән килеш бишәр сум куйдылар, крупьеның: «Без бирәр сумнан арттырмыйбыз», — дип әйтүенә, кунакларның берсе ямьсез итеп: «Минем акча — күпме телим, шунын кадәр куям», — диде, ләкин анлыйсыздыр, Ярослав Кириллович та җавап белән көттермәде: «Теләгән кадәр итеп Тбилисида куярсыз, ә биредә үзгә кагыйдәләр, сезне нәрсәләр канәгатьләндерми икән, ишек әнә тегендә генә...»

Кунакларның уйныйсылары бик нык килә иде, ахры, шуннан соң тыннары чыкмады, гәрчә, мөгаен, үзләреннән һаман-һаман көлеп-мыскыллап торган яшь Проскуринга яхшылап кына җавап кайтарасы, ә бәлки хәтта янак төбенә утыртасылары да килеп киткәләгәндер — егет тиз арада отып алып кунакларны «парижаннар» дип кенә атауга күчкән иде: «әнә парижаннар», «бәлки, парижаннар», болай гына да — «парижаннар». Студентыбыз усал гына түгел, бик кыю да иде — «парижаннар»ның әледән-әле ана сөзеп карауларын сизми калмагандыр ул. Араларына кереп, грузиннарны борчыма инде, диярго авыз да ачкан идем, әмма Игорь туктатып калды: «Кысылма, Проскуриннар шул рәвешле характер ныгыта, мин кичә үк сина анын чын егет икәнлеген әйттем бит».

Иң мөһимен онытып торам икән: төшке аш вакытында буфетта Игорь белән юлыбыз кисеште, һәм иң беренче сүз итеп: «Бүген уйныйбызмы?» — дип сорады ул! Яшен кебек уй ми күзәнәкләремне өтте — гаҗәп, шундый акыллы, төпле кеше, югыйсә, ә уенга ничек тиз капкан, күзендә ялкын дөрли — мондый халәттә тәүге күрүем иде аны. Мин әле генә Ярослав Кирилловичны очраттым, ул бүген дә, кичәге кебек үк, кичке аштан соң уйныйбыз, диде, дип җаваплыдым. Игорь, тәмам канатланып, әкрен генә буфетчы кызга иелде: «Зоя, гүзәлем, бүген мина кунаклар керә, шуна күрә ватаныбызның иң ерак почмакларыннан җибәрелгән тәмле-тәмле күчтәнәчләрне җыеп бир әле, сүземне кире какма...»

Чираттагы уенда Рузадагы юмарт кунаклар күренмәде, әмма алардан кара «Волга»да «илче» — бер кинорежиссёр килде, ул да, кичәге дуслары кебек үк, табынга мул сый-нигъмәтләр чыгарып салды. Шушы кичне байтагыбыз тәүге тапкыр «Наполеон» коньягыннан авыз итте, эчемлекнең бусы Горький урамындагы «Елисеевский» кибетендә күренгәләп, бәясе шактый зур куелуга карамастан,

киштәләр бер сәгать эчендә бушый иде инде. Мин кабымлыкка казы алып килдем – шәрык халыкларының яраткан ризыгын һәммәсе үз итте, казы булганда, табигый ки, югослав ветчинасы да, чи килеш ысланган колбаса да онытылды.

Бүген дә барысы да кичәге кебек барды – уен, тәнәфес, тәмәке тарту; уенчылар да кабат тугыз кеше иде – Проскурин үзе белән дустын иярткән, ләкин кичәге уен урыныннан акрын гына кузгалса, бүген фишкалар тукыма-картонга төшүгә үк умырып китеп барды. Тимер акча куючы аз иде – бөтенесе, хәтта сакчыл Волгин да, кәгазь берлек ыргыта, студентның дусты һәм... мин генә алай ук итәргә базмый идек. Студент үзе янә бәхет кошын эләктерергә теләп фишка арты фишка тезде, әмма кичәге «ярдәмчеләр» юк иде шул, ул, аптыраганнан, яна Руза кунагына ияреп карады – әмма бу гамәле дә файда китермәде, крупье әледән-әле аның акчаларын җыючегә этә торды, кайвакыт үзенә таба да тарткалады.

Мин уенга чумсам да, җину-җинелү мәсьәләсе күңелемне тырнамады, артык кызмадым. Ләкин хәтеремә кинәт легендар язучы Ф.С.Фицджеральд килде, ул бик хисле кеше була бит – кәрттән кала, рулетка белән дә мавыга... Эврика! Азарт – безнең әдәбиятта өр-яңа тема лабаса! Шундый уйга бирелеп, Голованов тирәсендә җыелган уенчыларны игътибар беләнрәк күзәтә башладым.

Үземә кинәт шундый нәтиҗә ясадым: ярый әле бүген кешеләрнең яртысы диярлек алышынды – яңа хис-кичерешләр, яңа тәм; мине аеруча яшь грузиннар кызыксындыра иде – алар уенның нерв кылы гүя – һаман-һаман яңа йөреш, яңа комбинацияләр уйлап табалар – кичәге киночылар белән көйчеләрен бер кырыйда торсын! Ләкин боларына да бәхет елмаймый...

Кабат янәшә туры килгән Волгин минем Тбилиси уенчыларын күзәтүемне сизеп, болай диде: «Мина бу уен явыз, усал кешеләрне яратмыйдыр кебек тоела, йомшак, рәхәт, зур максатлар һәм бурычлар куймыйча уйнарга кирәк, әнә, яшь Проскурин төсле». Игорь моны һич икеләнмичә әйтеп салды, гәрчә бүген Проскуринның җиңүеннән битәр җинелеп баруын күреп тора иде, мин исә, Волгинның фикере белән килешмәсәм дә, бәхәсләшмәдем. Гүя ул уенны аңларга тели иде, аны уенчыларның үз-үзен тотышы, тиз арада кәефләре үзгәреп куюы, димәк – гамәлләре үзгәрүе дә кызыксындыра иде. Ләкин ни өчен кирәк бу аңа? Казино ачарга теләмидер бит? Теләсә дә, мөмкин хәлме? Тыгызлап ябылган пәрдә артында мәңгелеккә урнашкан социализм вакыты лабаса...

Язылачак хикәям яисә бәянымның планы башымда өлгереп килә иде инде, ул әсәрдә бу кызу канлы егетләргә шактый урын бирергә мөмкин – соңгы мода буенча кыйммәтле, ыспай, затлы итеп киенүләре аларны Малеевкада яшәп иҗат итүче башка күп кенә язучы-шагыйрьләрдән аерып тора иде. Мин, ирексездән, үз каһарманнарымны ярата башладым, чөнки – бәхәссез: каһарманнарыңны яратмыйсың икән, әсәрең туганда ук үле туачак – үзем уйлап чыгарган шундый нәтиҗәгә һәрвакыт тугрылык сакларга тырыштым. Хыял дингезендә йөзгән мәл: тагын бер-ике көн күзәтермен дә, имеш, хис-кичерешләрем сүрелгәнче чираттагы эшемә тотынырмын – югыйсә хәзерге хезмәтемнең тәгәлләнеп килгән вакыты...

Головановның «господа» сүзен калдырырга исәбе дә юк – мондый мөрәҗәгатьтән башка уенның тәме калмый, рулетка кадәр рулетка ниндидер затсыз, мәгънәсез бер нәрсәгә әверелә дип инанган иде ул, ахры.

«Господа»ны грузиннар аеруча якын итте, шушы сүз аларны Проскуринга карата агрессив гамәлләр кылудан тыеп тормагандыр да, бәлки. Ахырдан барыбер түзмәде, Ярослав Кириллович студентка кисәтү ясады, үзен тыйнаграк тотарга һәм аның кунакларының ачуын чыгармаска кушты. Грузиннар бу «сабак өйрәтү»не хуп күрсә дә, яшь егет әллә ишетте Головановны, әллә юк – аның тәртибе бер тамчы да үзгәрмәде, киресенчә, өстәвенә, кул астына эләккән Гофманга да бер-ике «бәрелеп» алды ул.

«Господа, акчаларыгызны куегыз!» – диюгә мин берүзем генә сискәнеп китә идем, ахры – әйтерсең, хаинмен – ниндидер изге, мөһим нәрсәгә хыянәт итәм, әмма йөрәгемнең дөп-дөп типкәнен учым белән каплап булса да сиздермәскә тырыштым. Бу турыда Игорь ни уйлагандыр – белмим, бер-ике тапкыр сорап карарга теләсәм дә, базмадым – соравы да, җавабы да икебезне уңайсыз хәлдә калдырыр дип шикләндем. Әле дә ярый шуна төшенергә башым җиткән.

Эчке тавышым әллә кайчаннан бирле пышылдап торды: безнең кыза-кыза уйнавыбызда Волгинның һичнинди гаме юк...

Үз ниятләремә чумган килеш, мин кинокамера шикелле бу бүлмәдәге һәр кечкенә вакыйга-күренешне хәтер тасмасына яздырып барырга, сеңдерергә, җиңгән һәм җинелгәннәрнең әйткән сүзләрен ятларга, Ярослав Кирилловичның һәр аңлатма-бәяләмәсен отып калырга тырыштым — Голованов бүген үзен аеруча шәп тотты, гомеремдә дә ишетмәгән акыллы һәм сирәк әйтемнәрне уңга-сулга сипте генә. Булачак каһарманнарымның төсе-кыяфәтен яхшылап истә калдырырга кирәк иде, өстәл тирәсенә тезелгән һәр уенчы — әзер образ югыйсә! Мин инде хикәямнеме, бәянымнымы Иҗат йортыннан киткәнче үк тәмамларга һәм аны һичшиксез Волгинга бүләк итеп өлгерергә уй корган идем, дустымның бит әле картина ясыйсы бар, иҗат җимешем ана ярдәм итми калмас, ә Игорьның уенга фәкать рәссам, художник буларак кына килүе миндә һичнинди шик уятмый иде, без һәммәбез аның яңа әсәре өчен натура идек, шуңа күрә дә ул уенга килгән һәр яңа кешегә, һәр яңа йөзгә сабый бала кебек чиксез куанды. Ул элеккечә йә «җөп һәм җөп түгел», йә «кызыл һәм кара»га берьюлы куя торды, ә өч тапкыр аның «зеро»га куюын үз күзләрем белән күрдем — уен дип, акчалары уен түгел бит, мондый гамәлгә җинелер урыны калмаган, чарасыз кешеләр генә бара, ләкин Волгинның йөзендә бер генә күзәнәк тә тартылмады. Бәлки, ул бар кешенең берьюлы җинелүен күрергә теләгәндер? «Зеро» туры килсә, ставкалар тулаем аңа күчәр иде бит. Әмма, күрәсең, язмышына башкача язылгандыр — бер генә тапкыр да «зеро» төшмәде (монысыннан да гаҗәп кызыклы картина килеп чыгар иде, исемен уйлап та торасы юк — «Зеро», бетте-китте — вәссәлам!). Чынлыкта килеп чыкмаган бу вакыйганы үз әсәремә һичшиксез кертәчәкмен дип башыма салып куйдым.

Грузин яшьләре бүтән уенга килмәделәр, ә озакламый, Мәскәү күрергә дип, гомумән, Малеевкадан китеп тә бардылар. Яңа әсәрем башланмаган килеш тәмамланырга дучар булды...

Өченче көнгә безнең сафлар кинәт кенә тулаем үзгәрде. Гофман МДУның бер студент кызына күз төшереп, гыйшык-мыйшык дөньясына чумды, аның өчен рулетканың кызыгы калмаган иде инде, башка күренмәде ул. Яшь Проскурин да ике көнгә башкалага китеп олакты — шулай ук, мәгъшукасының туган көне икән, югалып торачагы турында алдагы төнге уеннан соң кисәтеп куйган иде. Аның дусты да гаип булды. Грузиннар да. Композиторлар һәм Кино йортларыннан килгән кунакларның да эзе суынды...

Мин дә икеләнеп калдым: барыйммы, юкмы? Төн уртасына таба Азатлык радиосында яңа Борис Парамонов сөйләргә тиеш иде, өстәвенә, болай да тапшыруның алдагысын, рәссам Хаим Сутинга багышланганын, кичә тыңламый калдым — аның өчен кайгыруларымның чиге-кырые булмады. Шикләремне Игорьга белдердем, ул канәгатьсез рәвештә баш кына селкеде: «Компанияне җимерергә ярамый. Хәтта Парамонов өчен дә... Матур түгел. Алай бик теләгәч, Проскурин кебек кичә әйтеп китәргә кирәк иде. Голованов үпкәләргә мөмкин, — диде ул, аннары, кинәт кенә тавышын үзгәртеп: — Бүгенге тапшыру кем турында?» — дип кызыксынды. Мин җавап биргәч, ул елмайды гына: «Алайса, борчылма, үзем сөйләрмен».

Белмим — язучы халкы уен турында каян белеп бетергәндер, әмма ул кичне халык шактый — бер егерме кеше җыелган иде. Барысы да безнең Иҗат йортында яшәүчеләр. Урын тарайды, шулай да, сыештык тагын үзе. Яңа составка Игорь һич кенә дә борчылмады, киресенчә, күзендәге ут тагын да ныграк балкыды, мөгаен, хәзер аны уенның үзеннән бигрәк уенчыларның «урыс холкы» ныграк кызыксындыргандыр. Себердән Валентин Распутинның биш якташы килгән иде, Алтайдан янә икәү — исктимәле комарлы (азартлы) кешеләр! — холык-фигыльләре белән алар миңа кичәге грузиннарны хәтерләтте.

Ләкин ул кичәдә миңа иң гаҗәп тоелганы шул булды: «почвенник», «деревенщик», ягъни, гади итеп әйтсәк — хезмәт кешеләре, авыл һәм шәһәр эшчеләре, мартен һәм элеватор җырчыларына караган җиде язучының ник берсе ни шаярып, ни җитди рәвештә «господа»га игътибар итсен. Әллә алар да үзләрен чын аксөякләргә санадымы икән? Кеше күнеле — кара урман, дип белми әйтмиләрдер шул. Игорь белән гәпләшеп

алырга иде... Кинәт минем башымнан яшен тизлеге белән үзгә уй үтте: бу турыда Григорий Яковлевич Бакланов яисә Лев Адольфович Озеровтан сорасаң яхшырак лабаса! Бүген Ярослав Кириллович «господа»ны аеруча күп куллана кебек тоелды миңа, ул тегеләрне турыдан-туры «кытыкларга», «чеметергә» тели иде сыман — ләкин яңа кунакларның кылы да селкенмәде, алар баштанаяк уенга кереп киткән иде инде. Уйнауларына килгәндә — бәрәңге утырталармыни: тирән казыйлар, яхшылап күмәләр, безнең казинога хас шаяру, елмаеп-көлеп алуның эзе дә юк — яшь Проскуринның дәрт-дәрманы һай житми иде хәзер! Кызык бит: рухы әтисенең ижатына якын әфәнделәр белән әйткәләшер-тарттергәләр идеме икән ул?

Әлбәттә, Волгин да бик авыр хәлдә иде, әмма аның йөзенә караудан гына бернәрсә дә белеп булмый, ул, инглиз лорды сыман, һич борчусыз тоела иде, үзенчә уйный, кешеләрнең ничек уйнавы ана мөһим түгел, ул, шагыйрь һәм тирән тамырлы Мәскәү кешесе буларак (кем белә, бәлки, дворяннардыр да әле), географиясе һәм, дөресен генә әйткәндә, мәдәнияте белән дә үзенә бигүк якын булмаган кешеләрнең табигатен, тотышын өйрәнә иде шикелле.

Уен, бер карасаң, һәрвакыттагыча бара иде кебек, монда да хисләр ташый торды — әмма ул хисләр, әллә ничек, гадәти һәм беркатлы иде: жиндең — жиңелдең. Уенның тарту көче, магниты югалды, күз ачып йомганда чынбарлыкны үзгәртеп ташларлык ут чаткысы житми иде. Уен затсызланды... Крупьега хас әтәчләнү югалды, аның авызыннан афоризмнар, канатлы гыйбарәләр, кеше табигате турындагы фәлсәфи фикерләр ишетелми башлады, гәрчә нәкъ менә хәзер — эчпошыргыч чакта! — кирәк тә иде алар. Голованов бер-бер артлы жинә торса да, бу ана әллә ни ләззәт китермәде, бүген, гомумән, куелган акчалар өстәлнең бер башыннан икенчегә күчеп йөрмәде, нигездә ул крупье алдына жыелды. Ара-тирә мин дә откаладым.

Аптыраш — беркем дә яшь Проскурин кебек, ни кызыгып, ни көнләшеп, ни сокланып: «Фарт килә сезгә бүген, Ярослав Кириллович!» — димәде, бу жөмлә бугазыма төердәй утырып, тышка чыгарга алгысынса да, мин, кыенсынып, аны тыныч кына йотып жибәрдем. Үземне шунда ук күңелсезлек басты: ә бит хәзер рәхәтләнеп Борис Парамоновның сәгать ярымлык тапшыруын тыңлап ята ала идем; уенга да, компаниягә карата да һичнинди кызыксынуым калмады, миңе биредә үзенең «жөп һәм жөп түгел» табышмагы белән Игорь гына тотты.

Мин ул көнне тәмам кәефсезләнеп кайтыр идем, мөгаен, әмма күпме вакыт жанымны бимазалап торган бу табышмакның очына чыга башладым кебек — ничек моңарчы башыма килмәгән диген, мин Волгинны күптәннән беләм бит югыйсә! Игорь беркайчан да башкаларның гонорарына, премияләренә кызыкмады, алар турында беркайчан да сүз кузгатмады, мин аның хәтта бурычка ничәдер сум алганын да хәтерләмим — ул акчага карата гомумән битараф иде. Менә-менә: акча белән Волгинны берьюлы телгә алганда иң туры килә торган сүз бу — битарафлык. Үз-үзем өчен шундый нәтижә ясаганнан соң, табышмакның жавабын да таптым бугай мин: мондый акча — комарлы уенда табылган акча — жанын рәнжеткәндер, кулын пешергәндер, ана бернинди отыш кирәкми — зурысы да, кечесе дә, бу хәл аның табигатенә каршы килә! Менә ни өчен ул фишкаларын беркайчан да отмаслык итеп куя! «Жөп һәм жөп түгел», «кызыл һәм кара»... Шундый мантыйкый ачышымнан соң мин хәтта жиңел сулап куйдым, тагын бер кат дикъкать белән, ихтирам итеп, Волгинга күз ташладым.

Инде тәмам тынычладым кебек, әмма хушлашыр алдыннан гына йөрәгемне тагын бер табышмак — тегесеннән дә куркынычрагы! — өтеп алды: алайса, ни өчен шулай кызыксынып йөри соң ул монда? Рухи таләпләренә, культурасына туры килми торган кешеләр янында ни калган ана? Бу сорау миңе тагын да ныграк пошаманга салды.

**Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

Илнең язмышы бик хәвефле булган 1941 елда ук, язучыларыбызның күбесе, Ватанны, Туган илне фашист-кабахәтләрдән сакларга Кызыл Армия сафларына басты, кулына корал алды, сугышның бөтен авырлыгын һәм газапларын үз җилкәсендә күтәрде, бөтен сынауларын баштан кичерде, атакаларга барды, суларны, утларны кичте, илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге өчен канын, җанын аямады.

Ул көннәрдә фронттагы язучыларыбызга һәм журналистларыбызга бик зур бурычлар йөкләнгән иде. Беренчедән, алар дошманга каршы батырларча сугышырга, икенчедән, язарга, иҗат итәргә, ялкынлы сүз белән сугышчыларны рухландырырга, ут астында да, бомбалар шартлаганда да, Муса Җәлилнең образлы сүзләре белән әйткәндә, «палач балтасы астында да» язарга тиеш иде. Алар бу бурычларны намус белән үтәде.

1942 елның июленнән татар телендә фронт газеталары чыга башлый. Татар язучылары, журналистлары шул газеталарда хәрби корреспондент яки корреспондент-оештыручы, иң кимендә корректор буларак хезмәт итә.

Хәрби корреспондентлар барлык фронт газеталарының төп фигуралары була. Менә шулар инде оборона вакытында да, һөҗүм вакытында да, һәр көнне батыр сугышчылар сафында фашистлар өстенә атакага бара, хәрби операцияләрдә катнаша, дошман уты астында окоптан-окопка йөреп, батырларны күреп, алар белән таныша, сөйләшә һәм яза. Хәрби корреспондентлар солдатлар белән бергә фронт тормышының бөтен авырлыкларын кичерә, сугышчыларның тиңдәшсез батырлыклары турында сөйли, иҗади осталыгын бертуктаусыз камилләштерә, басма сүзнең тәэсир итү көчен арттыра.

Хәрби корреспондентлар командировкага бер айга, кимендә ике атнага бара. Менә шулар инде Бөек Ватан сугышының тарихи елъязмасын яза. Аларның сугышчан язмаларын да, хәбәрләрен дә, репортажларын да, мәкаләләрен дә, очеркларын да бөртекләп җыеп, матбугатта чыгарып, халкыбызга җиткерәсе иде.

Сугышның кайнар көннәрендә хәрби корреспондент сугышчы да, кирәк булса, командир да булып китә. Тиз генә каләмен куеп, кулына пистолет яисә автомат ала, дошман траншеясына бәреп керә, үлем белән күзгә-күз очраша, ә сугыш тынгач, буш вакыт табып, газетага хәбәрләр, мәкаләләр, очерклар, ялкынлы шигырьләр яза, батыр сугышчыларның исемнәрен мәңгеләштерә.

Хәрби корреспондентның сугышчан әсәрләре еш кына ут эчендә, һич югы окоп шартларында, землянкадагы сукыр лампа яктысында языла. Ул фронт хәлләрен сугышчыларга җиткереп тора, сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән солдатның рухи дөньясын ачып сала. Бу язмалар сугышчыларны канатландыра, рухын күтәрә һәм аларны яңа батырлыкларга чакыра.

Шул елларда ут эчендә йөрүче татар язучылары сугыш тынган арада вакыт табып, бер-берсе белән даими рәвештә хат алышып торган. Бу хатлар дошманны җиңүгә зур ышаныч, шундый авыр көннәрдә дә татар әдәбиятының, каләмдәшләренең язмышын кайгырту үзара иҗади дуслык хисе белән сугарылган.

Язучылар алгы сызыкта булганда, гади солдатлар кебек, окоп стеналарына сөялгән хәлдә кәгазьне йә көрәккә, йә итек кунычына, йә котелок төбенә куеп хат яза. Алар әнисен дә, туганнарын да, бала-чагаларын да, җанкисәген дә сагына. Ак каен агачының яз ачылган тәүге яшел яфракларын да сагына... Бу хисне җаны-тәне белән басарга тырыша. Йөрәкләрне сагыну хисләре тырнап тормаганда, ут астына керү дә, ялкын эчендә йөрү дә ансатрак.

Язучы Афзал Шамовның шәхси архивында Бөек Ватан сугышы чорына караган бихисап документаль материал саклана: унбиш фронт дәфтәре, 1943-1945 елларда Калинин һәм Беренче Балтыйк буе фронтларында язучы үзе очраткан һәм алар

турында газетага язган сугышчыларның исемлеге (биш йөздән артык исем!), дистәләрчә фронт газеталары, фронтта төшерелгән рәсемнәр, сугышчан листовкалар, солдат хатлары. Алар арасында фронттагы каләмдәш дусларыннан килгәннәре дә, әтиемнең фронттан өйгә язганнары да бар. Алар әбиемә, әниемә, дүрт баласына, туганнарына язылган. 161 хат! Төрле-төрле кәгазьләргә язылган алар. Барысы да әтинеке, аның уйлары, фикерләре, хыяллары...

Татар язучылары башта хатны рус телендә язган. Цензура аркасында рус телендәге хатлар тизрәк – атна-ун көн, татар телендәгеләр – бер ай чамасы, гарәп графикасындагылар өч айлап барган.

Өчпочмаклы хатлар... Фронт хатлары... Алар гадәттә гади графит яки химик карандаш белән язылган, кайберләре, еллар үтү белән, саргая башлаган, танымаслык хәлгә килгән. Бик күп хатлар вак, хәтта чамадан тыш вак хәрефләр белән төрле кәгазьләргә (папирос, әйбер төрә торган кәгазьләргә) язылган. Мондый хатлар хәзер төрле архивларда, музейларда һәм аерым кешеләр кулында изге һәм мөкатдәс ядкарь булып саклана.

Бу хатларны табу, уку теләге мине Татарстан Республикасы Милли архивына алып килде. Анда Язучылар Союзы фондында казынып, мин башта әтиемнең хатларын гына укыдым. Эзләнүләр барышында, әтинең каләмдәшләре язган хатларга да юлыктым. Максатым – аларны җыеп-барлап, китап итеп бастырып чыгару.

Соңгы елларда Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендәге Россия Федерациясе Саклану министрлыгының Үзәк архивындагы бүләкләү кәгазьләрен дә уку бәхетенә ирештем, татар фронтовик-язучылары турында күп кенә яңа, кызыклы һәм кадерле мәгълүматлар таптым. Аларны белү һәркемгә кирәк, чөнки Бөек Ватан сугышы чоры – ул инде чал чәчле ТАРИХ.

Язучыларның фронт хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре белән элек тә кызыксынучылар, билгеле, булгандыр, ләкин, кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр алар китап итеп дөньяга чыгарылмаган. Аларны ике, хәтта өч том итеп бастырып чыгарасы иде, яшьләр укысын, данлы бабаларының, туганнарының батырлыклары белән горурлансын, гыйбрәт алсын иде.

Хат авторлары арасында – сугыштан кайтмаган, изге җиребез өчен гомерен биргән күренекле шәхесләр: Моабит төрмәсенең салкын камераларында, кулына богау кидерелгәч тә, фашизмга каршы көрәшүен дәвам иттергән герой-шагыйрь Муса Җәлил, Көнчыгыш Пруссиядә Кёнигсберг шәһәре янында барган каты сугышларның берсендә батырларча һәлак булган шагыйрь Фатих Кәрим, Австрияне азат итү өчен барган соңгы сугышларның берсендә, ерак Альп таулары итәгендә мәңгелеккә ятып калган күренекле шагыйрь Нур Баян, Польшадагы Згеш шәһәренең хәрби госпиталендә вафат булган Гадел Кутуй, әле яңа гына яза башлаган, әдәбиятта беренче адымнарын атлаган яшь шагыйрьләр Мифтах Вәдүт, Касыйм Вахитов һәм Исхак Закиров, прозаик һәм тәрҗемәче Кәшфи Басыйров хатлары да бар. Ил өчен, халык бәхете өчен җаннарын аямаган, каннарын кызганмаган батырлар алар.

Сугыштан исән-сау туган иленә әйләнеп кайткан язучылардан Афзал Шамов, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Гази, Госман Бакиров, Мәхмүд Максуд, Сибгат Хәким, Шәрәф Мөдәррис, Шәйхи Маннур, Гариф Галиев һ.б. хатлары да бар.

Тылда эшләгән язучылар да Казаннан фронтка каләмдәш иптәшләренә хатлар җибәреп торганнар, алар белән элемтәдә булганнар. Болар – Гомәр Бәширов, Гази Кашшаф, Фатих Хөсни, Хәмит Ярми, Әхмәт Ерикәй һ.б. Яхшы кәгазьгә кара белән язылган бу хатлар, кызганычка каршы, бик аз.

Хатларның күбесе ут эчендә язылган булса да, аларда зар, әрнү, сыкрану әсәре юк. Аларда дошманны тар-мар итү, җиңеп кайту турындагы ялкынлы теләкләр белән бергә киләчәк матур тормыш турындагы уйлар, хыяллар гына бар. Алардан әле дә дары исе, окоп исе килә. Аларда – батырлык хисе.

**Әлфия ШАМОВА**

## Кәшфи Басыйров хаты
*(1906–1943)*

Хикәяләр авторы һәм тәржемәче Кәшфи Басыйров (Кашшаф Хәбир улы Басыйров) 1906 елның 17 апрелендә Башкортостан Республикасының хәзерге Бәләбәй районы Мәтәүбаш авылында туган. 1917-1921 елларда Бәләбәй шәһәрендәге алтыеллык рус-татар мәктәбендә, 1922-1927 елларда Бәләбәй педагогия техникумында укый. Шунда сабакташлары Гази Кашшаф, Фатих Кәрим белән бергә әдәби түгәрәк каршында кулъязма журнал чыгара. Шул елларда авыл һәм укучылар тормышы турында кыска хикәяләр яза. Аның бу хикәяләре әдәби яктан эшләнеп житмәгән булсалар да, шул заман күренешләрен, социаль вакыйгаларны бирү ягыннан шактый әһәмиятле.

Техникумны тәмамлаганнан соң, К.Басыйров алты ел чамасы Дүртөйле (Башкортстан), Кукмара (Татарстан) авылларында һәм Казанда балалар укыта. 1934 елны Казанга килә һәм 1942 елга кадәр Татгосиздатның (хәзер Татарстан китап нәшрияты) матур әдәбият бүлегендә корректор, техник редактор һәм тәржемәче булып эшли.

1927 елда «Безнең юл» журналында К.Басыйровның «Минем сөюем» исемле хикәясе басылып чыга һәм укучылар тарафыннан уңай бәя ала. Язучы үзенең хикәяләрен «Совет әдәбияты», «Азат хатын», «Чаян» журналларында бастыра. Күпчелек әсәрләре лирик җылылык белән сугарылган, аларда янага, югарыга омтылучы совет авылы кешеләре оста сурәтләнә.

К.Басыйровның тәржемә өлкәсендәге эшчәнлеге аеруча мактауга лаек. Кыска гына вакыт эчендә ул татар теленә шактый күп әсәрләр тәржемә итә. Алар арасында Ю.Лебединскийның «Неделя» («Бер атна», 1936), немец язучысы В.Бредельнең «Сыналу» (Г.Хәбиб белән уртак тәржемә, 1936), М.Лермонтовның «Герой нашего времени» («Безнең заман герое», беренче басмасы 1937 елда) романнары, В.Катаевның «Я – сын трудового народа» («Мин — хезмәт халкы улы», 1938), К.Паустовскийның «Колхида» (1938) повестьлары һәм Н.Гогольнең мәшһүр «Мёртвые души» («Үле жаннар», беренче басмасы 1947 елда чыга) роман-поэмасы бар.

К.Басыйров зур күләмле әсәр язу өстендә эшли иде. Ләкин Бөек Ватан сугышы аның хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде.

1942 елның 13 гыйнварында Кәшфи Басыйров Бауман район хәрби комиссариатыннан армиягә алына һәм фронтка озатыла. 128 нче укчылар полкының 44 нче гвардияче дивизиясендә сугыша. 1943 елның 16 гыйнварында батырларча һәлак була. Ростов өлкәсендәге Червоный шахтёр янында, Төньяк Донец елгасы ярында жирләнә.

Менә Кәшфи Басыйровның хаты. Бу хат конверт эчендә җибәрелгән. Конвертта химик карандаш белән: «г. Казань. Дом Печати, Татгосиздат. Шамову[1], Газееву И.[2], Алееву[3], Бурнашеву В.[4], конвертның икенче ягында эти кулы белән: «Җавап 24/XI-42 язылды.» дип язылган Конверттагы штамп буенча хат Казанга 20 ноябрьдә килеп житкән. Ул гади карандаш белән тәмәке кәгазенә бик вак хәрефләр белән Татгосиздатның матур әдәбият бүлегендә эшли торган Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Жиһанша Алиев һәм Вафа Бурнашларга юлланган.

Әтинең архивында 1939 елның ахырында төшкән, беркайда да басылмаган шундый фоторәсемне дә эзләп таптым: анда шагыйрь Касыйм Вахит[5], прозаик Кәшфи Басыйров, шагыйрә Зәкия Садыйкова, язучы Афзал Шамов һәм Фәтхулла Киллиев[6] Татгосиздатның 84нче бүлмәдә сурәткә алынган. Фотога төшерүче — Ибраһим Гази.

Хатыгызны алдым.

Мин сезгә өч көн буе кузгалмый яза алган булыр идем. Хатыгыз шулай кузгатты, дулкынландырды. Ләкин нәкъ бу көннәрдә алай озаклап язарга мөмкинлек юк.

Сез язасыз: тегеләй йөрүләрең күз алдында, шундый сыйфатларын күз алдында дисез. Үзем турында мин сезгә күбрәк әйтим: мин бит бик тә мескен, зәгыйфь һәм күп кимчелекле бәндә. Кимчелекләремне белгән саен, күбрәк изелеп җәфаланам. Бигрәк тә тән зәгыйфьлеге, көчсезлек харап итә. Ишеткәнсез, армиягә алынуның беренче аенда ук авырдым. Шуннан соңгы вакытларда да һәрбер форсатны тәнне ял иттерергә бирергә туры килде. Юкса язарга вакыт булмады түгел, булды. Безгә физкультура турында 20 ел тукып килделәр, физкультура белән шөгыльләнми торган кешене, теге шагыйрь әйтмешли, барлык шайтаннар янына җибәрер идем мин. Шулай да көннән-көн ныгый бардым. Хәзер, әгәр хисапласаң, минем гимнастёрка инсәсендә кимендә бер мең данә сагызлы яки күмерле бүрәнәнең эзе булыр, беләкләр шулай ук шуннан ким санда окоп казымаганнардыр. Сезгә хат язмауның тагын бер сәбәбе: мин сезне китеп беткәнсез дип уйлаган идем.



*Касыйм Вахитов (сулдан уңга), Кәшфи Басыйров, Афзал Шамов, Фәтхулла Килдиев. Артта басып торган — Зәкия Садыйкова.*

«Кайларда булдың? Ниләр күрдең?» — дисезме. Июнь аеннан алып алдынгы линиядә булдым. Ләкин баштагы ике ай гел диярлек оборонадан гыйбарәт булды. Аның каравы, соңгы ике ай ярым һөҗүмнән торды. Менә ул исә кызыклы дисәң дә кызыклы. Кызыклы дигәннән, сугыш, әгәр үзеннән инициатива куймасаң, кушканны гына үтәп йөрсәң, авыр йөк кенә булып тоела. Ә бирелеп, кызыгып сугышу өчен хәзерлек, белем һәм хәрби сәләт кирәк. Бик яхшы итеп менә шуны белдем. «Ничек сугыштың?» — дисәгез, мактана алмыйм. Мин фәлән сугышта, фәләнчә чор эчендә шунча санда дошман солдатын кырдым, дип әйтә алсам икән. Мылтыктан да, гранатадан да төбәп-төбәп һәм аягүрә торып аткаладым-атуын. Әйтергә кирәк, дошман бик усал һәм хәйләкәр. Ләкин без дә бөтенләй сантыйлар түгел. Без бит үзебезнең участкада аны шактый кудык. Шуның нәтиҗәсендә безнең фронт хәзер Көнбатыш фронты белән тоташып, шул исемдә йөртелә.

Көнкүреш мәсьәләсе: алгы линия турында кайгыртучанлык гаять зур. Ашау-эчүне алсаң, анда хәзинәдә булган һәммә нәрсә — колбасадан алып тозлы кыяр, горчица, лавровый листка кадәр килеп җитә. Шунысы характерлы: иң алдынгы эшелонда да без обедны, кагыйдә буларак, икешәр блюдадан ашадык. Шул ук алгы линиядә мунча керү, бельё алмаштыруны оештыруны да әйтергә кирәк. Болар безгә, шиксез, нык тәэсир итә.

Тылның кайгыртучан тавышы турында. Беркөнне безгә: «Бойцам от Татарстана» дип язган сабын бирделәр. Шунда бер номер «Кр. Тат.»[7] газетасы да килде. Дошман самолётлары бомба төяргә киткән араларда, окоптан чыгып юынган саен, һич арттырмыйм, күңел күтәрелә, көч керә торган булды. Газетаны да кадерләп саклап йөрттем. Ә инде башка

язуларым белән бергә аны осколок очыргач, ачуым кабарып йөрде. Нәтиҗә чыгарыйм: сездәй язучыларның газеталарга катнашулары бик тә тәэсирле димәкче булам. Тик, үзегез дә әйткәнчә, аз селкенәсез бугай. Бу мәсьәләдә урыслар гаҗәеп матур эшли. Чатнап торган сугыш хәлләре турында гади, ачык, матур итеп язган күп санлы хикәяләрне күреп хәйран калам. Шәриф абый Камал[8] әйтмешли, без язмыйбыз, ә язарга уйлап кына йөрибез. Ягъни кәгазьгә төшерү кадәресе җитми. Мин үзем нәкъ шулай. Шундый әйбәт темаларым, наброскаларым булды, ә кәгазьгә төшерә алмадым.

Хәзергесе көндә мин ерак тылда. Такташ[9] дустыгыз туган губернада бугай без. Ялга чыктык. Язгалавыгызны үтенәм. Тагын бер үтенеч: миңа бераз кәгазь — гомуми дәфтәр җибәрегезче. Бандероль теләгән кадәр йөри. Юкса, дошман белән йөзгә-йөз очрашканда, язу һәм кәгазьләремнең бер өлешен үзем юкка чыгардым, бер өлешен, әйткәнемчә, осколок очырды. Шунда бергә папирос кәгазе дә салсагыз иде. Безгә тәмәкенең иң әгъласен биреләр (бирделәр), юка кәгазь дә булса, ул инде тәмәке түгел, ә конфет. Бу эшне Җиһанша белән Вафа эшли алсалар кирәк. Бик тә кирәк дип әйтмим, ә күңелле һәм кызык булсын дип кенә язам. Янәсе, посылка алдым дип йөрермен.

Басыйр дустыгызның эшләре, хәлләре, аннан-моннан әләктереп әйткәндә, әнә шулай. Шундый зур масштаблы, җаваплы, катгый, зур эшкә катнашып һәм исән-сау йөрүемә бик канәгатьмен, шатмын. Хатыгыз өчен тагын бер тапкыр рәхмәт.

Гвардеецларча сәлам белән К.Басыйров.
3.XI.1942.

Адрес тик менә болай гына:
11-я полевая почта, часть 423. Басыйрову К.

## Искәрмәләр

[1] Шамов — Афзал Шамов (1901-1990) — татар язучысы.

[2] Газеев И. — Ибраһим Гази (1907-1971) — татар язучысы.

[3] Алеев — Җиһанша Алиев — Таттосиздатның редакторы.

[4] Бурнашев В. — Вафа Бурнаш (1900-1974) — Таттосиздатның редакторы; күренекле драматург, шагыйрь, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче Фәтхи Бурнашның (1898-1942) бертуган энесе.

[5] Касыйм Вахит — Касыйм Вахитов (1916-1942), яшь татар шагыйре. 1942 елның 4 октябрендә Сталинград өлкәсендә барган каты сугышларның берсендә батырларча һәлак була.

[6] Фәтхулла Килдиев — Таттосиздатның редакторы.

[7] «Кр. Тат.» — «Красная Татария» газетасы.

[8] Шәриф абый —Шәриф Камал (1884-1942) — татар язучысы.

[9] Такташ — Һади Такташ (1901-1931) — татар шагыйре. Тамбов губернасында туган.

*Дәвамы киләсе санда*

# ИЗГЕ СӘФӘР ҖИҢЕЛ ГАМӘЛ ТҮГЕЛ

ХАҖНАМӘ

## Кереш

Тарихи чыганакларга караганда, 1698 елда татар әдәбиятында үзенчәлекле бер жанр – хаҗнамә барлыкка килә. 1917 елгы борылышка кадәр дә, аннан соң да, безнең көннәрдә дә бик күпләрнең әлеге изге җирләрдәге сәфәрдән алынган тәэсирләрен язу очраклары билгеле. Бу юлларның авторына да, якташыбыз Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети тудырган тәүге хаҗнамә дөнья күреп, нәкъ 315 ел үткәч, шушы теманы дәвам итәргә мөмкинлек туды. Тагын шунысын да ассызыкларга кирәк, миңа Исламда хөрмәт ителә торган изге урыннарга барып, хаҗ гамәлләрен кылып кайтканнан соң, шушы хакта матбугатка язма әзерләү, аны чыгачак китапларга кертү бурычы алдан ук йөкләнгән иде...

Сүзебезне «Кем соң ул беренче хаҗнамә язган Мортаза бине Котлыгыш-әс-Симети?» дигән сорауга җавап бирүдән башлыйк.

2012 елның 20 июлендә районыбызның Югары Симет һәм Түбән Симет авыллары арасындагы борынгы зират урынында Мортаза Гали бине Котлыгыш әс-Симети әл-Казани (тулысынча шулай язылa) җирләнгән урынга таш куелып, чардуган урнаштырылды. Дөрес, аның кабере хәзер төп-төгәл билгеле түгел. Әмма күренекле мәгърифәтче һәм дин әһеле үзенең васыяте буенча шушы зиратка җирләнә. Бу төбәктә туып, өч дистә гасыр элек үз халкының тормышына, рухи дөньясына искиткеч унай йогынты ясаган шәхесне өйрәнүгә гомер буе балаларга белем биргән педагог, хәзер Түбән Симет авылы имамы вазифасын алып баручы Шәймөхәммәт хәзрәт Җиһангиров (тумышы белән Түбән Симет авылыннан булган татар халкының яраткан язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең әнисе Бибирәбыйга белән Шәймөхәммәтнең анасы ягыннан бабасы бертуган икәнен дә искәртергә кирәк) зур тырышлык куйды. Аның сөйләвенчә, Мелла Мортаза бине Гали Котлыгыш әс-Симетинең нәсел чыгышы Тәтеш ягыннан була. 1552 елда, Казан яуланганнан соң, Мортазаның әтисе Гали Симет якларына күченеп утыра. Самара өлкәсендәге Гали авылына да шушы нәсел нигез салган дигән фараз бар. Мортаза башлангыч белемне атасыннан ала. Аннары Дагыстанның Дербент шәһәрендәге мәдрәсәдә укуын дәвам итеп, тора-бара үзе дә шунда мөгаллимлек итә. Аннары шул чорның мәгърифәт үзәге саналган Бохарага күчә. Мортаза хәзрәт биредән Мәккәгә барып, Хаҗ гамәлләрен үти. Бу хакта аның югарыда телгә алынган хаҗнамәсендә ачык тасвирлана. Автор турында тулы мәгълүмат та бирелгән, сәфәренең максаты, Хаҗ юлалары ачык сурәтләнгән. Мортаза хәзрәт изге җирләрдә нәкъ бер ел йөреп кайта. Кайткач, Югары Симет авылында таштан мәдрәсә салдырып (бу бина 1960 елда гына сүтелә), шәкертләр укыта, «хаҗи», «күрәзәче», «мөфти», «әфәнде», «хафиз» кебек исемнәр белән дә хөрмәтләнә ул. Әс-Симетинең «Казани» алдындагы «әл» кушымчасы аның Казанның күренекле муллалары – дин эшлеклеләре белән тыгыз элемтәсе турында сөйли. Мортаза Гали бине Котлыгыш әс-Симети әл-Казани 1727 елда бакыйлыкка күчә, мәңгелеккә борынгы Саба җирендә кала. Мәшһүр галим, мөгаллим гарәп телендә беренче татар әлифбасын – «Иман шарты»н төзүче буларак та тарихка керә.

Еллар, гасырлар узган саен хаҗнамәләр басылып тора. Мәсәлән, 1862 елда Казан университеты типографиясе чыгарган «Мөхәммәт Әмин сәяхәтнамәсе»ндә изге сәфәр киң тасвирлана. Тумышы белән Арча төбәгенең Яңа Кишет авылыннан булган Мөхәммәд-Әмин Гомәр улы 1783 елда түбәндәге катлаулы маршрут белән бара хаҗга: Казан – Әстерхан – Кизләр – Рей – Аксай – Анапа – Истанбул – Родос – Искәндәрия – Мәккә – Мәдинә – Димәшкъ (Дамаск) – Иерусалим.

Шушы типографиядә үк басылган икенче хезмәттә эшмәкәр Исмәгыйль Бикмөхәммәтовның сәүдәгәрләр төркеме составында 1751 елның 11 сентябрендә Оренбургтан Һиндстанга чыгып китүе һәм шуннан Мәккәгә Хаҗ кылуы бәян ителә. Изге җиргә баруның маршрутлары күптөрле булган. Бабаларыбыз ниятләрен тормышка ашыру өчен җәяү киткәннәр, акчалары беткәч, тукталыш ясап, берничә ай эшләгәннәр һәм юлларын дәвам иткәннәр. Аларның Хаҗга зур авырлыклар күреп баруы көчле иманлы булуларын күрсәтә, билгеле. Андый кешеләр, сирәк кенә булса да, хәзер дә очрап куя. Мәсәлән, 58 яшьлек Габделгазиз Рәҗәпов (милләте буенча таҗик) унбиш ел буе Хаҗга барырга хыяллана. Биш бала атасы, һөнәре буенча физкультура укытучысы туган җирендәге хезмәтен калдырып, Мәскәүгә, хәзергечә әйтсәк, гастарбайтер сыйфатында килеп, алты ай буе акча эшли. Шуның бер өлешен яшәп тору өчен гаиләсенә җибәрә, 1 мең долларын һәм дөнья картасын үзе белән алып, 2005 елда Мәскәүдән җәяүләп Согуд Гарәбстанының башкаласы Әр-Рияд шәһәренә кузгала. Безнең Казан аша да уза ул. Башта 3-4 сәгать кенә йоклап, көн-төн бара. Әмма бервакыт машина бәрдерә язгач, төн караңгылыгында баруын туктата. Габделгазиз Идел буе шәһәр-авылларын узганнан соң, Кавказны үтә. Тугыз айга сузылган сәяхәте вакытында бер генә мәртәбә транспорттан файдалана: Кара диңгезне Төркиягә паром белән кичә. Аның монарчы бөтенләй диңгез күргәне булмаган. Юлда бик күп проблемалар белән очраша ул. Визасыз дип Согуд Гарәбстанына кертмәскә дә тырышканнар. Әмма Мәскәүдән үк җәяү килүче Габделгазизгә Ходай Тәгалә үзе һәм яхшы кешеләр гел ярдәм итеп торганнар. Ниһаять, килеп җитә ул Әр-Риядка. Бик олы хөрмәт күрсәтелә Рәҗәповка. Башта Согуд Гарәбстанының баш мөфтие Габделгазиз әл-Шәйех, аннары принц Сәлмән, алардан соң король үзе кабул итә. «Мина акчалар, бүләкләр, хәтта үзләренең Сарайларыннан тору бүлмәләре тәкъдим иттеләр. Каршы килдем. Чөнки мин аның өчен шундый озын, авыр, куркыныч юл үтмәдем бит», – дип искә ала ул. Бәлки җәяүле сәфәре һәм тыйнаклыгы өчендер дә аны галиҗәнап король Габдулла ибн Габделгазиз Кәгъбәтулла эченә үк алып керә. Мондый бәхет зур дәүләтләрнең кайбер башлыкларына гына эләгә.

Рәҗәпов туган ягына икенче юлдан – Үзәк Азия илләре аша кайта, моңа сигез ай вакыт сарыф ителә. Аны Үзбәкстан белән Таҗикстан чигендә – Турсунзадә шәһәре янында якыннары каршы ала. Яндыра-көйдерә торган кояш астында тузанлы юлдан кулына озынча таякка таяныбрак атлаучы, гәүдәгә әллә ни озын булмаган мөхтәрәм затны ерактан күреп алалар. Аның аягында кроссовка, өстендә спорт костюмы, башында панамка, аркасында рюкзак була. Соңгысын Рәҗәпов үзе үткән илләрнең дәүләт флаглары белән бизәгән икән. Озак көтелгән тарихи очрашудан соң хаҗига машинага утырырга тәкъдим итәләр. Каршы килә ул, әлбәттә, газиз Күләбенә кадәр тәпи-тәпи атлый...

Ярар, таҗик Рәҗәпов 17 айдан соң исән-сау әйләнеп кайткан. Шушы изге юлда мәңгелеккә калучылар да шактый булган. Хаҗ вакытындагы эпидемияләр байтак кешенең гомерен өзгән. Мәсәлән, 1891 елда килгән 46 мең халыкның 21 меңе вафат була. 1865 елда холера эпидемиясеннән 90 мең хаҗидан 20 меңе үлә. Ә инде 1893 елда холерадан бер ай дигәндә 14 мең мөселманның гомере өзелә. Тарихчылар раславынча, 1831–1912 елларда һәр өч ел саен холера эпидемиясе кабатланып торган.

Ул вакытта Россиядән Мәккәгә баручылар ишле булмый. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында – 1894 елда Хаҗга 3349 кеше китә, шуларның 75 проценты Урта Азия вәкилләре, 46 кеше генә татарлар була. Узган – 2013 елда Россиядән бу изге гамәлне – 16400, Татарстаннан –1200 мөселман кыла.

Әгәр дә совет чорына күз салсак, СССР 1926 елда Хиҗаз Корольлеге дигән дәүләтне, аннары аның дәвамчылары Нәҗед солтанатын һәм берләштерелгән биләмәләрне, 1932 елдан Согуд Гарәбстаны Корольлеге дип аталган (хәзер дә шулай) илне таный. 1932 елда Әмир Фәйсал ибн Габдел-Газиз СССРга визит белән килә һәм ел саен ун-унбиш мең мөселманны Хаҗ кылырга җибәрү турында сүз кузгата. Әмма бу тәкъдим хупланмый. 1945тән 1990 елга кадәр, ягъни кырык биш ел буена нибары 900 совет гражданы Хаҗ кыла. Узган гасырның туксанынчы елларыннан соң Хаҗга барырга теләүчеләргә зур мөмкинлекләр тудырыла. 1992 елда Казаннан турыдан-туры һава юллары ачыла. Бер елдан Татарстан Республикасының беренче Президенты

Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең шәхси ярдәме белән 170 хажи 26 майда Сочи шәһәре аша Согуд Гарәбстанының Җиддә шәһәренә тәүге тапкыр очалар. Әлеге төркемгә академиклар Мирза Мәхмүтов, Тәлгат Галиуллин, Россия Ислам университетының хәзерге ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, ул вакыттагы Татарстанның халык депутаты Дамир Сиражиев, Казан дәүләт университетының гарәп теле укытучысы Лена Тажиева, мөфти Габдулла хәзрәт Галиулла (әнисе Сажидә абыстай белән), Рәшидә абыстай Исхакова, Җәлил хәзрәт Фазлыев, журналист Фәния Хужахмәтова кебек халкыбызга билгеле шәхесләр керә. Рәшидә абыстай инде анарчы – 1991 елда Уфа Диния нәзарәте аша улы – булачак мөфти Госман хәзрәт һәм килене Гүзәлия абыстай белән Хажга бару бәхетенә ирешкән булганнар.


*Т.Нәҗмиев Рахмәт тавында.*

Тора-бара Илбашыбыз Минтимер Шәймиев, Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казанның ул вакыттагы мэры Камил Исхаков, башка җитәкчеләребез дә Хаж кылдылар. Бу урында Камил Шамил улының Җиддә шәһәрендә урнашкан Бөтендөнья Ислам лигасында Россия Федерациясе илчесе булып эшләп кайтканын да искәртү кирәктер.

2013 елның март аенда хәзерге Президентыбыз Рөстәм Миннеханов, Казан мэры Илсур Метшин, Татарстан сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе Шамил Агеев, республиканың Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Линар Якупов, «Ак барс» банкы идарәсе рәисе Роберт Миннегалиев, Президентның халыкара мәсьәләләр буенча ярдәмчесе Радик Гыйматдинов Согуд Гарәбстанына – Җиддә шәһәренә халыкара икътисадый форумга баргач, кече Хаж, ягъни гомрә йоласын үтәп кайттылар.

Татарстан вәкилләре Җиддәдә Ислам хезмәттәшлеге оешмасы уздырган халыкара икътисади форумда катнашып, унөченче мәртәбә оештырылган әлеге чарада Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы да чыгыш ясады. Форум кысаларында ул Мәккә провинциясе әмире Халид әл Фәйсал белән дә очрашты. Татарстан Президенты әлеге сәфәрне һәм Мәккәдә кече Хаж гыйбадәтен оештыруда ярдәме өчен әмиргә рәхмәт белдерде. Согуд Гарәбстанына нигез салган беренче патшаның оныгы һәм хәзерге патшаның улы Халид әл-Фәйсал шигырьләр дә яза икән. 2010 елда Түбән Новгородтагы «Мәдинә» нәшрияты аның «Хәреф һәм төс» исемле җыентыгын урыс телендә бастырып чыгарды. Аннары Татарстан китап нәшрияты бу китапны (шагыйрь Ркаил Зәйдулла тәрҗемәсендә) татар телендә нәшер итте. (Шунысын да искәртик, Халид әл Фәйсалның шигырьләре «Мәдәни җомга» гәзитендә дә дөнья күрә). Рөстәм Миннеханов җыентыкның беренче нөсхәсен авторга тапшырды һәм аны Казанга китапны тәкъдир итү тантанасына чакырды.

## Хаҗга әзерләнә башлау

Көче һәм сәламәтлеге җиткән һәр мөселманга гомерендә бер тапкыр Хаж гамәлен кылу кирәклеген, аның Ислам диненең төп шартлары булган биш фарызның (алар: Аллаһның берлегенә һәм Мөхәммәд галәйһиссаламнең Аның илчесе булуына ышану, намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү, Хаж кылу) берсе икәнен белә идем. Дин тыелган елларда да намазда булган Хәдичә әбием ( гүре нурлы булсын) хәтеремә сеңдергән догалар гел күңелемдә йөрде. Бала вакытта өйрәнгәннәр онытылмый, олыгайгач ятлаганы суга сәнәк белән язгандай була, диләр бит.

Җиденче сыйныфта укыган вакытта укытучылар коллективы куйган спектакльдә мулла ролен бирделәр. Шул образны сәхнәдә тудырганда, текстта булмаса да, иман догасын кычкырып укый башладым. Тамаша залында тынлык урнашты. Аны колхоз рәисе Рафаэль Камал улының өлкән яшьтәге әнисе Факиһә апа бозды. «Үләм, дөрес укый бит», – дип, бөтен клубны яңгыратып кычкырып җибәрде. Спектакль беткәч, Чиләбедән кайткан Шәрхемулла җизни беләгендәге сәгатен салып, халык алдында бүләк итте...

Гомумән, Хаҗга бару теләге кинәт кенә тумады, җай чыкты да китеп бардым булмады. 1997 елда, Казанда чыгып килә торган «Заман – Татарстан» газите мөхәррире Муаммәр бәй Мурад чакыруы буенча (үзләренен басмаларын Саба халкына яздыруда ярдәм иткән өчен) бер атна аларның шәхси кунагы булырга насыйп булган иде. Төркиянен данлыклы каласы Истанбулда дүрт мең мәчет барлыгын белдем. Менә шуларның манараларыннан шаулап торган, сөйләп бетергесез моңлы итеп әйтелгән азан тавышларын ишеткәч, үземдә ниндидер үзгәреш сиздем һәм кайткач, ураза тота башладым. Ул вакытта көннәр кыска иде. Бернинди дә авырлык сизмәдем. Соңгы өч елда Рамазан аенда укыла торган Тәравих намазларына да йөрергә тырыштым.

2006 елның 8 Март бәйрәме уңаеннан, халык күңеленә Ислам нигезләрен житкерүдә, авылдашларын иманга кайтаруда армый-талмый изгелек кылучы илаһи затларны – остабикәләрне Саба муниципаль район башлыгы Рәис Миңнеханов Байлар Сабасының «күзендәге» «Чулпан» кафесында – мул ризыклы табын янында кабул итте. Абыстайлар белән әңгәмә вакытында Хаҗ турындагы сөйләшү дә булды. Шуннан соң ул мина: «Сине шунда җибәреп, шул изге сәфәр турында язмаларыңны район халкына житкерәсе иде, – дип куйды. Еллар уза торды. Ул вакытта әле мин, дөресен әйткәндә, мәчеткә йөрми идем. Анысына да сәбәп көтмәгәндә килеп чыкты. 2009 елның маенда, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының район оешмасы житәкчесе буларак, 13 июньдә үтәчәк «Изге Болгар жыены»на хакимият һәм мөхтәсибәт белән берлектә, делегация туплап алып килү турында телефонограмма алдым. 30-40 кешене барлап жыйнау бик жиңел булмады, билгеле. Чөнки бу көнне авылларда милли бәйрәмебез – Сабантуйлар үтә иде. Шулай да бер зур автобус кеше бардык Шәһри Болгарга һәм Ислам дине кабул ителгән жирдә тәүге тапкыр намаз укучылар сафына бастым, шушы сәяхәттән чирканчык алып, икенче жомгага мәчеткә бардым. Дистәгә якын намаз догаларын әкренләп өйрәнеп бетердем, кайберләрен ике-өч ай ятладым, әби өйрәткәннәрне генә истә тиз калды. «Мәчеткә йөри башласам, намазга бассам, мине белгәннәр ни әйтер икән»,– дигән киртәне узу жиңел түгел икән. Андыйларга шикләнеп, яратмыйчарак карыйлар бит. Имеш, алар элек тегеләй-болай иткән: партиядә торган (бу урында КПССның дәрәжәле вакытында райком бюросы әгъзасы итеп ике чакырылыш сайланганымны әйтү дә кирәктер), «ужымга» йөргән, эчкән, ире өстеннән «гуляйть» иткән, «жилдән» бала тапкан... Әгәр дә инде алай фикерләсәң, хәзер мәчеткә, күренекле татар халык язучысы Мөхәммәт абый Мәһдиев әйтмешли, «почти» беркем дә йөрмәскә тиеш булып чыга түгелме соң?

Ярар, читкәрәк китеп кителде, ахры. Хаҗга бару теләге тууга тагын бер сәяхәт сәбәпче булды. 2010 елда ике гаилә Мисырның Шарм-әл-Шәйх шәһәрендә ял иттек. Шуннан Израиль дәүләтенең борынгы каласы булган Иерусалимга бер тәүлеклек экскурсия оештырдылар. Менә шул кыска гына сәяхәт вакытында Үле диңгездә коену, өч дин – Ислам, христиан һәм иудаизм диннәре барлыкка килгән борынгы Иерусалимда, иң мөһиме, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәлам күккә ашкан Әл-Әкъса мәчетендә булу бәхетенә ирештек. Әл-Әкъса мәчетенең ярымшар формасындагы алтынсу гөмбәзе әллә кайдан балкып тора икән. Кеше башына егермешәр доллар түләп, махсус яллаган гарәп гидыбыз шушы изге бина янына алып килде. Әмма әле ана жайлы гына кереп китә алмавыбыз ачыкланды. Каршыбызда автомат тоткан Израиль солдаты постта тора. Синең чын мөселман икәненне ачыклау өчен берәр сүрә укырга кирәклеген аңлата. Коръәни-Кәрим башындагы «Фатиха» сүрәсен кычкырып укыйсы булды. Сәфәрдәшләрем: «Ләәә иләһә илләАллаһу Мөхәммәдүр расүлуллаһи»,– дип хуплап тордылар. Шуннан соң гына безгә юл ачылды. Башта яһүд солдаты Әл-Әкъса мәчетен саклый дип уйлаган идек. Соңыннан аның изге Иерусалим жиренен иминлеген мөселманнардан саклавын, ягъни террорлык булдырмау өчен торганын белдек.

Шулай итеп, Мигъраж вакыйгасы белән бәйле булган Аллаһ йортына аяк бастык. Һич уйламаганда бу хажнамә авторына Әл-Әкъса мәчетендә ике рәкәгать фарыз намазы укырга да насыйп булды.

## Күңел тартылу

Иерусалимдагы Әл-Әкъсада булып, Шарм-әл-Шәйехка кайткач, ничектер, күңелнен олы Хажга тартыла башлавын тойдым һәм Кызыл дингезнең Мисыр өлешендәге ярына бастым да, каршы якта урнашкан Согуд Гарәбстаны Корольлеге биләмәләрен карый-карый, Аллаһ Тәгаләдән Мәккә шәһәрендәге Кәгъбәтулланы һәм Мәдинәдәге Мөхәммәд пәйгамбәребез (с.г.в) мәчетен дә күрү һәм аларда гыйбадәт кылу мөмкинлеге тудыруын кат-кат самими ихласлык белән сорадым.

Әллә кайчан түгел, безнен әби-бабайлар, әти-әниләр яшәгән узган гасырда гына да Хажга бару еракта гы якты хыял булып, андый бәхет бик-бик сирәк кешеләргә генә эләгүен белсәм дә, ниятемнең тормышка ашачагына өметем юк түгел иде...

Шулай да вакыт уза торды. Дүртәр фасыллы өч елнын үткәне дә сизелмәде. Ә менә 2013нең ямьле май аенда могҗизалы хәл булды. Башкалабыздагы Тукай урамынын 3нче йортында урнашкан «ДУМ РТ Хажд» ширкәтенә чакырылдым. Шунда изге сәфәргә бару өчен 147нче санлы Килешү төзелде һәм шул мизгелдән үк хәстәрлек эшләре башланды. Иң беренче итеп, дифтериягә, менингитка һәм гриппка каршы прививкалар ясалды. Булачак хаҗиләргә куела торган таләпләр арасында «чит ил паспортында Израиль визасы булмау» дигән пункт та бар икән. Паспортымнын мөддәте (срогы) 2015 елда гына бетсә дә, теге вакытта – Иерусалимга чыкканда (15 сәгатькә генә булса да) яһүд тамгасы сугылган икән. Ашыгыч рәвештә төп документны алмаштырырга туры килде. Сәламәтлек турында участок табибыннан белешмә дә таләп иттеләр. «Белмим шул, аптыраган. Сезнен йөрәк чыдар микән андагы эссегә», – дип, участок табибәсе Роза ханым Нурмиева да икеләнеп торды. Матбугатта әледән-әле: «Согуд Гарәбстанында йөрәк чире белән бәйле куркыныч авыру – короновирус чыккан, алтмыш биш кеше үлгән, быел Хажга барудан тоткарланып тору сорала» дигән хәбәрләр канга тоз салды. Күпмедер вакыттан соң олы биштәр һәм һәрвакыт үзең белән йөртә торган намазлык беркетелгән кечкенә сумка, кулланма әдәбият –«Гыйбадәте исламия» (авторы Әхмәдһади Максуди), «Хаж һәм гомрә догалары», «Хаж һәм гомрә Мәккә–Мәдинә буенча юл күрсәткече» авторы (Вәлиулла Якупов), «Татарча-урысча-гарәпчә сүзлек», «Медицина белешмәсе» кебек ярдәмлекләр бирелде.

Сумкаларны алып кайтып, ышанычлы һәм чиста урынга яшереп куйдым да, дога җыентыкларын укырга тотындым. Җәмәгатемә әйтми тордым. Беренчедән, минем әле якын арада республика клиник хастаханәсенен (РКБ) бөерләр күчереп утырту бүлегенә кереп тикшеренеп чыгасым, аннары хәләлем белән бергәләп Сочига ялга барасыбыз бар иде. Икенчедән, Әл-Әкъса мәчетендә булганнан соң, Хаж кылу теләге барлыгын әйткәч, Лемара: «Юк-юк, бармыйсың, шушында булганы житеп торыр, синең инфарктлы йөрәгең андагы эсселекне, юл газабын күтәрә алмый! – дип кырт кискән иде. Пенсиядәге шәфкать туташына ул вакытта каршы килеп маташмадым. Ерак сәфәргә бер атна калгач кына чиштем ул серне. Башта ышанмый торды, сумкаларны алып кереп күрсәткәч, хәерле юл теләргә мәжбүр булды һәм «Медицина белешмәсе»ндә куелган таләпләр нигезендә дарулар, башка юл кирәкләрен бик тиз арада жиренә житкереп хәстәрләде.

Менә дүрт ай буе, Тукай әйтмешли, «хәсрәт эчендә, уйда мин» халәтендә үз күзем белән күрәчәк Хаж тормышы турында уйланып һәм борчылып йөрдем. Борчылмаслык та түгел бит. Ике арада төзелгән Килешүдәге түбәндәге пункт гел күз алдында торды:

Б).Наступление смерти: В случае моей смерти в период совершения Хаджа на территории Королевства прошу репатриировать (похоронить меня в той стране, где я буду находиться (нужное подчеркнуть).

Подпись хаджия:

Уйланып тордым да, репатриировать (туган илгә кайтару) дигәннен астына сыздым. Бик сәерсенеп карады белгеч кыз. Кем әйтмешли, күпләребез җәннәткә саваплы

жирдә керергә теләсә дә, берәүнең дә вакытсыз үләсе килми бит әле. Кендек каның тамган жирдә балаларын, оныкларын, гомумән, якыннарын зиярәт кылырга кабереӊ дә булмаса... Алла сакласын!

Әйдәгез, үлем турындагы фикерләрне туктатып торыйк. «Кем дә кем гайбәт сөйләшмичә һәм гөнаһ эшләмичә, Аллаһ ризалыгы өчен Хаж кылса, яна туган сабый кебек, гөнаһсыз хәлдә өенә кайтачак» ди бит күренекле дин галиме әл-Бохари.

## Казаннан очу

2 октябрь көнне өйлә намазы алдыннан Казан аэропортына жыйналдык. Универсиада алдыннан «Халыкара» дигән статус алган заманча терминалларны күргән булмаган икән әле. Алдан бирелгән программада Казан–Жиддә һава юлы буенча очу планлаштырылган иде. Сонрак Дубай аша барачагыбыз хәбәр ителде. Тагын бер ил – Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең үзенең курортлары, ял базалары һәм күккә ашкан биек йортлары белән дан тоткан каланы күрү комачау итмәс дип уйладык.

Аэропортта ук үзебезнең төркем әгъзалары белән таныша башладык. Нигездә Чаллы мөселманнары икән. Житәкче имамыбыз Рамазан хажи Хисаметдинов Саба кияве булып чыкты. Анын икенче баруы икән инде. Башкортстанда туып-үскән Радик (паспорттагы исеме) Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәне армиядән сон тәмамлый. (Хәзер Россия ислам институтында югары белем ала). Аннары «Кулон» акционерлык жәмгыяте генераль директоры Альберт Фәхретдинов соравы буенча Балык Бистәсенен Янавыл авылына имам булып кайта. Бу Альберт Шамил улынын туган авылы икән, ул Янавылга мәчет салдыра, мулла өчен йорт-жир житкерә, хезмәт хакы билгели. Хәзер дә бар бит иманлы-игелекле меценатлар. Альберт Шамиловичны сабалылар, бигрәк тә туктарлылар яхшы хәтерлиләрдер. Ул Юлбат сайлау округыннан район Советы депутаты булган елларда Туктарда башлангыч мәктәп, балалар бакчасы һәм фельдшерлык пункты комплексы төзеткән иде.

...Менә 22 кешелек төркемебез тупланып бетте. Озатырга «ДУМ РТ Хадж» жәмгыяте вәкилләре дә килгән иде. Алар безгә визалы чит ил паспортларыбызны тараттылар.

Аэропортның өченче катында бөтен унайлыклары белән ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым намаз уку бүлмәләре ачканнар икән. Габдулла хәзрәт шунда кузгалыр алдыннан: «Багажларны караштыргалап торырга намазда булмаган кешеләр бармы?» – дип сорап куйды. Без колакларыбызны торгыздык. «Ничек инде Исламның биш төп баганасының берсен үтәмәгән кеше Хажга бара алсын,»–дигән уй баш миебезне игәүләп үтте. «Әйе, әйе, мин сорауны уены-чынын кушып бирдем, намаз укымаган кеше изге сәфәргә чыгарга тиеш түгел дигән нәрсә юк»,– дип анлатты Габдулла хәзрәт. Ул үзе Азнакай ягыннан икән. Мөлаемлыгы, гыйлемлелеге, гөрләп торган тавышы, туры сүзле булуы белән үзенә тартып тора. Анын турында сүз башлагач, Мәдинә каласында булган кечкенә генә бер вакыйганы да теркәп куйыйк әле. Ашханә-кафе сонрак ачылдымы, әллә ризыкның кайбер төрләре азрак булдымы –хажиялар ризасызлык белдерә башлады. Шуннан сон хәзрәт жәһәт кенә урындыкка сикереп менде дә: «Әбиләр, апалар, сез бит Хажга эләксәк, барлык авырлыкларга, килеп туган кыенлыкларга түзәр, тыныбызны чыгармас идек, фәкать изге жирләргә барырга гына насыйп булсын, дигән идегез. Нишләп Казанда әйткән сүзләрегезне бик тиз оныттыгыз?» – диде. Хажиялар «шым» булды...

Габдулла хәзрәт безгә аэропортның намаз бүлмәсендә юл вәгазе сөйләде, нәсыйхәтләр бирде. Үзе иң ахырдан – барлык төркемнәрне озатып бетергәч, сонгы рейс белән килде.

...Менә без күктә. Унбер мен чакрым биеклеккә күтәрелеп, кыйблага таба очып киттек. Очкычның тизлеге сәгатенә 777 чакрым, салкынлык – 56 градус күрсәтә.Зур «Боинг» самолётында Хаж сәфәренә чыгучылар 22генә, калганнар Дубайга ял итәргә, кәеф-сафа корырга бара. Һәркем үз уй-хисләренә чумган. Булачак хажи-хажиялар Алладан сабырлык, ныклы иман, ихласлык, саулык-сәламәтлек сорый. Биш сәгатькә сузылачак очышның унышлы тәмамлануын, урысча әйтсәк, «мягкая посадка» тели. Ара якын түгел бит... Мәккәгә кадәр 3900 чакрым диләр. Дүрт тапкыр күккә күтәрелеп төшәсе бар. Шуна күрә тәннәребездә һәм жаннарыбызда жинелчә калтырану, борчылу

сизелә. «Изге җирләргә аяк басарга, Пәйгамбәребез (с.г.в.) йөргән эзләрдән атларга, аның мәчетләрендә намаз укырга әзерме без?» Шушы сорау һәркемне борчый. Башта икенде, аннары ахшам вакытларын бер-берсенә шыпырт кына хәбәр иттеләр сәфәргә чыгучылар. Утырган килеш кенә укылды бу намазлар.

Дубай безне аллы-гөлле утлары белән каршы алды, парлы мунчадагы кебек анда: 40 градус эсселек, дымлы һава. Бирегә без ун сәгать тирәсе булдык, төн кундык. Көтү залында башка гарәп илләреннән Хаҗга баручылар да байтак иде. Ирләр ап-ак озын күлмәкләрдән, башларында өчпочмак яулык (шимаха), хатын-кызлар кара киемнән, хиҗабтан. Халыкның нинди тәнлесе генә юк: карасы, агы да, сарысы да. Аның кара дигәне дә, әйбәтләп карасаң, кырык төрле икән. Валлаһи! Күренекле милләттәшебез Туфан абый Миңнуллин әйтмешли, без нәрсә күргән инде...

Дубай аэропортында госел коенып, ихрамга кердек. Гади генә итеп аңлатсак, Казанда ук сумкалар белән бирелгән ике ак тукыма кисәге ихрам киемнәре була. Кендектән билгә бәйләп, гаурәтләрне каплый торганы — «изар», иңбашларга һәм аркага салынычагы «рида» дип атала. Аларга энә белән җеп тиярга тиеш түгел. Башта булавка ярый дигәннәр иде, соңыннан анысын да «нежелательно» диделәр. Аэропорттагы махсус бүлмәдә ике рәкәгать нәфел намазын укыгач: «Йә Раббым, дөреслектә, мин Хаҗ кылуны ниятлим, мина Хаҗ кылуны җиңеләйт һәм Хаҗ гыйбадәтемне кабул ит»,— дип ниятләү догасы кылдык. Аннары кычкырып түбәндәге «Тәлбия»не әйттек. Аны өйдән үк өйрәнеп чыккан идек. Озын түгел ул: «Ләббәйкә, Аллаһуммә, ләббәйк. Ләббәйкә лә шарикә ләкә, ләббәйк! Иннал-хәмде вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлк лә шарикә ләк!»

Мәгънәсе: «Мин Синең алда, йә Аллаһ, мин Синең алда! Мин Синең алда, Синең тиңдәшең юк. Мин Синең алда, чынлыкта, барлык мактау, барлык нигъмәт, барлык хакимият Синеке генә. Синең тиңдәшең юк».

Ихрамга кергәч, ягъни рида һәм изарга чорналгач, дисталәгән тыелган гамәл бар. Менә алар: начар сүз сөйләү, низаглашу, бәхәсләшү, баш һәм битне каплау, хушбуй сөртү һәм аларны иснәү, кырыну, чәч кисү һәм тәндәге төкләрне йолку, тырнак кисү (соңгылары ихрамга кадәр башкарыла), парлап килгән ир һәм хатыннарга җенси мөнәсәсәбәткә керү, шундый теләк уята торган гамәлләр кылу, тегелгән кием кию, Әл-Хәрам мәчете тирәсендәге яшеллекләргә зарар китерү, аучылык белән шөгыльләнү. «Тегелгән кием кию» дигәннән, хаҗ кылучы хатын-кызлар ихрам кимичә, Хаҗ кылу өчен тегелгән үз киемнәре белән йөриләр, башларын ачык тотмыйлар, «Тәлбия»не кычкырып укымыйлар.

Ә без, ир-атлар, яланбаш килеш ак ихрам тукымаларыннан (гәүдәдә башка эчке киемнәр, ягъни майка-трусик та калмый) дәрвиш сыман башта Дубайдан Җиддә шәһәренә «Боинг»та очтык. Килеп төшкәч, аэропортта таможня тикшерүе үттек. Монда хәтта кояш та бездәгедән яктырак яна, көн үтә дә эссе. Һавасы коры. Аэропорт искиткеч зур, чиста, җиләс, уңайлы. Бөтен уңайлыклар бар. Шуңа тагын бер мисал китерим әле: бәдрәфләрдәге унитазларга кадәр җылытылган биредә. Төп бина янына ап-ак чатырлар корылган. Җиддә бик күп хаҗиларны каршы алып, Мәккәгә озата торган шәһәр икән. Без алга таба җитмеш чакрым араны автобусларда узарга тиеш булып чыктык. Кузгалырга кушылгач, безнең төркем икегә аерылды. Дөресрәге, беренчесенә уңлап кеше сыя алмадык. Автобусыбыз бер сәгатьтән соң гына кузгалды. Әмма алдан киткәннәр бездән соңрак килеп җитте, аларның салонындагы кондиционер сафтан чыгу сәбәпле, кире борылып кайтып, шуны ремонтлаганнарын көтеп торганнар. Моның белән шуны әйтәсем килә: кондиционер эшләмәсә, транспорт чаралары биредә рейска бөтенләй чыкмыйлар икән.

Автобусыбыз тигез асфальт юлдан элдерә. Күзләребез — тәрәзәдә. Тирә-якта ком чүле, таш диләнкәләре, берән-сәрән генә үсеп утырган дөя чәнечкеләре, саксаул агачлары. Сирәк-мирәк кенә бәдәви гарәпләренең торак пунктлары, сарык көтүләре, озын муенлы дөя төркемнәре күзгә чалынып китә. Бензин салу станцияләре янәшәсендә мәчет, кунакханә, кафе, кибет, бәдрәф кебек биналар тезелеп киткән. Биш вакыт намазның сәгате-минуты кайсы урынга туры килә — шунда туктыйлар. Гомумән, мәчет салмасаң, заправка станцияләре төзү өчен биредә участок бирмиләр икән. «Җир» дип аңлы рәвештә язмадым. Юк бит ул бу якларда. Шәһәрләрдә бина төзергә урын кирәк

булса, сораган мәйданда гранит тавы бирәләр дә, шуны кисеп, йорт яисә башка объект саласың икән. Ә бит яши гарәпләр, шул ком-таш өстендә хөрмә бакчалары үстерәләр. Бер нефтькә генә аркаланып ятмыйлар, яхшы сортлы бодай игеп, башка илләргә дә саталар, ашлыктан тыш, сусыл җәннәт җимешләре, ит, сөт, май, балык та дөнья базарына чыгарыла икән. Гомумән, бу җирләргә Аллаһы Тәгалә изге догалар, китаплар гына җибәреп калмаган, табигать хәзинәләрен дә муллан биргән.

Бензин салу станцияләре турында сүз чыккач, әлеге төр ягулыкның бәясе безнең акча белән нибары дүрт (!) сум икәнен искә төшерим. Аның да югары —98ле маркасы гына кулланыла икән. Бу җирләргә яшәү чыганагы итеп Аллаһы Раббыбыз Үзе ком-таш астына бәрәкәт иңдергәндер, мөгаен.

## Исәнме, Мәккә!

Менә без кешелек цивилизациясенең гаҗәеп әһәмиятле урыны — иң мөхтәрәм Йорт — Кәгъбә урнашкан изге шәһәр Мәккәгә якынлашабыз. Ул төрле яктан әйләндереп алучы тау итәгеннән гыйбарәт булган, диңгез өстеннән 300 метр биеклектәге үзәнлеккә урнашкан. Нәкъ менә әлеге шәһәр Хаҗ кылу өчен билгеләнгән.

Мәккә безне кырыс кара кыялары, таш өстендә су агызып үстерелгән декоратив куаклары, хөрмә пальмалары белән каршы алды. Шәһәр кырыендагы бер пунктта тукталыш ясадык. Автобустан чыгуга, мунча ләүкәсендәге кебек күз алмаларын, битләрне пешереп ала торган эсселек белән очраштык. Асфальтка баскач, аяк киеменең асты эрер кебек тоелды. Тизрәк кондиционерлы автобусыбызга кереп таю ягын карадык. Тамак ялгап алдык, кечкенә берәр шешә су, хөрмә (финики), камыр ризыкларыннан торган «сухой паёк» бирделәр.

Ниһаять, без Мәккәнең үзендә. Дөнья йөзендә 7 миллиард халык яши дип исәпләсәк, шуның 1 миллиард 700 миллионы тирәсе мөселман булса, аларның байтагы шушы җирләрне күрергә хыялланып гомер итә. Әле монарчы шуларның бик азы гына Гарәбстан ярымутравының көнбатыш өлешен алып торучы шушы тарихи өлкәне —Хиҗазны күргән, Хаҗ кылган икән. Мәккәгә якынаю белән шәһәрнең һәр ягыннан күренә торган Әл-Хәрам мәчете янындагы 380 метр биеклектәге бинага урнашкан сәгать күзгә ташлана. Аяз көнне 20 чакрым ераклыктан вакытны карап була. Ул 2010 елда Рамазан аеның беренче көнендә — 10 августта йөри башлаган. Дөньядагы иң зур сәгать өстенә дүрт яклап та Аллаһ исеме язылган. Дүрт циферблатның төп саналган икесенең биеклеге — 80 метр, ә киңлеге 65 метр икән. Ә ян-яктагылары — 64х43әр метр. Сәгатьне бизәү өчен 90 миллион мозаикалы плитә кулланылган. Кичен азан әйткән вакытта ул утлар чәчеп яна башлый. Бу нурлар, һәркемнең күз явын алырлык булып, ун чакрым югарыга күтәрелеп балкый. Әл-Хәрам мәчетенә терәлеп торган кунакханә биналарында бик байлар һәм түрәләр генә яши икән. Бәяләре дә без аңлый торган түгел...

Менә шул сәгатькә соклана-соклана бер айга якын үзебез яшәячәк кунакханә янына килеп тукталдык һәм җиде ир-ат сигез караватлы бүлмәгә урнаштык. Бер караватны ашау өстәле итеп файдаланырга планлаштырдык. Бүлмәдәшләр белән соңрак таныштырырмын. Безгә бүген — ике тәүлек юлда килгәннән соң, бераз хәл алгач, Әл-Хәрам мәчетендәге Кәгъбәтулла дип аталучы куб рәвешендәге корылмага барып, тәваф кыласы, ягъни аның тирәли җиде кат әйләнәсе бар. Кәгъбәтулланың биш вакыт намаз укыганда һәр мөселманның карашы юнәлгән Аллаһ йорты һәм бу Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) чорыннан алып — 1400 елдан артык шулай дәвам иткәне мәгълүм. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, җирнең үзәге булган Кәгъбәтулланың Адәм пәйгаәмбәр (г-м) төзегән елы һәркайда да күрсәтелмәгән. Вәлиулла Якупов чыганакларыннан да, энциклопедияләрдән дә таба алмадым. Ә менә Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты профессоры, Татарстан Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы, хәзер инде вафат булган имам Садрислам хаҗи Миңнулла (ул күренекле академик якташыбыз Әбрар ага Кәримуллинны соңгы юлга озата кайткан иде, җеназа намазын да укыды) үзенең 2005 елда басылган китабында Кәгъбәтуллага кырык гасыр икәнен күрсәткән. Шушы чорда ул күп тапкырлар үзгәртелгән. Безнең чорда — 1996 елның маеннан октябрь аена чаклы зур яңартып корулар үткәрелә. Бу эшләрне башкарганда Кәгъбәтулланы тәшкил иткән ташлардан кала, башка бөтен җирләре, шул исәптән, түбәсе дә яңартыла.



*Әл-Хәрам мәчете уртасында — Кәгъбәтулла.*

Кәгъбәтулла Ибраһим пәйгамбәр (г-м) яшәгән чорда тукыма белән тышлана башлаган. Ул материя башта күрше мөселман илләрендә житештерелә. Ә һижри белән 1322 елда (1972) фабрика ачылып, тукыма (махсус ефәк, авырлыгы 670 килограмм) шунда эшләнә башлый: япмага алтын укалы хәрефләр белән гарәпчә сүрәләр язылган. Япманы дүрт яктан әйләндереп алучы пута бар. Бу фабрикада төп продукциядән тыш Кәгъбәнең эчке бизәлеше өчен кирәк-ярак, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәдинәдәге кабере өчен кулланыла торган япма, шулай ук Согуд Гарәбстаны флаглары да житештерелә икән. Кайберәүләрдә: «Кәгъбәтулланың эчендә ниләр бар икән?»— дигән сорау килеп туарга мөмкин. Төньяк Американың Ислам җәмгыяте президенты доктор Мөзәммил Ситдыйкка 1998 елда әлеге изге корылманың эченә керү насыйп була. Ул күргәннәрен түбәндәгечә тасвирлый: «Эчтә ике-өч колонна, кирәк-яракларны куяр өчен өстәл бар, түшәмгә ике лампа беркетелгән, электр уты кертелмәгән, тәрәзәләр юк, Кәгъбә диварлары мәрмәр плитә белән тышланган, идәненә дә мәрмәр түшәлгән, эчендә илле кеше сыярлык урын бар...»

Кәгъбәтулланың тышкы ягында — көньяк өлешендә 1,1 метр биеклегендә урнашкан Хәҗәр Әсвәд (кара таш) дип исемләнгән таш бар икән. Аның үлчәме 25 сантиметрга 17 сантиметр. Кайчандыр ул бербөтен булган. Әмма киеренке вакыйгаларның берсе вакытында ватылган. Кара таш хәзерге көндә төрле зурлыктагы сигез кисәктән тора. Алар зур ташка беркетелгәннәр һәм көмеш белән каймаланганнар. Хажга килүчеләр әлеге изге ташларны үбәргә омтылалар да инде. Нәкъ менә шушы урында жиде кат әйләнү (тәваф) башлана һәм тәмамлана. Мөмкинлек булса, «Бисмилләһи Аллаһу әкбәр» сүзләре белән кара ташны үбәргә, андый жай килмәсә — уң кул белән кагылырга һәм кулны үбәргә кирәк икән.

Үзебез белән алып килгән чыганаклардан әнә шундый башлангыч мәгълүматлар белән төнге гомрә хажыбызны башкару өчен Әл-Хәрам мәчетенә юнәлдек. Ул торган жиребездән ерак булмаса да, маңгайларына «ДУМ РТ Хажд» дип язылган автобуслар йөртәчәген (биш вакыт намазга да) белдек.

Ике ара жиде-сигез минутлык кына булса да, озын туннель аша чыгасы булгач, хәйран ерак тоелды. Ир-атлар автобуска утыргач та, кычкыра-кычкыра Тәлбия әйтә башладык: Ләббәйкә, Аллаһүмә, ләббәйк...

...Минем иң курыкканым тәваф кылганда, ягъни Кәгъбәтулланы жиде кат әйләнгәндә — йөрәк тоту иде. Автобус тукталышында төшеп, кеше диңгезенә чумдык. Андагы халык! Бер аякны алга атлагач, басарга урын табып булмый. Алла безнең төркем житәкчесе Рамазан хәзрәт һәм тәжрибәле имамнар буларак үз ярдәмнәрен тәкъдим иткән Чистай һәм Арча районнары мөхтәсибләре Алмаз һәм Раил хажилар бара. Нәкъ алдан сизенгәнчә булды, йөрәк кыса, һава житми башлады. Монарчы ярдәм итә торган изокетымны сиптереп карыйм, алмый. Төркемдәгеләрдән дә калырга ярамый. «Шушында жан бирәм икән»,— дигән куркыныч уй беренче тапкыр башка килде. Азапланып бара торгач, Әл-Хәрам мәчетенең төп капкасыннан кердек (аның 45 капкасы бар икән), жилкә сумкаларыбыздагы кечкенә шешәләргә тезелеп киткән краннарның берсеннән зәмзәм суы тутырдык, бисмиллабызны әйтеп, тәүге мәртәбә туйганчы эчтек изге суны. Аннары аяк киемнәребезне өйдән үк хәстәрләп алып килгән ак чүпрәктән тегелгән букчага салып, муеннарыбызга астык та, яланаяк Әл-Хәрам мәчетенә кердек. Алдыбызда — Аллаһ йорты Кәгъбәтулла һәм Жәннәттән иңгән кара таш (Хәжәр Әсвәд).

...Алмаз хәзрәт тарафыннан соңгы күрсәтмәләр бирелә: төркемнән аерылмаска, ясле-бакча балалары кебек, бер-берәнә тотынып йөрергә, иданнәргә нәрсәндер төшсә, иелмәскә, бөгелсәң – тапталасың, адашсаң — полицейскийларга беләгеңдәге гарәпчә язылган беләзекне, муеныңдагы бейджикларны, жилкә сумкаңдагы күренә торган итеп киертелгән адресыңны, фотосурәтеңне күрсәтәсең...

Минем хәлнең мөшкел икәнен Рамазан хәзрәт сизеп-күреп алды да «Ашыгыч ярдәм» сумкалы табибны яныма бастырды. Ул үзе Буа районыннан икән.

– Сез «Татарстан яшьләре» газетасына язып торучы Нәҗипов абый түгелме сон?– дип сорап, эчемә жылы кертте ул.

– Әйе, Тәлгат Нәҗмиев булам мин, Нәҗипов түгел, – дидем. — Бөтен ышаныч Сездә, исән-сау кайтасы иде, язып бетерәсе китаплар бар,–дип тә өстәдем.

Доктор валидол кебек төймәләр бирде, тәваф кылганда янәшәмдә буласын әйтте. Алар доктор Рамил Хисамов житәкчелегендә сигез табиб килгәннәр икән. Барысы да намазда, билгеле. Сәламәтлек Саклау министрлыгы кирәк кадәр бушлай дарулар белән тәэмин иткән. Кунакханә биналарында медицина пунктлары тәүлек буе эшләп, табиблар кизү торачак икән. Барысы да уйланылган, оештырылган, кыскасы.

Менә без халык ташкыны белән Кәгъбәтуллага таба якынаеп, сәгать йөрешенә каршы (тәртибе шундый) тәваф кыла башлыйбыз. Кара ташка якын килә торган түгел, шуна күрәерактанрак әйләнергә уйладык. Андагы мөселманнарның никадәр күплеген тел белән генә аңлатып булмый. Син монда беркем дә түгел, фәкать алга тәгәрәүче жан иясе, дан-шөһрәтләрең дә, байлыгың да ярдәм итә алмый. Монда бөтен кеше дә – ике метр ярымлы мөселман негр да, метр да ун сантиметрлы Индонезия кешесе дә бер дәрәҗәдә. Кайбер урыннарда аяклар жиргә тими – ташкын үзе этеп, күтәреп алып бара. Төркемдәге таза гәүдәле ир-атлар хажияләрне, безнең кебек йөрәк чирлеләрне тапталудан саклый, рәхмәт төшкерләре. Янымдагы табибым әледән-әле хәлемне сорый, башыма кечкенә шешәсендәге зәмзәм суын сибә. «Хәлегез начар булса, чыгып торыйк, аннары янадан керербез», – дип, акыллы киңәшләрен бирә. «Түзәргә иде, Аллаһ жиңеллек бирер әле», – дим.

Ял итәргә чыксаң, беренчедән, төркемеңнән каласың, икенчедән, шул туктаган жиреңнән янадан кереп, барыбер жиде тапкыр Кәгъбәтулланы әйләнеп бетерергә кирәк була. Шулай эшләмәсәң, Хажың кабул булмый бит...

Тәваф кылуны дәвам итәбез. Табибның беләгенә чытырдап ябышкан хәлдә алга атлыйм. Урыны-урыны белән этү-төртү (гафу итешә-итешә), кысу көчәеп китә. Кайсыдыр аягыма басты, шул якка борылып карасам...

Якташыбыз, атаклы актёр Шәүкәт абый Биктимеров әйтмешли, гүәрдин кадәр негр икән, гәүдәсенең «мәһабәтлеген» тасвирлап тормыйм, башының биеклеге генә 70-80 сантиметр бардыр. Ана мин генә түгел, төркемебездәге башкалар да игътибар иткән булган. Соңыннан шаккатып сөйләделәр. Кыскасы, монда үзеңне консервы савытына тутырылган балык сыман тоясың. Туктарга ярамый, артыннан стена булып халык килә.Тәваф кылганда кайбер халыклар, бигрәк тә кара тәнлеләр, кычкырып елыйлар, кулларын өскә сузып Аллага ялваралар, битләрен тырныйлар. Кичерешләрен тышка чыгармыйча яшәүче безнең халык өчен бу, әлбәттә, ят күренеш иде.

...Без Алмаз һәм Раил хәзрәтләр артыннан Кәгъбәтулла тирәли әйләнү – тәваф кылуны төгәлләргә жыенабыз. Аллага шөкер, жиденче – соңгы әйләнешкә китеп, тиешле догаларны кабатлый-кабатлый Кара ташка йөз белән борылган хәлдә тәвафны тәмамладык та, бераз гына читкәрәк чыгып, ике рәкагәт намаз укыдык.

Хәзер безгә Хажның чираттагы фарыз гамәлен үтәргә – Сафа һәм Мәрва таулары арасын йөгереп-атлап узарга кирәк. Беренчесе Кәгъбәтулладан көньяк-көнчыгышка таба 130 метр тирәсе генә урнашкан, хәзер мәчетнең гөмбәзе астында калып, тулы Әл-Хәрам комплексына керә. Ә инде икенче тау – Мәрва дигәне 300 метр ераклыкта икән.

Зәмзәм чишмәсенең әлеге ике калкулык арасында икәнен ассызыклап үтик. Ул Кәгъбәтулладан 21 метр гына ераклыкта. Зәмзәм – Жәннәт чишмәләреннән булган жирдәге иң яхшы су. 1953 елга кадәр ул чиләкләр белән генә алынган. Хәзер инде Әл-Хәрам мәчетеннән берничә чакрым ераклыкта – Куда дигән урында сусаклагыч төзелгән, зәмзәм суы шунда суыртыла һәм саклана икән. Сусаклагыч 150 000 куб.

метр сыеклык сыйдыра ала. Су моннан илнең башка өлкәләренә, аеруча Мәдинәдәге Пәйгамбәр (с.г.в.) — Нәбәви мәчетенә җибәрелә.

Зәмзәм суы чыккан урынында аеруча тәмле. Аны сөннәт буенча, йөз белән Кыйблага борылып, уң кул белән эчәргә кирәк икән. Башта бисмилла әйтү тиешле. Гади эчемлекләрне утырып эчү сөннәт булса, зәмзәмне басып, өчәр-өчәр йотым итеп эчәргә кирәк. Эчеп бетергәч, Аллаһыга шөкер итеп, «Әлхәмдү лилләһи» дип дога кылу фарыз. Безгә хәзер Сәгый йоласын — ике тау арасын — 700 метрны җиде кат үтәргә кирәк. Бу хакта Коръәндә аять тә бар икән: «Ул ике калкулыкны — Сафа һәм Мәрваны бөек итте, хаҗ йолаларының берсен башкару өчен Аллаһымның изге урыннары итеп ясады» («Бәкара», 158).

Шушы таулар арасындагы 100 адым ара яшел багана һәм яна торган лампалар белән билгеләнгән, аны кызу адымнар белән үтү зарур. Менә шул таулар арасын җиде тапкыр чабу сәгый йоласы була да инде. Аның тәваф кылгандагы кебек укый торган җиде циклдан (шәвт) торган озын-озын, ягъни зур күләмле догалары бар. Аларны «Хаҗ һәм гомрә догалары» дигән ярдәмлектән ана телебездә укыдык, намаздан соң зәмзәм суы эчтек һәм кунакханәгә кайтып, чәчләребезне кыскартып, ихрамнан чыктык. Әйе, без һаман Дубайда ук кергән ихрам хәлендә, югарыда телгә алынган ике кисәк ак тукымадан йөрдек. Һәм, ниһаять, авыр һәм саваплы юлда килеп, кече Хаҗ гамәлләрен үтәгәннән соң, тыныч күңел белән татлы йокыга чумдык.

Олы Хаҗга кадәр әле уң көнебез бар иде. Вакытыбызны файдасызга сарыф итмәдек. Көн саен диярлек иртәнге 9дан элеккеге мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, шулай ук Габдулла хәзрәт Галиев, Алмаз хәзрәт дин дәресләре алып барып, Корбан бәйрәменә һәм олы Хаҗга әзерләделәр. Кунакханәләрдә барлык унайлыклар тудырылган иде. Зәмзәм суларын күп сыйдырышлы шешәләр белән китереп тордылар, чәйне дә шуның белән генә эчтек. Кунакханәнең беренче катында тәүлек буе бушлай каһвә, чәй, писүк һәм коры сөт, кайнар су өзелмәде. Иртә-кич күрше корпустагы ашханәдә тукландык. Хезмәтне мөслимә негрлар — хатын-кызлар күрсәтте. Беренчегә бирелә торган аш дигәнен генә аңлап бетереп булмады. Үзләрендә үскән ниндидер борчак шикелле нәрсәдән иде ул, икенчегә тавык ите белән дөге дә, бәрәңге дә бирелде. Ипи юк, нечкә батон белән ашыйсың. Чәйне йә каһвәне эчәргә кечкенә пластмасс савытларда бал, төрледән-төрле джемнар куела. Аларны әбиләр ашамадылар диярлек, онык-балаларына күчтәнәчкә җыйдылар. Хаҗдан кайткан була бит!

Өйдән мулрак итеп казылык, сыр кебек хәләл ризыклар ала бардым. Сабадан ук ике литрлы шешә белән чишмә суы алган идем. Исән-сау барып җитте ул. Дөрес, Казан һәм Җиддә аэропортлары таможняларында йоттырып карадылар, әмма алып калмадылар. Хәзер булса, үткәрмәсләр иде, өстәмә канун чыкты бит. Мәккәдә Саба суы белән чәй эчү үзе бер символик мәгънәгә ия булды. Бүлмәдәшләр сырны да бик тәмләп ашадылар. Сабаның статусы югары бит хәзер, гел мактап кына тордылар. Ә менә биш-алты таяк махсус эшләнгән казылыкны Арчадагы дустым, үзе бу изге җирләрдә ике мәртәбә булган Мөзакир хаҗи Габдерахманов биреп җибәргән иде. Моның берсен күрше кунакханәдә яшәүче якташ хаҗи-хаҗияләрне дә авыз иттерергә насыйп булды. Яхшылык беркайчан да җирдә ятмый ул. Әлеге татлы милли ризыкның ничек итеп тел астында эрүе турындагы хәбәр үземнән алда Сабага кайтып җиткән иде...

Кыскасы, аларга бик тә рәхмәтле булып кайттык, хәзер дә тыгыз элемтәдә торабыз. Дини бәйрәмнәр, туган көннәр белән котлашабыз.

Хаҗи-хаҗияләрне махсус автобуслар Әл-Хәрам мәчетенә биш вакыт намазга ташып торды. Анда бара алмаганда торган җирдән ерак булмаган Тәкъва мәчетенә йөрдек. Мәккәдә ике меңнән артык Аллаһ йорты бар икән. Һәрберсендә ике-өч имам, аларның барысы да Коръәнне яттан белә диделәр. Мәчетләрдә бездәге кебек сәдака әрҗәләре юк. Чөнки дин дәүләттән аерылмаган, хезмәт хакы һәм башка кирәк-яраклар, су һәм җылы белән Корольлек тәэмин итә. Киресенчә, намазга килүче олыларга суыткычта шешәле су, балаларга кәгазь каплардагы сок тора. Барасың да аласың. Акча сораучы да, сәдака өмет итүче дә юк мәчетләрдә. Үтә байлар хаҗиларга Коръән китабы, намазлык, дисбе, түбәтәй кебек әйберләрне бүләк итеп тә тараткалыйлар.

Аллан олы Хаж кыласы урыннарга сәяхәтләр дә оештырылды. Без атабыз Адәм (г.с.) белән Анабыз Хәва (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) очрашкан үзәнлектә, Ибраһим (г.м.) корбанлык китергән Мина (басым ахыргы хәрефкә төшә) җирендә, Коръән иңдерелә башлаган Нур (Һира) тавында, Мөхәммәд Пәйгамбәребез (с.г.в.) Әбү Бәкернең (р.г.) Мәдинәгә һиҗрәт кылганда мөшрикләрдән качып калган Сәүр тавының куышлыгында һәм Мөздәлифә үзәнендә сәяхәттә булып, тирән тәэсирләр алып кайттык.

Ерактан гына булса да, Нур тавы башындагы Һира куышлыгының кайда икәнен күз белән чамаладык. Пәйгамбәрлек килгәнче (аңа ул кырык яшьтә килә) Мөхәммәд (с.г.в.) монда булырга һәм гыйбадәт кылырга яраткан. Ул диңгез тигезлегеннән 621 метр биеклектәге биек һәм меңү авыр булган тау икән. Нур куышлыгында намаз уку өчен күпләгән кеше чират көтеп тора. Без ул биеклеккә менә алмадык. Ә менә Килдебәк авылы тумасы, өч тапкыр олы Хаж, ике тапкыр кече Хаж кылган, ун елдан артык Казан мәдрәсәләренә гошер сәдакасы туплап илтүче Тимербай хәзрәт Зарипов Һира тау куышлыгына менгән...

Бу юлларның авторына Гарәфәт үзәнлегендәге Рәхмәт тавына — Рәсүлуллаһ (с.г.в.) тукталып, Аллаһыга дога кылган урынга менеп, андагы ак таш баганага орынырга, фотосурәткә төшәргә дә насыйп булды. Тауның монысы әллә ни биек түгел, безнең хәлдән килә торган. Әмма шунда мәңге истән чыкмый торган бер күренешкә тап булдым. Тауны йөз меңнәрчә ап-ак киемле халык сырып алган, әйтерсең лә, мәхшәр көн булып, барлык әрвахлар өскә кузгалып чыккан. Менә шул халыкның аяк астындагы баскычлар, кап-кара, соры кайнар ташлар арасында, гарип балалар хәер көтеп ята. 50—60 градустагы эссе нурлар сибүче Кояш астында ничек чыдыйлардыр алар? Житмәсә, таш баскычның өске өлешенә аякларын сузганнар, башларын аска таба салганнар. Ыңгыраша-ыңгыраша, чиный-чиный яталар, акча өмет итәләр. Ел да була торган олы Хаж көннәрендә мондый гарип-горабаларны башка илләрдән дә күпләп кертәләр икән. Аларны Мәккә урамнарында да, Әл-Хәрам, башка мәчетләр тирәсендә дә күпләп очратырга мөмкин. Кайбер гаиләләрдә, хәер җыю максатыннан, махсус рәвештә сабый чагында ук үз балаларыннан гарип ясыйлар дип тә ишеттек. Мона күнел башта ышанып та бетмәгән иде. Әмма Рәхмәт тавы баскычындагы бер кызчыкны күргәч, икеләнеп тә калдым. Ул баланың ике кулы да, терсәктән югарырак итеп, бер тигезлектә киселгән иде. Ә шул урыннарның тән тиреләре тартылып, бала имезүче ананың имчәк башы формасына китерелгәнен күреп шаккаттым...

Башка гарип-горабаларга карарга кыймадым, теге кыз бала кебек күз алдыннан китмәс дип уйладым. Шуның янына ун риалны куйдым да, юлымны дәвам иттем. Ә хәер акчасын олау белән алып килеп таратсаң да, житкерә торган түгел монда. Бүлмәдәшем Наил Минсәгыйть улы белән халык мыжлап торган урыннан кайтып киләбез. Бер төркем яшүсмер кызлар бездән сәдака сорый башлады. Изге күңелле Наил, акча янчыгын чыгарды да, берсенә ун доллар бирде һәм: «Делитесь!» — диде. Синең «делитесь» дигәнеңне беләмени алар. Акчаны алганы — калды. Калганнары ике чакрым озата барганнан соң юк булды. Ә берсе һаман ялынуын дәвам итте.

— Тәлгат абый, вак акчаң юкмы? Бир шуңа, коткар мине, — диде Наил туган.

Андый очракка дигән берничә риал бар иде күлмәкнең күкрәк кесәсендә. Бирдем. Теге шунда ук югалды.

Хәер сорауны кәсепкә әйләндерүчеләр дә юк түгелләр. Мәсәлән, Гарәфәт тавында яшәгәндә палаткаларга бала күтәреп, йә житәкләп керәләр иде негр хатыннары. Чытырдавыклы кәгазьләргә төрелгән камыр ризыклары, печенье-конфетлар, төрле соклар биреп карыйбыз. Кул гына селтиләр, алмыйлар. Димәк, ач түгел алар. Фәкать акча җыялар.

**Тәлгат хажи НӘҖМЕТДИН**

*Ахыры киләсе санда*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Каюм НАСЫЙРИ**

## «Фәвакиһел җөләса»дан

Әбү Хариска берәү әйтте: «Сиксән яшенә житкәч, кешенең баласы буламы?» – диде. Әбү Харис әйтте: «Күршесендә егерме яшәр егет булса, була», — диде.

***

Бер мәжүси вафат булды. Муенында күп бурычы бар иде. Углына әйттеләр: «Йортынны сат, атаңның бурычларын әда кыйл», — диделәр. Углы әйтте: «Алай итсәм, атам оҗмахка керерме?» — диде. «Юк», — диделәр. Углы әйтте: «Алайса, тимәнез, әти ятсын утта, мин тораем йортта», — диде.

***

Бер ялкау кызны бер ялкау егеткә никях итеп бирделәр. Никяхтан соң, йомшак түшәкләр вә гайре җиһазлар хәзерләп, кызны озатканда, атасы әйтте: «Ятыныз, кызым, рәхәтләненез, шик юктыр ки, фәкыйрьлектән гайре нәрсә тудыра алмассыз», — диде.

***

Берәү үзенең бер дустына кашсыз йөзек бүләк итеп җибәрде. Ул кеше йөзекне алгач, әйтте: «Рәхмәт, Аллаһы Тәгалә ана оҗмахта түбәсен япмаган сарайлар бирсен», — диде.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Рабит Батуллага

Батулланың беләм төрле чагын
(Бергә булдык эштә, табында).
Бәйдән ычкынганын күргәнем бар,
Мулла мәчеседәй чагын да.

Язганнарын тәнкыйтьләп тә була
Һәм дә була «шәп!» дип мактарга.
Бәхәссез бер егетлеге аның —
Ике татар бирде татарга.

Шәүкәт ГАЛИЕВ

## Куен дәфтәреннән

«Светлана» дип язылган кибет янында узышлый мәче тукталып карап тора. «Сметана» дип укыган, ахрысы.

***

Эт ияртеп ике ханым килә. Бер кызны күреп, буылып-буылып өрә маэмай. Инде мина килә. Туктадым да елмаеп каршылыйм. Килде, исни дә тора. Яратканны сизде бугай. Әллә инде: «Үзебезнең сабакы», — диеме?

***

Бабайның колак аппараты бозылгач, яманы аласы килми. Хәйләкәр генә карап куя:

— Ишетмәгәч тыныч. Ишеткәч, җавап бирәсе була.

***

Картлар гына җитмешкә җитә дип уйлый идек. Безнең кебек яшьләр дә җитә икән ләбаса!

***

Чит җирдә, чит телдә сөйләшүләр... Кинәт берәү татарчалап төчкереп җибәрде. Рәхәт булып китте. Исәнлеккә-саулыкка, туган телем!

Ләбиб ЛЕРОН

## Татар тычканы

*Мин, мөгаен, тычкандыр...*
*...мин татар тычканы...*
*...мыегым да*
*Тычканныкы шикелле!*
Роберт Миңнуллин

Мине кемнәр белми — әйтәм:
Мин татарның тычканы! —
Кешегә охшаш тычкан мин,
Күлмәгем бар, ыштаным...

Кеше кыяфәтле булгач,
Юньсез дә мин, юньле дә...
Тычкан кебек мыеклы һәм
Бераз гына йонлы да...

Истә әле: сабый чакта
Тәбегә баш кысылды;
Шуңа минем күзләр шундый —
Җәенке дә кысынкы.

Гади генә тычкан түгел,
Укымышлы тычкан мин:
Чичигырьләр яза беләм...
Чичиләргә оста мин.

Мин — бик шәп һәм затлы тычкан:
Ашыйм, эчәм, кимерәм...
Мин бит депутат тычкан да! —
Шуңа күрә симерәм.

И күнелле яшәүләре,
И рәхәт бай чагында...
Ә шулай да тычкан булу
Туйдыра кайчагында.

Тычкан булу туйдыра ла...
Күсе буласы килә!
Күсе — кем ул! Һич югында,
Кеше буласы килә!!!

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Аңлашу

***(и-и, ул чаклар)***

Гәрәй Рәхим белән Мөдәррис Әгъләмов урам чатында очрашалар. «О-оо, сине күрмәгәнгә...», «Ә-әәә, туган, бер ел узгандыр...» – дип, бер-берсен күрми торуларына эчтән сөенеп, тыштан сагынган булып кыланышалар – шагыйрьләр галәте...

— Кайларда йөрисең югалып? – ди Гәрәй Рәхим.

— «Шәһри Казан»га эшкә кердем бит, малай, — ди Мөдәррис Әгъләмов.

— Бәрәч, мин дә шунда эшлим бит, — ди Гәрәй.

— Шулаймыни, ишетмәгән идем әле. Кайчаннан бирле эшлисең? – ди Мөдәррис.

— Бер ел була инде, эшли башлаганга, — ди Гәрәй Рәхим.

— Менә кызык, минем дә эшкә кергәнгә байтак булды инде, — ди Мөдәррис. — Нишләп бер дә күренмисең соң син?

— Өйләнеп йөрдем әле соңгы арада, яшь хатынга, — ди Гәрәй.

— Мин дә яңа гына өйләндем бит, вакытлыча, — ди Мөдәррис Әгъләм.

— Син кайсы бүлектә эшлисең? — ди Гәрәй.

— Әдәбият-сәнгать бүлегендә инде, — ди Мөдәррис.

— Бәрәч, мин шул бүлекнең мөдире бит. Нишләп сине бер дә очратканым юк икән?

— Син төшкә кадәр генә киләсең мәллә? Шулайдыр, мин бит кичке якта эшлим. Шимбә-якшәмбедән кала, дүшәмбе белән сишәмбене санамаганда, җомга көнне ял итәм.

— Нишләп алай? — ди Гәрәй.

— Синең бер дә гарәп илләрендә булганың юкмыни? Хәзер теләсә нинди урам этен хаҗга алып баралар. Анда мөселманнар кинәнеп ял итәләр икән, – ди Мөдәррис.

Шулчак, битенә кунган черкине куарга дип, Гәрәй кулын күтәрә. Чукынырга, ахры, моның исәбе, дип уйлап өлгергән Мөдәррис:

— Онытып торам икән, мөселман түгел бит әле син, безнең янда гына – Гәрәй, Казанны чыгып китүгә, Гөргәригә әйләнәсең бит... Христианнарга эшләргә дә эшләргә, туганкай, — дип ул, башын Мәккә ягына кыйшайтып, китеп бара. Гәрәй аны кычкырып туктатырга тели:

— Мин бүлек мөдире, син миңа буйсынырга тиеш! Бүген үк эштә бул!

Мөдәррис, борылып карамыйча, сүзен җилкә аша гына, тәмәке төтене белән бергә бөрки:

— Мин буйсынырдай бәндә җирдә тумаган әле!

## Ярамай!

Уфа шагыйре Рафаэль Сафин өенендә дә, төшендә дә, ятканда да, торганда да башкортча сукалый торгач, тәмам «чи башкорт»ка әверелеп беткән иде. Мостай Кәрим, Муса Галиләр рәхәтләнеп татарча гәпләшкәндә дә, ул су урынына «Һыу» эчеп утырыр иде.

Бер елны ул Казан һәм Уфадан бер төркем язучыны туган авылына алып кайта. Табында татарча гөрләшеп, җырлашып кинәнәләр болар. Арада бер Рафаэль Сафин гына үденсә һеңдереп һөйләй...

Әнисе түзми, әйтеп куя:

— Кыланып утырмасана, улым, үзебезчә генә сөйләш!

Рафаэль Сафин, куркынган күзләрен зур ачып, тәшвишле тавыш белән:

— Ярамай, әсәй, бедгә ярама-ай, — дигән.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*



*Ак җилкән*

*Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!*

# ҖИЛКӘНЛЕ ЯШЬЛЕК

Әдәбиятыбызда бик матур бер традиция бар. Ул – остазлык-шәкертлек. Үзеннән соң килгән яшь буынга дөрес сукмак сайларга ярдәм итүгә, ак юл ярганда, фикердәш һәм терәк булуга ачык мисалларны әдипләребез арасында шактый күрергә була. Иҗатта шулай булырга тиештер дә...

Әлеге нечкәлекне аңлаган хәлдә, «Казан утлары» журналында баш мөхәррир урынбасары Рәфикъ Юныс тәкъдиме белән «Ак җилкән» рубрикасы эшли башлаган иде. Матбаганың бик аз өлешен алып торган бу рубрика санаулы гына вакыт эчендә шактый җилкәнчене җилкетергә һәм аеруча да яшьләрнең яраткан «почмагы»на әйләнергә өлгерде. «Ак җилкән» үз эченә берничә сәхифәне сыйдырды, төрле иҗат юнәлешләрен алга куеп, укучы-студентларга киң мөмкинлекләр тудырды. Соңгы вакытта журнал битләрендә үзенә күрә бер ярыш барлыкка килде.

Укучылар һәм студентлар арасында Россиякүләм «Ак җилкән» әдәби әсәрләр конкурсын игълан иткәндә дә, иң беренче нәүбәттә, шул мәсьәлә күз уңында тотылды. Редакциябездә күп еллар эшләп, «Казан утлары» һәм милли сүз сәнгате үсешенә зур өлеш керткән күренекле язучы-шагыйрьләр каләм тибрәтүче яшьләргә киңәш-теләкләрен җиткерергә бик теләп риза булдылар, конкурска килгән язмаларга бәя биргәндә дә, кызыксынып катнаштылар.

30 август көнне узган бүләкләү тантанасына Татарстан һәм Башкортстан республикаларыннан конкурста җиңүче 39 яшь иҗатчы җыелды. Чара хәзерге әдәбият, иҗат серләре, заман укучысы хакында фикер алышудан башланып китте. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза), бүлек мөхәррирләре, язучы-прозаик Камил Кәримов, шагыйрәләр Гөлзадә Бәйрәмова, Ләйсән Фәтхетдинова, халкыбызның абруйлы язучы-шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев җилкәнчеләрне зур җиңүләре белән тәбрикләде.

Конкурста катнашучылар ике төркемгә бүленде: мәктәп укучылары һәм студентлар. Арада Линар Закиров, Эльнар Байназаров, Алсу Нургатина, Айдар Шәйхин кебек укучыларга яхшы таныш яшьләр дә бар иде. «Ак җилкән» конкурсы ачык рәвештә узды – жюри һәм редакция хезмәткәрләре уңышлы дип тапканнары даими рәвештә басылып килде. Бу эш әле алга таба да дәвам итә: һәр сан саен сез бер-ике яңа исем белән танышып барасыз. Фикер белдереп шалтыратучы яки хат язучыларыгыз да шактый.

«Ак җилкән»не алдагы елларда да уздыру күздә тотыла. Озакламый аның икенчесе старт алачак. Даими рәвештә журналыбызны укып барсагыз, җилкәнчеләр иҗатындагы яңалыклардан, конкурс шартларыннан хәбәрдар булырсыз. Кызыклы һәм мавыктыргыч язмалар көтеп калабыз. Иҗат каләмегез һәрчак тынгысыз булсын!

**Рамил ХАННАНОВ**








# СЫНАУЛАР

БӘЯН

## Син кайларда, әти...

Ноябрь ахырларында кискен салкынайтып җибәрде. Урамда бик озак басып та торып булмый, җил өйгә куып кертә. Барысы да тизрәк кар яуганын көтәләр. Җир туңып, ярылып-яргаланып бетте, бу салкынга ул да чыдый алмый, күрәсең...

Урамга чыгарга исәп тә юк, буш вакыт булганда, имтихан эшләре белән утырам. Татар һәм рус теленә артык басым ясамыйча, кул астында гел математика гына. Биремнәрне үтәгәндә, кайбер урыннарда Роза апаның аңлатканы искә төшә. Хәтта кайсы урында тормыштан нинди мисал китергәне дә күңелдә. Бернинди укытучының да сөйләгәннәре шулай исемдә калмый минем. Роза апаның үзенә генә хас бер серле көче бар микән әллә?!

Тышкы ишек «чарт» итеп ябылды, өйгә әни килеп керде. Хәзер ул борын тартып, иркен генә сулыш алып куячак. Кышкы салкыннан туңып, өйгә хуш ис алып керә ул. Җай гына өске киемнәрен сала да минем ишегемне ачып карый: әзерләнәмме мин, юкмы?! Югыйсә, кайвакыт дәреслек астына башка китап куеп укып утырган чаклар да була. Тик бу очрак мондый түгел. Математикага кереп киттем, һәр эшләнгән бирем – кечкенә генә җиңү! Шуңа да мавыгып, кызыгып эшли башлыйсың.

– Өйдә кешеләр бармы? Исәнлекләр ничек?

Монысы күрше Әлфия апа. Ул һәрвакыт шулай кергәләп-чыккалап йөри. Мин яратмыйм аны, өйгә кереп бөтен хәлләрне белеп чыгып китә дә аннары берне биш итеп калганнарга сөйләп йөри. Үзе ялгыз яши ул. Шуңа да парлыларны яратмый.

Кухня ягында әни белән сөйләшкәннәре ишетелә. Хәзер әти хакында сораячак. Аннары үзенең хәлләрен сөйләп җибәрәчәк. Минем уйларымны ишетте ахрысы, әниемнән сорап куйды.

– Рәфидә, Гариф күренгәне юкмы соң?!

– Юк инде, Әлфия. Кая безгә килсен инде ул хәзер. Яшь Салисәсе белән мәш киләдер. Инде улы тәпи йөри башлагандыр. Бездә аның эше юк инде.

– Иии, дөньясы. Нишлисең бит. Мужигың да китә, башкасы да. Ярар, борчылма. Ходай ярдәм бирер. Табылыр әле, сиңа тиңе дә, дим.

– Хәзер ярлар өмет итмим инде, юкны сөйләмә. Ходай шул бердәнбер кызымнан аермасын. Әле ярый ул бар. Аннан башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм хәзер.

Әни монысын юри, миңа ишетелерлек итеп әйтте. Беркайчан да миңа мондый сүзләрне күзгә-күз әйтми ул. Күзе гел яшьләнергә генә тора. Әй, язмыш. Нигә генә эткәй шул Салисә апаны яратты икән? Язмышлар шулай язылгангамы? «Язмыштан узмыш бар, язмышны үзгәртү үз кулыңда», дип әйтүчеләр дә бар бит. Тик бу очракта узмыш була алмыймыни? Хәер, минем хәзерге вакытта математик биремнәр белән тулган баш аңлый алмаслык нәрсәләр күп шул ул дөньяда...

---

*Дәвамы. Башы 7, 9 нчы саннарда.*

***

Әй, эти... Кайларда икән син хәзер. Ичмасам, юлыма да очрамыйсың бит. Әллә сине югалту хәсрәтеннән дымланган күзләремә карарга куркасыңмы? Мин бит сине бик яраттым, эти. Ләкин син безне ташлап киттең. Тик шул көндә минем өчен үлдең син, уйларымда сине хәтер туфрагына җирләдем. Синең хәлләрең ничек икән? Безне сагынган чагың була микән? Әллә яшь улың белән безне уйларга вакытың да калмыймы? Күңелемә син иң кирәк вакытта янәшәмдә түгелсең. Ниндидер чит, кырык ата баласы сиңа эти дип дәшә, син тапканны ашый, синең теләкләреңне ишетеп яши. Синең барлыгыңны тою миңа хәзер бер рәнҗүгә әйләнде. Безне ташлап киткән көннән башлап мин сине күрә алмыйм, эти... Исеңдәме, күз кергәндә, синнән кошларга җимлек ясатып ала идем. Аны безнең тәрәзә төбенә кадаклап куя идек тә, җим салып, кошларны күзәтә идек. Хәзер җимлек тә юк, чүплектә чыр-чу килгән кошларга карыйм да сине сагынам. Исеңдәме, зал бүлмәсенә телевизор карарга чыккач, йоклаганга салышып яткан чагым. Син көчле кулларың белән күтәреп алып, мине бүлмәгә алып кереп, караватка сала идең. Бераздан мин көлә-көлә яңадан чыгып утырам. Шулай ике арада йөри-йөри чынлап йокыга китәм. Хәтта үземнең сабый чагымны хәтерлим. Әнинең бертуган абыйсы үлгәч, әни бер атнага аларга китеп барды. Шулвакыт мин бик каты авырып киттем. Син мине юрганга төреп хастаханәгә алып менгән идең. Анда бер төн кунып, хәлем яхшыргач, җылы юрганга төреп, кышын, чатнама суыкта өйгә алып кайттың... Шунда мин тәүге кат йолдызларны күрдем. Шунда тәүге тапкыр йолдызлар хәтеремдә калган...

Ә бит мин сине җибәрергә теләмәгән идем. Салисә апа «Рәфидә Гарифны өеннән куып чыгарган», дигән гайбәт тараткач, сезгә үзем килдем. Рөхсәт сорамыйча өйгә үттем. Ниятем йөземә чыккан иде бугай, мине күргә, балалар шым булдылар. Кухня кырында Салисә апа токмач җәя бугай. Эчтән генә нидер көйли, бармагындагы алтын йөзегенең уклауга «шак-шык» итеп бәрелүеннән ләззәт ала иде. Тынлыкны бозып: «Исәнмесез», – дип дәштем. Салисә апа, мине күрү белән, кулыннан уклавын төшереп җибәрә язды. Еш-еш сулый, аннан, үз-үзен кулга алып, миңа дәште.

– Гариф янына килдеңме? Ул анда, юынгычта иде бугай...

«Әтиең янына килдеңме» дә дими, исемең белән дәште. Мин ул күрсәткән якка үттем. Син битеңне юа идең. Бигрәк җирәнгеч булып тоелдың син миңа шулвакыт. «Әйдә, әйдә, юын. Тик су белән генә күңелебездәге яраларны юып төшерә алмассың», – дидем мин эчтән генә.

– Айсылу? Нишләп йөрисең?

– Килдем әле, эти. Яшь хатыныңның теле тик тормый бит, әни хакында теләсә нәрсә сөйләп йөри. Без сине өйдән куып чыгардыкмыни?

Син, минем кыза башлавымны сизеп, тышка алып чыгып киттең.

– Юк сүздер ул, кызым, Салисә апаң андый кеше түгел...

– Нәрсә, аңыңны гына түгел, авызыңны да томаларга өлгерде мәллә Салисәң?

Минем тавышымны ишетеп, Салисә апа да йөгереп чыкты.

– Нишлисез, нәрсә бара монда?

– Бар, Салисә, кереп кит әле, – дидең син, үрсәләнеп.

– Кермәсен, калсын. Үзенең сүзләре өчен үзе җавап бирсен! Минем әни хакында ничек шулай сөйли аласың, оятсыз. Әниемнең кисеп аткан тырнагына да тормый торган нәрсә!

– Кем, минме? – диде Салисә апа, яшенә буылып.

– Сез! Әтине тартып алу гына җитмәгән, төрле гайбәт сөйләп йөрисез! Оятсыз сез, әле оялмыйча ана исемен күтәреп йөри!

Мине син ишек төбеннән өстерәп алып киттең. Салисә апа ишеккә сөялеп калды. Тавышка өйдән бер кеткү бала йөгереп чыкты.

– Мәңге рәхәт күрмәс кешеләр сез, – дип кычкырдым мин. Бот бүе балалар Салисә апаның аякларына сарылдалар. Кечкенә Кәрим исә күзләрен мөлдерәтеп итәк артыннан карап тора. Тагын әллә ниләр әйтергә теләгән идем, Кәримне кызгандым. Әнисе шундый булганга бала гаепле түгел бит...

Әни, сезгә баруымны белгәч, үңлап-суллап яңаклады. «Нәрсә кирәк сиңа, ни җитми. Атаң кебек өйдән чыгып китәргә җыенасыңмы? Киткәннәр кире кайтмый, ятратканнар ташлап китми! Минем хакка талашып йөрүеңне тагын бер ишетим әле! Мин үзем өчен үзем дә җавап бирә алам!» Аннан мине кочаклап елап җибәрде ул. Нинди хәлгә төштек бит, Ходаем...

– Ярый, Рәфидә, исәнлектә, яме. Үзең дә кергәләп йөре. Мин бит берүзем, ни... Ялгыз, минсиңайтим.

– Ярар. Эшләрдән бушасам кереп чыгармын, Әлфия.

– Ярар, ярар... И, чукынган! Карале, бер кәсәгә катык оеткысы салмассың микән, шуны сорарга кергән идем, онытып чыгып барам лабаса...

Турыга бәреп әйтә алмаган...

– Ничек оялмыйча минем өстәлемә кул тидерә алдыгыз! Оятсызлар сез! Әллә сезгә карап торган үндүрт бала миңа бер сүз дә әйтмәс дип уйладыгызмы?! Җавапларыгыз начар булса, кабат барсын да такта янында аңлар идек! Оятсызлар сез!

Математика дәресенә бераз соңга калган идем. Мине ишектән әнә шундый сүзләр каршылады. «Керергә ярыймы», дигән соравыма Роза апа күзлеген төшереп ым какты. Сыйныф тып-тын. Нәргизә белән Радик кына басканнар. Эшнең нидә икәне бермә-бер аңлашыла иде.

– Сез генә төзәткәннән берәр нәрсә үзгәрер дип уйлыйсызмы? Башкаларның да сезнең кебек үк яхшы билге аласы килә. Нәрсә, Ранилның бишле аласы килмиме, Гөлчәчәкнең чирекне яхшы билгегә тәмамларга теләге юкмы? Әллә сез генә Алланың кашка тәкәләре булдыгызмы? Кем сезгә шундый ирек биргән, кем кушкан?

Радик, иелгән башын күтәреп:

– Роза апа, үпкәләмәгез инде. Бу хәл башка кабатланмаячак...

– Дәшмә, Радик! Әлбәттә, кабатланмаячак. Мин эшләрне дәрес башында эшләтәчәкмен дә, шунда ук тикшереп, билгеләрен дә куячакмын. Иң беренче сезнекен, шпионнар! Оятсызлар! Күзгә карап артка тибүче кешеләр сез. Ышанычымны акламадыгыз...

Роза апа соңгы сүзләрен әрнү белән әйтте. Хәер, ни буласы алдан ук билгеле иде бит инде. Роза апаның сыйныфында укучы, шоколад яратудан черегән алгы тешле әләкче Фәнил барысын да укытучы апага әйтәчәк... Хәзер исә Роза апа Радик белән Нәргизәгә бер дә ышанмаячак һәм һәр эшләренә дә зур шикләнү белән карыйсын көт тә тор. Кыңгырау шалтырагач та, бер кем дә урыныннан кузгалмады. Тактага язган өй эше номерларын күчергәч кенә чыгып киттек. Чып-чын тәрбия дәресе булды бу...

...Көзге каникуллар тәмамланып, яңадан мәктәпкә аяк бастык. Сагындырган икән мәктәп, сагындырган... Өйдә әнигә булышып, йокы туйганчы йоклап ятсак та, шушы йорт барыбер безне үзенә дәшә. Өмә вакытында зәңгәр төскә буяган капка да күңелгә якын. Ишекне ачып керүгә үк, үз эченә тарта мәктәп. Әнә куыша-куыша башлангыч сыйныфлар йөгерешә, беренче каттагы теннис өстәлендә дәресләрне тозларга яраткан унынчы сыйныф егетләре «рекорд» куя, гөлләрне кем сындыруын һәм стена плакатларының кырыйларын кем тишкәләвен таба алмыйча азапланган техничка Сәвия апа...

– Нишлибез соң инде? Ясатабызмы-юкмы бу альбомны? Төгәл бер фикергә килә алмадык...

Сыйныфның яртысы каршы, яртысы риза иде.

– Сез ничектер, мин барыбер ясатам! Фотога төшәрсез дә алмассыз! Истәлек булып миңа калыр, – диде Илһам.

– Чыннан да... Күбебез, тугызынчы сыйныфны тәмамлап, укырга китсәк әгәр дә...

– Үзеңне күрәсең килсә, көзгегә карарсың!

– Ә син – маймыл күрәсең килсә – кара. Көзгесен үзем бирәм!

...Шулай да ясатырга булдык альбомны. Шушы көннәрдә фотограф килеп төшереп китәргә тиеш иде.

Шулчак Ранил сумкасыннан фотоаппарап чыгарды.

– Минем монда фотоаппарат бар! Әйдәгез, барыбыз да бергә истәлеккә төшәбез. Җыйнаулашып басыйк.

Ул арада этешә-төртешә тезелешеп баса да башладык. Илһам иптәшкә сыйныфтагы скелетны да алды.

– Нуу, елмаегыз инде. Сез нәрсә, зиратка барган төсле басканнар.

– Бәлки зиратка да барырбыз әле бу экзаменнар белән...

– Тәүбә диген!

Ранил барыбызны билгеле бер тәртиптә тезеп тә чыкты. Тик йөзгә барыбер елмаю өсти алмады. Хәер, нигә елмаерга... Наргизә белән Радикны әле генә Роза апа «пешереп» чыгарды, ә калганнарның сынаулар белән баш каткан.

– Илһам, нигә скелетны шулкадәр кочакладың? Биленнән кочакла, вәәәт. Ныграк тот, курыкма. Бу бит сиңа Миркасыймовнаның биле түгел!

Сыйныф дәррәү көлеп җибәрде. Мин ни булганын аңламасам да, башкалар көлүенә кушылдым. Илһам, скелетны бер читкә атып, бер-ике «затлы» сүз кыстырып, Ранилны сыйныфтагы парталар өстеннән куа башлады. Без көлгән арада «черт» иттерергә өлгерде тагын...

Миркасыймовнаның бил вакыйгасын мин һаман төшенмәгән идем әле. Физика башланыр алдыннан Радик барсын да сөйләп бирде. Көлдем рәхәтләнеп. Бар нәрсәнең сере шул «Көзге бал»да икән. Дискотека тәмамланыр алдыннан техничка апалар чыгып киткән һәм зал дөм-караңгыда калган. Аратирә кәрәзле телефон яктысы гына булган. Илһам шушы арада ничә еллар җавап ала алмаган мәхәббәте Айгөлне күреп алган. Төшләрендә мендәр кочып, Айгөл дип үбә-үбә саташкан егет аны караңгыда барып кочакларга уйлаган. Тик ул күргән «Айгөл» тәртипне саклар өчен кергән Галия Миркасыймовна булган. Илһам аны барып кысып кочаклагач, бер рәхмәт төшкересе утны кабызган.

Радик сөйләп бетергәч, Илһамны чын күңелдән кызганып куйдым. Хәер, бер-ике ай көлеп йөрерләр дә туктарлар. Айгөл бу турыда ни уйлаган икән? Якын кешесенең мыскыллы карашын күргәч, икеләтә авыр булгандыр инде Илһамга...

***

Иртән тыкрык башында Алмазның машинасы күренгәч аптырап киттем. Көзге балдан соң мине ничек озатса, шул килеш урынында басып тора. Ә бәлки ул монда мине сагынып килгәндер?! Юк, булмас, Казанда бит ул! Ышанмыйча номерларына күз салдым. Шулар! Алдагы көпчәкләрнең буш булуын күреп туктап калдым. Менә нидә икән сәбәп. Икесендә дә шактый зур тишекләр бар. Димәк, юри эшләнгән... Димәк, Динар?! Унбердә укучы «якын» дустыма үпкә туплап, мәктәпкә ашыктым.

Беренче дәрес башланганчы сыйныфына кереп эзләсәм дә таба алмадым. Ярар, күрешербез әле барыбер.

Биология башлангач, апа сыйныфны барлап, журналга теркәп чыкты. Бары тик Гәрәева гына юк, калганнар барысы да монда. Гүзәлнең дәресләргә йөрмәве мине борчуга сала иде. Каникулдан соң инде бер атна укыйбыз, әле һаман мәктәптә күренгәне дә юк, хәбәре дә ишетелми. Бүген кайтышлый сугылырга булыр. Кем белә, бәлки авырып ятадыр...

Дәресләр тәмамланып, өйгә кайтырга чыккан идем, мине Динар куып җитте.

– Айсылу! Айсылу, тукта әле! Бүген мине эзләгәнсең, диләр. Ни булды?

– Сорап торасыңмы тагын, – дидем мин, аңа үпкәле караш ташлап. – Мин сине якын дуска санап йөри идем, ә син? Ничек шулай эшли алдың?

– Аңламадым. Ни эшләдем соң мин сиңа?!

– Нигә Алмазның машина көпчәкләрен тиштең? Теге юлы, ул мине озаткач... Күзгә балдан соң. Миңа туры бәреп әйтә алмадыңмыни?!

– Айсылу? Нинди фантазияләр бу? Берни дә эшләмәдем мин! Гаепләмә мине юкка!

– Син, – дидем мин, сулышымны акрынайтып, – син – адәм актыгы. Ошамыйсың син миңа, йөрмә минем арттан! Кеше әйберенә кул салгансың, аның бәясе дә шактый бит! Кай җирең белән уйладың син, Динар?

– Между прочим, синең Алмазыңны Зәлия белән күргәннәр әле, бик беләсең килсә.

– Алдалама, Динар! Башка бер сүзеңә дә ышанмыйм! Шундый түбәнлеккә төшәрсең дип уйламаган идем!

Динар арттан нидер кычкырып калды, ишетмәдем. Үзебезнең урамга йөгердем. Кабат йөгереп килеп, кулымнан тотып алды.

– Минем эш түгел бу, Айсылу. Ышан! Йөрмә син ул Алмаз белән, синең тиң түгел ул...

– Аның синнән меңгә якшырак булуыннан көнләшәсең син! Килеш минем сүзләр белән! Аңа үпкәңне туры бәреп әйтергә иде, ә порча чужого имущества – статья ул, бик беләсең килсә!

Ул басып калды. Бер сүз дә дәшмәде. Аннан:

– Туры бәреп әйтә алмаган сүзләр бар шул миндә, Айсылу, – дип кычкырды.

Өйгә кайтышлый Гүзәлләргә кердем. Ул бик каты авырып яткан булып чыкты. Хәлләрен белеп, мәктәп мажараларын сөйләшеп саубуллаштык...

**Алсу НУРГАТИНА**

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

**Фәнилә ШӘЙДУЛЛАТОВА**

## Табигатьтә – матурлык!

Болын буйлап бүген йөргән идем,
Яшеллеккә карап сокланып.
«Иң гүзәл җир шушы булыр!» – дидем,
Алсу чәчәкләргә таң калып.

Сандугачның җырын тыңладым да
Шул кошчыкка кушылып җырладым.
Күпме моңнар аның тавышында!
Матуррак җырчы тапмадым.

Йомшак жилләр, талгын гына исеп,
Сыйпап үтте битем очларын.
Чиста сулы саф чишмәгә төшеп,
Сулар эчтем, тутырып учларым.

Шат елмаеп миңа зәңгәр күктән
Кояш сипте жылы нурларын.
Бар гүзәллек табигатьтә икән!
Шуңа бүген мин инандым.

Якты кояш, киң болыннар безнең
Байлыгыбыз икән ләбаса.
Әгәр кеше шушы гүзәллекнең
Кадерен белеп яши башласа...

**Алинә АКМАЛОВА**

## Якын дус син, и каләм!

И каләмем, әле дә син бар,
Адашыр идем лә күптәннән.
Юл табалмый арлы-бирле йөрим,
Сорау алам үткән-сүткәннән.

И каләмем, әле дә син бар,
Күңел төшәр иде базына.
Ишекләрен йозакларга бикләп,
Кагылмас та иде сазына.

И каләмем, әле дә син бар,
Нуры бетәр иде дөньяның.
Сандугачка игътибар да итми,
Ишетмәмен саг(ы)шын торнаның.

И каләмем, әле дә син бар,
Кем ишетер йөрәк авазын?
Бар серләрне тыңлап торасың да
Әкияти жырлар язасың.

**Эльвира РАФИКОВА**

## Йолдызлы төн

Даһи тынлык, ап-ак кары белән
Көн дә инде кичкә авышкан.
Акрын гына атлап кайтып киләм
Ай яктысы сибелгән юлдан...

Ай нурында ак бөртекләр ялтырый,
Әйтерсең лә алар йолдызлар...

Һәм шулвакыт аем телгә килә:
«Күктә сиңа таныш йолдыз бар!»

Исеңдәме, җәйге серле төндә
Йолдызларны уйнап санадык?
Ике йолдыз, пар булсыннар диеп,
Хыял белән күккә карадык...

Ә хәзер кыш, алар һаман күктә,
Бәлки әле бергә булырлар...
Әйе, көтәм, вакыт кына үтә,
Тик язларга якты өмет бар...

Шушы тыныч, серле күгебездә
Йолдызлар күп... чикләрен белмим...
Ләкин беләм ике йолдыз барын:
Аларның бит исеме — «Син» һәм «Мин»...

Алисә МӘГЪДӘНУРОВА

## Сагышлы көз

Тагын көзләр килде...
Мин яраткан көзләр,
Һәр ел шулай моңсу, сагышлы,
Күңелемдә күчеш чоры, гүя,
Яфракларның күктән агышы...

Тагын көзләр килде,
Син яраткан көзләр,
Безне аеручы сары көз,
Күңелемдә күккә очам гүя,
Казлар төркемендә мин бер кош...

Тагын көзләр килер,
Тик безнеке түгел,
Бу көз миңа бик тә чит инде,
Җылыталмый «әби чуагы» да,
Болытлар да түгел элекке...

Тагын көзләр килер,
Җир өстенә елар
Чиләк-чиләк булып яңгырлар,
Тик хәтердән сине юмас алар,
Хатирәләр мәңге калырлар...
Тагын килер көзләр...

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

- Кеше балчыктан ярался да, судан тора.
- Көнлекчене көнчелек үтерә.
- Кала – саланың үксез баласы.
- Татар, дигәч, Иблис тә алтатарга үреләдир.
- Уй басса, буй да базыклана.
- Вак жан белән дә зур күренә белүчеләр була.
- Кан коелганда, кансызлык арта.
- Иярдән егылганга тәхет тәтемәс.
- Исерек сәясәтче аек шагыйрьгә бәрабәр.
- Яулык бөркәнеп кенә яучы булмассың.
- Ирен матур кызларга күз ата дип көенмә, матур егетләргә сүз катмый дип сөен.
- Эшем кешеләре күп, эшләр кеше генә чамалы.
- Ат сыртын ата сырты белән дә бутыйлар.
- Хатын-кызның иң матуры — житешсезлеген яшерә белгәне.
- Кеше сөйми – халыкны ярата.
- Таш балбал ишәйгән илдә кешенең кадере булмас.
- Салкын сугышта кайнарбашлар җиңелә.
- Кеше маймылдан түгел, маймыл кешедән ралган.

***Газинур МОРАТ***

- Кәжәсенә күрә сакалы,
  Заманына күрә мәкале.
- Түрә үз файдасын гына күрә.
- Кем үрдә, шуның исеме түрдә.
- Жырның жыртыгы сәхнә тулы.
- Сайлаган белми, санаган «белә».

***Ирек БӘДРЕТДИНОВ***

- Ястыгың калын булса, саулыгың юка булыр.
- Пакь янчыкка акча ябышмый.
- Оятлы да акча, оятсыз да акча.
- Абруйлының каурые озын.

***Линар ЗАКИРОВ***

*Кадерле авторлар һәм укучыларыбыз! Үзегез чыгарган яңа мәкальләр – XXI гасыр мәкальләре көтәбез сездән. Аларның шәпләре, журналда гына түгел, китапта да урын алып, алар аша халык теленә күчеп, бәлкем, XXII гасырга да ялганыр әле...*

*Бу санда бирелгән мәкальләрнең кайсылары күңелегезгә хуш килде? Иң шәбе кайсы?*

## İctimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### САЙЛАУ

«Гражданлык активлыгы күрсәткәннәре өчен татарстанлыларга рәхмәтемне ирештерәм. Мин моны якын көннәрдә эшкә керешәчәк V чакырылыш Дәүләт Советына зур ышаныч күрсәтү дип саныйм». — Республика сайлау кампаниясенең беренче йомгаклары мәгълүм булгач, ТР Президенты Рөстәм Миннеханов шундый белдерү ясады.

Президент Дәүләт Советына сайлау унышлы үтте дип саный. Республика сайлаучыларының 80 проценттан артыгы тавыш бирүдә катнашты.

Исегезгә төшерик: Дәүләт Советына, 5 процентлы киртәне узып, «Бердәм Россия» белән КПРФ үтте. Моннан тыш, бер мандатлы округлар буенча сайланганнар арасында ЛДПРдан да бер депутат бар. Шулай итеп, алдагы биш елда парламентта өч партиянен вәкилләре эшләячәк. Гомумән алганда, 100 депутатның 83е «Бердәм Россия» вәкиле булачак: 47 депутат — партия исемлеге буенча, 36сы бер мандатлы округларда җинеп сайланды, 3 депутат — КПРФ вәкиле.

«Бердәм Россия» партиясенең барлык сайлау алды вәгъдәләре республиканы үстерү программасының нигезен тәшкил итәчәк», — диде Президент Рөстәм Миннеханов. Сайлауның беренче нәтиҗәләренә багышлап, Россия Хөкүмәте Рәисе, «Бердәм Россия» партиясе җитәкчесе Дмитрий Медведев катнашында видеоконференция үтте. Татарстанда сайлауның ничек узуы турында видеоконференциядә ТР Дәүләт Советы Рәисе, партиянең төбәк бүлеге җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин сөйләде.

### ТАНТАНА

30 августта, Республика көнендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы булды. ТР Президенты Рөстәм Миннеханов бу олы бүләкне «Утлы дала» тарихи романы өчен Вахит Имамовка һәм каллиграфия композицияләре сериясе өчен Владимир Поповка тапшырды.

### ФЕСТИВАЛЬ

Казанда X халыкара мөселман киносы фестивале узды. Анда 22 илдән 50 фильм күрсәтелде. Моннан тыш бәйгедә катнашмаган 150 кинофильм тәкъдир ителде. Фестиваль «Мәдәниятләр аралашуы аша — мәдәниятле аралашуга» дигән шигарь белән уздырылды. Фильмнарга бәя бирүче жюрида Төркмәнстан кинорежиссёры, сценарийлар язучы, оператор Хуҗаколы Нарлиев (рәис), төрки киносы белгече, тәнкыйтьче Ихсан Кабил, драматург Мансур Гыйләҗев, Азәрбайҗан режиссёры Тофик Измайлов, Көньяк Кореядән кино белгече, тәнкыйтьче Хонг Санг Ву эшләде. Кунаклар арасында Һолландия режиссёры Йос Стеллинг, Россия Федерациясенең атказанган артисты Наталья Аринбасарова, режиссёр, Россия Федерациясенең халык артисты Вера Глаголева, актриса Анна Леванова һ.б. күрергә була иде.

Фестивальне ачу тантанасы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә үткәрелде. Тамашаны алып барган Россия Федерациясенең халык артисты Борис Щербаков РФ мәдәният министры Владимир Мединскийның котлау хатын укыды. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның сәламләү сүзләрен җиткерде. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, мөселман кинофестиваленең президенты Равил хәзрәт Гайнетдин Казанда үткәрелә торган бу чараның гуманлылык идеяләрен таратуда зур роль уйнавын әйтте.

Фестивальнең ябылу тантанасында кино һәм театр артистлары Ирина Алфёрова, Алла Бабенко, режиссёрлар Егор Кончаловский, Александр Гордон, жюри әгъзалары, кино белгечләре, тәнкыйтьчеләр катнашты. Җиңүчеләрне бүләкләү концерт номерлары белән үрелеп барды. Мәгълүм ки, Казаныбыз 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителде. Әлбәттә, бу фестивальдә дә чагылыш тапты. «ТӨРКСОЙ» халыкара оешмасы үзенең бүләген әзерләп куйган иде. Ана «Перекрёсток» фильмы өчен төрек режиссёры Файсал Сойсал лаек булды. Быел беренче тапкыр Казан мэры Илсур Метшинның махсус бүләге дә тапшырылды. Аны «Корбан-роман» фильмы өчен режиссёр Салават Юзеевкә бирделәр. Гомумән, бу фильм берничә төрдә бүләкләнде. Иң яхшы ир-ат роле өчен, мәсәлән, «Корбан-роман»да Йосыф ролен башкарган Даниил Шиһапов бүләкләнде. Даниил иҗат юлын Казаныбыз-

нын Яшь тамашачылар театрында башлаган. Бүгенге көндә ул Санкт-Петербургта яши һәм Лев Эренбург театрында бөтен спектакльләрдә дә диярлек катнашып килә. Үзебезнең режиссёр Илдар Матуров төшергән «Туфан есть Туфан» документаль фильмы жюри бүләгенә лаек булды. Ә менә Татарстан режиссёры Алексей Барыкинның язучы Денис Осокин әсәре буенча төшерелгән «Сухая река» кыска метражлы нәфис фильмы тәнкыйтьчеләр һәм кино белгечләре гильдиясе бүләге белән билгеләп үтелде. Иң яхшы мультфильм да безнеке — Сергей Киатровның «Зилантовы сказки». Иң яхшы сценарий өчен Бразилиядән Марсио Курин («Последняя остановка» нәфис фильмы) бүләкләнде. Иң яхшы оператор — Россиядән А.Котт («Испытание» фильмы). Тулы метражлы нәфис фильмның иң әйбәт режиссёрлары буларак «Умереть отомщённым. Письма из прошлого» фильмын төшергән азәрбайжан режиссёры Актай Мир-Касыйм һәм «Прошлой зимой» иран фильмын төшергән Сәләм Салавати танылды. Ниһаять, фестивальнең төп җиңүчесе — хорват режиссёры Арсен Антон Остойичның «Путь Халимы» нәфис фильмы. Билгеле булганча, фестивальдә җиңүчеләргә менә инде берничә ел Президентыбызның «Кино сәнгатендә гуманизм өчен» бүләге бирелә. Быел Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова аны «Она» фильмы өчен Россия режиссёры Лариса Силовага тапшырды.

## ФОРУМ

Казанда төрки телле әдәби журналларның VII халыкара форумы булып узды. 4 көн дәвамында барган җыенны Татарстан Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы ТӨРКСОЙ халыкара мәдәният оешмасы белән берлектә уздырды.

Дөньяның 14 иленнән килгән 29 әдәби журнал мөхәррирләре, мәшһүр язучылар катнашындагы форумны ТР Милли китапханәсе бинасында ТР Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов ачты, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин алып барды.

Казакъстанның ТӨРКСОЙдагы вәкиле Мәлик Отарбаев ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы җитәкчесе Дүсен Касейновның форумда катнашучыларга котлавын ирештерде. Аннары форум кунакларын Ауразия Язучылар берлеге рәисе Якуб Өмәроглу сәламләде.

Республика Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов форумның Казанда узуы зур мәгънәгә ия булуын искәртте һәм Татарстанда нәшер ителә торган милли басмалар белән таныштырып үтте.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов берлек бинасында үткән утырышны ачып җибәргәндә игътибарны төрки дәүләтләр һәм республикалар белән бәйләнешләрнең ныгый баруына юнәлтте.

Республика көнендә парламент бинасының кече залында төрки телле әдәби журналлар форумында катнашучылар Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән очрашты. Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан белән төрки телле илләр арасындагы бәйләнешләрне ныгытуның аеруча мөһим булуын әйтте.

Аурразия Язучылар берлеге рәисе Якуб бәй Өмәроглу үзенең җавап чыгышында форумның югары дәрәҗәдә оештырылуын искәртте. Татарстан Республикасы җитәкчелегенә, аеруча Президент Рөстәм Миннехановка, Татарстан Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгына рәхмәт белдерде.

Милли китапханәдә һәм Язучылар берлегендә үткәрелгән утырышларда төрки телле әдәби журналларның баш мөхәррирләре Диләвер Осман («Йолдыз», Кырым), Әмир Әминев («Агыйдел», Башкортстан), Интикам Касыймзадә («Азәрбайҗан», Азәрбайҗан), Илфак Ибраһимов («Казан утлары», Татарстан), Таһир Каһһар («Гүлистан», Үзбәкстан), Улыгбәк Есдәүләт («Жулдуз», Казакъстан), Тодур Занет («Ана Созу», Гагауз), Али Акбаш («Кардәш каләмнәр», Төркия), язучы Ркаил Зәйдулла, галим, әдәбият белгече Хатыйп Миңнегулов һ.б. чыгыш ясады.

## ТӘКЪДИР ИТҮ

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» чуаш теленә тәрҗемә ителде. Тәрҗемәче — Валерий Тургай. Татарстан Язучылар берлегенең Габдулла Тукай клубында әлеге җыентыкны тәкъдир итү кичәсе булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, шагыйрьләр Ренат Харис, Җәүдәт Сөләйман, Чуашия Республикасыннан язучылар Порфирий Афанасьев, Раиса Сәрби, Татарстандагы чуаш милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе Константин Яковлев, «Салан» чуаш фольклор ансамбле, җырчылар Зилә Сөнгатуллина, Айдар Нургаянов, нәфис сүз остасы Ришат Әхмәдуллин катнашты. Кичәне Валерий Тургай һәм Луара Шакирҗанова алып барды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертkәне, күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен шагыйрь **Касыймов Наил Васил улына (Наил Касыймга)** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: А.ЕГИН. Роман «Узбекхан»; Повесть К.БУЛАТОВОЙ; Рассказ Г.АДГАМ; стихи М.КАРИМОВА, Р.ИДИЯТУЛЛИНА, Ф.СУФИЯРОВА, К.АУХАТОВА, А.МАЗГАРОВА, Ф.АХМЕТШИНА, Н.ХАБИБДИЯРОВОЙ.
«Конкурс на повесть малого формата»: Р.КАМАЛ. «Таня-Тансылу». Сентиментальная повесть.
«Литературная критика»: статья С.ПОВАРИСОВА о поэтике Л.КАШФИ.
«Наши юбиляры»: статья Н.ЮСУПОВОЙ, посвящённая юбилею академика Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.
«Искусство»: Г.САГИТОВА. «Галиябану».
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»; Р.МИРХАЙДАРОВ. Мемуары. «Вот и всё... Я пишу вам с вокзала» (прод.).
«Жизнь и религия»: Хаджнама Т.НАЗМЕТДИНА.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: повесть (прод.) А.НУРГАТИНОЙ; стихи Ф.ШАЙДУЛАТОВОЙ, А.АКМАЛОВОЙ, Э.РАФИКОВОЙ, А.МАГДАНУРОВОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Последний бой у мечети Кул-Шариф». *Ф.Халиков*; Победители на I Всероссийском конкурсе литературных произведений «Белый парус». *Фото Г.Сагиевой.*

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: A.EGIN. Novel «Uzbekhan»; novel by K.BULATOVA; story by G.ADGAM; poems by M.KARIMOV, R.IDIYATULLIN, F.SUFIYAROV, K.AUHATOV, A.MAZGAROV, F.AHMETSHIN, N.HABIBDIYAROVA.
«Competition for the small-format novel»: R.KAMAL. «Tania-Tansylu». Sentimental novel.
«Literary criticism»: article by S.POVARISOV about poetics by L.KASHFI.
«Our anniversaries»: article by N.YUSUPOVA dedicated to the anniversary of academician D.ZAGIDULLINA.
«Art»: G.SAGITOVA. «Galiyabanu.»
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fates are linked with the fire of war»; R.MIRHAYDAROV. Memoirs. «That's it ... I'm writing to you from the station» (cont.).
«Life and religion»: Hadzhnama by T.NAZMETDIN.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail»: story (cont.) by A.NURGATINA; poems by F.SHAYDULATOVA, A.AKMALOVA, E.RAFIKOVA, A.MAGDANUROVA.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Last battle at the mosque Kul-Sharif.» F.Halikov; Winners at the I All-Russian competition of literary works «White Sail». Photo by G.Sagieva.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кол Шәриф мәчете янында соңгы сугыш». *Ф.Халиков.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* I Бөтенроссия «Ак җилкән» әдәби әсәрләр конкурсында җиңүчеләр. *Г.Сагиева фотосы.*

# Яңа китаплар




**Шәрифуллин Н.И.**
**КАЯ БАРА БУ ДӨНЬЯ?**
*Публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 254 б. Тиражы – 2000 данә.*

«Милләтнең көче, ныклыгы, иминлеге һәм шулар белән турыдан-туры бәйләнгән даны, дәрәҗәсе нәрсәдә? Әлбәттә, дәүләтле булуда. Әлбәттә, шанлы казанышларда, икътисади уңышларда, лаеклы тормыш-яшәешне кора, оештыра белү осталыгында, милләт вәкилләренең гыйлемлегендә», — дип яза язучы һәм публицист Наил Шәрифуллин әлеге җыентыкта. Биредә авторның хәзерге вазгыятьне, тормышны төрле яктан чагылдырган, төрле елларда көндәлек матбугатта дөнья күргән мәкалә-язмалары урын алган. Китап киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

---




**Мөслимова Ф.Ә.**
**БАШКА КЕШЕ**
*Хикәяләр, публицистик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 174 б. Тиражы – 2200 данә.*

Әдәбият сөючеләргә үзенең матур җырлары, тирән эчтәлекле шигырьләре аша таныш Фәйрүзә Мөслимованың бу китабына чәчмә әсәрләре, әдәбият-сәнгать кешеләре турындагы язмалары туплап бирелгән. Әлеге китапка кергән хикәяләрдә тормышта булган проблемалар, аларны чишү юллары, кешеләр язмышы киң яктыртылган. «Публицистик язмалар» дип аталган бүлектә исә укучылар татар сәнгатенең күренекле ул-кызлары – Р.Мостафин, Н.Юлтыева, Ф.Сөләйманова, Р.Тумашев һ.б. иҗатлары һәм шәхси тормышлары белән якыннан таныша алалар. Китап киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ




Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)